КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Газинур МОРАТ. Гел үткелдән үтеп йөрмешебез... *Шигырьләр*. ....3
Миргазиян ЮНЫС. Кыпчак кызы Аксанә. *Роман*. *(Равил Рахманиның кереш сүзе белән)*. ....8
Рәмис АЙМӘТ. Ятлар салган юлдан бармадым мин... *Шигырьләр*. ....68
Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА. Сүз – әҗәлгә дару да... *Дүртьюллыклар*. ....88
Лилия ФӘТТАХОВА. Мәсәлләрдән гөләндәм. ....141

*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....145

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Данил САЛИХОВ. Мөхәммәт. *Драма*. ....73

ЯҢА ИСЕМНӘР

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ. Әкиятсез балачак. *Повесть*. ....92

«ХӘЗИНӘ» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Альберт ХӘСӘНОВ. Кәҗәкәй – матур бәләкәй. *Хикәя*. ....147
Айзирәк ГӘРӘЕВА-АКЧУРА. Төркиянең беренче нефтьчесе – татар. *Документаль бәян*. ....151

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА. Йолдыз белән күк матур... *Шигырьләр*. ....164

НУРИХАН ФӘТТАХНЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

*Фотоархив*: Нурихан Фәттах тормышыннан мизгелләр. ....168

Вахит ИМАМОВ. Татар илле Нурихан. ....170

*Әдипнең тәүге китабыннан:* Нурихан ФӘТТАХ. Безнең бабай. *Хикәя*. *(Рамил Ханнановның кереш сүзе белән)*. ....175

ЮБИЛЕЙЛАР

Рәдиф СӘГЪДИ. Каләм алса – уй салыр! *(Данил Салиховка 60 яшь)*. ....178
Дания ЗАҺИДУЛЛИНА. Йөрәге аша «дөнья уза шаулап...» *(Рәмис Аймәткә 50 яшь)*. ....181

*Безнең календарь:* Шәүкәт Биктимеровның тууына 90 ел. ....187

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. ....188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип һәм проза бүлеге – 222-09-83 (өст. 1613)*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*
💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмахәнәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 28.09.2018, график буенча 28.09.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-2577. Тираж 4167.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Газинур
Морат

# ГЕЛ ҮТКЕЛДӘН ҮТЕП ЙӨРМЕШЕБЕЗ…

## Упкын күзе

*Ркаилгә*

Без тауларга барган идек берчак,
Үткелен дә күрдек, упкынын да.
Безнең маңгайга да язылган шул
Упкыннарга карап укынырга.

Үткелләрдән үткән мәлләреңдә
Упкын  күзе күзли ымыңны да.
Безгә дә бер үрелепләр генә
Ярыйдыр ла күккә орынырга.

Таулар белән бер даулашыр өчен
Бирелгәнме әллә йөрәк безгә?..
Ә үзебез Язмыш үзәнендә
Гел үткелдән үтеп йөрибез лә.

Гел үткелдән үтеп йөрмешебез –
Упкын күзе күзли үзәндә дә...
Күңелләр дә тетрәп убыладыр,
Кыйбла тарафлары үзгәргәндә.

Хәвефтән дә хәвефлерәк фалдыр,
Упкын ояласа калебләргә.
Кем дә искәрмәстер –
Беркөн Кояш
Килеп чыкса әгәр гарепләрдән.

---

Газинур МОРАТ (1959) – *шагыйрь, публицист; «Җәяүле кошлар», «Төнге әверелеш», «Кош хокукы» һ.б. китаплар авторы. Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Гарепләрдән чыга калса Кояш,
Бу дөньяны инде танымабыз...
Хан Тәңребез*, бәлки, көтә булыр,
Кабат китик мәллә тауларга без?

Ә тауларда
  әлмисакка чаклук
Әверелгән Вакыт тораташка...
Бер бушанып алу ярыйдыр ул,
Башкаеңны ора-ора ташка.

Бер бушанып алу ярыйдыр ул,
Упкыннарга карап укынганда...
Безнең хакта хәбәрнең дә
Ташка
Уелганын, бәлки, укырлар да,

Әйтерләр күк: «Бу кавемне, – диеп, –
Йоталмаган хәтта упкыннар да!»

Сатаналар сатайланган чакта,
Җанга инде тынгы табалмабыз.
Таланмабыз,
        күккә якынайсак,
Китик,
        әйдә,
            кабат
                тауларга
                    без...

## Дәрдемәндкә эндәшү

Тел – кисек. Авыз – ямаулы.
Чайкала чүлдә кораб...
Сыңар сәтырга тормастай
Вакытлар килде кабат.

## Узаман

*Хезмәт Каһарманы Камил Шакиров рухына*

Камиллекнең чиге юктыр ансы,
Ә чиксезлек мотлак камил лә!
Иксез-чиксез салаватлар булсын
Габделфаяз улы Камилгә.

Иксез-чиксез салаватлар яусын,
Гел догада торсын бу заман.
Үз заманын узып яшәде ул,
Ул тумыштан булган узаман.

Малай килеш яулар-даулар кичкән,
Күп иснәгән дары исен дә...
Үз иленә кайткан полк улы
Халык улы булыр өчен дә.

Каһарманлык кылды тынычта да
Үз заманы белән узышта...
Гомер буе ул төзеде генә,
Ул төзүче булган тумыштан.

* Хан Тәңре – кытайча Тянь-Шань.

Ул – төзүче иде...
Төзү генә
Төс адәмгә туган эргәдә...
Герой килеш хәтта «бугор» булды,
Кай диварны өйдек бергә дә.

Ул – төзүче иде...
Таш та салды,
Дәвер белән дауда – башын да.
Ул – чорының хак шаһиты иде,
Шәһите дә булды асылда.

Иксез-чиксез салаватлар яусын,
Гел догада торсын бу заман.
Габделфаяз улы Габделкамил... –
Ул тумыштан иде узаман.

## Тылмач

Татарга тылмач кирәкми –
Билгеле әүвәлгедән;
Мәсләге белән ул күптән
Тылмачка әверелгән.

## Кеше

Гомерен суга да сала,
Сала хәмеренә дә,
Күнә сөмсез түрәләрнең
Денсез әмеренә дә,
Гаме юк – каннан исергән
Чорсыз дәверендә дә...

Шулай яшәп ята кеше
Колга әверелә дә...

## Евтушенко шигырь укый

*(Хатирә)*

Муса Җәлил сәхнәсендә бүген
Бер шагыйрьлек кенә тамаша, –
Евтушенко безгә шигырь укый,
Үз яшьлеге белән аңлаша.

Евтушенко шигырь укый безгә,
Яшьлек мәгъшукасы хакында.
Үзе һаман япь-яшь...
Сүзе генә
Олыгайган инде чак кына.

Чынлап сөя белсәң, сиксәндә дә
Сөюнамә бик шәп языла.
Очкын чәчә күзе...
Үзе генә
Сабырланган инде аз гына.

Күк астында гомер чигә-чигә,
Аң да, җан да, дан да чүкелә.
Уе гел биектә...
Буе гына
Чүгә төшкән бугай чүт кенә.

Казанны да ул үз итте бугай,
Үз иткәндер, димәк, Казан да, –
Яшьлегендә безгә юкка гына
Килмәгәндер дастан язарга.

Канатланыр Сүзгә бәрабәрдер
Шагыйрь гомеренең кыйммәте...
Евтушенко безгә шигырь укый,
Дон Кихоттай – бөтен килбәте.

Евтушенко шигырь укый безгә,
Үз яшьлеге белән аңлаша.
Муса Җәлил сәхнәсендә бүген
Бер шагыйрьлек кенә тамаша...

## Чапай

*Рафаил Фәттахов истәлегенә*

Кәккүк гомер юраса да,
Безгә
Гел яшисе икән сагаеп...
Тагын бер яшьтием китеп барган,
Малайчакның чая Чапае.

Тагын бер яшьтием китеп барган,
Чапай кебек җилә торганы –
Ат караучы Кәшиф абзый улы,
Бөдрә Бәдәр апа оланы,

Син – Тауасты узаманы идең,
Тауга карап без дә исәйдек...
Без шыртлака сөзгән инештә дә
Сыза әнә күпме истәлек.

Шул инешкә чумып, бата-калка,
Без өйрәнгән идек йөзәргә.
Йөзә-йөзә, бер талчыгыр чаклар
Килә икән, килә безгә дә.

Тауастының казы таласа да,
Еламадык бугай – түздек без...
Тау башында атлар саклап үстек,
Колын чакта гына үзебез.

Тау башында атлар саклап үстек.
Учак үрләттергән чакларда
Дөнья гизә идек
Үзебезнең
Борак дигән парлак чаптарда.

Дөнья гизә идек...
Сәфәрләрнең
Көтеп алдык аннан азагын –
Син Мәскәүгә китеп оя кордың,
Мин ятиме булдым Казанның.

Еракмы без, әллә якындамы –
Күкләр торыр һәрчак тигезләп, –
Кая гына барып сыенсак та,
Сыгынырбыз туган нигезгә.

Мин дә, яшьти, йөзне яшәмәмдер,
Яшәүләрнең белмим хәйләсен.
Кабаланмый гына,
Бу дөньяга
Бер-ике сүз бардыр әйтәсем.

Мин дә, яшьти, учак тирәсендә
Дөнья гизгән чакны сагынам.
Бер үксисе иде...
Яхшы түгел... –
Малайчагым тарта чабудан.

Син бит, яшьти, безнең Чапай идең,
Гел Чапай күк җилә торганы –
Ат караучы Кәшиф абзый улы,
Бөдрә Бәдәр апа оланы.

Без үскәндә ут күршеләр идек,
Хыялдаш та идек, кардәш тә...
Мин ышанам: бакый йортыбыз да
Төп нигездә булыр, янәшә...

***

Кычкырмагыз
    изге сүзне,
        бугаз ертып!
Пышылдаулар һәр телдә дә
    мәгънәлерәк,
        ләззәтлерәк,
            илаһирак...

## Таган

Безне кем дә аңламастыр,
Таралмастыр томан да...
Күзге таңда
    ике ялгыз
Атынабыз таганда.

Атынабыз. Атлыгабыз.
Күккә тия түбәбез.
Күзге таңның мөлдерәмә
Күзләреннән үбәбез.

Әллә инде дөньясы да
Томан кебек агарды...
Томан безне адаштырды,
Кавыштырды аннары.

Гүя безнең хәлләрне дә
Аңлый күзгә таң гына.
Ике ялгызак кавышса,
Куш бәхет, ди, табыла.

Шулай юрыйк.
Юкса инде
Чигәләр дә ак кына...

Ә таганда – без түгел ул,
Безнең яшьлек атына.

Ә яшьлеккә иләслек тә,
Исәрлек тә килешә...
Ялгыз уза икән гомер
Кайчак парлы килеш тә.

...Безне кем дә аңламастыр,
Таралмастыр томан да, –
Күзгә таңда
ике ялгыз
Атынганда таганда.

## Без башкача яши башлыйк, дисең...

*А. әзи авызыннан*

Без башкача яши башлыйк, дисең,
Җиргә төшик. Дөнья күтәргә.
Безнең сәер иләс-миләслекне
Аңламастыр, дисең, күкләр дә.

Без башкача яши башлыйк, дисең,
Мин – тормышлы, ә син – оныклы...
Безгә инде сөю килешмәстер,
Фани дөнья барын онытып.


Безгә, дисең, сөю килешмәстер.
Башны җуеп. Уйлыйк азагын.
Кавышуның соңы – хушлашудыр...
Хушлашуның татлы газабын

Татып яшәү ләззәтенә күник,
Имен күрик назлы әрнүнең.
Мең шифалы сагыш белән тулсын
Һәрбер күзәнәге бәгырьнең.

Без башкача яши башлыйк, дисең,
Җиргә төшик – яшик... бер көйгә.
Безне һушсыз иткән хушлашуның
Ярасыннан калмас бер җөй дә...

Тик мин алай яши алмамдыр күк, –
Бу сөюнең юктыр башкасы...
Түшкәеңә чал башымны куеп,
Гарешләргә килә ашасым.

...Әгәр кабат яза калсаң,
Хатың
Яңабаштан, зинһар, башлачы...



# Миргазиян Юныс

## Кереш сүз урынына

*«Кыпчак кызы Аксанә» романының язылуы үзенчәлекле булып чыкты. Һәр бүлеген автор миңа – үзенең кырыс тәнкыйтьчесе һәм таләпчән редакторына биреп укытып ала иде. Икебезнең дә Мәскәүдә яшәвебез һәм еш очрашып торуыбыз бу яктан бик уңай иде. Әмма беренче бүлек – әсәрнең камертоны җиңел генә табылмады. Икебезне дә канәгатьләндергән нәтиҗәгә килгәнче, унга якын вариант язылды. Минем 2005 елда Казанга кайтып китүем бу эштә тагын да өстәмә авырлыклар тудырды. Миргазиян абый язылып беткән бүлекләрне, әледән-әле бандероль аша юллап, Казанга җибәрә башлады. Мин исә укып чыгып, фикерләремне, киңәшләремне әйтеп, текстны машинка битләренә салып, чиста битләрне төзәтергә кире җибәрә идем. Шул нигездә, ул өр-яңа иҗат ашкынуы белән, кулъязманың таныр җирен дә калдырмыйча, үзен-үзе яңабаштан редакцияләп чыга иде. Инде бу төзәтелгән кулъязманы мин кабат компьютерда җыеп, чиста вариантны янә үзенә кайтардым. Чөнки ул, өендә компьютеры булса да, анда җыярга өйрәнмәде, машинкада да үзе басмады – тимер клапанлы йөрәгенә ярамый иде. Безнең җиде елга сузылган эшчәнлегебез барыбер азагына барып ирешә алмады. Миргазиян абый мәңгелеккә киткәч, әсәр тәмамланмаган хәлдә, вариантлары белән торып калды. Кайбер сюжет сызыкларын, гомум композицияне ахыргача хәл итеп бетерергә кирәк иде. Баш героиняны нишләтергә дигән сораулар да эленеп калгандай булды.*

*Әсәр иҗади эшләнү процессында иде. Шуңа хәтта корабль-лайнер яисә кайбер геройларының исемнәре генә дә 3-4 төрле булып саклану бик табигый. Авторның үз кулы белән бербөтен итеп күчергән, алты бүлектән гыйбарәт әсәре торып калды. Әлеге ун бүлекле әсәрнең дүртесе исә язучының караламадагы калган төрле вариантлары нигезендә һәм аның башка язмаларын файдаланып башкарылды. Авторсыз калган редактор хәле, шахмат тактасында берүзең уйнаган кебек, шактый четерекле эш булып чыкты. Әсәрне тәмамлау шактый сузылды, чөнки авторның мөмкин кадәр күбрәк язмаларын һәм үзе редакцияләгән текстларын кулланырга тырыштым. Бәхеткә, автор белән бер юнәлештә фикер йөртүебез, шул исәптән аның алдагы томнарын эшләгәндәге тәҗрибә һәм искиткеч бай вариантлар торып калу әсәрне теләгәнчә башкарып чыгарга мөмкинлек бирде.*

**Равил РАХМАНИ**

# КЫПЧАК КЫЗЫ АКСАНӘ[1]

РОМАН

*Өзелеп сөйгән ярлар барыбер ятка кала...*
Татар халык җыры

**Беренче бүлек**

**1**

Сиксәненче еллар азагында Габдрахман Рахманкулов җир алу бәхетенә иреште.

Җир – аның канына сеңгән күптәнге хыялы; игенче гаиләсендә туып-үскән кеше буларак, җир эше аның күзәнәкләрендә иде. Ерак бабаларының туган туфрактан куылуы, гасырларга сузылган җирсезлек михнәте, үзенең инде тыныч кына тормыш алып бару теләге – аның яшәү рәвешенә үтеп кергән табигый бер ихтыяҗы иде. Мәскәү язучылары бакча кооперативы оештыра икән дигәнне ишеткәч, ул шунда ук гариза язып илтте. Иркутск оешмасында мәшһүр Агишев җитәкчелегендә тәрбия алган секретарь Рахманкуловны исемлеккә кертте. Кооперативның рәисе, милләтенә кагылып тормыйк, ике тапкыр сызып ташлап, әшнәсен теркәде. Өченче баруында Агишевның шәкерте: «Әгәр Рахманкуловны кабат төшереп калдырсаң, мин аны синең үз урыныңа кертәм…» – дип кисәткәннән соң гына, Габдрахман морадына ирешә алды.

Бакча кооперативы Мәскәү – Волоколамск арасындагы тимер юл буенда, урыс әдәбияты классигы Антон Павлович Чехов берничә җәйге ялын уздырган урында, патша заманында Воскресенск, бүген Истра дип аталган шәһәрдән, Яңа Иерусалим монастыреннан унсигез чакрымда, Истра сусаклагычы янына урнашкан иде. Мәскәү белән Волоколамск арасында, генерал Панфилов кулы астында батырлык күрсәткән 28 геройның каны коелган җир – Дубосековоның да кооператив юнәлешендә икәнлеген искә алсак, бакча урыны турындагы мәгълүмат тагын да тулылана төшәр иде.

Колхоз җире мул, аны эшкәртүче машиналар никадәр көчле булса да, совет халкының тамагын туйдыра алмады. Сугыш елларында бирелгән хәерче сыныгына тиң алты сутый хуҗалы җир дә шәһәр базарының шактый гына өлешен тәэмин итте. Шушы чынбарлыкны истә тотып, Рахманкулов үз өлешенә тигән җәймә зурлыгы җирендәге каеннарны егып, җимеш һәм яшелчә бакчасы ясарга ниятләде.

Иң беренче каенны кисеп аудару белән, гаилә тынычлыгына давыл бәреп керде:

– Әти, зинһар, минем каеннарыма тия күрмә, – диде кызы Кәримә. – Яшелчә-җимешне үзем сатып алам, каеннарыма кагылма, яме!

Габдрахманның хатыны Мәрьям исә шундук дәлилен дә тапты:

– Кәримәнең йолдызнамә символы – каен. Син нәрсә, үз кулың белән аның язмышына балта чабасың. – Сөйләшү урысча иде. – Руки прочь от берёз!

Рәсәй шартларында беркем, беркайчан тулы хокуклы хуҗа була алмаган. Озакламый ачыкланды: Рахманкулов җиренә дә ул үзе түгел, кооператив хуҗа иде... Крепостной коллык бетерелгәннән соң да, крәстиян үзе түгел, аның җиренә община хуҗа булган. «Община» – урыс табигатенең дәүләтчелеге барлыкка килгәннән бирле ярым солдат, ярым кол, ярым ушкуйник булып яшәргә дучар

[1] Равил Рахмани әдәби эшкәртүендә.

ителү. Рахманкулов, «Россию умом не понять, её аршином не измерить...» дигән чынбарлыкка килеп төртелгәннән соң, бу турыда баш ватмаска тырышып, башкалар ничек уйласа – шулай фикерләп, башкалар ничек яшәсә – шулай яшәргә тырышып карады. Әлеге илдә көтү сыман яшәү психологиясе бик тирәнгә киткән, күрәсең. Габдрахманга бирелгән бу кооператив җир кишәрлеге дә барча законнар белән шул гомум буйсыну законына барып тоташа иде. Аерма тик шунда: әгәр «бөтенесе колхозныкы, димәк, минеке», дип фикер йөртүче бәрәү бу милекне урларга ишекне киереп ачса, кооперативныкы саналган җирдә үскән бармак очы зурлыгы кыярны, үтеңне сытарлык ачы – корт төшкән алманы рөхсәтсез алганда тотсалар, аны бәреп үтерергә дә мөмкиннәр иде.

Буйга утыз, аркылыга егерме метр шул җирне койма белән ураткканда купкан гаугаларны сурәтли башласаң, язылачак романның күләменә сыймас иде. Әйтерсең, бөек урыс (хәзер инде украин) язучысы Николай Васильевич Гоголь бакча кооперативы тудырачак матавыкларны йөз сиксән елга алданрак белгән. Аның «Как поссорились Иван Иванович с Иваном Никифоровичем» повестендагы якалашулар нәкъ Рахманкуловның бакчасы урнашкан кооперативтагы вакыйгалардан алып язылган шикелле иде.

***

Рахманкуловның сул як күршеләре бакча алган елны ук каеннарының бер өлешен төпләп, түтәл ясап, яшелчә чәчтеләр. Габдрахман да, бакчаның дүрттән бер өлешен каеннардан чистартып, барлыкка килгән урынны тиресләп, бәрәңге, суган, карлыган, кура җиләге, хәтта бер түтәлгә кыяр да утыртып өлгерде. Тир түгүнең әҗерен түләгәндәй, хуҗаның күңелен күргәндәй, беренче һәм икенче ел уңышы бик мул булды.

Әмма ике-өч ел уздымы икән, ашлама кертелгән шул җирләргә мыштым гына каен тамырлары сузыла башлады. Тиздән аларның җиләк-җимешен генә түгел, карлыган куакларын да каен «ашап» юкка чыгарды. Бу хәл Габдрахманны уйга калдырды: «Бу моңсу агачны кемсәләрнең «үз» каены дип тамгалавында дөреслек тә юк түгелдер? Алар да бит нәкъ шушы агач кебек, тамырларын күрше халыклар җиренә җибәреп, ашламаларын имеп яши... тегеләре шуңа һич мантый алмый?»

Шулай итеп, эшләгән саен ишәя, арта килгән җирне эшкәртүгә каеннарның әрсез тамырлары белән көрәшү мәшәкате дә өстәлде.

Көз көне җиргә коелган яфракларны, уталган чүп үләннәрен черетеп ашлама әзерләр өчен, Рахманкулов, тимерчыбык челтәр белән уратып, тиреслек урыны ясады. Язын ашламага әверелгән шул тиресне түтәлләргә тарату өчен, тимер сәнәк белән казый башлаган иде – хәйран калырлык вакыйгага юлыкты: каен тамырлары, тиреслекне эзләп табып, андагы ашламаны тәмам үзләштереп бетергәннәр иде... Инде моннан соң да бу агачларның кем каены булуына ышанмый кара син!

***

Фридрих Энгельс: «Адәм баласын хезмәт кеше иткән», – дигән. Коммунистик идеягә нигез салышучының бу күрәзәлегендә дөреслек тә юк түгелдер. Әмма шул сакалбайның сүзләрен тормышка ашыру өчен, Рәсәй җирен тоташтан диярлек ГУЛАГ лагерьларына әверелдереп, адәм баласының хезмәттән башка гамәлләрен юкка чыгарып, бил бөгүне генә калдырганнан соң, кеше, кеше булуын югалтып, әкренләп йөк атына әверелә башлады. Атка әверелү белән генә чикләнмәде коммунистик идеологияне йодрыклап кертү.

Дини инану урынына мәҗүсилек чорының хорафаты тамыр җәйде. Октябрь баласы, пионер, комсомол сабакларын бисмилладан тирәнрәк үзләштергән Мәрьям коммунизмның җәннәт алып килүенә җаны-тәне белән ышанып кына түгел, инанып яши иде. Революциягә кадәр, исламның шәригать кануннары көчле чакта, ырымнарга, сихергә буйсыну халыкның аңында тамыр җәя алмаган булса кирәк. Коммунистик идеяне халыкка дин урынына куркытып тагучылар ислам (шулай ук носарилык) дине тәэсирен юкка чыгарырга мәҗбүр булганнар. Идарә дилбегәсе коммунистлар кулыннан ычкынып, демократик идарә итүгә күчкәч, егерме беренче гасырның тәүге елларында халыкның, бигрәк тә ярым-йорты зыялыларның аңына мәҗүсилек кануннары бәреп керде. Күрәзәчелек, гороскоп, сихер, мең төрле ырым-ышанулар – барысы да шуңа барып тоташа түгелме соң?!.

«Шәрекъ – Шәрекъ ул, – ди инглизнең күренекле шагыйре, Нобель бүләге лауреаты Ридьярд Киплинг. – Көнбатыш – Көнбатыш. Алар үзара беркайчан да кушыла алмаячаклар...» Түтәл казыганда, Габдрахманның исенә шушындый гыйбрәтле фикерләр килеп төшә иде.

Рәсәйнең башкаласында туып үскән хатыны белән Рахманкулов өч дистә ел тату яшәде. Шуңа карамастан, аларның җиргә булган карашлары Киплинг фикерендәгечәрәк иде. Габдрахман, инде илле елдан артык шәһәрдә яшәсә дә, авыл кешесе булуыннан һич арына алмый. Бу сыйфат бигрәк тә җир мөнәсәбәтендә көчле иде. Мәрьямнең исә табигатендә һәм күзаллавында шәһәрчәлек өстенлек итә. Ул бакчаны ишегалды, ял итә торган урын-дача буларак тоя, ә Бәкер малае аны бәрәңге бакчасы, җиләк-җимеш үстерә торган ризык чыганагы итеп күрә иде. Никадәр тырышсалар да, бу өлкәдә алар үзара уртак тел таба алмыйча интегә бирделәр. Никита Хрущёвның шәһәр белән авыл арасындагы аерманы бетерү өчен, агрокала төзү планы да нәкъ әнә шулай сабын куыгы шикелле шартлап җилгә очты бит...

Урман ягыннан килгән күке тавышы Габдрахманның балачак хатирәләрен уятып җанландыра. Сагындырып Караяр искә төшә. Гомер үтеп бара. Ул бит армия хезмәтеннән арынгач, туган авылына кайтып, тәрәзәләре урам ягына карап торган зур йорт салу, ат асрау, җиде бала тәрбияләү турында хыялланып яшәде. Кайда ул зур, иркен йорт? Юыртканда йөрәк кага торган җирән кашка аты кайда? Ишегалды тулы таза, матур балалар кайда?!

Мәрьям иртән, гадәттә, йоклый. Шәһәр кешеләре иртә торырга яратмый. Кәримә – эштә. Ул бакчага ял көннәрендә генә килеп йөри ала...

Габдрахманның яшьлектәге татлы хыяллары еллар дәвамында акрынлап сүнеп юкка чыкты. Ул үз яшәешенең чынлыгына кайтты. Бәкер малае бит хәзер шәһәр кешесе... хәтта күпләргә борын чөяргә, шапырынырга мөмкинлек биргән башкалада яшәүче. Москвич! Әнә, ул хәтта Мәскәү язучылары кооперативындагы дачаның хуҗасы! Тик менә шушы дәрәҗәгә ирешкәч кенә, аның күңел дөньясындагы чынбарлыкның асты өскә килде...

## 2

Әнә, яз кояшының тансык нурлары агач ботаклары арасыннан Рахманкуловның яңа бакчасына коела. Каен бөреләреннән бөркелгән исерткеч татлы ис сулыш юлына кереп канга тарала. Җылына башлаган җирдән сабый үлән сабаклары төртеп чыккан. Яз һавасы балачак хатирәләрен җанландырып җибәрде. Ботинканы салып ыргытып, бәләкәй чактагыча, йомшак чирәм өстеннән ымсындыргыч киләчәккә таба күзне йомып йөгерәсе килә…

Габдрахман кишер утыртырга түтәл казыган җиреннән кырмыска оясына юлыгып туктап калды. Кара кырмыскалар, үзләреннән зуррак ак, озынча йомыркаларын күтәреп, көрәк астыннан качып читкә йөгерәләр. Менә бит туачак бала кадере! Җан кадере!

– Күрше, чык әле, әйтәсе сүзем бар...

Габдрахман коймага таба борылып карады. Урам ягында, ике кулы белән җилкапканың тактасына тотынып, Рахманкуловның уң як күршесе Евгений Моисеевич Резник тора иде.

– Хәерле иртә, – диде Габдрахман. – Нигә кермисең... әйдә, уз.

– Юк инде, кереп тормыйм. Үзең чык. Көрәгең кулыңда чакта синең белән сөйләшеп булмый. Сукыр тычканга әверелеп беттең инде. Көне-төне чокынасың. Җире юньле булса бер хәл. Сабын шикелле сыланып торган яшькелт балчык. Монда бит бернәрсә дә үсми. Иван Пересветовның язмаларын укыгансыңдыр?! Мәскәү җире уңдырышлы булса, урыслар Казан ханлыгының «подрайские землицы»ларын басып алмаган булыр иде.

– Күрше урамдагы Вадим Каргаловның «разбойничье гнездо», дип, Казан ханлыгына пычрак аткан яласын да укыганым бар. Без инде тарихны шакшыландырып күрсәтүгә күнеккәнбез, әһәмият бирмәскә тырышабыз.

Сатулашуның озакка китүе бар иде. Рахманкулов, бияләен салып, җиргә кадаган көрәк сабына кигезде дә урамга чыкты.

Алар кул биреп күрештеләр дә кооператив бакчаларын бүлеп, буйдан-буйга сузылган үзәк урам – «Бродвей»га чыгып, урманга таба атладылар.

– Хәтерлисеңме икән, бер тапкыр син миңа «басып алучылар оккупацияләнгән җир белән уртак тел таба алмый», дип исбатлаган идең. Күзәтеп йөри торгач, синең бу фикереңдә дөреслек барлыгына төшендем.

– Син мине фәлсәфә куертырга чакырдыңмыни? – диде Рахманкулов, атлавыннан туктап.

– Юк, миңа синең киңәшең кирәк. Аны син генә бирә аласың.

– Әллә син дә, чирәмеңне казып, бәрәңге утыртырга ниятләдеңме?

– Юк инде. Әнә, син өч аршын җиреңдә күпме чокындың, күпме тирес ташыдың. Берәр нәрсә үстерә аласыңмы соң?..

– Җирнең ашын каен тамырлары суырып бетереп тора. Каен кайгы китерә, дип картлар дөрес әйткән икән...

– Ә нигә кисеп ташламыйсың?

– Кызым кистерми. Якын да җибәрми.

– Бакчаңа ул хуҗамыни?..

– Узган ел мин аңа яздырттым. Картаела бит... Гомер үтеп бара.

– Мин барыбер аңламыйм, бакча аныкы булгач, нигә син шулай интегәсең?..

– Тәнемдә крәстиян каны акканга. Җир миннән көчлерәк булып чыкты. Ул исә үзен, сабый бала шикелле, назландырып торганны ярата... Син бит миңа... сүзем бар, дигән идең.

– Күрше, әйт әле, диңгездә шторм вакытында күңел болганудан нинди дару эчәләр?

– Утыз елга якын эшләп, дару эчкән диңгезчене очратканым булмады минем. «Салагаларга» диңгез бүреләре якорьга ябышып төптән чыккан ләмне ашаталар. Мыскыллап инде, билгеле.

– Хәзер бит медицина бик тә алга китте. Андый дару булмый калмас. Син аны белергә тиеш.

Күршесенең җәмгыятьтәге прогресска шулай мөкиббән булуы табигый иде.

Чыннан да, фән һаман алга бара. Ә менә җәмгыятьтә яшәүче адәм балалары... «Комсомольская правда», «Московский комсомолец» газеталарының, йөзләгән гламур журналларның эчтәлекләре иң примитив хорафатка – җенесне кытыклап, аздырып торуга көйләнгән. Фәнни яктан дәлилләп булмаган йолдызнамәләр, һәр санда авантюрист кыяфәтле күрәзәләр, ырымчы шарлатаннар! Ә аздыргыч китаплар? Медицина, чыннан да, туктаусыз алга бара. Йөрәккә операция ясау, хәтта адәм баласына, тузып гариплэнгән йөрәген кисеп ташлап, яңа йөрәк тегеп кую да хәзер гадәти хәлгә әйләнде. Тагын әллә нинди катлаулы операцияләр инде күптән көн тәртибендә. Операция ясатып, корсакларындагы майларын алдырту, имиләрен, тагын әллә кай җирләрен зурайтулар табигый тоела башлады... Адым саен очрап торган аптекаларда ялган дару сату! Тик, нигәдер, дәва акчалы кешеләрне сайлый, акчасызларга Газраил килгәнен генә көтәргә кала...

«Бродвей» урамы урман читенә килеп төртелде. Алар кире якка борылдылар.

**3**

«Диңгез авыруы» белән данлыклы Трафальгар герое адмирал Нельсон да газапланган, дип сөйлиләр. Имеш, шторм вакытында бөек адмиралның денщигы көмеш чиләк тотып янында йөри торган булган. Сугыша башлау белән, Гораций Нельсонның «диңгез авыруы» шундук юкка чыккан. Габдрахманның күп тапкыр сынаганы булды: өлкән штурман чагында үләр хәлгә җитеп «диңгез хастасы»ннан интегүчеләр, капитан булып эшли башлау белән, авыруларыннан арына.

– Әйдә, безгә кереп чыгыйк әле, – диде Евгений Моисеевич. – Минем син ярата торган вискием бар.

– «Сантори» түгелме?

– Нәкъ шул.

– ЦДЛның[2] буфетында саталар иде. Барахло, – диде Рахманкулов. – Японнар иң затлы, иң алдынгы автомашиналар, электроник приборлар ясап, дөньяны шаккатырып торалар. Искиткеч тырыш, талантлы халык. Ә менә чын вискины Шотландиядә генә ясый алалар.

– Дөрес, син күпне күргәнсең. Нигә вискины шотландлар гына ясый ала? Шуны аңлата аласыңмы?

Габдрахман бертын уйланып торды:

– Шотландиянең туфрагы акбурлы. Вискины чистартканда кулланыла торган вереск (арчан) куаклары анда гына үсә. Шуңа өстәп, гасырлар буе камилләшә, байый килгән халык тәҗрибәсе. Алар бит вискины, коньяк шикелле, имән мичкәләрдә саклыйлар. Бер тапкыр виски сакланган мичкәне кабат кулланмыйлар. Шотландиядәге коймалар шул имән мичкәләрне утыртып ясалган. Гаҗәеп матур, искиткеч үзенчәлекле шул имән кисмәкләр белән уратып алынган ихаталар.

– «Сантори»ны эчеп караганың бармы соң?

– Карамаган булсам, сөйләп торыр идеммени? Тукта әле, син бит сафсата саттырып, мине эшемнән бүлдерәсең!

– Нигә «диңгез авыруы»ннан котылу чарасын яшерәсең?

– Ул сиңа нигә кирәк? Син бит мәкаләләр бастырып тамак туйдырасың. Редакцияләрдә шторм башланмагандыр бит?.. Көймәң Истра сусаклагычында. Анда давыл буламыни?

[2] ЦДЛ – Центральный дом литераторов (Мәскәү язучыларының үзәк клубы).

– Мин, күршекәем, диңгезгә чыгарга әзерләнәм.

– Ялланыпмы? Кайсы пароходчылыктан? Нинди кораб белән?

Күршесен кызыктыра алуына Резник канәгать иде. Ул бертын юри җавап бирмичә серле итеп елмаеп торды.

– Корабы әле билгеле түгел, – диде бераздан. – Босс миңа өч вариант тәкъдим итә. Берсе Санкт-Петербургтан Көньяк Америкага. Кайтышлый кораб Кызыл диңгездәге, Урта һәм Кара диңгезләрдәге портларга кереп чыгарга тиеш.

– Калган икесе кайсы якларга?

– Берсе Сүәеш каналы аша Һиндстан, Шри-Ланка, Гонконг, Сингапур, Япония портларына. Владивостокта безне төшерә дә, яңа пассажирлар утыртып, Одессага кайта. Өченчесе – Одессадан Европа континентын урап, Санкт-Петербургка кадәр. Дистәдән артык Европа портларын күреп була, диләр. Мин, бәлки, шунысын сайлармын. Артык еракка китәсем килми. Бераз шөллим. Шторм вакытында язып булмый торгандыр бит?

– Тукта әле, Женя күршекәем, син бу турыда мине ымсындырыр өчен генә сөйләми торгансыңдыр ла? Мактаныр өчен?..

– Күршеңне диңгез сәяхәте турында очерк язарга круизга җибәрәләр... Аңлашыламы?

– Кем җибәрә?

– Гафу ит. Әйтә алмыйм. Эксклюзив. Күңел болгану хастасыннан ничек котылалар, син миңа шуны аңлат. Белмәсәң, кооперативта синнән башка да диңгезчеләр бар. Әнә, каршы як бакчада гына беренче ранглы капитан Животрупов яши. Ул ярдәм итәчәк.

– Диңгезчелек аның һөнәре түгел. Погоны гына хәрби диңгезчеләрнеке. Животрупов маршал Будённыйның денщигы. Диңгезне ярдан гына күреп яшәгән...

– Әйтмәсәң, башка берәр диңгезчедән барыбер белермен әле...

– Син бит моңа кадәр шоу-бизнес, ачык күкрәкләр, шәрә ботлар, тамашачыларның азгын тойгыларын кайнарлаучы эстрада стервалары турында яздың. Диңгез хакында язар өчен кимендә биш-алты ел диңгездә тозланырга кирәк. Белмим, бәлки, диңгезчелек эше хәзер җиңеләйгәндер? Без, күршекәем, ул эштәге авырлыктан кан сидек, сеңерләр өзелер дәрәҗәгә җиткәнче көчәндек. Диңгезне бары шулай гына аңлап һәм яратып була...

– Европа круизы кыска, диләр. Минем озаграк йөзәсем килә. Бәлки, Көньяк Америка портларына бара торганын сайлармын әле. Диңгез авыруын баса торган даруны табып, нинди кием сайларга кирәклеген генә белергә кирәк иде.

– «Диңгез авыруы»н баса торган дару юк. Кайбер бәндәләр аэрон таблеткасын йотып карыйлар. Тик файдасы тими. Дөрес, бар ул аннан коткара торган чара. Кораб бата башласа, «диңгез авыруы» шундук юкка чыга. Үләр хәлгә җитеп ятучылар сикереп торып йөгерә башлыйлар. Аның даруы шул – бирешмәү, үзеңне кулга алып эшләп йөрү. Авыр, җаваплы эштә хасталыгың онытыла. Капитаннарга кагылмавының сәбәбе – җаваплылыкның чирдән көчлерәк булуы. Ә кием-салым мәсьәләсенә килгәндә, әйтик, Одессадан кузгалып китеп, Антарктикага барганда, бер-бер артлы эссе җәй, юеш, яңгырлы көз, суык кыш климатлары аша үтәргә туры килә. Без диңгезгә чыкканда, эчлеге алына торган куртка һәм берничә свитер ала идек. Тропикларда җитен тукымадан тегелгән кыска җиңле күлмәк һәм кыска чалбар. Син бит пассажир лайнерында йөзәргә тиеш. Андый корабта комсостав салонына, кают-компаниягә галстуксыз кермиләр. Банкетка, мәсәлән, смокинг яки фрак киеп кенә керәләр.

Резник капкага таба юнәлде:

– Рәхмәт сиңа, күрше. Йөзүдән мин сиңа бер шешә виски алып кайтырмын. Иң затлысын. Кулъязманы төзәтсәң, өстәргә дә була.

– Син шул шешә белән миннән котылырмын дип уйлыйсыңмы? Арзанга куясың син минем тәҗрибәмне. Һичюгы син миңа кораб хуҗасының (испаннар аны «арматор» дип атыйлар) телефонын бирергә тиешсең. Менә шул.

Евгений Моисеевич тукталып калды.

– Әйтергә ярамаганны белеп сорыйсың бит син! Мин бит аның телефонын беркемгә дә бирмәм, дип ант иттем. Син мине, күрше, җинаять эшләргә мәҗбүр итмә. Бер шешә виски, шуңа өстәп бер шешә затлы коньяк алып кайтырмын. Сувенирлар. Килештекме? Коньякның ниндиен яратасың?

– Мин испаннарның кырыс «фундодор»ын французларның тәме бер атна авызыңнан китми торган мең долларлык «крук»ларыннан өстен күрәм. Эш анда түгел. Эчәргә ярамый миңа. Син миңа кораб хуҗасының телефонын бир... Син менә диңгезче булырга җыенасың. Чын диңгезчеләрдә сер яшерү булмый. Әйтергә теләмәсәң, мин кораб хуҗасын барыбер эзләп табачакмын. Вакыт кына әрәм булачак.

Евгений Моисеевич уйга калды. Рахманкулов дәвам итте:

– Советлар Союзы таркалганда, сәүдә флоты кораблары кинәт юкка чыкты. Алар бит батмадылар. Чит илләргә дә сатмадылар өч меңгә якын морфлот корабын. Аларны кемнәрдер үзара бүлештеләр. Бүлештеләр дә Кипр, Сингапур, Либерия дәүләтләренең флаглары астында йөзәргә теркәделәр. Аларның берничәсе Иосиф Кобзонга эләккән икән дип ишеткәнем булды. Данлыклы Мәскәү дизайнеры Альбина Назимованың ире Влад Листьевне үтерү фаҗигасе дә кораблар бүлешүгә бәйле, дип сөйләп йөрделәр.

– Мин боларны белмим. Имеш-мимеш юктан тумый, билгеле. Бәлки, ул сүзләрдә дөреслек тә юк түгелдер... Чыннан да, бүгенге эшмәкәрләр тапкан миллионнарын чүлмәктә саклап тотмыйлар. Хәзер, күршекәем, иң отышлы бизнес – теләсә нәрсәдән акча ясау.

– Мин шуннан куркам, инде скинхэдлар, ата шовинистлар: «Рәсәй – бары тик урысларга!» – дип сөрән салып йөриләр, ә үзләре «Ичкерия – чеченнәргә!» сүзен ишетү белән, Кавказга танклар җибәрделәр.

– Мин, хөрмәтле күршем, сәясәткә кагылмаска тырышам.

– Сез безнең шикелле бушка ләчтит сатып йөрмисез. Сез, яһүдләр, сәясәтне астан хәрәкәткә китереп торасыз, – диде Габдрахман һәм шунда ук «яһүд» сүзенең ычкынып китүенә үкенеп куйды.

– Без эшлибез. Ялкау яһүдне күргәнең бармы синең?.. Яисә эшнең рәтен белмәгәнне?.. Без эшкә урнашу белән, иң башта вазифаның файдалы һәм файдасыз якларын җентекләп тикшереп чыгабыз. Иң кирәкле хезмәткәр булуга ирешкәннән соң, җитәкчене үзеңнеке итү ягын карыйбыз. Туры әйткәнгә хәтерең калмасын, күзәткәнем бар: сез, татарлар, куштанланып, урыс файдасына бил бөгәсез, ялагайланасыз, шовинистлар җырын җырлап ярашырга тырышасыз. Ә без, җаен табып, аларны үз файдабызга эшләтәбез. Безнең берничә мең еллык гыйбрәтле тәҗрибәбез бар бу өлкәдә... шул ярдәм итә.

«Бу нигә болай чишенеп сөйләшә башлады әле?..» – дип, Рахманкулов бераз шикләнеп тә куйды. Шуннан соң, «Бәйрәм ашы – кара кара-каршы» дигәндәй, ул да серен ачты:

– Мин дүрт елга якын фәнни институтта диңгез флотын оештыру һәм аның белән идарә итү бүлегендә баш белгеч булып эшләдем. Бүлектәге биш кешенең

икесе вафат. Без өчәү калдык. Сер итеп әйтәм, алар икесе дә синең милләтеңнән иде. Шулар эшне капиталистларча оештырырга астыртын гына димләп, мине дә үз компанияләренә үгетләп чакырдылар. Сәламәтлегем начар булу аркасында корабларны приватизацияләүгә катнаша алмадым. Хәзер шулар кулында илледән артык иң яңа, иң кыйммәтле океан лайнеры. Тораклары – «Никулина гора»да. Монте-Карлода – виллалары. Шул чакта йөрәгемә операция ясатырга ятмаган булсам, мин дә бүген кишер утыртырга түтәл казып йөрмәс идем. Мин, күршекәем, сине круизга кем җибәргәнлеген барыбер беләчәкмен. Мин инде аны чамалыйм да... Вакыт кына әрәм. Курыкма, бир син аның телефонын. Кемнән алганымны беркем белмәячәк! Татарда «Күрше хакы – Тәңре хакы» дигән изге канун бар. Бу – тәңречелек чорыннан калган закон. Без аны нык хәтерлибез... Турысын әйт, Америкада яисә Израильдә яшәүче туган-тумачаң оештырдымы синең диңгезгә чыгуыңны?

Евгений Моисеевичның хәтере кырылды:

– Син, дустым, урысларга ияреп, болар эшне гел Израиль аша гына эшлиләр, дип гаеплисең. Дөрес, дусларым минем Америкада да, Израильнең үзендә дә бар. Әмма аларның бу эшкә бернинди катнашы юк. Тынычлан. Мине круизга «Коммерсант» нәшриятының спонсоры Лебедев җибәрә. Аңа реклама кирәк. Шул максат белән җибәрә ул мине...

– Владлен Семёновичмы? Ул җибәрәмени?! Аның телефонын ачыклау берни тормый.

– Син аны беләсеңмени?

– Белмәскә. Без аның белән ун елдан артык бер пароходчылыкта эшләдек. Ул кораб төзү факультетын тәмамлаган иде. Шунлыктан башта йөзү эшенә эләгә алмады, пароходчылыкта комсомол оешмасын җитәкләде. Аннан соң партком секретаренең урынбасары булып утырды. Мисыр белән Израиль сугышы вакытында Лебедев пассажир флоты белән идарә итә иде. Сер саклау максаты белән, яһүдләрне җитәкчелектән алып ташлагач, ул эшсез калды. Минем фәнни институтта эшләгән чак иде, Владленга Союзморниипроектка[3] урнашырга ярдәм иттем.

– Үзен белгәч, телефоны да бардыр бит синдә? Нигә юкка башымны катырасың?

– Әле дә бар, ләкин искерде... Союзморны күптән яптылар. Ул, билгеле, өч бүлмәле кетәген дә күптән ташлап киткән. Димәк, хәзер аның телефоны да башка булырга тиеш.

– Әйттем бит, аның бу телефонын бирергә ярамый дип. Син минем бугазыма пычак терисең... – Бераз икеләнеп торганнан соң, Резник блокнотына лайнер хуҗасының телефонын язды да, ертып алып, Габдрахманга сузды. – Белсә, җанымны алачак... Син Мәскәүгә кайтырга җыенмыйсыңмы? Әйдә, мин берүзем, сөйләшеп кайтырбыз.

– Рәхмәт, әлегә булмый. Гаилә килгәнче, азрак кыймылдап калырга кирәк...

Бүген җомга көн. Шимбәдә дачага аның кызы Кәримә киләчәк. Соңгы атнада җирнең ашламасын аяусыз суырып торган каеннарны кисү турында каты бәхәс бара иде. Килү белән, Кәримә каеннарын барлап чыгачак. Шушы көннәрдә Мәрьямне дә хастаханәдән чыгарырлар, шәт?.. Ул килсә, иртәнге сәгать унбергә кадәр кадак кагу катгый тыелачак. Алар килгәч, җир казу да туктатылачак. «Йөрәге авыру кешегә авыр эш башкарырга ярамый...»

[3] Союзморниипроект – диңгез флотының үзәк фәнни институты.

диячәкләр. «Күршеләрне көлдерү»дән куркып, тирес ташу да бетәчәк... Хезмәтне ак һәм кара эшкә бүлү гадәткә кергән. Томаналык түгелмени инде бу, йә? Ләззәт биргән эш һәр очракта ак һәм изге. Шунлыктан Габдрахман җир эшләрен хатыны юк чакта, ялгызы калганда башкарырга тырыша.

Менә бүген дә ул бакчасына сыер фермасы тиреслегеннән бер уфалла ашлама алып кайтып, казыйсы җиренә таратты... Аннан, көрәген үткенләп, эшкә кереште.

**4**

Евгений Моисеевичны озаткач, Рахманкулов кабат түтәлен эшкәртергә тотынды, әмма ни хикмәт, эшенең бөтен тәме югалып өлгергән иде инде. Күршесенең диңгезгә чыгарга әзерләнүе аны тәмам әсәрләндереп, алгысытып ташлады. Аяк-куллары – җир казуда, ә күңеле белән ул күптән Одесса ярлары буенда, диңгездә, ерак яшьлек елларында йөри иде инде...

Өмет. Шул өметнең яшерен бер эчке мәгънәсе, тынгысызлыгы бар. Менә нәрсә иде аның күңелендә. Әле бүген иртән, түтәлне казый башлаганда гына да җир казу яшәешкә мәгънә, тәм биреп тора иде. Адәмне балчыктан яратылган, дип аңлата дин. Шулай булмаганда, җир сине шушындый тылсымлы көч белән чокынырга тартыр идеме икән?.. Мәңгелеккә омтылу шул ук кара туфракка кушылуга бер ашкыну түгелме? Бу тартылу аның куенына кереп тынычлану белән генә тәмамланмыймыни? Томанлы зәңгәр чиксезлектә дә бит тынгы юк. Диңгездә дә шул ук кара туфракка басып йөрүне сагынып җирсү... Ә алай булгач, диңгез-океаннар киңлегенә омтылу каян килә? Диңгез чакыруы җир тартуыннан да көчлерәк микән әллә? Моны аңлавы чиктән тыш читен. Габдрахман көрәген баскыч астына илтеп яшерде дә каен төбендәге утыргычка аркасын терәде...

Лебедев диген... Лебедев Габдрахманга, чынлап та, бик яхшы таныш, хәтта, кем әйтмешли, кирәгеннән артык якын белгән таныш иде. Әлеге фамилия аңа әле үзе дә чын-чынлап төшенеп җитмәгән ымсындыргыч серләр яшереп тора кебек иде...

Бераз уйланып торгач, ул куен дәфтәрен алып чыгып, күршесе биргән телефон номерын җентекләп барларга кереште. Блокнотта язар урын калмагач, Габдрахманның иң кирәклеләрен яңадан күчереп яза торган гадәте бар иде. Шулар арасында Лебедевның фәнни институттагы номеры да теркәлгән булып чыкты. Тәкъдир шушы түгелме икән? Блокнотта да аның зәгыйфь эзләре сакланган ич әнә...

***

Лебедев белән сөйләшү уе, баш миенә каккан кадактай, бер генә минутка да онытылып тормады. Габдрахман әле йокының караңгы билгесезлегенә чумды, әле уянып китеп, кабат шул кайгы-хәсрәтләрдән арындыручы төнге рәхәтлек кочагына кайтырга теләп, көн актырганчы бимазалануын дәвам итте. Ниндидер яңалыкны көтү, бәлки, аның канына сеңгәндер. Ни дисәң дә, Рахманкулов нәтиҗәсез көтүчеләр җәмгыятендә яши. Юк, аның көтүе ерак бабалары шикелле меңләгән баш мал көтүен карау мәшәкатендә түгел. Шушы көнгә кадәр ул көтүдәге сарык хәлендә совет халкына коммунизм килгәнен көтте. Тик менә аны якынлаштыру нияте белән, миллионнарча гомерләр корбан ителсә дә, килергә теләмәде коммунизм. Ә хәзер ул хакимият вәгъдә итеп торган пенсия артуын көтә. Билгеле, көтүнең бусы да пшик булачак. Әмма, гавам белән бергә күмәк көтүгә иярми чараң юк...

Йокысыз төн озакка сузыла. Ниһаять, таң атты. Ятагыннан тору белән, чәй дә эчеп тормыйча, Габдрахман каравыл йортындагы бердәнбер телефонга юл тотты. Ятып калганчы, атып калырга кирәк.

Үзәк урам, дача биләүчеләр телендәге «Бродвей»ның асфальты, кооперативны урталай бүлеп, урман читенә килеп терәлә дә, сулга борылып, Мәскәү ягына китеп югала. Буйга бер генә урам булуы шактый уңайлы. Кичке якта хатын-кыз күлмәк күрсәтергә, аларның язучы ирләре исә, кыяфәтләренә даһилыкларын элеп, Бродвейга чыгалар. Мыштым, астыртын ярыш башлана: кем бөегрәк? Кемнең үлемсез исеме Лев Толстойлар, Достоевскийлар янына язылып куелачак?!.

Мәскәүдән килгәндә, иң беренче җир – каравыл йорты. Шобага тотканда, бу урын Мәскәү университеты профессоры Роберт Гата улы Бикмөхәммәтовка чыккан иде. Җир алган елны Робертның хатыны, гарәп миллионеры белән никахлашып, Алжирга китеп барды. Шул ук елны күз нурына тиң кызын Антон Табаков алды да, балага узгач, аерып җибәрде. Фатирын атлап кергәндә, Робертны инсульт бәреп екты. Бикмөхәммәтовның ятим йортының түбәсен ябып, каравыл йорты иттеләр.

Бродвейны каравыл йорты башлап, унбер урамчык кисеп уза. Килгәндә уң якта – «көньяк», сулда «төньяк» сүзе өстәлгән. Рахманкуловларның йортлары «Төньяк җиденче» дип исемләнгән урамчыкта иде. Урамчыкларның барысы да урман читенә барып төртелә. Кооператив төзегән елларны өеннән сиксән метр ераклыктагы урманнан Габдрахман ярты сәгать эчендә ярты чиләк гөмбә, чиләкләп кара җиләк җыеп кайта иде. Дүрт-биш елдан урман эче тапталды, гөмбәлекләрне, куак төпләрен юештә лайлаланып беткән целлофан капчыклар, аракы-сыра шешәләре каплап китте. Гөмбә үсми башлады, җиләк куаклары корып бетте. Иртәнге якта яңгыраган кош сайраулары, кәккүк тавышлары да елдан-ел тоныграк ишетелә иде.

Телефон-автомат куелган алачык-будка янына Рәсәйнең кара язмышы белән янәшә яшәп килгән чират торучылар инде җыелырга өлгергән...

– Кайсыгыз иң соңгы кеше?

– Мин, «соңгы» түгел, «крайний», – диде кырыклар тирәсендәге симез ханым.

Габдрахман чират шартына буйсынып көтәргә кереште. Сөйләшү бәхетенә ирешкәннәрне арттагылар ашыктыралар. Рәсәй чынбарлыгының бер төп кануны бу – чиратлары җитеп, телефон трубкасын эләктергәннәр көтеп торучыларны шундук оныталар иде.

Рахманкулов шуңа игътибар итте. Үз заманында әдәбият фонды ярдәмендә кооперативка эләгүчеләр саны елдан-ел кими, сыегая бара. Аның күршесе Резник шикеллерәкләр гламур журналларда басылып, берничә бизнес рухлы китап чыгарганнан соң, Рәсәйнең эстрада мадоннасы – Алла Пугачёва салдырткан коттедж тирәсеннәнрәк яхшы җир алып, шунда төпләнергә тырышалар. Бакча кооперативы әкренләп вак-төяк эшкуарлар, вак чиновниклар кулына күчеп килә. Боларының кесә телефонына ирешү бәхете алдарак иде әле.

***

Ниһаять, чираты җитте. Пип-пип-пип... Шушы өзек сигналлар гомернең кыска булуын, очрашмыйча гына сөйләшергә теләүчеләрнең ишле булуын, яшәүдә сабырлык кирәклеген – җәмгыятьнең тагын әллә нинди шартлары барлыгын искә төшереп кисәтә иде. Телефон трубкасында хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Сезгә кем кирәк?

– Владлен Семёнович! – диде Рахманкулов.

– Ул Англиядә.

– Кайчан кайта?..

– Билгеле түгел...

«Беләсең син, стерва!» – дип кычкырудан көчкә тыелып, Рахманкулов сүзен дәвам итте.

– Мин Владленның бизнесы белән кызыксынам. Диңгезче мин. Аңа кирәкле бер киңәшем бар иде.

Күкрәкләр, билгеле, яртылаш ачык, шәрә аяклары да гаурәтенә кадәр диярлек капланмаган... Хатынның тавышы шуңа ишарәли иде.

Сөйләшүнең өзелүеннән куркып, Габдрахман кабаланып әйтте:

– Без Владлен Семёнович белән Одессада, аннан соң Мәскәүдә бергә эшләдек. Ул мине яхшы белә. Аңа минем бик мөһим бер гозерем бар иде.

– Әйтегез, тапшырырмын, – диде трубкадагы тавыш.

– Әйтә алмыйм. Аңа үз телем белән җиткерәсем килә.

– Үзегез һәм йомышыгыз турында бер генә җөмлә белән әйтегез.

– Рахманкулов Габдрахман Бәкерович мин. Диңгезче... Диңгезчелек буенча фәнни хезмәткәр. Морфлотта бүлек начальнигы... Без...

Телефондагы тавыш, автомат техника төгәллеге белән, Габдрахманның сүзен кырт кисте:

– Киләсе чәршәмбедә, төгәл унбиш сәгатьтә шалтыратырсыз. Кабат кисәтәм: шефның вакыты чиктән тыш тар. Сүзегезне кыска гына итеп алдан әзерләп куегыз. – Трубкада металл бугазлы «пи-пи-пи...» яңгырады.

***

Әйе, диңгез «чакыруы», аның татлы сыкрандыруы еллар үткәч тә җанында аз гына да югалмаган икән. Әлеге ымсыну аның канына гомерлеккә кереп сеңгән, күрәсең... Шул ук вакытта күңелендә ул кисәк кенә икенче бер татлы тойгының тирбәлеп куюын да ап-ачык итеп сизеп алды. Куллары, аяклары җир казуда, ә уйлары Габдрахманны Одессада яшәгән, хәтерендә нык уелып калган диңгезчелек елларына – кораб врачы Юрий Владиславович Дадоновның Ланжерон паркы капкасының каршысында диярлек йорттагы фатирында пилмән ясаган көнгә илтеп куйды. Ник югалмый, нигә шулай чат ябышкан бу үткән көннәр? Ул гына да түгел, нигә алар шулай аяусыз әрнетә?!. Габдрахман, ниһаять, аңлады: Лебедев белән очрашасы килүенең нигезендә дә барыннан да бигрәк Владленның хатыны Оксана турында нидер ишетәсе килү теләге посып ята иде шикелле...

## 5

Көнкүрешнең әрсез мәшәкатьләре теңкәгә тиеп, күз алдында үз кулың белән әтмәлләгән дарның элмәге чекерәеп тора башлаган мизгелләрдә Рахманкулов хыял дөньясының зәңгәрсу томаннарына яшеренеп котылырга тырыша иде. Сөт беткән; бакчасыннан чакрым ярымда урнашкан – ГУЛАГ тоткыннары Истра сусаклагычын казыганда барлыкка килгән Алёхново авылыннан ипи алып кайту көн тәртибенә килеп баскан; кесә тәмам такыраеп калган.

Тамак кайгысының аяусызлыгыннан Габдрахман фәлсәфә чытырманына кереп качарга тырыша иде. Мантыйк кануннары аяусыз. Алардагы хакыйкать юнәлеше үз-үзеңне аңларга да ирек бирми. Әнә, безнең ерак бабаларыбыз... Без

нигә дип ваз кичкәнбез соң аларның әхлак саклау тәҗрибәләреннән? Юк, без ваз кичмәгәнбез... Безне мәҗбүр иткәннәр. Ә нишләп каршы тора алмаганбыз? Баерак та яшәгәнбез, культурабыз да аларныкыннан югарырак булган... Алтын Урда татарлары, аннан да элегрәк Атилла чорының корыч тәвәккәллеге Мәскәү кенәзлеген Левон рыцарьларыннан саклап калган...

Пенсиянең кыска койрыклы акчасы искиткеч бәрәкәтсез... Өстәвенә Ичкериядә елга булып аккан каннарны күрсәтеп, телевизор җанны ала. Телекның төнге күрсәтүләре Чечня хәбәрләреннән дә аяусызрак. Төннәрен телеэкраннан олигархларның шәрә кәнизәкләре түшәк уены уйнап күрсәтә...

Өч дистә океан лайнерының хуҗасы белән телефоннан сөйләшергә чират көткәндә, Габдрахманны шушы уйлар бимазалый иде. Бакча кооперативы йортларына килеп терәлгән урманда матәм моңы белән кәккүк кемнеңдер газиз гомерен саный... Кәккүк тавышын тыңлап хозурланырга гына иде югыйсә. Габдрахманнан алдарак килеп чиратка баскан ике хатын телефоннан сөйләшүчене ашыктырып чәрелдиләр.

«Тукта әле, – дип уйлап куйды Рахманкулов, – диңгез дип аталган шул зәңгәр чиксезлек яшьлегемне чәйнәмичә генә йотып җибәрде... Өч дистә ел гаиләмнән аерып иза чиктерде. Ә мин, карт томана, кабат шуңа ашкынам...»

Аллага шөкер, алдагы хатыннар бүселеп будкадан чыкты. Габдрахман ашыгып шул кысанлыкка чумды.

Рахманкулов телефон номерын җыйды. Шунда ук ирләр тавышы:

– «Океан юллары»ның үзәк офисы. Лебедев тыңлый.

– Владлен Семёнович, сезне Рахманкулов борчый, Габдрахман Бәкерович. Без Одессада, аннан соң «Союзморниипроект»та бергә эшләдек.

– Аңлатып тору кирәкми, старик. Минем компьютерда синең тулы биографияң. Хәлләрең ничек?

– Пенсия белән тукланып ятам. Ишеп түлиләр. Кесәгә сыймаган чаклары да була. Кая куярга белгән юк.

Трубкада кеткелдәп көлгән тавыш ишетелеп сүнде. «Соң бит фиргавен-олигарх синең күпме пенсия алганыңны яхшы белә!»

– Мин синең китаплар язып акча каеруыңны ишеткән идем. Шул эшне дәвам итәсеңме? – Кабат кеткелдәп көлү тавышы ишетелеп югалды. Мыскыллап әйтә, маланский[4]!

– Влад, мин синең дистәләгән океан лайнерларының хуҗасы булуыңны ишеттем. Шуларның берсенә мине утыртып җибәр әле – тозлы һава сулыйсым килә.

– Люкс алырга уйлыйсыңмы? Язучының сармагы юк түгелдер?..

«Сармак...» Диңгезчеләр акчаны шулай атыйлар иде. Рахманкуловка үзенең әле һаман диңгезче икәнлеген күрсәтеп мактанмакчы була олигарх.

– Сармакның монда катнашы юк. «Море зовёт», – диде Габдрахман да, диңгезчелеген югалтмавына ишарәләп. – Море зовёт, а Лебедев не пускает. Диңгезләргә чыгуның ачкычы бит Владлен Семёнович кулында.

– Хәтеремнән чыккан. Синең диңгезчелек дипломың ШДП[5] мы, әллә КДП[6] мы?

– КДП, – диде Рахманкулов. – Шунысы бар: мин капитан булып эшләмәдем. Капитанлыкка – күзләр минус өч, йөрәкнең сул як карынчыгы иске оекбаш хәленә җитеп таушалып беткән булмаска тиеш. Юк, мин штурман рубкасына

[4] Маланский – одесситлар яһүдләрне шулай атап йөртә.
[5] ШДП – штурман дальнего плавания.
[6] КПД – капитан дальнего плавания.

дәгъва кылмыйм. Нишлисең бит! Диңгез кочагына керер өчен, мин саклау камерасында чемодан алып торырга, хәтта киоскта газета сатарга да риза. Люкс хуҗалары да, палубада баручы урынсыз пассажирлар да – шул ук диңгез һавасын сулыйлар бит.

– Без болай килешик, – диде Лебедев. – Син иртәгә нәкъ шушы вакытта минем мобильникка шалтырат. Мин сиңа кайсы лайнерда, кайчан, нинди статуста диңгезгә чыгуыңны төгәл әйтермен. Каләмең бармы – яз! – Шунда океан лайнерларының хуҗасы унбер саннан торган телефон номерын әйтеп яздырды.

**6**

Сөйләшүнең нәтиҗәсе белән канәгать калса да, Габдрахманның җаны тыныч түгел иде. Ул язмышын миллионнар, хәтта миллиардларга җиткән доллар белән эш итүче хәйләкәр, һәр мөнәсәбәтләрне акча белән үлчәргә күнеккән кеше кулына тапшырып азаплана. Аңа дөнья гизү, яңа портлар, яңа кешеләр белән очрашу турында кыбырсып йөрмәскә, күргәннәренә шөкрана кылып, урман һавасы белән ләззәтләнеп, дачасында тыныч кына ятарга иде...

Сөйләшкәндә ул ычкынып китә язган ике ялгышлыктан тыела алды. Ялынмады, мескенлеккә бирелмәде һәм «нәрсә ул мобильник?» дигән сорауны читләтеп үтте.

Японнарның кесәдә йөртерлек бәләкәй, теләсә кайсы шәһәр һәм ил белән сөйләшеп булырлык телефон уйлап чыгарулары турында Рахманкулов «Наука и жизнь» журналыннан укып белә иде. Иртәгә ул шундый аппараты булган кеше белән сөйләшәчәк. Димәк, адәм балаларының шундый телефон уйлап табулары чынбарлыкка күчкән дигән сүз. Җәмгыятькә нинди үзгәрешләр кертә алыр икән ул кесә телефоны? Гади телефон ярдәмендә сөйләшкәндә үк абонентның йөзен, аның күз карашын, ишарәләрен күреп булмый иде. Телефон трубкасыннан ишетелгән шәрә сүз... Без бит ничә мең еллар әңгәмәдәшеңнең әйткән сүзеннән тыш аның ишарәләрен, хәтта утырыпмы, басыпмы сөйләшүенә карап, ул әйткән фикерләрнең ихласлыгын, аның сиңа карата нинди мөнәсәбәттә икәнлеген билгеләргә күнеккәнбез. Кешенең сөйләшкән чактагы күз карашы? Аның битенә бәреп чыккан кызарыну?! Телефоннан сөйләшү – ялганлау, күз буяу, итәк астыннан ут уйнату. Телефон ярдәмендә бу кабахәтлекләрнең мөмкинлеге бермә-бер артачак. Ә кешеләрнең сөйләшүләрен тыңлау мөмкинлеге?.. Һәркем мобильниклы була алган очракта, дәүләт шымчыларсыз да һәркемнең хакимияткә, аның сәясәтенә карата нинди мөнәсәбәттә булуын тулысынча күзәтү астында тота алачак.

Рахманкулов каравыл йортына иртәнге якта чират җыелганчы барырга уйлап йокларга ятты. Яту белән йокыга китте дә төн урталарында уянып, сөйләшер вакыт җиткәнче йоклый алмыйча газапланды. Яшь чакта да йоклый алмыйча интеккән төннәре була иде. Ул вакытта аның йокысызлыгы кичтән йокыга китә алмыйча яту белән чикләнә иде. Хәзер ул йокының караңгы базына чума да төн урталарында уяна, кабат шул кайгы-хәсрәтләрдән арындыручы онытылу кочагына чумарга теләп, төш вакытлары җиткәнче диярлек бимаза кичерә.

Ятагыннан тору белән, чәй дә эчеп тормыйча, Габдрахман каравыл йортына ашыкты. Чиратта бары тик ике генә хатын иде. Алар телефон будкасыннан тиз чыктылар. Габдрахман номер җыйды:

– «Океан юллары» офисы. Лебедев тыңлый.

– Сез миңа шалтыратырга кушкан идегез, Владлен Семёнович. Рахманкулов борчый сезне.

– Саумы, старина. Хәтерлим. Шушы көннәрдә Одессага ике тагарагым круиздан кайта. Шуларның берсе Австралиягә йөри. Барышлый һәм кайтышлый күп кенә портларга кереп чыга. Икенчесе Рио-де-Жанейро белән Петербург арасында эшли. Билгеле, маршруттагы һәр әһәмияткә лаек портка кереп чыга. Шуларның кайсысын сайлыйсың?

–Ниләр эшләргә тиеш мин корабта? Круиздагы туристлар шикелле күңел ачып йөри алмам шикелле. Мин бит диңгезче. Пенсионер статусында йөрүгә риза түгелмени. Минем хәләл аш ашап йөрисем килә.

Бераз җавап бирми торды Лебедев. Ул хәзер нәрсәдер әйтергә тиеш иде.

– Туристларның чемоданнары зурайды соңгы елларда... Аларны хәзер пенсионер гына күтәрерлек түгел. Киоскта газета-журнал сату проблемасына килгәндә, аның эше авыр түгел. Тик шунысы бар: киоскёрны мин кают-компанияда ашата алмыйм. Комсостав каршы киләчәк. Люкс пассажирларының кайберләре кают-компанияда ашыйлар. Мин сиңа люкс бирергә мәҗбүрмен. Син, старина, офицерларның әңгәмәләрен дикъкать белән тыңларга тиешсең.

– Шымчы итәсеңмени син мине?

– Ашыкма. Шымчы итеп түгел, аналитик итәм. Син бит Союзморда диңгез транспорты белән идарә итүне өйрәнгән фәнни хезмәткәрләрне җитәкләдең, морфлотның үзәк аппаратында да эшләдең. Корабларда йөзүең турында әйтеп тә тормыйм. Син ничә ел йөздең әле?

– Утыз елга якын, – диде Рахманкулов.

– Диңгезчелек тәҗрибәсе дә, теория дә, безнеңчә әйткәндә – выше ватерлинии. Круиздан кайту белән, син минем өстәлемә тулы анализыңны китереп салырга тиешсең. Сервис өлкәсендә нинди кимчелекләр бар? Эшкә зыян китермичә, кемнәрне кыскартырга була? Круизны оештыруга нинди яңалыклар кертергә кирәк? Синең анализың дәлилләнгән булырга тиеш. Эш менә нәрсәдә: минем лайнерым зурлыгындагы корабта японнар сиксән-туксан кеше тоталар, ә минекендә ике йөздән артык. Аңладыңмы?

– Таныш мәсьәлә. Әмма кисәтеп куям, фән ягыннан мин артта калган кеше. Реклама хәйләсе белән таныш түгел. Пассажир флотындагы яңалыкларны да белмим һәм иң зур кимчелегем – компьютерны өнәмәвем.

– Старый конь борозды не портит, ди рус әйтеме. Экипажның эшендә объектив, субъектив, ситуацион кимчелекләре була. Менә нәрсә энәсеннән–җебенә кадәр ачыкланырга тиеш. Менә шул.

– Рәхмәт, – диде Рахманкулов, ихлас күренергә тырышып. – Дөресен әйткәндә, мин синнән мондый зур бүләк көтмәгән идем. Сочтёмся. Алай булгач, миңа әзерләнә дә башларга кирәктер... Лайнерның исемен сорарга онытканмын...

– «Оксана», – диде Лебедев. – Хатынымның исеме. Аны син дә беләсең бит. Трубкаңны куйма, мин икенче телефонга күчәм...

– «Оксана!..» – бу исем Габдрахманның күкрәк эчен көйдереп, тәненә таралды, баш миенә бәрде.

Будканың ишеген шакыдылар. Кашлары җимерелгән симез хатын йодрыклап ишек пыяласын төя иде:

– Бер сәгать лыгырдыйсың! – дип чәрелдәде ул. – Ир кеше, имеш... Болтун! Ач ишекне! Чык!

Трубкадан Лебедевның тонык тавышы килеп җитте:

– Оныта язганмын, – дип дәвам итте ул. – Оксананың сине күрәсе килә. Чакырырга кушты. Бу атна азагында Мәскәүгә кайта. Монте-Карло туйдырган. Хатын-кыз бит...

Рахманкуловның күз аллары караңгылангандай булып китте. Йөзе кызарды. Ул өнсез калды. Оксана!..

Тукта әле! Нишләп Владлен Габдрахманны үз хатыны белән очрашырга чакыра? Моны ничек аңларга?.. Үч алу, мыскыллау теләгеме бу?.. Монда ниндидер аңлашылмас нәрсә, берәр хәйлә бар кебек иде...

– Нигә җавап бирмисең? Оксана шимбә көн кайта. Якшәмбедә мин сине алып килергә машина җибәрәм. Әйт әле дачаңның адресын...

Бу... Бу ниндидер тузга язмаган, исәпкә сыймый торган хәл иде. Әллә сөйләшүдән туктарга инде?.. Ирексездән, теләмичә, хәтер коесыннан көчкә суырып чыгарып, Рахманкулов бакча кооперативындагы өенең адресын әйтә башлады.

– Истра сусаклагычы янында...

– Чубайсныкы янындамыни? – Бу сорауда да ниндидер мәсхәрәле кинаяя бар шикелле иде.

– Чубайсныкы – Плотинага якын. Безнең кооператив Алехново исемле авылдан чакрым ярымда.

– Волоколамски юлындамы?

– Шунда. Яңа Иерусалим монастыреннан унсигез чакрымда. «Мәскәү язучылары» дип атала. Җиденче Төньяк урам, өченче йорт.

– Сәгать уннар тирәсендә машинам килеп җитәр. Көтеп тор. Килештекме?

– Мәскәүдә торасыңмы?

– Юк. Минем алачыгым Барвихада. Сине шунда көтәбез.

«Алачык...» Барвиханың нинди урын икәнен Габдрахман яхшы белә иде. Совет чорында анда дача салу мөмкин түгел – Үзәк Комитетның профилакториясе иде. Микоянның биш метрлы таш койма эчендәге кальгасы. Партия золымы җимерелгәннән соң, димәк, Барвиха олигархлар кулына күчкән. Владлен «алачыгы»ның урынына карап кына да аның кулындагы акча күләмен җиңел чамаларга мөмкин иде.

## 7

«Көтәбез...»

Димәк, алар Габдрахманны икәүләп көтәчәкләр. Ирле-хатынлы. Заманында Габдрахманның сөйгән кызы, халык җырларындагы кебек, «өзелеп сөйгән яры» Оксана Тарасовна Ярёменко, аның ире Владлен Семёнович Лебедев (үткәндәге Арансон) Караяр авылының Әтәмби исемле урамында туып үскән Габдрахман Бәкер улы Рахманколыйны, урыслаштырылганнан соң Рахманкуловка әверелгән пенсионерны көтәчәкләр.

Яшәеш үзенең чын-чыннан бөек могҗиза икәнлеген туктаусыз исбатлап тора. Сабый чакта ук туган, үсмерлек елларында тамыр җәйгән зур хыял, картайган саен һаман ерагая торса да, һаман аның күңел түрендә яши ала икән... Халыкларның бөек хәрәкәтләнүе авыл булып укмаша башлаган җир – Чишмә башы урамында урам якка чиста пыялалы биш зур тәрәзә һәм зәңгәргә буялган тәрәзә капкачлары карап торган алты почмаклы, калай түбәле йорт һәм ак яулыгын чөеп бәйләгән уңган, җитез хатын, ишегалды тулы балалар... Армиягә киткәндә, Габдрахманны «көтәм» дип озатып калган кыз җилдән бала тапты... Сугышка китәргә әзерләнеп йөргәндә туган ашыгыч хис-тойгыларыңны

«беренче мәхәббәт» дип атап буламы икән? Караярның ирләре ул елларда сугышка китеп кырыла, хәбәрсез-нисез билгесезлеккә чыгып югалып тора иде. Габдрахман ул кыз белән армиягә китәр алдыннан гына йөри башлады. Бәлки, ул ашыгыч очрашулар мәхәббәт булып җитлегә дә алмагандыр? Гасырларга сузылган мәхәббәт тарихларында, халык җырларында, бәет-мөнәҗәтләрдә, эчтән генә янып-көюләрдә мәхәббәтнең нәрсә икәнлеген аңлап ышанырлык сыңар бер мәгълүмат та юк...

Тойгыларны кичереп була. Аның әрнеткеч һәм шифалы тәэсирен моңлы көйгә салып була. Әмма сүз белән аңлатуы чиктән тыш авыр, катлаулы. Бәлки, шуңадыр да егерме беренче гасырда инде мәхәббәтне секска алыштыруга каршы килми башладылар...

***

Габдрахман ул кызга «Ак Санәм» дип дәшә иде.

– Мин бит Оксана. Нигә исемемне бозасың?

– Юк, бозмыйм. Киресенчә, төзәтәм. Бу исемне урысчалаштырганнар. Мин төзәтеп әйтәм.

Кызның кыяфәте җитдиләнә. Аның күзләреннән чагылган кара тылсымлы нур тагын да тирәнәя төшә.

– Минем исемемнең «Ак Санә» булуын син каян беләсең?

– «Санә» – сан дигән сүз. «Санәмнең» мәгънәсе башка. Бу сүз «кумир»га тәңгәл. Синең тамырларыңда кыпчак каны акканы күренеп тора. Мин бит украина мәктәбен бетердем. Украина телендә кыпчак сүзләре тулып ята: «мәйдан», «яр», «келәм», «тютюн». Алар санап бетергесез. Фамилияләрегезнең «ко»га бетүе дә татар телендәге кушымча икәнлеген ачык күрсәтә – төрки телләрдә иялек килешендәге сүзләр шулай тәмамлана. Кырпу бүрекнең милли баш киеме булуы, чәчне кырып алып, баш түбәсендә «осиливец» дип аталган бер чуметем чәч калдыру. Украина хатыннары чиккән сөлгеләрдәге сурәтләрнең безнекенә охшаш булуы – боларның барысы да кыпчаклардан калган билге.

Кыз аңлатманы дикъкать белән тыңлый да матур итеп елмая:

– Ялганларга оста да инде син, Габдрахман! Монда тулысынча синең үз фантазияң булуы күренеп торса да тыңларга рәхәт. Без бит туган телебезне онытып барабыз. Украиналыларның күбесе үзен урыс дип яздырта. Мин урыс түгел, украиналы, дисәң, милләтчегә саныйлар.

– Әйдә, украинча гына сөйләшик.

Оксана бертын уйланып тора.

– Юк, кирәкми. Син бит украинчага Запорожьеда өйрәнгәнсең. Аларның теле яртылаш кацапча[7].

– Татарларны буйсындырырга җиңел булсын өчен дә бүлгәләп бетергәннәр. Юк, бүлгәләү белән генә чикләнмичә, безне тураклап ташлаганнар да бер-беребезгә каршы көрәштерүгә ирешә алганнар. Украинада да шул ук процесс башланды. Сез шуны аңлыйсызмы икән?

– Бу турыда сөйләшәсем килми. Әйдә, синең белән гел татарча сөйләшик.

– Син татарча белмисең бит.

– Беләм. «Мин синэ йаратам...» Бу татарча түгелмени?

– Түгел шул. Эш менә нәрсәдә. Безнең ерак бабаларыбыз әйткән сүзгә бик үк ышанып бетмәгәннәр. Алар кешене кылган гамәлләренә, биргән

[7] Кацап (укр.) – хохолларның басып алучылар итеп күрсәтәсе килгәндә, урысларны йә «москаль», йә «кацап» дип атавы.

вәгъдәләрен тотуына карап бәяләгәннәр. Шуннан чыгып, кыз да, егет тә яратуларын, бер-берсе өчен утка-суга керергә әзер булуларын исбатлау юлы белән белгерткәннәр. «Мин сине яратам» бу урыслар уйлап чыгарган күзбугыч сүз генә.

– Элегрәк бездә дә шулайрак булган. Ярәшкәнчегә кадәр бабай белән җитәкләшеп йөрергә дә рөхсәт ителмәве турында миңа әбием Мария сөйли иде.

***

Лебедев белән сөйләшкәннән соң, ялгыз калган чакларда Рахманкулов күбрәк Оксана турында уйлап йөри башлады. Танышу, очрашулар, озата барулар, аерылышканда буыннар йомшарганчы үбешүләр аз түгел иде бит. Оксананы югалту хисләре нигә болай авыр кичерелә икән? Шушы сүз белән аңлап-аңлатып та булмый торган йөрәк омтылышы Габдрахманның бәгырьләренә чытырдатып ябышкан да, дачасындагы саф урман һавасын сулау рәхәтлеген, кошлар сайравына моңаюның әрнеткеч рәхәтлеген агулап, астыртын гына суырып тора...

**8**

Әйе, Оксана белән хәтта беренче танышып китүләренә кадәр бүгенгедәй яхшы хәтерли: Рахманкулов чираттагы ялдан соң, туган авылыннан Одессага кайтты. Аның корабы әле йөзүдә иде. Кадрлар бүлеге эш хакының җитмеш биш процентын түләү шарты белән аны резервка куйды. Корабны көткәндә өлкән комсоставны эшкә кумыйлар иде. Пароходчылыкның үз кунакханәсе бар. Арзан гына хакка хәтта аерым бүлмәдә ялгыз яшәргә мөмкин. Корабның кайтканын тыныч кына көтеп яши бир. Дөрес, адым саен дусларың очрап торганда, тынычлыкны саклау чиктән тыш катлаулы иде.

Диңгезчелек эшендә, бер корабтан икенчесенә күчеп эшләгәндә, ерак юллар кичергән таныш-белешләрең, дусларың, әшнәләрең елдан-ел ишәя килә. Кемдер синең шикелле корабын көтә. Икенче берәү эшендә өскәрәк күтәрелә алган. Аны башка корабка билгеләгәннәр. Өченчесенең үзе югында хатыны юлдан язган – гаилә фаҗигасен хәл итәргә кирәк... Кунакханәдә, телисеңме-юкмы, син шулар белән очрашасың. Очрашу шатлыгын Рәсәй традициясе аракы белән юарга куша. «Юарга» теләмәсәң, син дошман ук булмасаң да – «безнеке түгел, әллә сырхау, әллә сволочь, кыскасы, ят кеше». Менә шул «юу» ритуалы сине әкренләп сәрхушлеккә сөйрәп кертә. Бу юлы Рахманкулов кунакханәдән баш тартты. Бәхетенә, кораб врачы, аның дусты Юрий Владиславович Дадонов та ялда иде. Аның җәмәгате, Нина Ивановна, кырыкка якынлашып килгән «карт» хатын, чын-чыннан кунакчыл иде. Рахманкулов Нина Ивановнаның «корабың кайтканчы бездә генә яшә», дип якты йөз күрсәтүеннән баш тартмады.

– Бүген иртәрәк кайтырга тырыш, пилмән ясарга булышырсың, – диде Юраның җәмәгате. Пилмән ясау аны ашаудан да татлырак. «Чолман»да эшләгәндә, Юра Дадонов, чыннан да, корабның кокларын ашны тәмлерәк пешерергә өйрәтә иде. Аның аш-суга оста булуын Габдрахман бу юлы тагын бер кат үз күзе белән күрде.

Рахманкулов кайтканда, пилмәнне әзерли башлаганнар иде. Бүлмә уртасына куелган өстәлнең түр ягында Юраның тугызынчыда укый торган кызы Евгения, сулда Юра үзе. Уң якта тагын бер кыз утыра. «Минем белән таныштырырга чакырмаганнардыр бит...» – дип уйлап куйды Габдрахман. Махсус таныштыру

гадәтен яратмый иде ул. Әйе, сыерны үгезгә илтү табигый. Ат караучыларның бияләргә айгыр табуына да тел тидереп булмый. Адәм баласы мәхәббәтен үзе, бары тик үзе генә эзләп табарга тиеш... Дөрес, ул ялгыша, алдана, алдарга, күз буярга өйрәнә. Менә шуларны җиңеп чыгучылар гына бәхеткә ирешә ала. Ул чорда Рахманкулов шулай уйлый иде. Өлкәнәйгәч, татарның улына килен, кызына кияү сайлауда катнашуы таза, зирәк оныклар тудырып, нәсел сыйфатын яхшыртуга юнәлгәнлеген аңлап хәйран калды.

Аяк киемен салган арада өстәлнең уң ягындагы урын бушады. Габдрахман шунда барып утырды.

– Оксана, бу якка чык әле, – диде Дадонов. – Сине дустым белән таныштырасым килә.

– Вакыт юк, дядя Юра. Пилмәнне болгатып торырга кирәк.

Габдрахман кухняга кереп качкан кызның Оксана Ярёменко – нәфис гимнастика буенча Одессаның чемпионы, Бөтенукраина ярышында икенче урынны алган кыз икәнлеген чамалап алды. Одесситлар бик патриот халык. Ул чакта Бөтенукраина ярышында, беренче урынны комсомолның үзәк комитеты секретаре хатынына хәрәмләшеп бирүне тәнкыйтьләп, бөтен Одесса шау-гөр килеп алды.

Дадоновның кызы Евгения пилмәннән калган итне, савыт-сабаны җыеп кухняга алып китте. Аннан чыгып, юеш чүпрәк белән өстәлне сөртеп алды да ак эскәтер җәйде. Оксана зур чынаяк табак белән суганлы ит исе аңкытып торган пилмәнне китереп утыртты.

– Танышыгыз, – диде Дадонов, кызның беләгеннән тотып. – Минем дустым Рахманкулов – капитанның беренче ярдәмчесе.

– Оксана, – диде кыз, кулын бирмичә генә. – Учыгызны юешлисем килми.

Башта кызның күкрәк тирәнлегеннән чыккан калынчарак тавышы, аннан соң җиңел атлап кире кухняга кереп китүе Габдрахманның күкрәк эчен рәхәт итеп кытыклап алды. Сугышка кадәр Караяр кызлары шулай атлап чишмәгә баралар иде.

Соңгы вакытта ул хатын-кызның атлап йөрүен мавыгып күзәтә иде. Шуңа карап аларның нindirәк икәнлекләрен аңларга, кораб йөзүдән кайткан чакларда ирләрен каршыларга килгән хатыннарның уңганмы, ялкаумы, иренә хыянәт итәме, юкмы – шуны ачыкларга тырыша иде. Шунысы кызык: ире диңгездә чакта сөяркә табып хәләл җефетенә хыянәт иткән хатыннарның гөнаһлары турында иренең үзеннән тыш, диңгезчеләрнең хатыннары хәбәрдар була. Күзәтә торгач, шул хыянәтчел хатыннарның атлап йөрүләрендә Габдрахман җентекләп күзәткәндә генә күренә торган үзара уртаклык тапты. Аларның гөнаһлары атлап йөрүләренә дә языла сыман иде. Хәер, бу тикшеренү кемгә генә файда китерә ала соң?..

***

Габдрахман кухня белән өстәл арасында йөргән кызга дикъкать белән карап утырды. Тән авырлыгы, аякларны хәрәкәткә китерү өчен көч түгү юк шикелле иде бу йөрүдә. Тән уйнату да юк иде Оксананың аяк атлавында. Аның киенүе дә гап-гади иде. Кызларның киенүендәге «Күрегез, минем билем нинди нечкә, арт саным матур, күкрәкләрем ымсындыргыч – мин бит гүзәлнең гүзәле», – дип, еректан сөрән салып торган гадәти нәүмизлек тә юк иде. Габдрахманны Оксананың татар кызына охшаш булуы тетрәндерде.

«Бу бит инде табигый хәл», – дип уйлады Габдрахман. – Украиналыларның

тамырларында яртылаштан да артык кыпчак каны ага. Оксананың татар кызына тартымлыгы табигый... Кызның Одессада һәм Киевта басылган газета битләрендәге фотоларына охшаш булмавы да сәер иде.

Ниһаять, табын әзерләнеп бетте. Өстәл уртасында муллык, тормыш канәгатьлеге аңкытып торган ит исе. Чиста итеп юылган биш сай тәлинкә янына чәнечкеләр куелган.

– Оксана, син менә монда утыр. Габдрахман Бәкерович, сезнеке дә монда, – диде Юрий Владиславович, түр яктагы урындыкларга күрсәтеп.

– Рөхсәт итсәгез, мин Женя янына утырам, – диде кунак кызы һәм ян тәрәзә ягындагы урындыкка барып урнашты.

Дадонов савыт-саба шкафын ачып, этикеткасына Бахус сурәте төшкән Италия коньягы, «Веккьия романья бутон» коньягы һәм кызыл шампан шәрабы чыгарып өстәлгә куйды.

– Әти, кыстый күрмә, Оксана белән без икебез дә эчмибез, – диде Дадоновның кызы.

– Минем дә алкоголь кушып пилмән тәмен югалтасым килми, – диде Рахманкулов.

– Нина да баш тартса, берүзем эчәргә туры килә инде, – диде Дадонов.

– Кызларга ярамаганны син бит белергә тиеш. Ә сез, Бәкерович, нигә баш тартасыз? – Нинаның сүзләрендә кыстау тоелмый иде.

– Минем әнием дә пилмән пешерә иде, – диде Габдрахман. – Мин милли гореф-гадәтле гаиләдә үстем. Сугышка кадәр бездә аракы эчү гөнаһ кына түгел, чын-чыннан җинаять санала иде. Бер мәзәк вакыйга истә калган. Әтиемнең Оренбургта яшәүче энесе кайткач, кунак чакырдылар. Өстәлдә зур бәлеш, ат казылыгы, каклаган каз ите. Чәй эчкәндә бавырсак, бал куялар. Табын тирәсендә басынкы гына әңгәмә бара. Ара-тирә Оренбург кунагы белән әтием һава суларга чыгып керәләр. Бер тапкырында мин дә ияреп чыккан идем, кунагыбызның мунчага кереп киткәнен күреп сәерсендем. Әти аны тышкы якта саклап калды. Алар өйгә кереп киткәч, мыштым гына мунчага кердем. Кунак хөрмәтенә мунча эчен кырып юганнар, утыргычка кулдан суккан палас җәйгәннәр. Паласның бүртенеп торган җирен ачкан идем, эченнән аракы шешәсе килеп чыкты. Димәк, ул чакта хәмер эчү гөнаһ саналган булган... – Габдрахман туктап калды. Аның сөйләвен күңел биреп тыңламыйлар иде.

Пилмәннән соң баллап чәй эчтеләр. Оксана саубуллаша башлады.

– Мин сезне озатып куям, – диде Рахманкулов.

– Рәхмәт, – диде кунак кыз. – Мин юлымны яхшы беләм, адашмаячакмын.

– Баш тартма инде, – диде Нина Ивановна. – Кичке якта урам тулы исерекләр. Күзәткәнем бар, синең яныңнан ирләрнең берсе дә тыныч кына үтеп китми. Исерекләргә, хулиганнарга юлыгуың бар.

Алар бергәләп урамга чыктылар.

– Сез култыклашып баруга каршы килмисезме?

– Гафу итегез. Мин җитәкләп йөртүне яратмыйм.

Рахманкулов кызның читкәрәк тайпылуын көткән иде. Оксана янәшәгә килде. Аларның аяк атлаулары җайга салынды. Арада җан гына сизә алырлык берләшү тугандай булды.

Алар Канава дип аталган киң, тирән чокыр өстенә салынган күперне үттеләр. Аста революциягә кадәр мадам Розаның түләүле яратышу йорты булган, одесситлар телендә «Ирод патша сарае» калды. Алар Кангун урамы буйлап ике квартал өскә күтәрелделәр дә, сулга борылып, шәһәрнең иң матур

проспекты – Пушкин урамына чыктылар. Як-якта үскән мәһабәт платаннарның ботаклары урамны каплап, кичке утлар яктылыгында яшел яфраклар япкан түбә тәшкил итә иде. Заманында Габдрахманның яраткан бу урамында Пушкин яшәгән.

Ул йортта хәзер «Моряк» газетасының редакциясе урнашкан иде. Шушы өйгә якынлашкач, егетнең әлеге газетада мәкаләләре басылып чыкканлыгын Оксанага әйтеп мактанасы килеп китте. «Юк, әйтмәскә кирәк, – дип уйлады эченнән Габдрахман, – минем горурлануымны Оксана мактану дип кабул итәчәк».

Алар Одессаның Монпарнасы – Дерибас урамына килеп җиттеләр.

– Дерибасны урап чыгабызмы? – диде Габдрахман. – Танышканнан соң култыклашып шушы урамны әйләнеп чыгу мәҗбүридер бит?

– Мин ашыгам, – диде Оксана. – Иртә торасым бар.

– Күнегүләргә шулай иртә йөрисезмени?

– Иртәнге поезд белән без Киевка китәбез. Анда Мельбурн олимпиадасына баручыларны сайларга тиешләр. Мине шуңа чакыралар.

– Сез үтәргә тиеш дип уйлыйм мин, – диде Рахманкулов.

Оксана сәер итеп елмайды:

– Осталыгыңа карап кына сайласалар, бәлки... Сайлану өчен сайлаучыларның күңелләрен күрә белергә дә кирәк шул.

– Ничек итеп?

– Ничек? Азгын ирләргә нәрсә кирәклеген белмисезмени?

Белә иде Рахманкулов. Җәмгыятьтә ришвәт алу елдан-ел көчәя бара иде. Яшь, чибәр кызларны түшәккә яткыру бу җинаятьнең иң таралганы иде...

Алар Сабанеев күпере аша үттеләр. Уң якта скульптор-медальер Толстойның сарае күренде. Бу сарайда хәзер Галимнәр йорты урнашкан иде. Галимнәр йортыннан соң ярты квартал чамасы баргач, Оксана туктады.

– Мин менә шушында торам, – диде ул, классик ысулда салынган өч катлы матур йортка күрсәтеп. – Сау булыгыз.

Габдрахман кызның беленнән тоткан иде, кызның каршы булуы катгый икәнлеген тою белән, аның кулын кысып бер мизгел җибәрми торды.

– Сез Киевтан кайткач кайда очрашабыз?

– Белмим...

Арада киеренкелек туды. «Бу инде минем белән очрашырга теләми дигән сүз...» Шушы әйтелмәгән фикерне аңлаган шикелле, Оксана егетнең кулын җиңелчә генә кысып алды да:

– Сезгә Женя әйтер. Сау булыгыз, – диде.

Ишек ачылды. Коридорда янган электр уты яктылыгында кызның гәүдәсе бер генә мизгелгә рамга куелган фотосурәт булып күренеп алды да юкка чыкты. Тирә-юньне кара бушлык каплады. Ялгыз калуның әрнеткеч җансызлыгы. Әле яңа гына бушлыкны җанландырып торган җылы, шат рәхәтлек шул эчтән бикләнгән ишек артына кереп юкка чыкты. Шул чакта өченче каттагы караңгылык каплаган тәрәзәләрнең берсе кинәт яктырып китте. Бу яктылык егетнең күңелен җылытып җибәргәндәй булды.

**9**

Башта Рахманкулов диспетчерга кереп корабының кайда икәнлеген белеште. «Чолман», Венециядә йөген кичә кич төяп бетереп, кайтырга чыккан иде.

– Кайсы портка кайтачак? – дип сорады Габдрахман.

Тәненә сыланып торган юка ак водолазка кигән яшь, чибәр кыз, үзенең иң отышлы елмаюын битенә элеп куйгач, тәмле тавыш белән әйтте:

– Әлегә туры Одессага. Позициянең үзгәрүе мөмкин. Белешкәләп торыгыз.

Бу кыз, институт бетергәннән соң, пароходчылыкка урнаша алган бәхетлеләрдән иде. Тәрәзәчек аша әнә ничек матурлыгын балкытып утыра. «Нинди чибәр, үзен ничек ягымлы тота», – дип уйлады Рахманкулов. Диңгезчеләрнең хатыннары бу кызның тупаслыгына зарланалар иде. «Кызык та инде кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, – дип уйлады Габдрахман. – Бәлки диңгезчеләрнең хатыннары бу чибәргә дигән кияүне тартып алган көндәш булып тоела торгандыр?..»

Ул кадрлар бүлегенә юл тотты. Дүрт-биш көннән «Чолман» кайтып җитәргә тиеш иде. Кораб диңгездә чакта иркенләп сынауларны тапшырып бетерергә кирәк иде. Ялдан кайткач, имтихан тапшыруны әле күптән түгел генә уйлап чыгардылар. Диңгез инспекциясенә – кораб йөртү гыйлемен, пароходчылыктагы тәрҗемәчегә – инглиз телен, пожарникка – ут сүндерү гыйлемен, таможенникка, хәтта партия, профсоюз оешмаларына кадәр шушы өлкәләрдә хәбәрдарлыгыңны күрсәтеп, диңгезчеләр телендә «побегушка» аталган кәгазьгә имза җыярга кирәк иде. Ялдан соң имтихан тапшыруны уйлап чыгаручыларның төп максаты, белемеңне тикшерүдән бигрәк, бу гамәлнең асылында чиновникларга ришвәт алу мөмкинлеге ятканын һәркем аңлый иде. Өстән төшерелгән боерык – закон, телисеңме-юкмы, син аны үтәргә тиешсең.

– На ловца и зверь бежит, – инспекторның шатлыгы йөзенә бәреп чыккан иде.

– Дүрт тәүлек котәргә калды. Корабым Одессага кайта. Приказны бүген язсагыз, дүрт көндә сынауларымны ашыкмыйча гына тапшырып бетерер идем.

Гадәттә, буш кул белән килгәндә, инспектор озак кына сатулаша иде. Бу юлы ул Рахманкуловның корабка кайтару кәгазен үз кулы белән машинкада суктырды да кул куйдырырга бүлек начальнигы кабинетына кереп китте. Озаграк торды инспектор начальник янында.

– Начальник сезне башка корабка җибәрергә кушты,– диде инспектор. – Кораб ике сәгатьтән кузгалачак. Сигезенче причалда тора.

Башта язылган приказны йомарлап чүп савытына ыргыткач, инспектор яңаны әмәлләде. «Рахманкулов Г.Б. фәлән елның төгән ае ...нче көнендә «Академик Крупчатов» теплоходына капитанның икенче ярдәмчесе итеп билгеләнә. Инспектор Фәлән Фәләнович. Кадрлар бүлеге начальнигы Төгән Төгәневич» дип ярты бит кәгазьгә язган арада егетнең баш миендә ун битлек дәфтәргә дә сыя алмаслык уйлар кабынып сүнде: «Чолман» Генуя портына барырга билгеләнгәч, алар корабына бер ришвәтчене утыртып, мине штурманнарның белемен күтәрә торган курска илтеп тыктылар. Корабымда калып, иң арзан барахло сатылган Генуяга бару өчен, мин инспекторга ришвәт бирергә яисә парткомга кагылып, кадрлар бүлегенең гадәтенә кергән ришвәтчелекне фаш итәргә тиеш идем. Инспекторның «кулын майларга» вөҗданым каршы төште, парткомда ришвәтчелекне фаш итү бернинди нәтиҗә бирмәячәген белгәнлектән, алай эшләмәдем. Менә тагын бер гаделсезлек эшләнә. «Крупчатов»ның штурманы, әлбәттә, юкка гына авырып китмәгән. Рейс йә бик авыр булачак, яисә диңгезчеләр телендәгечә «пустой» рейс. Бу юлы да тавыш чыгармаска булды Габдрахман. Түләгән акчалары ресторанга йөрергә дә, әнисенә җибәрергә дә җитеп тора, кадрлар бүлеге белән араны бозу дөрес булмаячак...»

Бүлек начальнигына керергә чират торырга да туры килмәде, хәтта пароходчылыкның бүлекләренә кереп имтихан тапшырып йөрергә дә кирәк булмады. Бу мәшәкатьләрнең барысы да телефон аша эшләнде.

–Тизрәк барып җитәргә тырышыгыз. Кораб кузгалырга тора. Семь футов под килем, – диде инспектор, приказ кәгазен Рахманкуловка тапшырганда. Күңелен ачыттырып кабынып киткән сүгенүне сүндереп:

– Сау булыгыз, – диде Габдрахман һәм кием-салымын, диңгездә йөзгәндә кирәкле әйберләрен алырга туры Дадоновларга юнәлде.

– Әллә приказ кәгазен алырга да өлгердеңме? – диде Юрий Владиславович.

– Алдым шул.

– Дөрес эшләгәнсең. Имтиханнарыңны иркенләп тапшыра алырсың.

– Мине ул мәшәкатьләрдән коткардылар.

– Зур начальство белән уртак тел таптыңмыни?

– Таптым шул. Мине «Академик Крупчатов»ка билгеләделәр.

Дадоновның йөзендә киеренкелек күренде:

– Аның кайларга йөргәнен әйттеләрме соң?

– Әйтмәсәләр дә аңладым. Түләнгән валютага бер кап шырпы да алып булмый торган портларга булса кирәк.

– «Академик Крупчатов», кадерле дустым, Кубага ракеталар ташый. Синең урыныңда мин, парткомга кереп, кадрлар бүлегендәге ришвәтчелекне аңлатыр идем.

– Карга күзен карга чукымый, дигәннәр картлар. «Чолман»да эшли башлаганнан бирле, океан киңлеген күргән юк. Мин инде карышмадым.

– Ара-тирә аларны тешләп алу да зыян итми. Сорарга оныта язганмын, бездән озата барганнан соң, Оксана белән очраша алдыңмы соң?

– Бер генә тапкыр, – диде Габдрахман. – Ул бит Киевтагы ярышка китте. Кайда урнашуларын Женя әйттеме? Оксанага телеграмма сугасым килә. «Саблин»нан радиограмма җибәрергә рөхсәт булмаячак.

– Аларны «Днепр» кунакханәсенә урнаштырганнар. Яз телефоннарын. Бәлки, диңгезгә чыкканчы сөйләшә дә алырсың, – диде Юрий Владиславович.

– «Чолман»ның капитанына әйт. Үз иркемнән утырмадым мин чит корабка. Бәлки, капитан кадрлар бүлеге белән мине үз корабыма кайтару турында сөйләшә алыр?..

Алар кочаклашып саубуллаштылар. Чемоданын күтәреп, Габдрахман ишектән чыгып китте.

Ишегалдында ачык тәрәзәдән Дадоновның башы күренде:

– Бу рейстан соң «Чолман»ыңа кайт инде. Нишләп кая җибәрсәләр, шунда йөрисең? Күрерсең, сине экипажыңнан колакактырачаклар.

– Кабат сау бул, – диде Габдрахман, йөгерә-атлый капкадан чыгып киткәндә һәм Кангун үреннән төшеп, порт капкасына таба атлаганда ачынып уйлап барды. «Чолман» арзанлы товарлар сатыла торган портларга кереп йөри башлаганлыктан, мине матди яктан иң файдасыз рейсларга җибәрә башладылар. Минем бит нәфесем шундый, – яңа илләр, яңа диңгезләр күрәсе килү комсызлыгы бимазалый. «Чолман» океан чиксезлегенә сирәк чыга. Ара-тирә Һиндстанга, Фарсы култыгына, сирәк-мирәк Гибралтар бугазыннан Көнбатыш Европа илләренә барып кайткалый. Миндә исә күчмә бабаларымның каны саклап калган дөнья гизү комсызлыгы, берьюлы дүрт океанны аркылыга-буйга ургылып узу өянәге һаман алга, һаман зәңгәрсу офыклар артына камчылап куып тора.

## Икенче бүлек

### 1

Рахманкулов ашыга иде. Кадрлар бүлегендә кисәттеләр. Кораб ике-өч сәгатьтән диңгезгә чыгачак. Ашыгуына карамастан, Габдрахман турыга – порт капкасы каршындагы Таможня мәйданына төшмичә, Башкарма комитет (патша заманындагы биржа) бинасы янына борылды һәм причалларга сырышкан күп дистә корабларның урман агачлары булып күренгән мачталары, ронгоутлары, аларның паспорты – торбаларга беркетелгән сурәтләре арасыннан «Академик Крупчатов»ны эзләп тапты. Туйганчы карап торырга вакыт тар иде. Кангун үреннән төшкәндә, үзенең буласы торагын, эш урынын, хезмәттәшләрен, ниһаять, язмышын билэп алырга тиешле патша сарае зурлыгындагы тимер көймә-йөзгечне күз алдыннан уздырды.

Рахманкулов эшлисе теплоходка охшаш корабларны Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң СССР белән Америка арасында кабынып киткән ут астыртын әхлаксызлыкка, пычрак мәкергә, дәүләт күләмендәге ялганга төрелгән «салкын сугыш» тудырды. Икенче Бөтендөнья сугышының башында социализм шартларында яшәүче ил бер генә иде. Сугышның азагында Алманиянең яртысы, Көнчыгыш Европа илләре, Кытай, Куба, Кореяның төньягы – болар барысы да социализм төзиләр иде инде. Дөрес, башка бер генә илнең социализмы да СССРныкына охшамаган иде. Һәркемнең бәхеткә омтылуы башкаларныкы кук булмагандай, һәр илнең социализм төзүе дә бер-берсенә охшаш түгел иде. Салкын сугыш кайнарга әверелеп, җир йөзендәге иң гадел, иң изге совет системасы буржуаз системаның көлен күккә очырып, бөтен илләрне яулап алганнан соң, социализм төзү СССР кулына күчәргә тиеш иде. Габдрахман эшлисе кораб та шул соңгы сугышка әзерләнү максатында төзелде.

Рахманкулов порттагы корабларга кереп, аларны карап йөрергә ярата иде. «Кодекс торгового мореплавания» корабны Ватанның бер кыйпылчыгы итеп саный һәм капитанны дәүләт йөкләгән вазифаны тормышка ашыручы итеп карый. Башка илнең кораблары да шушы канунда эш итәләр. Аерма шунда: аларда, бигрәк тә инглиз корабларында «закон – дышло» түгел, ә бөтенләй башка мәгънәдә тормышка ашырыла.

Габдрахман «Академик Крупчатов» янына килеп җитте. Алагаем зур иде бу судно. Йөге бушатылып беткәч, кораб ике, хәтта өч тапкырга биегәя. Аның корылмасын күрер өчен, сиксән-туксан адымга читкәрәк китеп карарга кирәк иде. Вакыт тар булганлыктан, ул турыдан-туры трапка юнәлде. Трапның һәр басмасы, атлаган саен шакылдап, тавыш биреп тора. Ниһаять, Габдрахман төп палубада вахтада торучы матрос янына менеп җитте.

– Гафу итегез, сез кемгә?

Аның ике сүздән торган «гафу итегез» дип эндәшүе корабта тәрбия эше барлыгын аңлатса, матросның җыйнак, чиста киеме һәм үз-үзен тотуы экипажда тиешле тәртипнең дә аксамаганлыгын күрсәтә иде. Рахманкуловның эченә җылы йөгерде. Тәртип куркытып буйсындыруга, казарма мохитендәге боерык йодрыгына көйләнмәгән очракта коллективта гаделлек, дустанә мөнәсәбәт барлыкка килә. Тәртип булган җирдә эшләве, хәтта яшәве дә җиңелрәк.

– Мин икенче штурманга алмашка килдем, – диде Габдрахман. Матрос телефон аша аның коллегасына хәбәр итте.

– Сезне чиф көтә, – матросның өлкән штурманны инглизчә әйтүе тәҗрибәле мариманлыгын күрсәтә иде.

– Минем коллегам ярдамыни?[8]

– Аны больницага салдылар. Сезгә өлкән штурманның каютасын күрсәтимме?

– Рәхмәт. Ул спардекта яшиме?

– Әйе. Капитанның каютасы белән янәшә.

– Ярар, табармын. Кабат рәхмәт.

Матрос коридорга ияреп керде.

– Әнә, лифт... – диде ул, тар гына куш ишеккә күрсәтеп. Лифтка утырып йөрергә көйләнгән корабны аның беренче күрүе иде. Димәк, бу корабта вазифалары корабка тәңгәл – күләмлерәк, катлаулырак булачак, – дип уйларга өлгергәнче, лифт аны өченче катка менгереп тә җиткерде.

Әйе, лифт аркасында «икенче кат»ка әйләнгән биеклек гадәттәге спардек, матрослар телендә шлюпка палубасы иде. Лифттан чыгу белән, корабның борыны – бакка таба барсаң, уртада – капитанның каютасы, уңда – өлкән штурманныкы, сулда өлкән механикныкы булырга тиеш. Җилкәнле кораблар чорында гына каюталар аста, йөзгечнең карынына урнашкан булганнар.

Рахманкулов өлкән штурманның ишеген шакыды.

– Әйе, – дигән карлыккан, калын тавыш ишетелде.

– Икенче штурманга алмашка җибәрделәр, – диде Габдрахман, приказ кәгазен каюта хуҗасына сузып.

– Коллегаңны больницага салдылар, – диде өлкән штурман. – Йөк бушатылып бетте. Конасаментка кул куелган. Кузгалырга ярты сәгать вакыт калды. Моңа кадәр кайсы корабта эшләдегез?

– «Чолман»да.

– «Көмеш» корабта? Италияләргә йөриме?

– Күбрәк шул тирәгә.

– Һаман шулай болан сыеры, «Тарантелло» сурәтләре төшкән келәм, болонья плащ ташыйлармы мариманнар?

– Ташыйлар. Шунлыктан, мин инде ярты ел диярлек үземнең беркетелгән корабыма әләгә алмый йөрим.

Өлкән штурман кабаланып әйтте:

– Бездә шундый гадәт, яңа кеше белән иң башта капитан үзе таныша.

Коридорга чыккач, Габдрахман бертын туктап торды. Өлкән штурманның үзен начальник итеп тотмавы, аның дустанә мөнәсәбәте экипаж әгъзалары арасында җылы мөнәсәбәт яшәвен раслый иде. Дөрес, йөзгәндә кешегә ашыгып бәя бирергә ярамый. Коллективның нинди икәнлеге авырлык килгәндә сынала.

Яңа коллективта еш кына капитан золымы, әләкчелек, гайбәт, бер-береңне күралмау шикелле кабахәтлекләр еш очрап торганлыктанмы, Габдрахманның әйбәт экипажда эшлисе килә иде.

– Рәхим итегез, – диде каюта хуҗасының тавышы.

Капитан эш өстәлендәге ярымфолиант зурлыгындагы кара тышлы калын Лоция китабын укый иде.

– Утырыгыз, – диде ул, өстәлгә янәшә диванга күрсәтеп. – Монда килгәнче нинди корабларда эшләдегез?

– Соңгы вакытта мине алмашка йөртәләр. Ә болай, минем штатный корабым – «Чолман».

– «Чолман» кобатажда йөргәндә, анда эшләмәдегезме?

– Ике елдан артык.

[8] Диңгезчеләр шивәсендә портка киткән кеше «ярда» санала

– Капитан Курбатов беләнме?

– Әйе, Василий Степанович кулы астында.

– Мин дә бит аның шәкерте. Бу турыда диңгезгә чыккач сөйләшербез. Эшкә керешегез. Яңа кешегә кимчелекләр ачыграк күренә. Эшегезне җентекләп тикшереп кабул итегез. Соңыннан минем үземә әйтерсез. Уңышлар телим.

Рахманкулов кабат өлкән штурманга керде.

– Аңлатып торырга вакыт калмады. Егерме минуттан аврал. – Ул ачкыч сузды. – Каютагызныкы. Эш киемегез рундукта. Авралда урыныгыз койрык палубасында. Капитан супер таләпчән. Авралга соңга калып чыга күрмәгез.

**2**

Супер таләпчән... Михаил Михайлович булып йөргән Мейер Моисеевич Зимин – капитан Курбатовның яраткан шәкерте. Василий Степанович үзе инглиз, итальян, гарәп телләрендә сөйләшә белсә, аның шәкерте инглизчәдән тыш француз, испан телләрен дә үзләштергән иде. Яһүдләр гарәпчә аңласалар да, бу телдә сөйләшергә яратмыйлар. Һәм тагын бер сәер нәрсә – Зимин Тәүрәт китабы теле – ивритне дә, халыкча әйткәндә, су кебек эчә иде. Әмма аның бу телне белүе чит кешегә сер иде.

Озак еллар аңларга тырышып караса да, Габдрахман бер нәрсәгә төшенә алмады. Совет чынбарлыгының мөһим бер постулаты – «бишенче пункт» татарларга гына түгел, Израил улларына да кагылса да, аның тәэсире төрлечә иде. Татар кешесе, түрәлеккә күтәрелә башлау белән, үзенең колониаль психологиягә тугрылыклы булуын күрсәтер өчен, җае чыккан саен милләттәшләрен җәберләүдән тайчынмый, шушы юл белән үзенең шовинистларга тугрылыгын күрсәтә. Өскә күтәрелүе дәвам иткән очракта, Чыңгыз хан токымы үз иркеннән исемен үзгәртеп урыслаша. Яһүдләр дә исем-фамилияләрен урыслаштыралар, урыс телен, урыс культурасын урысның үзеннән дә яхшырак үзләштерәләр. Бу очракта татар иң каты урыска әйләнсә, яһүд исә яһүд менталитетында кала. Алар шушы көнгә кадәр «Ветхий завет»тагы «Второзаконие» таләбен үтәп киләләр.

Моңа Рахманкулов әлләни кадәр баш ватканнан соң гына төшенде шикелле. Яһүдлек милләт кенә түгел, аларның милли кодекслары коммунистлар партиясенең уставын хәтерләтә. Нинди генә шартларда да алар «Второзаконие» кушканны тайпылгысыз үтиләр. Ятларга белгертмичә генә, тышкы яктан кайсы милләт арасында яшәсәләр, шуларча яшәп, эчке яктан үзләре булып кала беләләр. Менә шушы хәлне Габдрахман капитан Зиминның фикер йөртү үзенчәлекләрендә дә күзәтәчәк. Бу күзәтүләр аңа, билгеле, файда китермәячәк. Көнкүреш һәр кешедән гавам ихтыяҗын үтәүне, күпчелек үзен ничек тотса, җәмгыять нинди таләпләр куйса, бары тик шуны гына эшләүне сорый. Рахманкулов исә, үзе дә сизмәстән, яшәеш чүплегендә чокына башлый. Күзәтү, күргәннәр турында уйлап, тирә-юньдәге адәм балаларының кыланышларын, тормыштагы чиктән тыш четерекле һәм катлаулы кагыйдәләрнең кайдан килеп чыгуын аңларга тырышу хәзер инде аның канында диярлек яши. Бәлки, аның экипаждагы күмәк ялгызлыкка бирешмәү теләге белән туктаусыз китап укуы, чит илләрдәге тормышны СССРныкы белән чагыштырулары шушы юлга алып кергәндер... Соңгы вакытта ул шуңа төшенеп килә: аның, бу юлдан чыгып, башкалар шикелле көнкүреш гаменә күчәргә тырышуы сәрхушнең аракыны ташларга тырышуы белән бер чамада иде.

Морфлотның корабларында төрле милләт кешеләре эшли иде. Совет иленең зурлыгын, аның башка дәүләтләр арасында гайрәтле, хәлиткеч берәмлек

икәнлеген күрсәтү максаты белән тотылган «Максим Горький» престиж-лайнерының капитаны Марс Солтанович Галимов татар иде. Галимовка кадәр ул корабның капитаны грузин Сергей Ливанович Дондуа булды. Габдрахманның матрос яисә моторист булып эшләгән грузинны очратканы булмады. Грузиннардан чыккан капитаннарның барысы да диярлек күренекле шәхесләрдән иде. Бу турыда баш вата торгач, Рахманкулов шундый фикергә килде: грузиннарда артистлык сыйфаты һәм юмартлык көчле. Капитанлык вазифасын башкара белүдән тыш, капитан булып оста уйный белергә дә кирәк. Менә шул уйнау, үзен капитан итеп күрсәтүдә грузиннар белән башка бер милләт тә ярыша алмый иде.

Язмыш Рахманкуловны Кара диңгез пароходчылыгындагы бердәнбер яһүд капитан белән бер корабка китереп куйды. Мейер Моисеевич Зимин капитан буларак та, шәхес буларак та башкалардан кайсы ягы белән аерыла икән? Катлаулы мәсьәләләрне аңларга еш кына чагыштыру ярдәм итә. Рахманкулов та, һичшиксез, яңа капитанны Василий Степанович Курбатов белән чагыштырачак.

Чемоданындагы әйберләрне яңа каютага урнаштырганда, Рахманкулов шулар турында уйлана иде.

Ниһаять, аврал уйнадылар. Габдрахман корабның койрыгына йөгерде.

**3**

Рахманкулов үзе янында, корабның койрыгында эшләүче матросларга күз салды. «Чолман» белән чагыштырганда, аларның эше авыррак иде. Корабны ярга беркетеп торган швартов баулары «Чолман»ныкыннан күпкә юанрак, палуба киңрәк, бауларны турачкасына уратучы чыгыр зуррак. Матрослар исә нәкъ «Чолман»дагыча, хәтта бераз ябыграк, буй-сынга да бәләкәйрәк иде.

– Отдать кормовые! – Өлкән штурманның тавышы да көчлерәк яңгырады шикелле. Причалдагы ике швартовщик бауның элмәген ярдагы пушкадан көч-хәл белән сөйрәп чыгарып диңгезгә ыргыттылар. Швартов бавын, тиздән әйләнә башланачак винтка эләкмәсен өчен, палубага сөйрәп меңгерергә һәм чыгырга уратып өлгерергә кирәк иде. Рахманкулов бауны сөйрәүче ике матроска кушылды. Ул муенына аскан микрофонга корабның койрыгы ярдан ничә метрга ераклашуы турында мостикка хәбәр биреп торырга тиеш иде. Һәм ул кычкырып әйтә башлады:

– Өч метр... Биш... Сигез метр...

Акватория ягыннан корабның койрыгына таба диңгез буксиры якынлаша башлады. Ул әкрен генә якыная. Мостиктан команда яңгырады:

– Подать буксир! – Шкертик дип аталган, ташлана торган нечкә бауны өлкән матрос диңгез буксирына томырды. Бауны эләктереп алу белән, тиз генә аңа канатны беркетеп өлгерделәр. Икенче диңгез буксиры, зур кортны оясына сөйрәгән кырмыска шикелле, акваториягә сөйри иде.

– Самый малый, вперёд!

Теләр-теләмәс кенә винт әйләнә башлады. Корабка җан керде. Акваториянең уртасына җиткәч, «Академик Крупчатов»ны Воронцов маягына каратып борып куйдылар да бауларны ычкындырып җибәрделәр. Баулар винтка уралмасын өчен, корабның машинасын туктаттылар. Суда яткан буксир бавын тизрәк палубага сөйрәп менгерергә кирәк иде. Һәр секунд санаулы, су агымы корабны әкрен генә дулкынваткычка таба илтә иде. Ниһаять, су саркытып торган буксир бавы, судан чыгып, палубага менеп ятты.

«Аллага шөкер!» Рахманкулов иркенләп тын алды. Яңа корабта беренче аврал – һәр очракта хәлиткеч җаваплы мизгел. Синең һәр хәрәкәтеңне җентекләп күзәтәләр, бәяләп торалар. Сынатмады шикелле. Эшне шушы ябык, алҗыган матрослар, хәрәкәтләреннән күренеп торган авыл малайлары башкарып чыкты. Бирешмәделәр. Авыл кешеләре бер-берсен җиңел аңлый.

– Рәхмәт, егетләр! – диде ул матросларга. – Мин әле бу корабка күнекмәгән. Кабат рәхмәт сезгә.

Диңгезчелек күп сүзлелекне өнәми. Әйтмәскә дә була иде. Өлкән матрос арада иң бәләкәе, ябыгы, гәүдәсен артка ташлый төшеп җавап бирде:

– Спасибо, сэконд[9] – в рюмку не нальёшь...

Әйткән сүзнең мәгънәсен тырышып эшләгәннәре өчен матрослар Рахманкуловтан аракы көтәләр дип аңларга ярамый иде. Бу инде, үзенә күрә, «без дә синнән канәгать, без сиңа ышанабыз» дигәнне аңлата.

Вахтага чыгарга ике сәгатьтән артык вакыт бар. Ял итеп аласы килә. Эшкә керешкәнче, аңа эш урыны белән яхшырак танышырга кирәк иде. Рубка иркен. Штурвал гадәттәге кызыл агачтан эшләнгән сигез тоткалы зур көпчәк түгел. Бәләкәй генә, акка буялган тимер тәгәрмәч. Ике радиолокатор[10], Эхолот[11], Лаг[12], Радиопеленгатор[13]. Американнар ясаган, «Чолман»да булмаган яңа «Дека» приборы. Халык телендә «капитан күперчеге» дип аталган, уң һәм сул як палубаларга куелган гирокомпас ноктаузлары, «Чолман»ныкы белән чагыштырганда, бер-берсеннән ике тапкыр ераграк урнашканнар. Диңгездә каршы килүче корабларга юл биргәндә, портка кергән чакларда, бигрәк тә швартовка вакытында бу гигант көймәнең зурлыгын һәрвакыт истә тотарга туры киләчәк. «Зур корабка – зур киңлек», ди урыс әйтеме. Зурлык психологиясе моның белән генә чикләнми шул. Гигант корабларда эшләгән диңгезчеләр үзләрен бәләкәй пароходларда эшләүчеләрдән өстенрәк тотарга тырышалар. Шул ук хәл дәүләтләргә һәм аның гражданнарына да кагыла. Җир йөзендәге иң зур дәүләтләрнең берсе саналган Советлар Союзында яшәүчеләр үзләрен, әйтик, шведлардан яисә финнардан зуррак, көчлерәк тоеп горурланырлар иде, әгәр алардан ярлырак, мескенрәк булмасалар... Көнкүреш шартларында урыстан бәләкәйрәк тоелган шул шведның машинасы «Вольво», фатиры дистәләгән бүлмәдән тора, аның ялы Канар утрауларында, Франциянең зәңгәрсу ярларына урнашкан курортларда уза. Шушы хәл ачыклангач, урысның күңелендә әрнүле хөсетлек, эчендә сәбәпсез, аңлатып булмаслык авыр нәфрәт туа. «Полтава кырында безнең тарафтан кыйналган швед шулай майда йөзгәндә, мин, бөек урыс кешесе – Казан, Кырым ханнарын, шведларны җиңгән, Наполеонның арт сабагын укыткан, Гитлерның көлен күккә очырган империянең тулы хокуклы гражданы хокуксыз, ярым хәерчелектә яшим – кайда монда гаделлек дигән нәрсә?!.» Әйе, чит илләргә йөзүче моны аңлый, колхозчы, пролетариат, зыялыларның күпчелеге үзенең коллар дәрәҗәсендә яшәвен белми дә бит әле!

Сәгать унбер тулып киткән иде. Төгәл уникедә аның вахтада торуы башланачак. Бүген яңа йортка күченүдән дә җаваплырак. Рахманкулов ашыгып кают-компаниягә йөгерде.

---

[9] Сэконд (ингл.) – икенче штурман.
[10] Радиолокатор – төннәрен томан, яңгыр пәрдәсе аша тирә-юньне күрсәтә торган җайланма.
[11] Эхолот – су тирәнлеген үлчәгеч.
[12] Лаг – кораб тизлеген һәм үтелгән юлны үлчи торган җайланма.
[13] Радиопеленгатор – корабның барган урынын табу өчен куела.

## 4

Ул кәбестә шулпасыннан тыш, бер кечкенә кисәк ит өстенә куе соус салган солы боткасы алды. Диңгезче яхшы ашарга тиеш. Тиеш... Ә бит рацион тәүлегенә 83 тиен. «Социализм – учёт», – дигән Ленин бабай. «Экономика должна быть экономной», – дип өстәде Леонид Ильич Брежнев. Ашап компотка тотынганда, телефон шалтырады. Комсоставны ашатучы хатын буфетыннан:

– Сезне капитан сорый, – дип, трубканы Рахманкуловка сузды.

– Ашап бетердегезме?

– Компот эчеп азапланам.

– Мин сезне каютамда көтәм.

Габдрахман, каютасына кереп, аяк киемен алыштырды, өстенә җиңел куртка киде.

– Мөмкинме?

– Рәхим итегез.

Зимин киңәшмәләр үткәргәндә кулланыла торган зур өстәле янына урнашкан иде. Габдрахман сәгатенә карады:

– Утырыгыз.

– Унбиш минуттан минем вахтам башлана.

– Мин Кисляковны кисәттем. Сез каргопланны[14] күрдегезме?

– Юк, күрмәдем. Мин әле төяләчәк йөкне дә, без барачак портны да белмим.

– Без Гавана портына корал һәм гаскәр илтәбез.

– Николаевтанмы?

– Николаев янындагы Балабановка пунктында төйибез. Моңа кадәр корал ташыганыгыз бар идеме?

– Заманында Мисырга, берничә тапкыр Вьетнамга корал илткәнем булды.

– Димәк, кагыйдәләрне беләсез?

– Ул чакта мин өченче штурман идем. Корал төяү кагыйдәләрен яхшы белмим.

– Монда күрсәтелгән, вахтадан соң җентекләп тикшереп чыгыгыз. Каргопланны без чиф белән икәү төзедек.

Капитан корабның контуры сызылган кәгазьне икенче штурманга сузды.

– Икенче һәм дүртенче трюмнар иң зурлары. Аларның икесенә дә – ракеталар төяләчәк. Беренче һәм алтынчы трюмнарга – снарядлар. Өченче һәм бишенче трюмнарга – танклар, БТРлар. Шушы трюмнарның твиндекларына[15] гаскәрләр урнашачак.

– Чыдарлармы соң? Трюм капкачларын япкач, анда бик тынчу була бит.

– Вентиляторлар даими эшләп торачак. Твиндекка төяп гаскәр ташуның иң катлаулы ягы – шторм вакытында аларның ашаган ашлары авызларыннан түгелә башлый. Үзләре башларын да күтәрә алмыйча аунап яталар. Чистарту матрослар җилкәсенә төшә. Алар бу эштән үлеп җирәнәләр. Тагын бер катлаулы мәсьәлә: океанга чыкканчы, солдатларга көндез палубага чыгып йөрергә рөхсәт ителми. Һәр трюмга дүрт-биш чиләк-параша куярга кирәк. Матрос халкы параша түгеп йөрүне үлем газабына саный. Алдан белеп торыгыз – эшегез җиңел булмаячак.

Габдрахман сәгатенә карады. Бер туларга унҗиде минут калган иде. Капитан аның ашыгуын сизеп алды.

– Ярый, вахтагызны кабул итеп алыгыз. Өч сәгатьтән Буг елгасына керәбез. Безнең кораб аның уртасында гына йөзә ала. Сак булыгыз! Уңыш телим.

[14] Каргоплан *(ингл.)* – йөкне кайсы трюмга, нинди тәртиптә урнаштыру планы.
[15] Твиндек – трюмның өске каты.

– Гафу ит, – диде Рахманкулов өченче штурман Кисляковка. – Капитан тоткарлады. Мин үзем соңаруны яратмыйм.

Алар штурманнар рубкасына керде. Рахманкулов картага күз салды. Курс сызылган. Корабның барган урыны билгеләнгән. Судно журналына вахтаны кабул итеп алуы турында язып куйгач, ул ходовая рубкага чыкты.

Як-якта куак каплаган тәбәнәк ярлар. Ара-тирә күренер-күренмәс яткан вак утраулар узып китеп артта калалар. Заманында башта Алтын Урданыкы, соңрак Кырым ханлыгыныкы булган печәнле болыннар офык артларына кереп югалалар. Хәзер бу җирләр Украинаныкы. Бармы соң ул чын хокуклы булып саналган Украина? Карпат тавы итәгенә урнашкан өлкәләрдә генә хохоллар туган телләрендә сәйләшә. Донбасс тирәсе, Одесса, Днепропетровск, Азов, Кара диңгез буендагы җирләрдә милли гореф-гадәт юкка чыгып килә. Гади халыкта тамак гаме, өс-баш бөтенлеге, яшәргә ярарлык торак әмәлләү хәсрәте. Гади халыкны гасырлар буена мохтаҗлыкта тоту хакимиятнең өстенлеге өчен кирәк. Нигә дип мин бу турыда баш вата башладым соң әле? Миңа яңа корабны өйрәнергә кирәк. Аның барлык механизмнарын, приборларын, мөмкинлекләрен. Йөк төягәндә, һәр тартманы, һәр ракетаны шторм вакытында урыныннан кузгалмаслык итеп трюмга беркетергә кирәк. Без бит Кубага – Азатлык иленә үлем төяп китәбез...

**5**

Днепр белән Буг елгалары диңгезгә килеп җитәр алдыннан үзара кушылалар, Днепр – Буг лиманы дип аталган киң, иркен сайлык барлыкка килә. Елга суының тозлы диңгез суы белән кушылган урыны бу. Балык үрчи торган җир...

Вахтасын өлкән штурманга тапшырганда, кораб Николаев портына якынлаша иде инде. Бәләкәй генә катер-лоцбот корабка сырышты. Шторм-трап төшерделәр. Лоцманны Рахманкулов каршы алды. Бурят-монголга тартым җәлпәк битле кешенең өстендә таушалган соры костюм, башында күкшел постау кепка.

Рубкага капитан килеп керде.

– Малый вперёд! – диде лоцман. Капитан боерыкны кабатлады.

– Курс утыз дүрт градус.

Боерык янә капитан аша рулевойга җиткерелде. Лоцман биргән команданың кырыслыгы, тавыштагы кискенлек лоцманның хәрбиләрдән икәнлеген күрсәтә иде.

Николаев белән Балабановка арасы ике сәгатьлек юл иде. Шул йөз егерме минут эчендә икенче штурманга ял итеп, бераз хәл җыю мөмкинлеге бар. Рахманкулов рубкада калды. Яңа корабтагы яңа шартлар, моңа кадәр аңа таныш булмаган кешеләр белән эш итү Габдрахманны нык алҗыткан иде. Каютасына төшеп, диванына чишенмичә генә ятса да, авралга кадәр йокыга китә алмыйча, бер сәгать чамасы кыбырсынып ятачак. Йоклап китү белән, аврал уйнаячаклар. Елганың сул як ярларын каплаган әрәмәлек артыннан кояш чыгып килә иде. Шушы күренеш, егетнең эчен ачыттырып, аның туган Караярын, Ык буйларын, балачак куанычларын исенә төшерде. Әнә, әрәмәлек артында иген басулары башлана. Арыш серкәгә утырган чак. Нәкъ шушы көннәрдә Караярда печәнгә төшәләр. Игенчелектән, мал асраудан аерылмыйча, нарат бүрәнәләрдән, биек түшәмле, капкачлары зәңгәргә буялган, тупсаларында яран гөлләр чәчәк атып утырган алты тәрәзәле үз йортында берсеннән-берсе матур балалар үстерәсе урынга, Бәкер малае океаннар артына пароходка төяп

үлем ташый... Менә нинди дәрәҗәләргә күтәрелә алды ул – армиягә китәр алдыннан Караяр авылының беренче гармунчысы! Күр әнә – океаннарда кораб йөртергә өйрәнгән! Берничә сәгатьтән ул төйи башлаячак ракеталар җир йөзендәге иң бай, иң тәкәббер Америка дәүләтенең көлен күккә очыра алачак. Горурлыкмы бу, әллә җинаятьме? Хәтта Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» исемле әсәрен укыган кешеләр дә җинаятьнең нәрсә икәнлеген аңлап бетерүгә ирешә алмый. Кеше үтерү иң зур җинаять саналса да, хакимият боерыгын үтәп үтерү җуелмас дәрәҗәдәге изгелек санала.

Елганың сул як ярлары ягыннан әкрен генә чыгып килгән кояш әрәмәлек өстен кызгылт нурларга күмеп ташлады. Иртә таңның тоник нурлары яр кырыеннан еракларга сузылган соргылт койманы яктыртты. Берничә гектарга җәелеп, әрәмәлекне биек бетон койма белән әйләндереп алганнар. Якынрак килгәч, койма өстенә тотылган чәнечкеле тимерчыбык һәм югары вольтлы электр тогы җибәрелгән тимерчыбык күзгә ташлана. Койма буендагы елга ярына «Академик Крупчатов» озынлыгындагы ике генә кораб сыярлык причал корып куйганнар.

Кораб причал яныннан узып борыла башлады. Капитан өлкән штурманга аврал игълан итәргә боерык бирде. Ярты сәгатьтән Рахманкуловның яңа корабы Балабановка портының причалына бәйләп, беркетеп куелган иде инде.

– Экипаж әгъзаларына кызыл почмакка җыелырга. Кабатлыйм, экипаж әгъзаларына... – өлкән штурманның боерыгы мачталарга беркетелгән динамиклардан еракларга таралды да кайтаваз булып корабка әйләнеп кайтты.

Яңа коллективта эшли башлар алдыннан мондагы тәртип саклауны, шәхесара, капитанга, гомумән, өлкән комсоставка карата булган мөнәсәбәтләр үзенчәлегенә тизрәк төшенергә кирәк иде.

Унҗиденче елдагы түнтәрелештән соң, социализм төзү байрагы астында колбиләүдән дә каһәрле тоталитар идарә итү башлангач, Советлар Союзына алыштырылган Рәсәй империясендә яшәүчеләрнең шәхеслек тойгылары тамырын корыту башланды. Чит илләрдәге тормыш-көнкүреш белән очрашканда, Советлар Союзындагы крепостнойлар көнкүреше аеруча күзгә ташлана иде.

Экипажны кызыл почмакка җыялар. Нәрсә әйтәчәкләрен Рахманкулов алдан белеп тора иде. Бдительность! Бу сүзне татарча «уяу булу» дип тәрҗемә итсәң – мәгънәсе үзгәрәчәк. Бдительность. Тирә-юньне дошман каплаган. Аларның төп максаты – синнән дәүләтнең чит илләргә үлем ташыганын әйттереп, сине шпион итү. Чит илләргә йөрүче корабларда эшләвеңне дәвам иттерәсең килә икән – син беркемгә берни белгертмисең, күрмисең, ишетмисең, аңламыйсың.

Экипаж кызыл почмакка шактый тиз җыелды. Димәк, корабта тәртип үз урынында.

– Сүз «күршеләр» вәкиленә бирелә. Дикъкать белән тыңлагыз, – диде капитан Зимин. – Рәхим итегез.

– Шушы мизгелдән башлап сезгә радиотелефон ярдәмендә гаиләгез белән сөйләшергә рөхсәт ителми. Кая баруыгызны, корабка нинди йөк төялгәнен сезнең берегез дә белми, беркемгә сөйләми. Хәтерләргә дә тиеш түгелсез. Серне тотмавыгыз һәр очракта безгә мәгълүм булачак, һәм сезне җавапка тарттырачаклар. Аңлашылдымы?

– Аңлашылды, – диде ишек төбендә басып торучы тәбәнәк, чиктән тыш ябык бер бәндә.

– Башка сүзем юк. Беренче тапкыр ГИУ[16] йөген ташуда катнашучылар монда калыгыз.

«Виза ачылганнан соң», кадрлар бүлегендә сер саклау антын алалар бит инде, – дип уйлады Габдрахман. – Һәр яңа рейс алдыннан да кабат ант иттерү кирәк микәнни соң?»

– Минем исемем Геннадий, – диде вәкил, Рахманкуловның кулын кысып. – Каргопланны төзедегезме?

– Әйе, төзедек.

– Бер нөсхәсен миңа бирегез.

– Нөсхәсе юк әле. Әзерләп бирермен.

– Трюмнарны карап чыгасызмы?

– Карап тормыйм. Мин таныш мондый кораблар белән. Йөкне берьюлы икенче һәм дүртенче трюмнарга төйи башлыйбыз.

– Аларны тизрәк ачыгыз.

– Ачарбыз.Төяләсе йөкне күрәсем килә. Койма эченә кереп карыйбызмы?

– Сезгә анда керергә рөхсәт юк. Анда керер өчен өстәмә рөхсәт кирәк.

– Хәзер мин трюм капкачларын ачтырам. Шуннан соң каргопланның нөсхәсен әзерләп бирермен.

Ашык-пошык кына иртәнге чәйне эчеп чыккач, Габдрахман боцман белән икенче һәм дүртенче трюмнарның капкачларын ачарга тотынды.

**6**

Борынгы Финикия диңгезчеләре. Карфаген иле. Ренессанс чорындагы Венециянең диңгезчелек ярдәмендә иксез-чиксез байлык туплавы, португалларның, испаннарның, соңрак инглизләрнең диңгезчелек ярдәмендә колонияләре белән сәүдә итеп байлык туплаулары билгеле. Икенче Бөтендөнья сугышыннан соң Совет иле Англия һәм Америка белән мәйдан тотарлык меңләгән зур кораблардан торган сәүдә флоты төзеде. Бу илнең кораблары җир шарын әйләнеп, җәһәннәм почмакларын айкап йөриләр. Аларның нәрсә ташыганын, нинди максат белән дөнья гизүләрен белмәгән бәндә Советлар Союзы исеме эченә яшеренгән урыс иле череп байый башлар, дип ялгышачак.

Койма эченә яшеренгән йөкнең кораб янына куелган порт краннары астына килеп туктауларын көткән арада Габдрахман өске палубага менде дә койма эчендә өелеп яткан, чит илләргә озатасы йөкләрне бинокль аша карый башлады. Дистәләгән гектарга җәелгән җирне уратып алган койманың әйләнәсенә күзәтү вышкасы куелган. Шуларның һәммәсендә муенына автомат аскан солдат басып тора. Бинокльдән койма эчендәге хәзинәләргә карап торучыны күреп алуга, солдат каравыл начальнигына хәбәр бирәчәк. Рахманкулов палубадан чыгып торган вентиляция трубасы артына барып посты.

Яшел брезент астына яшеренгән гигант сигараларның Җир шарының кан коеласы төбәгенә барырга чират көтеп ятучы ракеталар икәнлеген тою катлаулы түгел иде. Алар хәзер «Академик Крупчатов»ның икенче һәм дүртенче трюмнарына кереп ятып, «Азатлык утравы» – Кубага юл тотачаклар. Соңгы тапкыр Венециядә торганда, Рахманкуловның танышы шипчандлер[17] Лючано «Карьерре делла сера» газетасын калдырып киткән иде. Шул газетага Никита Хрушёвның Куба утравына ракеталар урнаштыруын һәм «Американың шәрә

[16] ГИУ – главное инженерное управление – чит илләр сәүдәсе министрлыгында корал ташу белән идарә итүче оешма.
[17] Шипчандлер *(ингл.)* – корабка азык-төлек китерүче.

арты астына керпе тыгып куярга кирәк», – дип әйтүен язганнар иде. Советлар Союзының җитәкчеләре, югыйсә, сугышка каршы көрәшү, тынычлык турында туктаусыз тукып торалар. Берничә минуттан эченә «тынычлык» тутырылган ракета кораб карынына кереп ятачак та Американың аяк очындагы утрауга казылган базга посачак...

Ракеталар урнашкан җиргә янәшә, брезент астында «тынычлык саклар» өчен ясалган, йөк машинасы чамасындагы яңа төр «көчтәнәчләр» урнашкан. Алар күп, ким дигәндә йөз илле, ике йөз данә. Маңгайларыннан алга таба сузылган көпшәләре тырпаеп торудан Габдрахман аларның танклар, самоходкалар, БТРлар икәнлеген чамалады. Койма эчендәге тау-тау булып өелгән тартмаларны, канатлары беркетелмәгән очкычларны, торпеда снарядларын, дүртәрләп бер тартмага тутырылган миномётларны берәмләп карап чыгарга берничә сәгать вакыт кирәк булыр иде. Палубадан төшкәндә, Габдрахманның эче ачытып куйды: «Бу коралларны ясау, һичшиксез, хезмәт ияләре арка тирләрен түгеп тапкан миллиардларга төшкән. Шушы байлыкны пыран-заран китерүче түрәләр, чиновниклар үзләре дә хезмәт ияләренең җилкәсен кимереп яшиләр. Күп миллионлы хәрбиләр дә эшче-крестьяннар җилкәсендә. Әмене Габдрахманның авылдашлары... Аларның урлаша белмәгәннәре тулысынча каторжаннар михнәтендә шушы коралларны ясату өчен тырыша».

Пароходчылыкта эшли башлаганнан бирле, Рахманкулов Төньяк Кореяга, Вьетнамга, Мисырга, Эфиопиягә корал илтте. Үзенең дусларының Конгога, Никарагуага, Сомалига корал ташулары турында сөйләгәннәре бар иде. Дөрес, Америка, Англия, Франция шикелле дәүләтләр дә үзара сугышкан илләргә корал саталар. Аерма шунда: капиталистик илләр коралларын үзләре ише байларга сата, Советлар Союзы исә – социализм төзергә вәгъдә биргән ярлы-ябагага. Нәтиҗәдә, корал сатып, Америка байлык туплый, Габдрахман иленең дәүләте исә төп башына утырып кала бирә.

Өске палубадан причалга төшеп, корабның су эчендәге өлешенең күләмен блокнотына язганда, капкадан инде хәрби тягач ракетаның берсен салмак кына сөйрәп чыгара башлаган иде.

## 7

Ике тәүлек эчендә «Академик Крупчатов»ның унсигез мең тонна сыешлы комсыз карынында баллистик ракеталардан тыш дүрт дистә танк, алты дистәгә якын БТР, эченә миномёт, Калашников автоматы тутырылган такта тартмалар кереп утырган иде. Аларның иң авыры – патрон тартмалары. Коралларның иң кабахәте – мина. Автоматтан аталар, качып-посып аталар... Танк туп ату белән генә чикләнмичә, очраган солдатларны таптап, окоп җимереп бара. Танкның куркынычы сугыш кыры белән генә чикләнми. Корабка төягәндә, аны палубага чылбырлар белән тарттырып беркетеп куялар. Каты шторм вакытында танк, рессорларына иңә төшеп, чылбырыннан ычкына. Диңгездә йөзгәндә, дөньяда бәеннән ычкынган танктан да куркыныч нәрсә бармы икән?..

Корабка корал төяү өч тәүлеккә сузылды. Шул өч тәүлек эчендә Рахманкулов адәм затының шушы көнгә кадәр кеше үтерүдән арынырга теләмәвенә гаҗәпләнеп баш ватты.

Адәм балаларының бер-берсенә кул салулары турында мәгълүмат Коръән Шәрифтә дә бар. Атабыз Адәмнең олы улы Кабил энесе Һабилне үтерә. Сәбәбе – хөсетлек. Кабил иген игә, энесе мал асрый. Ул чорда әле кеше, табигатьне таптап-пычратып, экологик кризис ясарга өлгермәгән. Көнкүреш иркенлектә.

Һабилнең малы үрчи, җир эшкәртү авыр, уңыш чамалы. Шушы риваять исенә төшкәндә, Габдрахман: «Нигә Кабил игенчелекне ташлап, мал асрауга күчте икән?» дип баш вата иде. Океаннар артындагы Америка белән сугышып кан коюга әзерләнү Коръән риваятендәге кан коюдан күпкә катлаулырак иде.

Ниһаять, йөк төялеп бетте. Кузгалу вакыты җитте. Хәрбиләрдән диңгезгә чыгарга рөхсәт юк иде. Рөхсәт урынына боерык килде. Корабка ракетчиклар батальонын төяргә. Бу эшне бары тик төнге караңгылыкта башкарырга. Порттан да караңгы төшкәч чыгарга, Босфор, Дарданел, Гибралтар бугазларыннан да бары тик караңгыда үтәргә. Солдатларга палубага чыгып йөрү бары тик төнге караңгылык вакытында гына ярый.

Төнге караңгылык. Угрылар. Кеше үтерүче бандитлар. Төнге «күбәләкләр». Иренә хыянәт итүче хатыннар. Хатынына хыянәт итүче ирләр... Җинаятьләрне яшерү өчен, җиргә караңгылык иңә.

***

Параша. Урыс әдәбиятында бу сүз еш очрый. Бигрәк тә Сталин вафатыннан соң, әдәбиятка ГУЛАГ тоткыннары, Лубянка, Черек күл базлары темасы бәреп кергәннән соң, бу сүз китапта еш очрый башлады. Ә парашаның ни икәнен Габдрахман «Академик Крупчатов»та күрә алды. Солдатларның унысына бер параша тиеш иде. Өченче һәм бишенче трюмнарның диңгезчеләр телендә «твиндек» дип аталган өске катының палубасына брезент җәеп, солдатларның баш асларына салырга эченә салат тутырылган капчыклар әзерләгәннән соң, йөк машинасына төяп китергән парашаларны твиндекка төшерә башладылар.

Нәрсәсе көлке тоелгандыр инде Рәсәй тарихында мактаулы урын тапкан кәҗүннәй тәрәт савытының. «Сез ничек уйлыйсыз, Бәкерич, солдатлар үзләре белән алып китмәсләр бит бу затлы нәрсәне?» – диде Рахманкулов белән бер вахтада торучы матрос Алик Карташов.

– Америка диңгезчеләренә сатарга җыенмыйсыңдыр бит?

– Мин бит коммуналкада яшим. Дүрт гаиләгә бер сортир. Мин аны коридорның баскычы астына урнаштырып, ишек ясап бикләп куяр идем. Нинди фатирда торасың, дип сорасалар, бәдрәфе аерым, дип мактаныр идем.

Габдрахманга үзенең вахтасына беркетелгән Алик Карташов белән дүрт кенә сәгать бергә торырга туры килде. Шул дүрт сәгать эчендә дә матрос аңа әлләни кадәр мәзәк сөйләргә өлгерде.

Хәрбиләрнең поход кухняларын урнаштыру мәсьәләсен дә ничектер хәл итәргә кирәк иде. Палубага куйсаң, шторм вакытында дулкын юып төшерү куркынычы бар. Аннан да куркынычрагы – Босфор аша, Гибралтар бугазыннан үткәндә, бу – корабка гаскәр төялгәнен ачыктан-ачык фаш итү булыр иде. Әгәр Советлар Союзының Америка ярлары буенда гаскәр туплавын белеп алсалар, бу инде халыкара гауга дигән сүз.

Поход кухнясын су коена торган бассейнга урнаштырдылар. Бассейн өстенә брезент түбә – тент әмәлләргә туры килде. Кораб Кубага илтәсе гаскәрне кабул итәргә әзер иде. Солдатларны корабка якты вакытта төямиләр. Караңгы төшкәнне көтәргә туры килде.

Төн уртасында, Габдрахман вахтада торырга чыккач төйи башладылар ракетчиклар батальонын.

Гаскәрилек белән угрылык арасында охшашлыклар зур. Сугышка әзерләнү дә, урлашырга җыену да яшерен, кешегә сиздермичә башкарыла. Дөрес, караклар кеше үтерүне максат итеп куймыйлар, җинаятьләрен ачарлык шаһитка

юлыкканда, яисә сакчылар каршылык күрсәтсә генә корал кулланалар. Кеше үтерү – хәрбиләрнең төп вазифасы. Үтерү уңышлы булсын өчен, пехотаны, артиллерияне төз атарга, очучыларны бомбаны нәкъ гаскәр тупланган җиргә ташларга өйрәтәләр.

Угрылар да, хәрбиләр дә һөнәрләренең гөнаһсыз икәнлегенә ышанып эш итәләр. Чыннан да, җинаятьчегә аның гөнаһы, гамәле җинаять булып тоелмый. Хәрбинең һөнәре – вату, җимерү, кеше үтерү. Аны шушы эшкә махсус өйрәтәләр һәм аңа кеше үтерү гөнаһ саналмый башлый. Шушы хакыйкатьне Рахманкуловка үз тәҗрибәсе раслап тора иде. Ул унбер ел гомерен кырып-себереп хәрбилеккә бирде. Армия хезмәтендә буйсынырга, бомба ташларга өйрәнде. Бу чорда аңа командир уставка таянып кемне генә үтерергә боерса да, уйлап та тормыйча үтерә иде. Нишләп ул чакта аның баш мие томаланган булган? Кеше үтерү, кайсы яктан гына карама, гөнаһ кына да, җинаять кенә дә түгел. Үтереш – адәм баласы исеменнән ваз кичеп, ерткыч җанварга әверелү. Адәм баласының гомерен юкка чыгару Газраилгә генә бирелгән. Хәрби устав синең адәм баласы булуыңны юкка чыгарып, командирның боерыгын Калашников автоматының крючогына тоташтыра да үтерү җаваплылыгыннан котылуыңны тоясың. Командир да җавап тотмый биргән боерыгы өчен. Устав аны да җан алу җинаятеннән коткара. Ә кем соң җавап бирә? Хакимият? Ул да җавап бирми. Үлемгә югарыда утыручыларның кулы тимәде бит. Сизми ул җир йөзендәге иң әшәке, иң каһәрле җинаятьнең эшкә ашырылуын. Хакимият сугыш игълан итте, хәрбилек механизмын хәрәкәткә китерде. Аның кулында кан таплары юк. Хакимиятнең вөҗданы да чиста. Корал ташыр өчен ясалган зур корабның ике твиндегына гаскәр төяргә урын әзерләп йөргәндә, шушы тынгысыз, вөҗданны сыкрандыра торган уйлар Рахманкуловның йөрәген талкып торды.

Кояш офык артына кереп югалгач, елга буе әрәмәлекләре бертын шәфәкъ кызыллыгына буялып тордылар да, җир өстен караңгылык каплады. Төн пәрдәсен ертып, кораб янына өсләренә брезент япкан йөк машиналары бер-бер артлы килеп туктый башлады.

– Гаскәр килә.... – диде Габдрахман капитанга телефон аша.

– Юл күрсәтергә кешеләр әзерләдеңме?

– Боцман белән өлкән матрос җитәкчелегендә өч матрос. Өлкән механик электрик белән токарьне билгеләде.

– Кораб эчендә адашып йөри күрмәсеннәр. Туры твиндекларга озата торыгыз.

Машинадан төшкән бертөркем солдат трапка якынлашты. Солдатларның өсләрендә гап-гади тракторчылар кия торган соргылт-кара чүпрәк комбинезоннар иде. Юк, погоннарны кием астына гына яшереп калып булмый. Көндәлек тормышта җәмгыять тоташ бертөрле киенеп йөримени? Унсигез-егерме яшьлек ир җенесеннән генә торган төркем? Соң бит адәм балалары сугышсыз, сугышка әзерләнмичә яшәгән җирдә җәмгыять карт һәм яшь ирләрдән, бала-чагадан, карт-корыдан, таза, матурлардан тора. Ямьсезләрне, гарип-горабаны да яшереп калып булмый. Үзара боерык богавы белән беркетелгән, җәмгыятьтән аерылган яшь егетләр көтүен күрсәгез, баш ватып тормагыз. Йә башланачак сугыш бу, яисә сугышка әзерләнү бу...

Мескен солдатларга, билгеле, кайларга барачакларын, юлда нинди газаплар кичерәчәкләрен аңлатмаганнар. Корабка керүче солдатлар сугымга куып керткән сарыкларны хәтерләтә иде. Аларны да алдан барган кәҗә тәкәсенә

ияртеп кертәләр бит. Боцман белән өлкән матрос шул тәкәләрне хәтерләтә. Батальонның офицерлары да комбинезонга төренгән солдатлар арасында икәне мәгълүм булды. Өч өлкән офицер – батальон командиры полковникка, аның штабы начальнигына, замполитка каюта табарга кирәк иде. Командирның берүзен, замполит белән штаб начальнигын корабтагы пассажир каюталарына урнаштырдылар.

Кораб урыныннан кузгалганда, Рахманкуловның вахтага чыгар вакыты җиткән иде инде.

**8**

Киевка ярышка барасы спортчыларны өлкә комитетына чакырганнар иде. Киңәш-нәсихәтне озакка сузмыйча гына, алты дистә кешене банкет залына җыйдылар. Үзара берләштереп, буйдан-буйга сузылган өстәлләр тезмәсендә шәраб шешәләре, кояш нурларын чагылдырып торган бәллүр графиннар һәм исләре авыз суын китереп торган затлы ашамлыклар. Чакыру партия җитәкчеләре өстендә булса да, оештыруны комсомол үз өстенә алган иде. Комсомол турындагы: «Ул партиядән калышмыйча эчә, пионерлар чамасы эшли ала», – дигән анекдот биредә тулысынча акланган иде. Һәр урындык каршында ярышка баручының исеме язылган күрсәткеч белән генә канәгатьләнмичә, ишек төбендә спортчыларны урыннарына утыртып йөрергә бертөркем активистлар да күтәп тора иде.

Урынына утыру белән, тәмлерәк закусканы авызына озатучыларны да күреп алды Оксана, әмма күпчелек әле түрәләрне көтә иде. Ни гаҗәп, обком беренче секретаренең урыны Яременко янында булып чыкты. Очраклы хәл идеме икән бу янәшәлек?

Галстук белән кыршауланган күлмәк якасы өстеннән бүселеп чыккан кыска юан муенлы персек[18] килеп утырыр алдыннан, көрәк чаклы кулын кызның аркасына тигереп алгач, Оксана аңлады. Аны Одесса өлкәсенең хуҗасы янына утырту очраклы хәл түгел иде.

Беренче тостны хуҗа үзе әйтте. Тост сүзенең татарчага тәрҗемәсе юк, чөнки татарларда өстәл янына җыелып хәмер эчү булмаган. Дөрес, кымыз эчү булган. Тик бу эчемлекне тост әйтмичә генә эчәләр.

– Мин сезнең җиңеп кайтуыгызга ышанам. Җиңү хөрмәтенә!

Рәсәй дәүләте Алтын Урда югалткан җирләрне, урысча әйткәндә, «җыйганда» («собрание земель»), бер-бер артлы диярлек җиңеп торган.

...Оксананың бокалына шәрабны Зур хуҗа үзе агызды. Аның бит әле шунысы да бар: бокал күтәреп әйткән нотык белән сине аяктан егып ташлыйсы эчемлекнең икесе дә бер сүз белән атала. Тост! Бокал читен Оксана ирененә тигереп алды. Кызның борынын вәсвәсәле шәраб исе сыйпап, тын юлына узды. Бу затлы эчемлекне шәһәр читендәге Таиров исемендәге мәшһүр шәраб ясау фәнни институтында өлгертәләр иде. Эчемлекнең төп өлеше өлкә комитетының кунакларын сыйларга, Киевка, Мәскәүгә китеп тора иде.

– Тәмен дә татып карамадыгыз бит, – диде өлкә хуҗасы. – Әз генә ярый торгандыр бит?

– Гафу итегез, миңа ярамый, – диде Оксана.

– Европада мондый виноны балаларга да бирәләр.

Баш түрәнең тезе аның ботына килеп ышкыла башлагач, алдан уйларга өлгергәннәренең дөреслегенә шик калмады. Баш түрәнең урындыгы да

[18] Персек – беренче секретарь.

Оксананыкына якынрак куелган иде. Димәк, моның максатын оештыручылар да аңлыйлар булып чыга, алар да аңлы рәвештә аңа ярдәм итәләр. Оксана аякларын читкәрәк күчерде. Урындыгын этәрергә кыймады. Ни әйтсәң дә, хуҗа бит, хәтере калуы бар.

Картның тезе өстәл астыннан кызның сыйрагын эзли иде. Күршенең урындыгы кыз ягына сизелер-сизелмәс кенә шуышып куйды.

– Сезнең торак мәсьәләләре ничегрәк, Оксана Тарасовна?

Сораудагы кинаяне кыз шундук сизеп алды.

– Мине ялгыз карчык коммуналкадагы бүлмәсенә кертте. Түләве кыйммәт түгел. Әйбәт яшибез. Мин канәгать.

– Коммуналкада ничек әйбәт яшәп булсын. Үз торагыгызда яшисегез килсә, лично миңа әйтегез. Без Советлар Союзы чемпионы булырлык спортчыга лаеклы шартлар тудырырга тиешбез. Ярышка киткәнче, миңа кереп чыгарга тырышыгыз. Кичке якта. Көндез миңа бер генә минутка да тынгы бирмиләр.

Өлкә хуҗасы башлап җибәргән тәти сүзле тост нотыклары өлкә җитәкчеләре дәрәҗәсеннән шәһәр түрәләре, район җитәкчеләре дәрәҗәсенә төшеп җиткәндә, өстәлдәге затлырак ашамлыклар юкка чыгып, коньяк, затлы шәраб шешәләре бушап калган иде. Аракы шешәләре яртылаш бушаган вакыт иде. Аракылы бокалларын күтәреп әйткән тостларны тыңлап тормыйлар. Мәҗлес аракыга килеп җиткәндә, сүзне вак-төяк җитәкчеләр, мәҗлестән мәҗлескә халява эзләп йөрүче алкоголиклар әйтә. Аракыга тотыну үзенә күрә персекка, сезгә китәргә вакыт җитте дигән сигнал. Оксананың күршесе юкка чыгар алдыннан, кызның колагына пышылдап әйтергә өлгерде:

– Туры үземә шалтырат, – Оксананың кулына визиткасын салды. – Иң астагы телефон. Килештек.

**9**

Хуҗа юкка чыкты. Кузгалырга кыймыйча, Оксана утыруын дәвам итте. Җитәкчеләр киткәч, банкет әкренләп сәрхушләр туена әверелә башлады. Оксананың исенә заманында иң күренекле гимнастика остасы саналган, картайгач, күнегү залының мөдиренә әйләнгән Светлана Аркадьевна әйткән сүзләр килеп төште: «Бәхетле син, Оксана, – дигән иде ул. – Тренерың хатын кеше. Ирләрдән булса, син иң беренче аның түшәгенә ятарга мәҗбүр булыр идең. Белеп тор, чемпионлыкка дәгъва кылсаң, сине барыбер сындырачаклар. Киңәшем шул: түрәләр теңкәңне корыта башласалар... зуррагын сайла». Зал мөдире дөрес әйткән булып чыкты. Бүген түрәнең иң зурысы кармак сала. Әнә бит ничек остарган. Бу спорт дигән нәрсәне йомгакларга кирәктер... Ул бит Одессага мединститутка керер өчен килгән иде. Язмыш шушы тайгак юлга этеп кертте. Киевта беренчелекне алып булса, институтка керү үзеннән-үзе хәл ителәчәк. Күренекле спортчыларны сөйрәп кертергә әзер торалар...

Оксана залдан чыкты, лифтка кереп тормыйча гына, йомшак келәм җәйгән баскычтан беренче катка төшә башлады. Аяк батардай зәңгәр читле яңа кызыл келәмне һәр басмада ялтырап торган җиз калай белән бастырып куйганнар иде. Култык астына юка күн папка кыстырган япь-яшь кешеләр тыз-быз коридорда йөреп торалар. Костюмнары яңа, күлмәк якалары чиста, галстуклары матур. Мондагы эшкә аларны кем сайлап ала икән?

Баскычтан өскә таба күнегү залының мөдире менеп килә иде.

– Беттемени инде? – диде ул, исәнләшеп тә тормыйча.

– Бетеп килә. Анда инде юньле нәрсә калмады.

– Алай булгач, кереп тормыйм инде.

– Керегез. Әйтсәгез, китерерләр. Бар булганны чыгармаганнардыр әле.

– Юк, кермим. Хәер эстисем килми. Син өеңә кайтасыңмы?

– Күнегүгә барырга кирәк тә. Бераз ял итеп аласым килә.

– Әйдә, алып кайтам.

– Мин бит үз аягым белән йөрим. Әйдәгез трамвай тукталышына.

– Мин сине машинага утыртып кайтарам, – Светлана Аркадьевна мәйдан читендә торган кара «Волга»га төртеп күрсәтте. – Безне көтә.

Сәер тоелып китте. Кара «Волга»га Одессаның берничә түрәсе, Мәскәүдән тикшерергә килгән шишкалар гына утырып йөриләр... Әллә шаяртып әйтә инде. Спортчылар ярата иде зал мөдирен. Оксана иярде.

– Мин шофёр янына утырырга яратам, – диде Светлана Аркадьевна һәм ишекне киереп ачып кереп утырды. Оксана арткы ишекне ачты. Салон буш түгел иде. Уң якта бер ир кеше утыра. Оксана, гадәттә, башта кешенең йөзенә карый иде. Һәр очраган яңа ят кешедән, телибезме-юкмы, без нәрсәдер көтәбез. Бу инде адәм баласы мәгарәдә яшәгән чорлардан калган саклану инстинкты: дусмы син, дошманмы? Син үзең уйлап тормыйсың ла. Сорау синең инстинктыңа язып куелган. Ул, безнең теләгебездән тыш, үзеннән-үзе барлыкка килә.

Йөзенә кадәр Оксана пассажирның киемен күрде. Бу чорда чит илдә кием тектерү юк иде әле. Чит илдә теккән кием дә җитәкчеләрдә һәм фарцовщикларда гына иде. Бу кешенең өстендә сылап куйгандай таман аксыл соргылт костюм, кыйммәтле сары ботинка, чалбар очыннан күренеп торган оекбашы, чия көрән галстук – барысын да киенүнең серен белгән кеше сайлаган.

– Танышыйк. Мин Владлен Семёнович Лебедев булам. Чиновник. Танышуның сере – һәркем, кимчелекләрен яшерергә тырышып, үзенең иң яхшы, иң отышлы ягын гына күрсәтергә тырыша. Рәсәйдә «чиновник» сүзе – бандитка ук тиң булмаса да, адәм баласының абруен төшерә торган мыскыллы сүз. «Волга» пассажиры бу сүзне: «Мин җитәкче булуым белән мактанмыйм, чиновникларны яратмауларын белсәм дә, дөреслекне саклыйм», – дип, үзенең абруен күтәрү өчен әйтелгән иде.

– Оксана.

Бу сылуның кулы йомшак, җылы, кысуында чама саклау, тәрбиялелек бар иде. «Волга» пассажирының беренче сүзләре кызның дикъкатен читләтеп узды. Оксана әлеге очрашуның Светлана тарафыннан махсус оештырылганлыгын аңлагач, ачуын белдерде.

– Владлен Семёнович сиңа үзенең кем икәнлеген әйтмәде. Белеп тор, аңа Мәскәүнең иң зур түрәләре, данлыклы язучылары, халык артистлары ошарга тырышып ялагайланалар. Лебедев – пароходчылыкта пассажир лайнерларының хуҗасы. Пароходка утырып, круизга барып кайту аның кулында.

– Светлана бераз арттырырга ярата, – диде затлы костюм хуҗасы. – Мин пассажир флоты белән җитәкчелек кенә итәм. Круизларга җибәрү-җибәрмәүне райкомның махсус комиссиясе хәл итә.

Кызлар белән танышканда, кәнтәй ирләрнең һәр сүзе яшерен максат белән әйтелә. Алар әле танышып та өлгермәделәр диярлек, Оксана инде Владленның кызны, пароходка утыртып, чит илләргә җибәрү мөмкинлеге белән кызыктырмакчы иде.

– Светлана миңа сезнең сер саклый белгән акыллы кыз икәнлегегезне әйтте. Бу сүзләр сездән чыкмас дип ышанам. Киевтагы ярышта беренчелекне

яулаучыларны пароходчылык акчасына круизга җибәрү турында өлкә комитеты белән килешү бар. Сез бу мөмкинлекне кулыгыздан ычкындырмассыз дип уйлыйм.

Машина пароходчылык идарәсе урнашкан Ласточкин һәм Дерибас урамнары очрашкан чатка килеп җиткән иде. Лебедев шофёрга туктарга кушты.

– Син инде кызларны теләгән җирләренә илтеп куй да мине көт. Корабларның позицияләрен карап чыккач, мин Ильичевскига барып кайтам. Төшке ашка кадәр өлгерергә тиешбез.

Оксана үзен квартирасына илттерде.

– Күнегүгә киләсеңме? – Саубуллашканда, Светлана Оксананың кулын бертын җибәрмичә торды. – Мәскәү артисткалары, министрлар, данлыклы язучылар танышырга тырышалар Владлен белән. Сизгәнсеңдер? Син аңа ошадың. Дура булырсың танышлыктан файдаланып калмасаң. Теләгеңне генә белгерт... Ул сиңа Аркадия курортында дача салып бирә, Франциянең атаклы кутюрьеләреннән күлмәк тектертә, акчага күмеп ташлый ала. Ычкындырма кулыңа эләккән алтын балыкны.

– Ул сезгә кем соң? – Светлана бер генә мизгелгә югалып торды.

– Улмы? Без аның белән классташ. Ун ел без бер класста укыдык.

Теләкләренең иң кыйммәтлесен дә тормышка ашыра алучының Светланага сабакташ кына түгеллеген Оксана тоемлый иде. Аңлавын ул белгертмәскә тырышты.

– Рәхмәт сезгә түрәләр машинасына утыртканыгыз өчен, – диде ул, саубуллашканда. – Минем «Волга»га беренче тапкыр утыруым.

Баскыч төбендә кызның хәтеренә Дадоновлар таныштырган егет белән саубуллашуы килеп төште. Фамилиясе, бигрәк тә исеме сәер иде. Ярый әле танышканда аның әйтергә катлаулы фамилиясенең бөек композитор Рахманиновныкы белән бер яңгыраштa булуын хәтерләп алды. Гадәттә, танышкан көнне үк егетләр кочакларга, үбәргә тырышалар. Җибәрми торалар. Кулны боралар. Ә Ап..., Гап..., Абдурахман аңа кулын да тидермәде. Ашыкма әле, бераз сөйләшеп торыйк, дип тә әйтмәде. Мин бит аңгыра кыз түгел, дип уйлады Оксана. Битарафлыктан түгел иде аның кыланышы. Хәйлә генә дә булмаска тиеш. Евгениянең әтисе егетне үтереп мактый. Читтән торып Мәскәү университетын тәмамлаган, ди. Йөзәргә чыгар алдыннан, күтәрә алган кадәр китап сатып ала, күп укый, портта торганда, музейларга йөри, газета-журналларга мәкаләләр яза, ди.

– Тукта әле, диде Оксана, үзен тәнкыйтьләп. Мин нигә дип болай кисәк кенә юньләп таныш та булмаган егет турында уйлый башладым?.. – Әллә бүгенге кичәдән соң шулай күңеленең чын мәхәббәткә, саф мөнәсәбәткә сусавымы икән? – Алай дисәң, ул егет бит миңа мәхәббәт турында сыңар сүз дә әйтмәде. Аның кочакларга, үбәргә тырышмавы да, бәлки, битарафлыгыннан гынадыр? Одесса кызлары чит илләргә йөри торган диңгезчеләр өчен егылып үләргә торалар. Бу хаста миңа да кагылмагандыр бит?..

**10**

Уртак проект тудырган корабларны Рәсәйдә бер типтагы дип атыйлар. Инглизләр исә «систершип» – бертуган кызлар сүзен кулланалар. Шул «систершип» сүзе Габдрахманга күбрәк ошый иде. «Академик Крупчатов» исә бу зур проектның беренче корабы – «Ленин комсомолы»ның сеңлесе иде. Аларны Уинстон Черчильнең Фултон шәһәрендәге нотыгыннан соң

төзи башладылар. АКШ белән СССР арасында «салкын» дип аталган каршы тору әлегә, Аллага шөкер, кан коюга барып җиткәне юк. Өченче бөтендөнья сугышы СССР белән АКШ арасында булыр дип гөман кылучылар бар югыйсә. Чыннан да, шушы ике дәүләт берсеннән берсе узышып, киләчәк сугышта кулланыр өчен, ашкынып, корал ясарга керeште. Америка Икенче Бөтендөнья сугышы вакытында туплаган байлыгы бәрабәренә ясаса, СССР коралны хезмәт ияләренең авызларыннан соңгы тәгамнарын тартып алып, аларны ярым ач, ярым ялангач яшәтү исәбенә җитештерә иде. Америка белән Совет иле арасында океан киңлеге ятканлыктан, яңа сугышка Американың «йөзеп йөри торган утраулары – авианосецлары», Советлар Союзының йөзләгән су асты көймәләре һәм эсминецларыннан тыш гаскәр һәм корал ташу өчен зур тоннажлы сәүдә кораблары да кирәк иде. Тынычлык чорында товар ташырга, сугышка әзерләнгәндә, гаскәр һәм корал күчерергә көйләнгән судноларны Америка ясый башлады. Шундый корабларның берсен, «Маринер» теплоходын Габдрахман Италиянең Генуя портында торганда карады. «Академик Крупчатов»ныкына охшашлы зур, ракеталар сыйдырышлы иркен трюмнар, сәгатенә егерме биш «узел» тизлек[19] бирә алырлык көчле турбина, сугыш шартларында артиллерия куярга көйләнгән махсус платформалар. Американнар корабында дистәгә якын пассажир каюталары да бар иде. Шул каюталарны алар туристларга саталар, сугыш шартларында аларны гаскәр ташуда куллану каралган. «Академик Крупчатов»та исә өстәмә каюталар булмаганга күрә, гаскәрне твиндекларга төяргә мәҗбүр булдылар. Твиндекта һава юк, тынчу иде. Кара диңгездә чайкалу башлангач, мескен хәрбиләр диңгез хастасыннан интегә башлады. Укшыганда, ашказаныннан бәреп чыккан сыеклыкны тутырырга өләшкән кәгазь пакетлар ике генә тәүлеккә җитте. Кораб Босфор бугазына җиткәндә, твиндек эченә керерлек түгел иде инде.

Солдатлар да, аларның командирлары да кая баруларын белмиләр иде. «Совершенно секретно. Гибралтарны чыккач ачарга» дип тышына язып куелган пакет капитанның сейфында ята иде. Урта диңгездән Атлантикага чыгара торган су юлын узгач, «Совершенно секретно» конвертын капитан батальон командирларына тапшырды:

– Үзегез ачыгыз, – дип, яшь, монголга тартым җәлпәгрәк битле полковникка сузды.

Ачарга курыктымы, әллә шушы тарихи мизгелне озаккарак сузасы килепме, тракторчылар өчен тегелгән хэбэ комбинезон кигән командир, конвертның тышындагы сүзләрне укыганнан соң югалып калыпмы, кәгазь букчаны шактый озак ача алмыйча торды.

«Ватан сезне Ирек Утравы – Кубага җибәрә. Совет офицерына, тарихыбызның бөек полководецлары – Суворовлар, Кутузовлар, Бөек Ватан сугышы геройлары калдырган традицияне саклап, бөек ватаныбызның изге исеменә тап төшермәссез, дип ышанып калабыз...»

Кәгазьдә Кубага барып җитеп, ярга төшкәч, кем кулы астына әләгү дә ачыкланган иде. Полковник ул турыда уйлый да алмый иде.

– Хатыным минем кайда икәнемне белми. Ул инде мине кайтыр дип көтә башлагандыр. Сезнең радиостанциягез аша хатын белән элемтәгә кертүегезне сорыйм.

– Рөхсәт ителми, – диде капитан Зимин. – Безнең үзебезгә дә рөхсәт юк. Корал ташуның таләпләре шундый.

[19] 1 диңгез «узел» тизлеге – 1,852 км/сәг.

– Гаиләмә ничек белгертергә соң? Алар бит минем кайда икәнлегемне белмиләр.

– Моннан хәбәр итәргә ярамый. Барып җиткәч карарсыз. Анда берәр төрле җае бардыр әле.

– Корал ташыганда, без кораблар әз йөри торган аулаграк юлдан барырга тырышабыз. Солдатларны кисәтеп куегыз. Корылма эченә кереп чокынып йөрмәсеннәр. Кораб энергосистемасының көче бер бәләкәйрәк шәһәрнеке чамасы. Адым саен диярлек ут сүндерү җайланмалары, авиациядә кулланыла торган автоматлар. Ягыла күрмәсеннәр.

– Хафаланмагыз, кисәтербез, – диде полковник. – Бу бит особый батальон. Аның статусы полкныкына тиң. Личный состав та иң оста, иң тәртиплеләрдән сайлап алынган. Хафаланмагыз, мин аларны катгый төстә кисәтермен.

***

Габдрахманның диңгезчеләр телендә «кораблар каберлеге» дип аталган Бискай култыгының тыныч чагын күргәне юк иде. Хәрбиләрнең бәхетенә, «каберлек» корабны тыныч каршы алды. Ярлар күздән югалганнан соң да «Геркулес баганалары» дип аталган кыя-тау, шактый озак офык читеннән башын тыгып, Америка Кушма Штатларын яуларга барган хәрбиләргә хәерле юл теләп күренеп торды.

Габдрахман, океан чиксезлеген күргәч, солдатлар хәйран калып, океанны күзәтерләр, хис-тойгыларын үзара бүлешерләр, дип көткән иде. Палубадагы швартов баулары өстендә утырган бер чирләшкә кыяфәтле солдат белән аркаларын корылмага терәп сөйләшеп торган ике егеттән тыш океанны күзәтүчеләр күренми иде. Әнә, сулъяк шлюпка астында бертөркем яугир кәрт уйнап утыра. Карап торучылар түземсезлек белән чират җиткәнен көтә. Бинокль аша Габдрахман полубакка күз салды. Дистә чамасы конкистадор океанның тозлы һавасыннан изрәп йокларга яткан. Баш асларына кирза итекләрен салганнар, ыштырларын океан кояшы киптерә. Унъяк шлюпка астында һава суларга чыккан солдатлар, көлә-көлә, нәрсәдер чәйниләр. Рахманкулов бинокль аша солдатлар кулындагы ризыкка карады. Юк, ипи түгел иде алар ашаган нәрсә. Тәмле булырга тиеш, комсызланып авызларына тутыралар да чәйнәп тә тормыйча йоталар. Ашыгалар. Әнә, Бискай култыгындагы шторм вакытында үлә язган юан егет учлап авызына нәрсәдер тутырды да чәйни башлады. Менә ул учы белән бугазын уа, ашаганы тамагына тыгылды шикелле.

– Алик, – диде Габдрахман матроска, – нәрсә ашыйлар алар?

– Камбуздан берәр нәрсә чәлдергәннәрдер. Урлашмый торганда, солдатның кулы кычыта башлый.

– Ачыкла әле нәрсә ашаганнарын. Камбузны басып, безне ач калдырулары мөмкин.

Һәр экипаж әгъзасы солдатка дастан батыры булып тоела иде. Рахманкуловның матросы диңгезчеләр телендә мәзәк сөйли белгән «травило» иде. Юан солдат аңа нәрсәдер сузды. Алик та чәйни башлады. Матрос урыныннан торды, күперчелеккә төртеп күрсәтеп, нәрсәдер әйтте дә рубкага якынлашты.

– Галет чәйниләр тынычлык сакчылары, – диде матрос һәм өч тиенлек акча зурлыгы прәннекне Габдрахманга сузды. Чәйнәп йоткач аңлашылды. Чыннан да, сакланган комплекттагы ашамлык иде бу. Урлап алганнар. Тизрәк чара күрергә кирәк. Озакламый капитан рубкага менәчәк. Аның үзенә әйтергәме, әллә өлкән штурмангамы?

Офык читендә – зәңгәр күккә барып тоташкан илаһи чиксезлек. Винт, тирәюньгә су тегермәне тавышы чыгарып, океан суын бораулый. Кораб карынында урта гасырларда «тере товар» дип аталып йөртелгән солдатлар һәм шартлаганда берьюлы меңләгән, йөз меңләгән адәм баласының көлен күккә очырырга көче җитәрлек континенталь ракеталар яшерелгән.

Бөек урыс язучысы Антон Павлович Чеховның: «Әгәр сәхнәгә мылтык элеп куелган булса, ул озакламый атарга тиеш», – дигән акыллы фикере бар. Бу фикерне ракетага карата да кулланып буламы икән соң? Җавап урынына Рахманкуловның башына тагын да сәеррәк фикер килде: «Совет солдатларының Христофор Колумб ачкан юлдан сугышка барулары уналтынчы гасырның уртасында Мәскәүдән Казанны җимерергә юнәлүенең дәвамы түгелме?.. Яулап алулардан нигә туктала алмый икән бу ил? Әнә, Бөекбритания туктады бит. Барлык колонияләренә мөстәкыйль яшәргә ирек бирде. Тынычланды. Үзе турында гына кайгыртып яши башлады. Кайчан, кем туктата алыр бу сугыш чукмарын яу оештырып йөрүдән?..»

**Өченче бүлек**

**1**

Гимнастларның халык телендә «турник» дип аталган программасы ярышның соңгы төре иде. Снарядларның башкаларында Оксана Ярёменко иң зур балл туплап, үзенең лидерлык сыйфатларын күрсәтүгә ирешә алды. Дөрес, күптән түгел генә хатынын аертып, культура министрына кияүгә чыккан Киев гимнасткасы Полина Юрченконың да чемпионка исемен яулап алу мөмкинлеге әле шактый зур иде.

Чыгышка әзерлек вакытында Оксананың тренеры Светлана Аркадьевна аның колагына пышылдады:

– Перекладина синең иң отышлы урының. Бу ярышта син, һичшиксез, Полинадан өстен булачаксың. Министр хатынын якларга тырышырлар, дип курыкма. Бәя бирүчеләр арасында минем дусларым да бар. Мин аларны кисәтеп куйдым. Әйдә, дулкынланмыйча гына сәләтеңне күрсәт тә – Одессада сине триумф көтә.

Чыгыш ясау тәртибен, кәгазь кисәгенә язып, җиңгән командага тапшырыласы көмеш кубокка салганнар иде. Оксананың чираты азакка туры килде. Язмыш үземе Оксанага министр хатынының һәр хәрәкәтен, уңышларын, кимчелекләрен күзәтеп тору мөмкинлеген бүләк итте.

Киев каласының горурлыгы саналган «Динамо» спорт сараенда соңгы төр буенча ярыш башланды. Гөмбәз пыяла түшәмнән иркен залга кояш нурлары коела. Менә язмышын сынарга Оксананың сердәш дусты Евгения Дадонова чыкты. Музыка уйный. Тамашачыларның күзләре кызның хәрәкәтләренә төбәлгән. Ике тимер баганага беркетелгән тимер арата. Шуның тирәсендә Женяның гүзәл гәүдәсе бөтерелә. Аның бит әле мондый ярышта беренче генә катнашуы. Дулкынлана... дөрес, дулкынлану ярышка җан да кертә, өнди, куа, шул ук вакытта өстәмә көч алып, хәрәкәт иреклегенә аркылы төшә.

Евгения гаиләсе белән Оксананы да җылыта, туганлык хисләренә сугарылдырып, яшәешне җанландырып тора. Дадоновларда танышкан егет, аның озатып куюы кызның исенә килеп төшә. Ул хәзер диңгез-океаннар киңлегендә. Оксананың рәхимсез кискен җаваплылык каршында торуын тоямы икән?.. Кыз бер генә мизгелгә күзен йомгандай була... Көчле алкышлар аны кабат залга кайтарып ташлый. Женяның елмаеп балкуыннан ул аның

программасын төгәл очлап чыгуын һәм үз чыгышыннан канәгать калуын аңлап ала.

Менә перекладина янына киевлыларның кумиры Полина Юрченко килеп туктады. Бу хатынны Оксананың элек тә күргәне бар иде. Моннан ике ел элек Херсон шәһәрендә үткәрелгән ярышта, аннан да элегрәк Ужгородта. Ул чакларда көндәшлек хөсете тудырган кимчелек һәм өстенлек эзләү тойгысы юк иде әле... Гәүдә. Кырып ясаган орчык төгәллегендәге озын аяклар. Шөпшәнекен хәтерләткән нечкә бил һәм янбаш күперенкелегенә тәңгәл, ак майканы ертып чыгарга торган касә күкрәкләр. Маңгаен каплап, муенына төшеп торган ялтыравык куе кара чәч, карлыгач канатыдай кыйгач кашлар...

Бүген инде шушы матурлык астында аның Оксананың җиңүен җимереп, таптап китәргә әзер торган дошманлык посып ята иде.

Бернинди көчәнүсез очып, Полина турникның тимеренә тотынды. Гимнастканың һәр хәрәкәтен, аның отышлы сыйфатларын, кимчелек булып чагылган урыннарын – шуларның барысын да Оксана йотлыгып күзәтә барды. Ниһаять, соңгы хәрәкәт. Полина, элмәк ясап, очуын тәмамлап, идәнгә кунаклады.

– Хәтереңә киртеп билгеләп куй, – диде тренер. – Синең җиргә төшүең ун мәртәбә отышлырак.

**2**

Оксананың снарядка чыгуын да алкышлап каршыладылар. Кызның туган телендә чыга торган «Кичке Киев» газетасында Юрченконы җиңәргә әзерлеге булган төп көндәш икәнлеген белгертеп, аның фотосурәтен төшереп бирелгән мәкалә тамашачыларны алдан ук шушы җиңүгә әзерләп куйган иде. Әмма, үз өеңнең диварлары да ярдәмгә килә, дигән әйтемнең дөреслеген раслагандай, бүген бәхет аның көндәше Полинага елмайды.

Оксананың учлары турникның салкынлыгын тойды. Ярыш ялкыны кызны кочагына бөтереп алды. Һәр хәрәкәт, аның башы, күләме, ахыры, программаның тулы сурәте Оксананың баш мие һәм күңел дәфтәренә, мускул күзәнәкләренә язылган иде. Ярышка махсус чакырылган квартет уйнаган көй гимнастканың хәрәкәтләренә җан, ритм кертеп, көч биреп тора. Ниһаять, ярышның соңгы мизгеле – турниктан аерылып, элмәк ясап, җиргә төшү. Хәзер ул осталыкта үзенең Полинадан өстенлеген жюри әгъзалары, хәтта тамашачылар да сизәрлек дәрәҗәдә күрсәтергә тиеш. Тиеш...

«Нам нужна ещё одна победа... за ценой не постоим...» дип җырлыйлармы әле?.. Бу сүзләрнең мәгънәсе совет иленең спортчылары рухына да үтеп кермәдеме икән?! Әнә бит алар дөньякүләм ярышларда гел беренче, гел җиңүче. Ярыштан ярышка, омтылыштан омтылышка күчә килеп, Оксана да, сизмәстән, җиңү хастасына сабышуын тоемлаудан узган иде, күрәсең.

Спортчылар телендә «сальто» дип аталган бу хәрәкәтне перекладинадан аерылып идәнгә төшкән арада Ярёменко ике тапкыр ясарга өлгерә иде. Куш сальто. Спорт тарихында бу яңалык түгел. Икенче тапкыр әйләнеп чыкканнан соң, идәнгә басар алдыннан, кыз бер генә мизгелгә кулларын канат итеп җәеп һавада очып ала иде. Аның беренчелекне яулавын бөтен Одесса көтә. Моңа кадәр яшереп сакланган могҗизалы хәрәкәтне ул шушы ярышта күрсәтәчәк. Җиргә төшәр алдыннан җилпенеп алуны Оксана нәкъ менә Киев һәм Мәскәү өчен яшереп тотты.

Баш мие, тою, сизенү – барысы да тән хәрәкәтенә буйсынган. Хәрәкәт

хәрәкәткә тоташкан. Аяк-куллар, гәүдә, тәннең һәр мускулы перекладина тимере тирәсендә бөтерелеп, сокландыргыч матурлык тудыра. Соңгы омтылыш. Бармаклар язылып китте. Оксананың гәүдәсе һавада очып бөтерелә. Бер... Ике... Куллар канат булып җәелде. Хәлиткеч мизгел. Гәүдә вертикаль торыш алырга, аяклар идәнгә килеп төшкән мизгелдә тезләр, сыгылып, хәрәкәтне йомшартырга һәм тураерга тиеш...

Уң як җилкәне нәрсәдер яндырып алды... Нигә алкышламыйлар?.. Кул чабу урынына йөзләгән ыңгырашу, бергә кушылып, Оксананың колагына килеп бәрелде.

Ак халат кигән ике ир носилкада бөгәрләнеп яткан гимнастканы чишенү бүлмәсенә кертеп идәнгә куйды.

«Нәрсә булды?..» соравы, күңелдән чыга алмыйча, эчтә калды. Ирләр Оксананы күтәрә төшеп, җилкәсеннән тоттылар. Авырту кызның баш миенә килеп бәрелде, көйдереп тәненә таралды.

– Ике җирдән, – диде ирнең сакаллысы һәм, кисәтеп тә тормыйча, Оксананың арт ягына укол кадады.

Ашыгыч ярдәм машинасы әзер торган булып чыкты. Оксананы чыгарып салу белән, ул кузгалып китте.

...Кайгыру да юк иде, офтану да. Кызның хәле, мунча парында кызуга көчкә түзеп, янып-пешеп утырганда, чиләк белән өскә салкын су сибүне хәтерләтә иде. Беренчелек... Бөтенукраина чемпионы дәрәҗәсенә ирешү... Шул тыелгысыз омтылышның бер тиен тормаган кысыр шапырыну икәнлеген ул моңа кадәр нишләп аңлый алмаган икән?.. Шушы кичерешне кемгәдер сөйлисе, бушанасы килә иде. Уң як җилкә, күкрәкнең ярты ягы, кулның терсәктән өске өлеше кат-кат сыланган гипс эчендә. Дүрт кешелек хастаханә палатасы. Карават янындагы тумбочкага тәлинкәгә сыланган борай боткасы, ике телем ипи, ике бармак зурлыгы ит кисәге куеп киттеләр.

«Менә шушы бүләк өчен ашкынганмын икән...» – дип, кыз үзен-үзе мыскыллап куйды. Башка чара юк – түзәргә кирәктер. Ә ярыш? Уйларга кирәк булыр...

Оксананың Дадоновларда танышкан егет исенә килеп төште. Габдрахман кызның нинди хәлдә икәнлеген аңлар шикелле тоела иде.

### 3

Вахтасын өлкән штурманга тапшырганда, кораб Матансас портының траверсын узып килә иде. Зур Антил утрауларында октябрь аеның соңгы көннәре. Тоз катнаш суүсемнәренең әчкелт хуш исенә сугарылган җиләс, җылы диңгез сулышы. Атлантик океанның планктон, балык көтүләре тупланган җылы Гольфстрим агымы, Бермуд һәм Антил утрауларының ярларын юу белән генә чикләнмичә, нервларны чеметтергән мавыктыргыч маҗара эзләүче акчалы, бай сукбайларны да җыеп тора иде. Фидель Кастроның, властька килеп, социализм төзи башлавы Куба утравына гына түгел, Флорида ярларына, Бермуд һәм Антил утрауларына, пиратлар чорының җәннәте Тортуга җиренә, Дабл-Һелед-Шат-Кис һәм Ангила утрауларына килеп, ел әйләнәсенә бер ялдан икенчегә, түләүле мәхәббәтнең берсеннән икенчесенә, унынчысына күбәләктәй очып йөрүчеләрнең юлына таш булып ятты.

Дөрес, күзгә күренеп торган куркыныч юк. Ә менә газета битләрен, телевизор экраннарын каплап киткән «салкын сугыш» афәте инде һавада бөтерелә башлаган иде. Соңгы вакытта газеталар Советлар Союзы Кубага

ракеталар ташый, дип яза башлады. Синнән йөз егерме чакрымда Совет иленең ракеталары тырпаеп старт көтеп торганда, Майаминың зәңгәр дулкыннар юып чистарткан ак комлы пляжларында ял итеп яту мөмкинме?

Атлантик океанны кичкәндә, Габдрахман радиопеленгатор приёмнигыннан ара-тирә «Свобода» радиотапшыруларын тыңлаштырды. Дөрес, «Свобода»ны ялган коткы таратучы алдакчы, совет кешесенең дошманы дип аңлатып торалар. Колхоз эшендә яисә заводта эшләп, тыныч тормышта яшәсә, Рахманкулов «дошман радио»ның тапшыруларына ышанмас та иде. Ә бит ул менә үзе Кубага ракета һәм гаскәр илтү эшен башкара. Ул – сугышчы, салкын бәрелеш сугышчысы һәм, кызганычка каршы, үзенең салкын фронт сугышчысы икәнлеген сердәшенә дә сөйли алмый, чөнки сер саклау анты язылган кәгазьгә кул куйды.

Көндезге унике туларга кырык минут кала, аны уятачаклар. Төшке аштан соң рубкага менеп, вахтага басачак. Сәгать кичке дүрттә аны алыштырачаклар һәм алтылар тирәсендә «Академик Крупчатов», Гавана портының тышкы рейдына туктап, якорь салачак. Корал төяп килгән корабларны причалга чиратсыз куялар, диде капитан Зимин. Йөкне бушатып бетергәнче, ул йокы күрмәячәк. Алып килгән йөктән котылу бәхетенә ирешер өчен, атна буе йокысыз эшләргә дә риза. «Тере» йөктән, солдатлардан котылу шатлыгы өчен. Күпме бимаза китерде Габдрахманга «ике аяклы» йөк. Шторм вакытында твиндекны косыкка батыру. Палубага чыгып йөрергә рөхсәт алгач, подшпикерскида, спортзалда, салонда, машина бүлеге өстендәге рәшәткәләрдә чокынып, коткару шлюпкасындагы аварийный ашамлыкны урлаулар һәм, иң куркынычы – фальшборт аша суга егылып төшеп батып үлүләреннән куркып кан йотулар. Солдатларны бушаткач, сәгате-минуты алдан билгеле, таныш кораб йөртү эше Габдрахманга бәйрәм генә булып тоелачак.

Йокыга китәр алдыннан Габдрахманның күз алдына тышкы ишек артына кереп юкка чыккан Оксана килеп басты. Нигә онытылмый икән шул очрашу? Аның бит кызлар белән беренче тапкыр гына танышуы түгел иде. Таныш кызлары була торды. Дөрес, туган авылы Караярдагы беренче мәхәббәттән соң ул сөю бәхетенә ирешә алмады. Бергә укып, бер чорда колхоз эшенә йөреп үскән яшьтәшләре башлы-күзле булып тынычланалар иде. Авылда кияү таба алмаганнары читкә китте. Мәскәү университетында читтән чорып укыганда, аның белән ресторанга йөрүчеләр, үбешүләр, кияүгә чыгарга теләүчеләр дә булмады түгел. Корабы рейстан кайтканын көтеп, Одессада яшәгәндә бергә вакыт уздырган кызлары да бар иде. Әмма аларның берсе дә Оксана шикелле күңел тирәнлегенә үтеп керә алмады.

**4**

– Тор! Тизрәк!.. Капитан чакыра.

Күзен ачып җибәргәндә, матрос Гайдамакинның шапылдап ябылган ишектән аркасы гына күренеп калды. Шундук телефон шалтырады.

– Тыңлыйм.

– Тизрәк кил! Рубкага! – Бусы капитан тавышы иде. Ашыгу тизәйтми киенүне. Бигрәк тә ашыктырып уяткан чакларда. Кулдагы чалбарны каютаны бетереп эзләүгә, туфли шнурына буталуга берничә минут вакыт үтте. Гайдамакинның куркулы тавышын ишетү, төнлә «Свобода» радиостанциясе аша совет хәрбиләренең Куба өстеннән очып, фотога төшереп йөргән У-2 самолётын бәреп төшерү хәбәре хәтергә килгәч, югалып калу тагын да көчәеп

китте. Димәк, сугыш башланган?.. «Нельзя играть с огнём», ди урыслар. Шушы тоемлауның җавабы да урысча туды: «Доигрались!..»

Сугышча буялган очлы озын борынлы эсминец сул як кильватер юнәлешеннән «Академик Крупчатов»ка якынлашып килә иде. Габдрахман уң якка карады. Эсминецның икенчесе дә шул ук тизлек белән якыная. Эсминецның сул яктагысы прожектор уты белән туктаусыз сигнал бирә.

– Туктарга боерык бирә, – диде өлкән штурман Рахманкуловка. – Туктамасагыз, залп бирәчәкбез, дип куркыта.

Габдрахманның күзе эсминецның тупларына төште. Икесеннән дә корылмага янәшә төп калибрдан башлап барлык көпшәләре, ракета җибәрергә көйләнгән рельслар чекерәеп, «Академик Крупчатов»ка төбәлгәннәр. Курку, Габдрахманның, тез буыннарын йомшартып, йөрәге аша баш миенә йөгерде. Йа Хода! Сакла үлемнән!.. Эсминец командирының сыңар бер сүзе хәрәкәткә китергән тупларның ракета установкаларының гашетка төймәләренә басу белән, «Крупчатов» экипажын үлемнән саклап йөрткән кораб, кан, туракланып беткән гәүдәләр белән аралашкан ярчыклар су өстен каплап китәчәк, егерме-утыз минуттан утыз дүрт диңгезче һәм йөз утыз алты хәрбинең язмышын океан мәңгелеккә йотачак. Курку салкыны кабат, буыннарны бозландырып, баш миен авырттырып айкап узды.

– Абордажга алалар! – диде капитан, ярым пышылдап. Капитанның да иреннәре калтырый, бите соргылт ак төскә кергән. Ул куркуын яшерергә тырышса да, кичерешләрен җиңәргә көче җитми иде.

– Чиф, команданы сиңа тапшырам. Ике яктан килеп кыссалар, зигзаг ясап бара башла. Аңладыңмы?

– Аңладым.

– Помполит! – диде капитан рубканың арткы почмагында бөрешеп торган кешегә, – әйдә. Рахманкулов син дә.

Алар өчәүләп рубкадан капитанның каютасына төшә башладылар. Ишектән керү белән, Зимин йокы бүлмәсенә атылды. Шарт-шорт килеп йозак ачылган тавыш ишетелде. Икенче мизгелдә мендәр тышының яртысы зурлыгы кара капчыкны помполитка сузды.

– Камбузда яндырасың! Көлен юып ташла. Кокның ак курткасын кияргә онытма. Аңладыңмы?

– Аңладым.

Атлантик океанны кичкәндә, капитан каютасын эчке яктан бикләп, Зиминның помполит белән өч-дүрт тапкыр өчәр сәгать югалып торуларының сере сейфта сакланган шушы кара капчыкта иде. Капчык эчендә шпион һөнәрендә кулланыла торган шифрлар, шифр белән килгән сүз урынына тематика саннары язылган радиограммаларның эчтәлеген ачканда кулланылган кодлар сүзлеге икәнлеген Рахманкулов, ниһаять, аңлап алды. Помполит шуларны яндырырга йөгерде.

– Мә, укы, – диде капитан, конверт эченнән кәгазьгә басма хәрефләр белән язылган ярты битне икенче штурманга сузып.

Затлы фин кәгазе. Эре, калын хәрефләр.

«В случае реальной опасности захвата судна:

а) Назначить из числа комсостава – члена КПСС руководителя;

б) Рядового из числа машинной команды, так же члена КПСС, преданного долгу перед Родиной;

в) Немедленно послать в машинное отделение открывать кингстоны;

г) Сжечь все секретные документы;

д) По истечении 10-15 минут, лично проверить выполнение пункта «в» и обеспечить ликвидацию паники личного состава и пассажиров.

Отказ от выполнения содержания данной инструкции карается по законам военного времени».

– Кемнең приказы бу? – Габдрахманның таш булып каткан иреннәре көчхәл белән генә шушы сүзләрне тудыра алды.

– Кем?! Бала-чагаланма! Бар, тизрәк эшкә ашыр. Давай!

Капитан Зимин кинәт Рахманкуловны кочагына кысты:

– Бәхилләшик. Приказны үтәмәсәк, хатыннарыбыз, балаларыбыз Колымада булачак...

Коридорда Габдрахманны моторист Ясиненко көтеп тора иде. Аның башыннан яшен тизлеге белән: «Димәк, капитан ул кәгазьне мин рубкага менгәнче үк укыган булган!» – дигән уй йөгереп узды.

Батальон командиры коридор ишеген ачмакчы булып тоткага үрелә. Боцман җибәрми, полковникны этә-төртә коридорга куа. Камбуз ишегеннән бер генә мизгелгә бөркелеп коридорга чыккан төтен аша помполитның башы күренеп алды. Габдрахман белән Ясиненко, абына-сөртенә, машина бүлегендәге текә, тайгак трап басмаларыннан аска йөгерделәр. Трап текә. Аяк тая. Абынып китсәң – беттең. Ниһаять, корабның төбе. Үзәк турбина янында өлкән механик, вахтадагы механик, моторист.

– Сез кая? – дип, өлкән механик аларның юлын бүлде. Эчкә сизелер-сизелмәс кенә җылы йөгерде. Монда бит ул хуҗа. Бәлки, рөхсәт итмәс?..

Телефон шалтырады. Өлкән механик трубканы алды.

– Әйе. Алар монда. Аңладым.

Динамомашина, түмгәк булып калкып торган помпа-насослар арасыннан урап, туктала-атлый торгач, тимер идәннән калкып чыгып торган арба көпчәге зурлыгы тәгәрмәч янына туктадылар.

– Ач, – диде Рахманкулов, боерык кәгазендәге сүзне кабатлап. Үзе, астан су ташкыны бәреп ургыла башлагач, качарга аралык эзләүгә кереште. Акыл качып котылу мөмкинлеге юклыгын аңлый иде. Тозлы океан суы рәхимсез көч белән машина бүлегенә бәреп керә башлауга, кораб батарга тотыначак. Тупларын «Крупчатов»ка төзәп, абордажга алырга килүче эсминецның командасы исә, билгеле, су өстендә тончыгырга теләмичә йөзеп йөрүчеләрне дә берәм-берәм чүпләп алачак.

– Ач тизрәк! Нәрсә... Әллә ачарга теләмисеңме?!

– Ачылмый бит!

Көчәнүдән мотористның маңгай тамырлары бүртенеп чыккан иде.

– Давай, ач!

– Мә, үзең ач!

Ясиненко, тураеп, маңгай тирен сөртергә тотынды. Рахманкулов, иелеп, кингстон көпчәген бора башлады. Борылмый иде үлем көпчәге. Тимер тәгәрмәчне урыныннан да кузгатып булмый иде.

– Давай, лом тап. Каерырга кирәк. Кузгатырга...

Бер минут, ике, өч... Лом, көрәк, ыргак, балта... кораб турбинасы пульты янәшәсендәге кызыл тактада лабаса...

Трус икән бу Ясиненко дигәннәре... Юри тапмаган булып кылана, подонок... Курка. Үләсе килми, сволочьның!.. Пьялога тулган суны суыра торган помпаны урап үтү белән, Рахманкулов лом тотып килүче мотористка килеп төртелде дә артка борылды.

– Курыкма, ачабыз аны.

Габдрахман кире борылды. Ломны тимер көпчәкнең тимер араталары арасына тыгып каера башлауга, кингстон урыныннан купты.

– Кузгалды бу... – диде Рахманкулов.

– Туктагыз!

Өлкән механик ломны мотористның кулыннан тартып алды да тимер палубага ыргытты.

– Капитан ачмаска боерды.

Габдрахман пульттагы кызыл трубкалы телефонга үрелде. Туры рубкага тоташкан авария телефоны иде бу.

– Капитан!

– Михаил Михайлович, өлкән механик аркылы төшә. «Ачмагыз», ди.

– Әйе, ачмагыз. Әнә, китеп баралар.

Машина бүлегеннән күтәрелеп, Рахманкулов палубага чыкты. Эсминецлар корабтан инде берничә мильгә ерагайган иде. «Нәрсә булды боларга? Нигә китәләр?»

**5**

Оксананы Одессага кайтардылар. Алдан кемдер сөйләшеп куйган булса кирәк, монда өлкә комитетында һәм башкарма комитетта утыручы түрәләр генә ята иде. Бер кешелек палата. Бәдрәфе, коену бүлмәсе үзендә. Хәтта телевизоры да бар. Ашау – кунак сые. Сәламәтлеге турында Одессаның иң күренекле табиблары кайгырта. Мондый шартларга күнекмәгән кешегә шунысы уңайсыз: сөйләшеп эчне бушатыр кеше юк. Совет иленең түләүсез больницаларында дәваланучы авырулар, үзара аралашып, бер-берсенең сәламәтлеге турында кызыксынып торалар. Палатада ялгыз яту мөмкинлектән мәхрүм итә. Ашны палатага китерәләр. Врачка каралырга шәфкать туташы алып бара, алып кайта. Обком кешеләренең тормышына күнегүе чиктән тыш катлаулы иде. Сүзләре урыс телендә, мәгънәләре бөтенләй башка – Оксанага аңлашылмый торган эчтәлекле. Аларның бит атлап йөрүләре дә башкача, бераз Сталинныкын хәтерләтә. Ә куркулары... Югыйсә, власть шушы тоташтан диярлек кыска аяклы юан кешеләр кулында, ә нигә соң алар бер-берсеннән шулай шөллиләр?..

Киев хастаханәсендә арпа боткасы белән кәбестә шулпасыннан тыш, көненә бармак очы хәтле пешкән хек балыгы яисә сеңердән генә торган ит кисәге белән чикләнәләр иде. Обком больницасында көнаралаш тавык боты, иртән шактый зур бер кисәк сыр, колбаса, ялларда хәтта балык уылдыгы бирәләр. Әбәткә биргән ашлары бәйрәм көннәрендә кызның әнисе пешергән ит шулпасын хәтерләтә иде. Ял йорты бит инде югыйсә, ә барыбер эчке рәхәтлек юк иде мондагы уңайлыкта.

Оксананың хастаханәгә урнашуына дүртенче тәүлек иде, бер көлтә роза чәчәкләре күтәреп, өлкә комитетындагы банкеттан соң машинасына утыртып фатирына илттергән кеше аның палатасына килеп керде. Зур картон тартманы – тумбочка янына, чәчәк бәйләмен тәрәзә төбенә куйганнан соң, ул Оксананың сул кулын авырттырып кысты һәм аны иелеп үбеп алды. Хәрәкәтен дәвам итеп, кызны кочаклау иде бу кешенең гамәлгә ашырасы теләге, әмма каршылык буласын тоеп, тукталып калды, хәтта арткарак чигенде.

– Сез мине таныйсызмы?

«Әйе, таныйм», дип әйтүдән тыелып, Оксана:

– Юк. Мин сезне беренче күрүем, – диде.

– Чибәр кызларның хәтере кыскарак булуы табигый. Без өлкә комитеты оештырган банкетта танышкан идек. Банкеттан соң мин сезне фатирыгызга озатып та куйган идем. Лебедев мин, Владлен Семёнович.

«Әйе, исемә төште», – дип әйтүдән дә тыелды Ярёменко. Бу бәндәдә хатын-кызны үз ягына аудару, буйсындыру, соңгы чиктә аны үзенеке итеп аздыру тәҗрибәсе чиктән тыш көчле булуын Оксана хатын-кызга гына хас тоемлау сизгерлеге белән аңларга өлгергән иде.

Ир кеше, тәкъдимне көтеп тормыйча, караваt янындагы урындыкка утырды.

– Врач миңа, бер атнадан дәвалау тәмамланачак, диде.

– Бу больницадан соң, гадәттә, ял йортына яисә санаторийга путёвка бирәләр. Мин сезгә башка киңәш бирер идем. Әле узган айны гына «Литва» теплоходы урынына Европаны урап Ленинградка йөри торган круиз линиясенә яңа, бар уңайлыклары булган «Иван Франко» лайнерын билгеләдек. Мин сезгә, шул корабка утырып, круизга барып кайтырга тәкъдим итәр идем.

– Минем аңа түләрлек акчам юк. Булса да түләмәс идем. Нәрсәм калган ул круизда!

– Оныткан булсагыз кирәк, беренче секретарь олимпиада чемпионнарын зур бүләкләр көтә, дигән иде банкетта. Круиз билеты секретарьның вәгъдәсен үтәү булачак.

– Сез нәрсә, әллә минем җиңә алмаганымны да белмисезме?

– Травмага юлыгу җиңелү дигән сүз түгел. Сезнең ярышта җиңеп чыгуыгызга бөтен Одесса ышана.

– Әлеге сүзләр сезнең мыскыллап әйтүегез түгелдер бит? – Оксана беренче тапкыр бу ирнең йөзенә күз сирпеп алды. Әйе, чигәсенә ябышып беткән җәлпәк колак, шактый килбәтсез бөкре борын һәм эченә сыймыйча тышка бәреп чыккан генетик, милли хәйләкәрлек. Кызның эченә ирексездән курку йөгерде.

– Гафу итегез. Берничә минуттан укол кадарга керәчәкләр. Чәчәк китерүегезгә рәхмәт. Бу тартманы кире алып китегез. – Тумбочка янындагы тартманы алырга дип иелгән иде, җилкә белән күкрәк арасында кабынып киткән яндырулы авырту Оксананың тәнен айкап, баш миенә китереп бәрде.

– Рәхмәт якты йөз белән кабул итүегезгә, – диде Лебедев, артыннан ябылып калган ишектән чыкканда.

**6**

Гавана портының тышкы рейдында торганда, яр буен караңгылык каплагач, порттан өч тапкыр катер килеп, солдатларны төяп алып китте. Ярга чыгарга боерык яңгырагач, солдатларга автоматларын һәм башка коралларын өләштеләр. Солдатлар китте. Корабта җимереклек, урлашу эзләре һәм авыр ис калды.

«Академик Крупчатов»ны портка кертергә ашыкмыйлар иде. Капитан радиотелефон аша берничә тапкыр элемтәгә кереп карады. Порт идарәсе: без берни белмибез, сезнең хәлегез хәрбиләр кулында. Причалга кую-куймауны алар хәл итә, дип җавап бирә иде. Урысча «хәрби» сүзе ипи-тоз шикелле табигый яңгырый. Испан телендәге «милитаре»нең мәгънәсендә – Кортес һәм Писарроларның конкисталары тудырган вәхшилек, утыз алтынчы еллардагы Испанияне канга батырган гражданнар сугышының фаҗигале шомы.

Корабта эчә торган су тәмам беткән иде. Сусыз интегү өченче тәүлеккә киткәч, капитан морфлот министры исеменә SOS радиограммасы җибәрде. Җавап, гадәттәгечә, килмәде. Аның сәбәбен капитан Зимин белә иде. Корабны

хәрбиләр карамагына тапшырганнан соң, пароходчылыкның да, морфлотның да аның эшенә һәм яшәвенә тыкшыну хокукы югала. Кораб язмышы хәрбиләр кулына элгә. Бар нәрсәне дә алар кайгыртырга тиеш. ГКЭСка[20] кереп оялаган ГИУдагы[21] чиновник-хәрбиләр арасында сәүдә флотының хәрби флот белән аермасын белүче дә шәт булмагандыр?..

Гаскәрне бушатканнан соң, тагын бер тәүлек узды. Диңгез суын кайнатып, шуның парларыннан җыелган сыеклыктан чәй әзерли, аш пешерә башладылар. Чәй – эчәрлек һәм аш – ашарлык түгел иде.

Гаванадагы морфлот вәкиле, ракеталарны монда бушатмыйча, кире Балабановкага алып кайту турында хәбәр җиткерде. Эчә торган су, азык-төлек мәсьәләсен дә капитан шушы вәкил ярдәмендә хәл итте булса кирәк. Морфлот кешесе китеп, ярты көн үтүгә, шипчандлерның[22] катеры кораб янына туктаган иде инде. Порттан килгән баржадан танкларга эчәргә яраклы су тутырганнан соң, «Академик», якорен күтәреп, кайтыр юлга чыкты.

Корабны батыру турындагы инструкциянең үтәлми калуы өчен җавап бирергә кирәклекне капитан аңлый иде. Экипаж әгъзалары, империалистик АКШка каршы сугышырга барган хәрбиләрнең язмышы, кораб, аңа төялгән ракеталарның исән калуы тиешле боерыкның үтәлмәве каршында сукыр бер тиен тормый иде. «Приказ – закон!» Капитан Зимин сизенә иде. Аны, һичшиксез, җавапка тартачаклар. Сугыш шартларында кулланыла торган рәхимсез каты, аяусыз җавапка.

Михаил Михайлович Зимин инглиз телен русчага тиң диярлек белә иде. Француз, итальян, испан телләрендә иркенләп сөйләшә, укый-яза ала. Бабасы исә ивритны да су кебек эчә торган булган. Ул җиде ел бабасының җылы тәрбиясен татып рәхәтләнде. Башлангыч классларда ул әле Мейер Моисеевич иде. Аның Михаил Михайловичлыгы ун класс бетергәнлекне раслаган аттестаттан башланды. Мейер Моисеевич килеш калган булса, ОВИМУ (Одесское высшее инженерно-мореходное училище) аның төшенә дә кермәс иде. Ә инде пароходчылыкның иң зур, иң яңа корабы белән командалык итү – бусын иң абстракт фантазия сюжетына да сыйдырып булмас. Совет чынбарлыгында «бишенче пункт»ның гамәлгә ашып торуы – корабка дошман кулына элгү куркынычы килгәндә, аны диңгез төбенә батырып котылуга тиң иде.

## 7

Сорау алуны Зиминга иң астан, моторист Ясиненкодан башларга кирәк иде. Капитан аны каютасына чакыртты. Ишек шакыдылар.

– Әйе, керегез.

Башын ия төшеп, ишектән буе ике метрга җитә язган таза, матур егет килеп керде.

– Утырыгыз.

Ясиненко диванга килеп утырды. Мотористның әтисе Азов диңгезендә балык тоту белән шөгыльләнгән сейнерның капитаны икәнлеген Зимин белә иде. Тәмле ашап, муллыкта үскәнлеге күренеп тора. Халык телендә мондый кешегә «чиертсәң каны чыгарлык», дип әйтәләр.

– Минем шуны беләсем килә. Син теге вакытта нигә кингстонны ачарга теләмәдең?

[20] ГКЭС – Госкомитет по внешним экономическим связям (Тышкы икътисади бәйләнешләр дәүләт комитеты).
[21] ГИУ – главное инженерное управление. Вазифасы – «кайнар нокталарга» корал озатып тору.
[22] Шипчандлер – чит ил корабларын азык-төлек белән тәэмин итүче.

Моторист бертын стенадагы барометрга карап утырды.

– Ача алмадым.

– Көчең җитмәдемени?

– Көчкә зарланырлык түгел. Ул бар миндә. Никадәр тырышып карасам да ачылмады.

– Тутыккан булып чыктымыни? Ул бит ачылырга тиеш.

– Өлкән механик белән без аны ачтык. Тикшергәннән соң, мин вентильне кире якка борганмын булып чыкты.

– Рахманкулов эшегезне тикшереп тормадымыни?

– Торды. Ачылмаганны күргәч, ул әле лом алып килергә кушты. Лом алып килгән арада, ачмаска кушып, отбой бирделәр.

– Одессага кайткач, мин биргән сорауларны кабатлаячаклар. Син аларга да миңа әйткәннәрне кабатларсыңмы?

– Аларга башкача әйтергә кирәкмени?

– Аларга дөресен әйтергә кирәк. Аңлашылдымы?

– Аңламаска.

– Ярый. Мин сезнең җавабыгызны магнитофонга яздым. Сорау алучыларга башкача сөйләсәгез, сезне ялганчылыкта гаепләячәкләр. Шуны аңлыйсыңмы?

Шушы таза, матур егет бер генә мизгелгә шиңеп, бәләкәйләнеп киткәндәй булды. Капитан әйткән сүзләрнең тел очында калган эчтәлеге – сорау алучыларның кайсы, нинди оешмадан булачаклары, күрәсең, мотористка да барып җитте.

Капитан икенче штурман белән дә тиешле дәрәҗәдә сөйләшмәгән иде. Ул да, моторист шикелле, эшнең нәрсәдә икәнлеген аңлап бетермәгәнгә охшый. Чиктән тыш каты тетрәнү аркасында югалып калган Ясиненко кингстон вентилен, ачу ягына борасы урынга, кирегә, ябу ягына борган. Аның ялгышуы егерме-утыз миллион доллар торган корабны, күп миллионга төшкән дүрт ракетаны, экипаж әгъзаларының утыз дүрт, гаскәриләрнең бер йөз сиксән ике гомерен саклап калу – секретный инструкция белән чагыштырганда, арзанрак иде. Батып үлгән булсалар, алар держава каршында башка телгә тәрҗемә ителми торган «подвиг» эшләүче саналырлар иде, исән калу аларны трус, ант бозучыга әверелдерә. Диңгезчеләр телендә «контора глубокого бурения» дип аталган КГБга ике йөз уналты кешенең гомере, аларның балаларының ятим, хатыннарының тол калуы, кораб белән ракеталар бәясе белән чагыштырганда, «совершенно секретно – государственной важности» дип аталган боерыкның сер булып саклануы кыйммәтрәк тора. Ике йөз уналты совет бәндәсенең гомере белән күп миллионлык дәүләт мөлкәтенең кыйммәтрәк икәнлеген дәлилләп булмаячагын аңлау Зиминны ниндидер нәфрәтле шом салып куркыта иде. Дөрес, пароходчылыкта, морфлотның үзендә, хәтта тагын да өстәрәк Зиминны яклаучылыр бар. Лубянкага каршы торырга аларның көче җитәрме икән?

«Совершенно секретно – государственной важности» боерыгының үтәлмичә калуына капитанның яшерен тамгасы – «бишенче пункт» өстәлгәч, эш тагын да катлаулана. Икенче штурманга да «бишенче пункт» мөһере сугылган. Бусы да катлаулы. Төнге вахтадан соң Рахманкулов йоклап ял итәргә тиеш иде. Икенче штурманны сорауга чакырыр алдыннан капитан шушы турыда баш ватып утырды.

– Хәерле көн! Ашарга барыр алдыннан миңа кереп чык әле. Сүзем бар, – диде капитан Рахманкуловка телефон аша.

– Хәзер керәм.

Ун-унбиш минут үтүгә, Габдрахман капитанның каютасында иде.

– Мин сиңа бу сорауны бирдем дә шикелле: мотористның кингстон вентилен кире якка боруын күрмәдеңме, әллә күрә торып кисәтмәдеңме?

– Күрә торып кисәтмәдем, Михаил Михайлович. Эш менә нәрсәдә. Ясиненко сулагай. Кичә ул минем каютама душның кранын төзәтергә кергән иде. Сул кулы белән эшли. Аның шөреп борганын күргәч, мин шуңа төшендем: сул кул белән эшләгәндә, вентильне ачар өчен, ябу ягына борырга кирәк икән.

Капитанның битенә елмаю йөгерде.

– Чыннан да, бу хәл дикъкатькә лаек. Син Ясиненкодан корабның берәр вентилен бордырт. Кингстонныкын түгел, билгеле. Җентекләп тикшер. Одессада безнең тырнак астыннан кер эзләячәкләр. Җавап бирергә әзер тор. Аңладыңмы?

– Аңламаска. Әле кичә генә йокыга китәр алдыннан уйлап яттым. Без, утыз дүрт диңгезче, Александр Матросовның геройлыгын кабатларга тиеш булганбыз. Матросов шәрә күкрәге белән дошманның пулемёт утын каплаган. Әгәр һәр солдат, Матросовның батырлыгын кабатлап, күкрәге белән амбразура каплый башласа, сугышыр кеше калмаган булыр иде.

– Сугыш темасы мине нигәдер кызыксындырмый. Мин җилкәнле флот чорындагы диңгезчеләрнең мемуарларын укыйм. Шуларның бөек гамәлләре хәйран калдыра. Безгә нигә шулай сокланып карауларын аңларга тырышканың бармы синең?

Рахманкулов бертын уйланып торды. Аның һавада очуына да сокланалар иде югыйсә. Теләсә кем, тоташтан, Рәсәйнең басып алуларына, җиңүләренә пропаганда таләп иткәнчә соклана иде. Егетнең диңгезләр кичүенә зыялыраклар, ирек сөючеләр, «тимер пәрдә» артында нәрсә бар икән, дип кызыксынып яшәүчеләр соклана иде.

– Безгә баш иючеләр риясыз Магелланнар, Христофор Колумблар, Джеймс Куклар шикелле гигантларның данын өсти. Шуңа күрә дә безнең социалистик ярыш аларга соклангыч тоела.

– Михаил Михайлович, бер тапкыр мин сезнең Чарльз Дарвинны сәяхәттә йөрткән капитан Фицройның язмаларын укыганыгызны күрдем. Сезнең тагын шундый китапларыгыз бармы?

– Күп алар.

– Берәрсен, әйтик, капитан Джеймс Кукның көндәлекләрен укырга биреп тормассызмы икән?

– Ул китапларны мин сезгә үзем тәкъдим итмәкче идем.

– Рәхмәт. Мин китапны таушалдырмыйча, саклап укыйм.

– Сиңа, чыннан да, аларны укырга кирәк. Ансыз инглиз телен ныклап үзләштереп булмый.

– Инглизчәмени ул китаплар?

– Арада французчалары да бар. Күбесе инглизчә. Телисеңме-юкмы, иң элек сиңа инглизчә укырга кирәк. Портларда торганда, без әз-мәз сөйләшеп алабыз. Телне үзләштерү өчен ул гына җитми. Әдәби әсәр укырга кирәк. Башкача булмый.

**8**

«Академик Крупчатов», төяп алып килгән йөген бушатмыйча, кайтыр юлга чыкты. Диңгезчеләрнең күңелендә яшәүне агулап торган авыр киеренкелек хөкем сөрә иде. Корабның, аның экипажының язмышы кыл өстендә булуын

капитан үзе, помполит, икенче штурман һәм моторист Ясиненко гына белсә дә, әлеге сернең аларда гына калырга тиешлеге турында капитан Зимин катгый кисәтеп куйган булса да, без капчыкта ятмаганлыктан, икенче көнне үк экипаж әгъзалары бу турыда белә иде инде. Хәбәрне диңгезчеләр каян ишеткән? Аларның хәбәрдарлыгы КГБга да барып җитәчәк. Чара күреләчәк. Ничегрәк күреләчәк бу чара? Әлеге сорауга җавап эзләүче Советлар Союзында тетрәндергеч эз калдырган утыз җиденче елларга, Ежов, Берия, аларның терсәктән канга баткан кулларын эшкә җигеп торучы бөекләрнең бөеге Иосиф Сталинның «изге» гамәлләренә күз салырга тиеш. Дөрес, партиянең егерменче съездында Никита Хрущёв совет халкының җирдәге Алласы Сталинның дистәләгән миллионнарга Газраил булуын, Ватан сугышы дип аталган үтерештә Мәскәү белән Берлин арасында козгыннар азыгы булып ятып калган солдат сөякләрен таратып ташлавын фаш итте. Фаш итте, әмма Рәсәйнең, Явыз Иван чорыннан башлап, халкын ач-ялангач тоткан хәлдә, бар көч-егәрен, тапкан малын кан коюга һәм күрше дәүләтләрне дер калтыратып тотуын үзгәртә алмады. Америка кыйтгасына үлем яудырыр өчен алып барган ракеталарның СССРга кире кайту сәбәбен аңлауны капитан Зиминнан башка диңгезченең зиһене күтәрә алмый иде. Эштән тәмәке көйрәтергә туктаган арада, кичләрен «морская травля» ләчтитен куертканда, диңгезчеләрнең авызында даими бер фикер: «Без нәрсә, шул акча коллары янкилардан курыктыкмыни? Сәясәт дилбегәсен маршал Жуков кулына тоттырсалар, укытыр иде янкиларның арт сабагын! Хрущёв бит ул кукуруз үстерүдән башканы белми...» кебек сүзләр ишетелеп торды.

Кара, Мәрмәр, Урта диңгезләрне, Атлантик океанны ике тапкыр гизеп чыгар өчен, Баулы районының трактор-комбайннарына, барлык йөк машиналарына ике елга җитәрлек ягулыкны исраф итеп, хезмәт ияләренең авызыннан соңгы сынықны тартып алып, ярым ач, ялангач диярлек яшәтү бәрабәренә ясалган континенталь ракеталарны океаннар артына илтеп-кайтарып йөрүгә Габдрахман Рахманкуловның да җаны сыкрый иде.

«Академик Крупчатов» португалларның Мадейра атавы яныннан узып килә иде. Буйга илле җиде, аркылыга егерме биш мильгә сузылган – вулкан атудан барлыкка килгән утрау. Уртача еллык температура биредә плюс егерме биш градус чамасы. Кышның иң салкын көннәрендә җылылыкның егерме өчкә төшүе, җәйнең иң эссе чакларында егерме җидегә күтәрелүе мөмкин. Мадейралылар мичкә ягып, өй җылытуның нәрсә икәнлеген белми. Итальяннар елына ике тапкыр уңыш җыя алулары белән горурлансалар, бу утрауда уңышны өч тапкыр җыялар.

Рахманкулов бинокльдән көрәнсу-кара биек кыяларга, җимешләренең авырлыгыннан сыгылып төшкән агачларга карап соклана иде. Атау эченнән һавага вертолёт күтәрелде дә корабка таба очып килә башлады. Габдрахман капитанга шалтыратты.

– Безне фотога төшерергә киләләр, – диде Рахманкулов, вертолётка күрсәтеп.

Капитан биноклен алды, корабка якынлашып килгән геликоптерны күзәтеп торды да аңлатты:

– Без, Габдрахман Бәкерович, тарихка кердек. Американың һәм Европа илләренең радиостанцияләре безнең турыда көне-төне гайбәт сата. Кайсыдыр газета, корабның рәсемен беренче биттә бирү өчен, вертолёт яллаган. Гибралтарны, Мессина бугазын, Босфорны караңгыда узарга туры киләчәк.

Одессада безне нәрсә көтә торгандыр? Гаебемне яшерергә теләмим, Куба урынына Кытайга ашлама илтү мөмкинлеге бар иде. Андагы хәерчелекне күрәсем килмәгәнлектән Кубаны сайладым.

Капитанның йокы бүлмәсендә зур «Sony» магнитоласы тора иде. Шуның ярдәмендә төннәрен чит телләрдәге тапшыруларны тыңлый булса кирәк. Чыннан да, аның күрәзәлеге хак булып чыкты. Гибралтар бугазына кораб төн урталарында килеп керде. Гадәттә, көндез Урта диңгездән океанга чыккан һәм Атлантикадан Урта диңгезгә таба йөзгән кораблар күбрәк була. Бу юлы «Академик Крупчатов»тан алдарак өч һәм арттарак ике кораб бугаз эченә кереп килә иде. Каршы яктан бары ике генә кораб йөзеп бара. Бугаз эчен үтеп, Урта диңгезгә килгәндә, Гибралтар портыннан чыгып, «Академик Крупчатов»ны куып җиткән катердан прожектор ут көлтәсе корабның сул як бортына килеп бәрелде дә сүнде. Мотор такылдаган тавыш һаман көчәя, якыная иде. Кабынып кинәт сүнә торган фотовспышка утлары корабны чорнап алган караңгылыкны ерткалый башлады.

– Вашу мать! – диде капитан, ачы сүгенеп. – Безгә пресса помойкасына гына эләгү җитми иде!

Дүртенче атна бергә эшләү дәверендә Зиминның беренче тапкыр «урыс дога»сын каударланып укуы иде.

– Шушы гына җитмәгән иде безгә! Корабны клотиктан[23] алып кильгә[24] кадәр солдат нәҗесенә батыру, күршеләр тырнагына[25] эләгү. Хәзер безне чит ил газеталарының гаугалы беренче битләренә теркәп пычратачаклар.

Капитан дөрес әйтә иде. Босфор аша үткәрү өчен килгән төрек лоцманы лоцботтан «Крупчатов»ның палубасына аяк басу белән, рубканың ачык тәрәзәләреннән фотообъективны яктырткан утлар яшен тизлеге белән кабынып сүнә башладылар. Чит ил радиостанцияләренең тапшыруларын даими тыңлап барган капитан совет иле корабы белән шулай ярсып кызыксынуның сәбәбен яхшы белә иде. «Академик Крупчатов» Кубага килеп җитәр алдыннан 24 октябрьдә урыс совет зенитчиклары Куба өстеннән очып йөргән разведчик очкычны бәреп төшерделәр. АКШ президенты Джон Кеннеди мобилизациягә әзерләнергә боерык бирде. АКШ президенты белән генсек Хрущёв арасында сөйләшүләр башланды. Өченче бөтендөнья сугышы кабынуга бер, бары тик соңгы адым гына калган иде. Кеннедидагы зыялылык һәм киң караш, Хрущёвтагы сугыш тәмугын фронт шартларында кичерү тәҗрибәсе – менә шушы сыйфатлар кешелекне яңа кан коюдан коткарып калды.

**9**

Оксана больницадан төш вакытында чыкты. Гипска катырылган җилкә инде төннәр буе йокы бирмичә интектереп сызламый иде. Киләсе атнада аны ләгънәтле гипс золымыннан коткарырга тиешләр. Ул базардан кәбестә, суган, чөгендер алып кайтты. Хуҗа хатын эштә. Күнегүләр залына барасы, хәлдән таеп, күз алларың караңгыланганчы күнегү ясап чиләнәсе юк. Чәй эчеп алырга да Бульвардагы каштан яфраклары астындагы бер эскәмиягә утырып, күзләр талганчы, диңгезнең сихерле зәңгәрлегенә карап ләззәтләнергә дә була...

«Диңгез» Дадоновларда танышкан егетне хәтер түреннән актарып чыгарды. Менә шушы минутта кайларда икән ул?

[23] Клотик – мачтаның очы.
[24] Киль – корабның төбе.
[25] КГБны йомшартып, шул ук вакытта аларның кем икәнлекләрен яшерен әйтү.

Танышканнан соң, адресымны сорап алды. Хаты да юк, хәбәре дә. Диңгезче бит... Аларның порт саен сөяркәләре бар, дип сөйлиләр. Евгениянең әтисе ул егетне үтереп мактый.

Аның исенә Женяның кисәтүе килеп төште. Ул... кем әле, Габ... Габдрахман... Исеме – телеңне сындырырлык. Женя ул егетнең элемтә тотарга рөхсәт ителми торган секретный рейска китүе турында әйткән иде. Шуңа күрә хәбәрләшергә ярамыйдыр.

Оксана газ яндырды, су кайнатырга куйды да тумбочканы ачты. Шикәр савыты тулы, бер атнага җитәрлек. Чәй савыты яртылаш. Ипи катып, сохарига әйләнеп беткән, ярты телем калган. Кибеткә барырга кирәк. Ул акча саклана торган сумкасын ачты. Өч сумлык кәгазь һәм сумнан артык вак акча калган. Стипендияне ай ахырында бирәләр. Дөрес, стипендия акчасына күлмәк тә, хәтта оек та алып булмый. Әмма ипигә җитә. Хәер, менә ярты ел инде студентлар ашханәсендә ипи түләүсез. Аның шул түләүсез ипине кызларның сумкага салганнарын да күргәне булды. Андый эшкә Оксананың кулы бармый иде. Ул ипине ашаганда, эчеңне ачыттырып, кимсенүнең әчкелт тойгысы кабынып китүен сизеп аласың. Түләүсез ипине коммунизмның туа башлавын раслаучы ышанычлы дәлил, дип аңлаталар иде. Оксана киләчәктә бар нәрсәнең дә бушлай булачагына, никадәр уйласа да, ышана алмый иде. Әкиятне хәтерләтә иде бу ымсындыргыч вәгъдә.

Ишек шакыдылар. Шәһәрдә ничә ел яшәп, Ярёменко: «Кем бу?» – дип сорарга өйрәнә алмады. Ишектән Оксананың тренеры Светлана Аркадьевна килеп керде:

– Ниһаять! Кочакларга ярыймы? – дип сорады ул һәм, кызның имгәнмәгән кулы ягыннан килеп, күкрәгенә кысты. – Синсез спортзалда ямь юк, эшемнең тәме юк. Слава Богу, озакламый эшли башлыйбыз.

Спорттан ваз кичүе, тренировкага йөрүдән баш тартырга вәгъдә бирүе турында Оксана әйтми торды, бәхәс китүеннән куркып тыелды.

Светлана сумкасыннан өстәлгә күчтәнәчләр бушатырга тотынды. Торт килеп чыкты, бербөтен колбаса, фольгага төрелгән май, ниһаять, Одесса янындагы Таиров институтында әзерләнгән бер шешә вино.

– Сез нәрсә, әллә әбиегез васыять итеп калдырган акчаны алдыгызмы?

– Торт һәм вино Владленнан, – Светлана кәгазь төргәкне сүтеп, җиде ак розадан ясалган чәчәк бәйләмен алды, пыяла вазага су салып, өстәлгә куйды. Вазага утыртканда розалар арасыннан хат килеп төште.

– Укы. Минем инде ун ел чамасы шундый кайнар хат алганым юк. Картайдым.

Оксана хатны этажеркадагы китап эченә тыгып куйды:

– Киевта шундый запискалар җибәреп җанымны алдылар. Адәм көлкесе – автограф сорыйлар. Мин бит Лоллобриджида түгел. Ярышка килгән кызларның чибәррәкләрен айгыр түрәләр түшәкләренә сөйри башлады. Катнашмыйм мин андый ярышларда. Спортны да ташлыйм. Тыныч яшисем килә. Ярышсыз, дәгъвалашмыйча яшисем килә.

– Нәрсә әйтим? Дура син, Оксана. Мин, синең тренерың, ярышларга йөргәндә, аяк-кулларымны, ким дигәндә, егерме тапкыр имгәттем. Бала табудан мәхрүм калдым, ярыштан ярышка йөреп, гаилә кора алмадым. Яшьлекне кайтарып булса, бер генә минут та икеләнеп тормыйча, шул ялгышлыкларымны кабатлар идем. Спорт ярышы ул, сеңелкәем, яшәүнең чын мәгънәсе. Һәр кеше гомерен ярышып үткәрә. Яшәү ул, Оксюша, ир белән хатын арасында өстенлек

өчен ярыш, мәктәптә «бишле» билгесе өчен, эштә, үзең беләсең, социалистик ярыш. Күзеңне ач, сеңел, тирә-ягыңа кара, җир йөзендә ярышсыз җир юк. Бәлки, кабердә бардыр? Аннан чыгып сөйләүче булмагач, белмибез.

Чәйгә утырдылар. Светлана:

– Ипиең кайда? – дип сорады.

– Әле чыкканым юк. Алып кайтыйммы?

– Ялганлама. Акчаң беткән синең. Ач йөргәнеңне ничә тапкыр күрдем. Кабат әйтәм. Дура син, Оксана! Дурочка! Владлен Семёнович круизга барырга билет тәкъдим иттеме? Дөресен әйт: круизга чыгуны оештырам, дидеме?

– Әйтте. Люкска урнаштырам, диде.

– Ә син? Син риза булдыңмы? Әйт, яшермә.

– Баш тарттым.

– Чөнки син дура набитая. Идиотка. Шундый ымсындыргыч бүләктән кем баш тарта? Кем?

– Дура булсам да аңлыйм мин. Бу дөньяда бушлай бирелә торган бернәрсә дә юк. Син һәр алган нәрсәнең хакын түләргә тиешсең. Лебедевның путёвка өчен нәрсә белән түләтәсе килүен дә аңлыйм мин. Аның мине түшәккә яткырасы килә. Аңладыңмы?

– Ятсаң, укаң коелырмыни? Бер селәгәй егет, куак астына сөйрәп кертеп, синнән шул Владлен Семёнович сораганны барыбер алачак. Син шуны көтеп яшисеңме?

– Мин чын ярату көтәм.

Светлана Аркадьевна көлә башлады.

– Мин дә көттем аны. Нәкъ синеңчә. Юк ул чын ярату. Чын алдашу, яраткан булып күз буяу гына бар. Бу дөньяда һәркем үз файдасын, рәхәтен эзли. Онытa язганмын. Син миннән егетеңне яшереп йөрисең икән. Кем ул? Нигә күрсәтмисең?

– Кайчан, ничек күрсәтим икән? Аны мин үзем дә бер генә тапкыр күрдем.

– Кайда соң ул?

– Диңгездә.

– Морякмыни? Гади матросмы, әллә штурманмы?

– Кем белгән. Ул мине Евгениянең фатирыннан шушы йортка кадәр озатып куйды да югалды.

– Алар шундый инде. Бүген – бар, иртәгә – юк. Ул егетнең милләте кем? Шуны беләсеңме соң?

– Русча дөрес сөйләшә. Милләтен сорамадым мин. Нинди аерма?

– Сине озатып кайткан егет, Оксюша, натуральный татарин. Теге – Россияне өч гасыр золымда тоткан татар-монгол. – Светлана Аркадьевна капылт кына китәргә җыена башлады. – Яныңа килсәм, дөньямны онытам. Миңа күренергә яшь кызлар килергә тиеш иде. Көтә торганнардыр.

Китәр алдыннан, тренер соравын кабатлады:

– Димәк, син круизга чыгып керергә теләмисең инде?

– Юк, теләмим, – диде Оксана, икеле-микеле уйларга мөмкинлек калдырмаслык итеп.

– Дурочка син. Үкенерсең әле. Соң булыр. Владлен Семёновичка иң зур, данлыклы Мәскәү актрисалары, зур түрәләр, министрлар баш ия, ә Одессада? Ул кешедән баш тарта алырлык кыз юктыр Одессада.

Оксана соңгы акчасына Дерибас урамындагы кибеттән ипи, колбаса алды. Сумкасында бәрәңгегә җитәрлек акчасы калды.

Иртән Евгения аңа теге егетнең корабы бүген Одессага кайтып җитәргә тиешлеген әйткән иде. Диңгез бульварына җиткәч, кыз Потёмкин баскычы буендагы эскәмиягә барып утырды да йөзүдән кайтып, портка кергән, порттан диңгезгә чыгып киткән корабларны күзәтергә тотынды. Әле бит Киевка китәр алдыннан гына Оксана өчен ул егет искә төшәр-төшмәс дәрәҗәдә генә иде. «Нәрсә булды миңа? Мин нигә аның турында уйлый башладым соң әле?»

**10**

Үзгәрмәс гадәткә әверелеп беткән эш иде бу. Дөрес, монда «эш» сүзен куллану дөрес түгелдер. Чит илләрдә йөреп кайткан корабны Зур Фонтанның унынчы станциясе траверсында лоцман каршы алып портка кертә, причалга куя. Пирска беркетү эше бетүгә, корабка таможенниклар, чик саклаучылар, шулар арасына яшеренеп, үзенең кем икәнлеген белгертмәскә тырышып, мыштым гына КГБ вәкиле килеп керә. Чикне ача башлыйлар. Корабта бар нәрсә ачык югыйсә. Диңгезче үз каютасын портта торганда гына бикли. Тентү, төрмә тоткыннары телендә «шмон» ясау, актарынып куркытып йөрүне «чик ачу» дип йомшартып әйтәләр. Бу илдә күп нәрсә үз исеме белән аталмый. Шмон ясап йөрүчеләр «Академик Крупчатов»ка унынчы станция турында ук утырдылар. Бу юлы тентүчеләр саны гадәттәгедән дүрт-биш тапкырга күбрәк иде. «Чик ачу», гадәттә, чит ил паспортларын җыеп алудан башлана. Чик саклаучы каютаңа керә, паспорттагы фотоны синең кыяфәтең белән чагыштырып карый. Ул чыгып киткәч, каютаңа тентеп йөрүче таможенник килеп керә. Бу юлы трансляция аша, каютадан чыкмыйча тикшерүче килгәнен көтеп утырырга боердылар. «Беркая чыкмаска» сүзен өченче штурман өч тапкыр кабатлап әйтте. Югыйсә, тентүчеләрне көткәндә, каютадан чыгып йөрмиләр иде. Кат-кат кисәтү, үзенә күрә, «чик ачу»ның бу юлы аеруча җитди икәнлеген белгертә иде.

Кораб эчендә авыр, ялыктыргыч тынлык. Әнә, переборкага беркетелгән сәгатьнең, текелдәп, гомереңне бакыйлык ягына озатып торуы ишетелә. Машина бүлегендә, палубаны дерелдәтеп, дизель-динамо көчәнә.

Шакымыйча гына ачып, ишектән таза, матур ир кеше килеп керде. Кыяфәте кавказлыга тартым. Куе кара каш астында тирәнгә урнашкан коңгырт-кара күзләр, кылыч борын, хатын-кызныкын хәтерләткән матур иреннәр.

– Исәнмесез, – диде ул һәм, сәлам алып тормыйча гына, – фамилия, отчество, исемегез? – дип өстәде.

– Габдрахман Бәкерович Рахманкулов.

– Эсминецлар туктарга боерык биргәндә, кингстонны ачарга капитан сезне җибәрдеме?

– Минем белән моторист Ясиненконы җибәрде.

Сөаль алучы күзләрен туры Габдрахманга текәгән. Күзе белән аның битен бораулый.

– Капитанның боерыгын үтәүдән баш тартуыгызның сәбәбе нәрсәдә?

– Гафу итегез. Нинди боерык турында сүз бара? Кингстонны ачу турындамы?

– Так точно, корабның кингстонын ачу турында.

– Аны бит мин ачмадым, моторист Ясиненко ачты.

Тикшерүче карашын Габдрахманның күзләренә шактый озак текәп торды. Бер-береңнең күзенә туры, текәләп карап торганда, ике кешенең берсе түзә алмый, тайпыла. Рахманкулов түзәргә тырышты. Тайпылса, сорау алучы ялганлый дип уйларга мөмкин иде.

– Давай, ачыклыйк. Кингстонны ачу сезгә йөкләнгән булган. Ясиненко

гади эшне гамәлгә ашыручы исполнитель генә булган. Сез, Га... Гаптрахман Рахманкулов, нигә кингстонны ачарга биргән боерыкны үтәмәдегез? Ике эсминец як-яктан кыскан чакта обстановка фронт шартларына тиң булган. Фронтта командирның боерыгын үтәүдән баш тарткан сугышчыны нишләтәләр?

– Атып үтерәләр, – диде Рахманкулов һәм өстәде. – Тикшереп тә тормыйча, суд ясамыйча, хөкем чыгармыйча атып үтерәләр. Мин моны яхшы беләм. Ә сез... Сез үзегезнең кем икәнлегегезне әйтмәдегез...

– Это неважно. Мин ватанның иминлеген саклый торган оешмадан. Фамилияне белү сезгә мөһим булса, әйтик, мин Иван Иванович Иванов.

– Иван Иванович, сезнең вазифагызның җитдилегендә шигем юк. Монда кечкенә бер несоответствие бар. Мин хәрби түгел, мин сәүдә флоты штурманы һәм миңа кингстон ачарга боерык биргәндә, сугыш шартлары юк иде.

– Бу, иптәш Рахманкулов, чиста демагогия. Сезгә илләргә йөрү эше йөкләнгән. Капиталистик чорналышта эшләп йөрү – шул ук фронт. Сез моны аңларга тиеш идегез. Мин сезгә егерме минут вакыт бирәм, – Иван Иванович портфеленнән бер бит кәгазь чыгарып, өстәлгә куйды. – Кингстон ачарга бирелгән приказның нигә үтәлми калуын подробно языгыз. Комачауламас өчен, мин сезне егерме минутка ялгыз калдырам. – Ватанның иминлеген саклаучы чыгып китте.

Габдрахманның кечке мәктәпне бетергәндә язган сочинениесенә «биш»ле куйганнар иде... Ул хәзер язып акланырга тиеш иде. Күңелдә дөм бушлык. Нәрсә язарга? Ясиненко вентильне кире якка борганын ул чыннан да аңламады. Зиһен чуалган иде. Ярты сәгатьтән ул башкалар белән бергә су астында калып тончыгырга тиеш иде... Күрү һәм аңлау сәләтен үлем алды тетрәндерүе чуалткандыр инде. Моны бит аңлап булмый.

Габдрахман капитанның корабны батырырга кушкан боерыгын, кингстон ачарга төшүләрен һәм Ясиненконың, ялгышып, кире якка боруын язды.

– Яздыгызмы? – Иптәш Иванов Габдрахманга тагын бер бит кәгазь сузды.

Анда эре, басма хәрефләр белән язылган:

«Мин, Ф.И.О., «Академик Крупчатов» теплоходының ...ны корабның Кубага илткән йөге, аның Ангила утраулары янында АКШның агрессив кораллы көчләре тарафыннан һөҗүмгә юлыгуы һәм шушы рейста булган вакыйгаларның дәүләт сере булуын тулысынча кабул итәм. Шушы серне кемгә дә булса ачкан очракта җавапка тартылачагымны аңлыйм һәм серне сакларга ант итеп вәгъдә бирәм. Фамилия. Имза. Дата.»

Шушындый кәгазьгә һәр экипаж әгъзасы кул куйганы билгеле иде.

Чыгып китәр алдыннан «Ак йорт»[26] вәкиле кабат кисәтте:

– Аңлагансыздыр дип ышанам. Кингстонны ачу мәсьәләсе ачыкланып бетмәгән.

## 11

Комиссия чикне ачмады. Экипаж әгъзаларының хатыннары, балалары ярда калды. «Академик Крупчатов» алып кайткан йөген бушатырга Балабановкага юл тотты.

Балабановкада Рахманкуловны корабның штаттагы икенче штурманы көтә иде. Капитан Зиминга да алмаш җибәргәннәр. Бу хәл егетнең күңеленә шом

[26] Кара диңгез пароходчылыгы моряклары КГБны шулай атап йөртәләр иде

салды. Аны үз пароходы «Чолман»га кайтарырга телиләрме, әллә корабны батырмыйча калдыру җинаяте өчен җәза бирәләрме?

Ул үзенең нинди дәүләттә яшәгәнлеген яхшы аңлый иде. Советлар Союзына әверелгән Рәсәй империясе тарих битләрен канга батырып бетергән сугышлардан яралган. Шуңа күрәме, бу дәүләт сугышларда җиңә. Зурлыкның бер уңайсыз ягы бар иде. Бу илдә көнкүреш корып булмый иде. Әнә, космоска спутниклар чөя. Водород бомбалары белән җир шарын дер селкетеп тора, ә үзенең адәм рәтле джинсы чалбар тегәргә дә кулыннан килми. Корабны, аның экипажын, сугышырга барган мескен солдатларны, миллионлаган акча түгеп ясалган ракеталарны суга батырмаган өчен, Габдрахманны хөкемгә тартырга әзерләнәләр. Ракеталарны бушатмыйча кире кайтару корабның командасына «военная тайна», «совершенно секретно» санала, шул ук вакытта шушы сер Көнбатыш илләренең газета битләрен тутырган, аларның радиостанцияләре көне-төне Совет иленең сәүдә флоты Кубага ракеталар ташып торуы турында хәбәр тарата. Баштанаяк ялганга, күз буяуга корылган дәүләтнең киләчәге бер дә күңелне җылытырлык түгел иде.

Вахтадан алышынгач, Рахманкулов йокларга ятты. Нык арытканмы, әллә нервларның артык киеренкелегеме, нидер йокыга китәргә ирек бирми иде. Соңгы көннәрдә кичергәннәрне күз алдыннан үткәреп уйланып ятканда, күңелгә тузга язмаслык килбәтсез фикерләр килә. Әйтик, капитанның сейфында сакланган теге секретный боерыкны эшкә ашырып, алар кингстонны ачтылар, ди. Кораб, ракеталар, бу илдә бәяләре сукыр бер тиен саналган экипаж әгъзалары, солдатлар батып үлделәр, ди. Дәүләт мордарларының толларына, аларның ятим калган балаларына әтиләре үлемен ничек аңлатырлар иде икән? Шушы фаҗига газеталарда ничек яктыртылыр иде икән?

Хакимият сыртындагы түрәләр кавеме яшерергә тырышыр иде. Урыста кырын эшне халыктан яшерүне аңлаткан бер әйтем бар: «Концы в воду». Ә инде Көнбатыш вакытлы матбугатта, радио-телевидениедә бу вакыйганы совет кешесенә килеп җитәрлек дәрәҗәдә яктырткан очракта, су астында тончыгып үлүчеләрдән Александр Матросов ясарлар иде.

Шул шәрә күкрәге белән пулемёт утын каплаган мәрхүмнең шәүләсе инде дистәләгән еллар Габдрахманны эзәрлекли иде. Башта, армия хезмәтендә Рахманкулов үзенең җан сердәше Рәшит Агишев белән мәрхүмнең «подвиг» дип аталган батырлыгына сокланган чорда: «Андый батырлыкка, гадәттә, татар әвәс. Матросов безгә милләттәш түгелме икән?..» – диешкәннәр иде. Юраган юш килде – Александр Уфа шәһәрендәге балалар йортында тәрбияләнгән Шакирҗан исемле ятим булып чыкты. Политдәрес алып баручы капитан Урсулякка: «Матросовның батырлыгын һәр совет солдатына үрнәк-өлге, дип аңлаталар. Әгәр аның үрнәгендә бөтен сугышчы фашистларның пулемётларына күкрәге белән ташланган булса, немецләргә каршы сугышыр кеше калмаган булыр иде», – дип әйтәсе, шуңа Лев Толстойның «Патриотизм – последнее прибежище негодяя» дигән сүзләрен дә өстисе килгән иде. Ярый әле, телен тешләп, чыгыш ясаудан тыела алды.

Әмма бу фикерен ул кайдадыр ычкындырган булып чыкты. Матросов турындагы әңгәмәдән соң ике тәүлек үтүгә, Рахманкуловны «смерш»ка (смерть шпионам!) чакырдылар. Җир йөзендә моннан да мәкерле көч булдымы икән? Ул чакта аны тәүбә итү коткарып калды. «Башка кабатламам мин бу сүзләрне», – диде ул арт саны җиргә тия язып йөргән тәбәнәк буйлы капитанга. «Мин бит сугышта җиңеп чыгу өчен, дошман белән беренче очрашуда ук үләргә ярамый;

сугышырга кирәк, башка мөмкинлек калмаган очракта гына батырларча үләргә тиешбез», – дигән идем. Сезгә нинди мәгънәдә килеп җиткәндер, миңа мәгълүм түгел».

– Безгә ул, син телеңне тыя белмисең, мәгънәсендә килеп җитте, – диде кыска аяклы капитан.

Армиядә ул, «смерш» тырнагыннан шактый җиңел котылып, исән кала алды. Бу юлы Габдрахман егыласы җиргә, армиядәге шикелле, фәрештә канатын җәярме икән?..

Йөкне төялгән җиренә илтеп бушатыр алдыннан чикне ачтылар. Йөкне бушатканда, докерлар: «Нигә ракеталарны кире алып кайттыгыз?» – соравы белән Рахманкуловның теңкәсен корытып бетерделәр. Башта җавап кайтармады. Соңга таба: «Аларга бәләкәйләргә кирәк булган, без, уйламыйча, артык зурларын илткәнбез», – дия башлады.

Гомумән, эшче сыйныфы вәкилләре – актив халык. Алар бит радиосын тыңлап, телевидениесен карап, газетасын укып тора. Газета битләрендә, һичшиксез, Никита Хрущёв белән Джон Кеннединең очрашып килешүен укыганнар яисә радиодан ишеткәннәр, соңгы чиктә, эштән туктап, тәмәке көйрәткән чакларда үзара фикер алышмыйча калмаганнар.


Йөк бушатылып беткәч, «Академик Крупчатов» Николаев портына кереп, причалга туктады. Корабка экипаж әгъзаларының хатыннары, бала-чагалары ургылып керә башлады. Ирләрен кочаклап елаган хатыннарга Кубага барып җитәр алдыннан булган вакыйга турында сорап торасы юк иде. «Без капчыкта ятмый», – ди татар мәкале. Фаҗигале хәбәрне дә «секретно», «совершенно секретно», «секретность государственной важности» мөһерләре генә яшереп саклый алмый, күрәсең.

Николаевта ягулык, эчә торган су, азык-төлек һәм техснабжение алганнан соң, кораб Новороссийск портыннан, Япониягә илтер өчен, бодай төяргә тиеш иде. Ничә ел дөнья гизеп, Рахманкуловның Япон илен күргәне юк иде. Әлегә бу насыйп түгел иде булса кирәк. Николаевта аны алмаш штурман көтеп тора иде. Матди яктан файдалы рейсларга кадрлар бүлегендә эшләүчеләрнең «кулларын майлый» белүчеләр йөри. Әнә, аның штатный корабы Италиягә барырга наряд алгач, Рахманкуловның урынын «майлау» остасына бирделәр. Әгәр эш ришвәттә генә булса, вөҗданыңның бугазын кысып, әкренләп күнегергә дә булыр иде. Татар бит ул күнегергә оста. Әнә, колониаль коллык таләпләренә ничек күнеккәнбез. Армия шартларында хәрби боерык – приказ үтәүдә татар белән кайсы милләт вәкиле ярыша ала?

«Чиреннән» терелеп, үз корабына кайткан штурманга эшен тапшырганда, аның күңелен менә шушындый сафсаталар әрнетеп тырнап торды.

Капитан Зимин Одессага кайтырга такси чакырган иде. Машинасына ул Рахманкулов белән Ясиненконы да утыртты. Гадәттә, корабтагы эшне тапшырып, Одессага кайтканда, иң-иң мокытларның да телләре ачыла иде. Алар юл буе сөйләшергә сүз таба алмыйча интектеләр. Күкрәк эчендә авыр таш булып, корабның батырылмый калу фаҗигасе һәм шул җинаять өчен җавап бирелергә тиешлеге ята иде.

*Дәвамы киләсе саннарда.*



Рәмис
Аймәт

# ЯТЛАР САЛГАН ЮЛДАН БАРМАДЫМ МИН...

## Рухка эндәшү

И Рух!..
Күтәрел син, әйдә,
Биеккә, югарыга.
Җитте вакыт сине дә бит
Коллыктан тугарырга.

Җиргә тамыр җибәрергә
Ашыкма, иртә әле...
Син – Тере суы, синсез бит,
Аһ, сулыр җанның гөле.

Син – Күкнеке! Күкләрнеке!
Боекма, җәй канатың.
Бар әле безгә очасы,
Канатларны канатып.

Бар әле безгә менәсе
Хыялым кыясына.
Ышанамын, шул кыяга
Исемем уясыма.

## Гыйбрәт булсын сезгә бу югалту...

*(Татар теленең хушлашуы)*

Яклап-саклап кала алмадыгыз,
Соңгы төнем бүген, мин китәм.
Упкыннармы, чоңгыл-сазлыклармы? –
Алда, белмим, мине ни көтә?!

---

Рәмис АЙМӘТ (1968) – *шагыйрь; «Шомырт салкыннары», «Айның арьягында», «Бозлы җилкәннәр» һ.б. татар, рус, төрек телләрендә дөнья күргән китаплар авторы. М.Җәлил һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Ера-ера тыгыз төн карасын,
Мин китәмен, йә, күр, татарым.
Канатларым канлы килеш китәм,
Күкрәгемә кысып аһ-зарым.

Телем тешләп китәм, авызыма
Шыплап тулган, тулган кара кан.
Түкерергә базмыйм, кара кандай
Тиздән туар җиргә яңа таң.

Ә ул инде... минем таңым булмас,
Ятлар хуҗа аңа, ят рухлар.
Ләззәтләнеп чөй-тамгасын сугар,
Сугар аңа карагруһлар...

Ана телен сайлап буламыни,
Сайрап буламыни ят телдә?
Тел карында туа, үз бишеге,
Тел-бишеге кирәк һәр гөлгә.

Бөек идем, боек килеш китәм,
Канлы сөрем баскан күзләрем.
Тылмачларсыз дөнья гизә идем,
Җуелдымы абруй, эзләрем?!

Ихтыярый ихтыярсыз тел мин,
Чит-ят бакчаларның читендә
Килмешәктәй үсәм, үз җирендә
Туфрак телән, имеш... читен лә...

И татарым! Нәрсә булды сиңа,
Синме соң ул чүплек өеме?!
Үз телеңне саклап кала алмадың,
Нишләдең син Чыңгыз кавеме?!

Рәнҗеп китәм... Йә, хуш, бөек халкым.
(Чабатаңны, әйдә, эл түргә!)
Күрмисеңме, мин-минлегең белән
Кереп барганыңны тар гүргә.

Күрмисеңме, якыная бара
Инкыйразның канлы офыгы?
Тоймыйсыңмы, тетрәп телгә килә
Шәҗәрәңнең һәрбер яфрагы?

Бабаларың дәшә. Күзләреңә
Тутырып баккан алар, күр әнә.
...Яргаланган канлы иренемдә
Соңгы сүзем, тыным тетрәнә.

Соңгы аһым гөлтли... гомеркәйне
Ай күрдеме, кояш алдымы?
Авызыма су салучы берәр
Татар әле җирдә калдымы?

Кабат кайтыр өчен... китеп торам...
Яна-яна мәхшәр утында.
Мин яшәрмен Аңда, Канда, хәтта
Чәчәк сабагының сутында.

Мин яшәрмен, мин дәшәрмен сезгә,
Җаны барлар мине ишетер.
Күңеленә тутык кунганнарны
Рәнҗешләрем минем өшетер.

Гыйбрәт булсын сезгә бу югалту,
Күрешербез, көтеп алырмын.
Юк, гарасат мәйданыннан түгел,
Үз дәүләтем мөнбәреннән беркөн
Бар дөньяга аваз салырмын.

***

Диңгез, диңгез...
Мин әле бу тагын,
Җеп тә өзәр хәл юк. Арылган.
Һич тә аңлашмаган гашыйклар күк,
Китәлмичә торам ярыңнан.

Китәлмичә торам. Минем дә бит
Уем – тирән, уем – шаулы җыр.
Төпләреннән һаман калкан кебек
Калкып чыга, чыга туган җир.

Күңел барыбер кайта үз ярына,
Җир тетрәсен, дөнья ярылсын.
Туган якның болын-тугайларын
Яраталырмынмы икән соң?!

Алып китим әле дулкыннарның
Тынмас шавын салып җаныма.
Шаулар алар кушылып туган якның
Олпат имәннәре шавына.

Диңгез, диңгез...
Без әйтерсең игез.
Бер анадан, бер үк карыннан.
Һич тә аңлашмаган гашыйклар күк,
Китәлмичә торам ярыңнан...

## Ялкаулык

Ялкаулыкны күңел утарыңа
Кертә күрмә ялгыш кына да.
Ялкаулык ул – бер залимдер, аны
Күпме генә сына, сынама...

Кире ишәк кебек муеныңа
Атланса ул әгәр беркөнне,
Иҗтиһатың качар, рухың сүнәр,
Күрәсең дә килмәс беркемне.

Ку син аны, кагылмасын килеп,
Хәтта келәсенә капкаңның.
Сизмәссең дә, аның тозагына
Ничек итеп килеп капканны.

Кол ит аны, күтәрмәсен башын,
Юкса, сине хәлдән тайдырыр.
Ирек бирсәң аңа, өстеңдәге
Соңгы күлмәгеңне салдырыр.

Ялкаулыкка колач җәябез дә
Сылтыйбыз без соңрак язмышка.
...Ялкаулыкны күңел утарыңа
Кертә күрмә хәтта ялгыш та.

## Еллар аша...

*Мин сине гомерем буена*
*Ышыклап барырмын җилләрдән.*
*Өзелсә барасы юлларың,*
*Үрермен мин күпер гөлләрдән...*
Яшьлек дәфтәреннән

Гомер буе сине җил-давылдан
Бaралмадым саклап, ышыклап.
Үрәлмәдем күпер гөлләрдән дә,
Булсак та без тугры гашыйклар.

Тормышыңа хәвеф янаганда
Сугалмадым чакырып мин набат.
Барыр юлларың да мең өзелеп,
Ялгангандыр инде мең кабат.

Мин аларның ләкин берсенең дә
Булалмадым тере шаһиты.
Бары еллар аша йөрәгемне
Телгәләде сөюең уты.

Бәлки, мине уйламыйсың дадыр,
Сагынмыйсың дадыр син бер дә.
Бәлки, барлык хатирәләрне дә
Күмгәнсеңдер күптән кабергә.

Синең өчен, бәлки, мин күптәннән
Кипкән елга, сүнгән учактыр.
Назларыңнан мәңге мәхрүм калган
Котып кебек салкын кочактыр.

Ә кем белә? Бәлки, йөрәгеңне
Үкенү газаплары теләдер.
Бәлки, язмыш, һаман сыный-сыный,
Качып кына бездән көләдер.
(Дәшмәвең дә бары горурлыгың,
Ялган тәкәбберлек кенәдер).

Ни булса да, бар да булган инде:
Һәрбер юлның хәзер үз юлы,
Ул юлларның үз юлчысы хәзер,
Үз тирәге аның, үз талы.

Тормышымда «Сөю» дигән җырның
Мәңге тынмас көмеш көе син.
Йөзләреңдә һәрчак нур балкысын,
Күзләреңдә бәхет биесен.

***

Үз-үзенә бер дә охшамаган
Табигать тә бүген нигәдер.
Күз яшьләрен түгеп, быелгы көз
Китмәскә дип, бәлки, килгәндер.

Үз-үземә мин соң охшаганмы?
Нәрсә булды, нәрсә бу җанга?
Гүя тәүге тапкыр күргән кебек,
Карап торам соры җиһанга.

Үз-үземне мин соң югалтаммы?
Әллә инде табам гынамы?
Озаккарак китте, озаккарак...
Бу тормышның мине сынавы.

Качыр мине, качыр, и Табигать,
Кочагыңа алчы син, әйдә.

Терәгем бул олпат, карт имәнем,
Ябалдашларыңны син җәй дә.

Ташлап барлык дөнья мәшәкатен,
Аһ-зарларын, барын, барысын.
Кешеләрдән качып, сабыр гына
Табигатькә китеп барышым...

## Минем юлым

Ятлар салган юлдан бармадым мин,
Юлсыз юлдан һәрчак атладым.
Күкләремә багып, эчтән генә
Һаман изге сүрә ятладым.

Адашканда тимерказык йолдыз
Юл күрсәтте миңа төннәрен.
Юлдаш булды бары тулган Аем,
Читләткәндә хәтта тиңнәрем.

Ялгыз бүре кебек уладым мин,
Өмет йолдызыма юл тотып.
Ач булсам да, ятлар өлешенә
Ташланмадым.
Һәрчак ут йотып,

Дәвам иттем изге юлымны мин,
Сүрелсә дә рухым, көчләрем.
Нинди гаҗәп, һәрчак өннәремдә
Юш килделәр минем төшләрем.

Җан дусларга түгел, ак кәгазьгә
Серләремне чишеп бушандым.
Булды инде, булды... Кайчакларда
Ала каргага да ышандым.

Булды инде... Ант-вәгъдәләр биреп
Торалмаган чаклар сүземдә.
Үтергәнче кытыклаган чаклар
Шүрәленең хәтта үзен дә.

«Иблис коткысы»на бирелеп тә,
Үз кыйбламны ләкин җуймадым.
Язмадым мин юлдан, кирәк чакта
Тормыш сәхнәсендә уйнадым.

Нигә читләтергә? Барыбыз да
Коябыз ла бер үк инешкә.
Алар барсалар да шома юлдан,
Соңарырлар кебек финишка.

***

Вакытлыча бәхеттер бу,
Вакытлыча шатлык.
Шул мизгелне татыр өчен,
Күпме елны яктык?!

Эреп акты күпме шәмнәр,
Күз яшьләрен түгеп.
Узды еллар, һәр сурәтне
Хәтерләргә чигеп.

Бар да сүнәр, изге хисләр
Җанны назга төрер.
Вакытларның таҗыдыр ул –
Бер мизгеллек гомер.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Данил
Салихов

# МӨХӘММӘТ

ДРАМА

**2 ПӘРДӘДӘ**

**Катнашалар:**
Мөхәммәт – сугыштан ике аягын да өздереп кайткан егет.
Иделбикә – Мөхәммәтне сугышка озатып калган кыз.
Әлмөхәммәт – Мөхәммәтнең атасы.
Актеләк – Мөхәммәтнең анасы.
Рәссам.
Журналист.
Габдулла карт.
Айзирәк – Габдулла картның килене.
Ак әби.

*Вакыйга бүгенге көннәрдә һәм сугыштан соңгы елларда бара.*

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

**I күренеш**

*Бүгенге көн. Пәрдә ачыла. Районның үзәк урамында урнашкан ике катлы йортның җыйнак бакчасы. Як-яклап утыргычлар куелган. Чәчәкләр үсеп утыра. Уртада инвалидлар бронзадан коеп үз куллары белән ясаган бер карыш биеклегендәге арбада агачтан Мөхәммәт сыны тора.*

*Көн дә шул чәчәкләргә бер карт су сибә. Су сипкәннән соң, утыргычка утырып, тәмәке кабыза да озак итеп шул сынга карап утыра. Янына Журналист килә.*

Журналист. Гафу итегез. Сез кем?

Рәссам. Нигә?

Журналист. Дворник түгел инде. Анысын беләм.

Рәссам. Нигә?

Журналист. Бик интеллигентный күренәсез.

Рәссам. Сезнеңчә, интеллигент кеше урам себерергә тиеш түгелме-

---

Данил САЛИХОВ (1958) — *драматург; «Узып барышлый», «Гыйләҗ тәрәзәләре», «Таш сандык» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Казанда яши.*

ни?! Ә менә мин сезнең кем икәнегезне бер күрүдә үк әйтә алам. Сез – Журналист.

Журналист. Әйтәм бит сәер сез.

Рәссам. Көн дә бирегә килеп, шушы чәчәкләргә су сипкәнгәме?

Журналист. Нәкъ шулай. Сезне күргән саен, шуны сорыйсым килә.

Рәссам. Әле районның үзәк урамына чыгып, кешеләр ыргыткан чүпне дә җыеп кайтсам, бу карт саташа ук башлаган икән дип уйларсыз.

Журналист. Зинһар, сез мине гафу итегез. Без бит журналистлар шундый халык . Берәр сәер эш тойсак, шул тирәдә буталабыз.

Рәссам. Нигә гафу үтенергә? Сез үзегез кайсы яктан?

Журналист. Түбән Камадан.

Рәссам. Әйтегез әле, Журналист иптәш, бүген атнаның нинди көне?

Журналист. Дүшәмбе.

Рәссам. Сәгать ничә?

Журналист. Унбер.

Рәссам. Дөрес. Унбер. Хәзер артыгызга борылып карагыз. Артыгызга терәлгәне – нинди ике катлы бина?

Журналист. Мәктәп.

Рәссам. Бүген сентябрьнең бере. Әнә ике аяксыз инвалид фронтовик Мөхәммәт утыра. Дөнья ямьсезләп, агачтан кеше сыны кырып. Кемне көтә, нәрсә көтә? Сәер. Ә бер тиле карт аның сыны янындагы чәчәкләргә су сибеп йөри.

*Музыка. Ут сүнә.*

**II күренеш**

*Кинәт поезд кычкырткан тавышка, сәхнә яктыра, сугыш чорындагы киемнәрдән карт-корылар, бала-чагалар, ире, хатыны чыга. Аларның кайсы сата, кайсы ала, кайсы каршы ала. Әлмөхәммәт кенә сәхнәнең алгы планында олы толып күтәргән дә әле бер якка, әле икенче якка йөгерә. Поездның тормоз башмакларын сызгыртып туктавы ишетелә.*

Әлмөхәммәт *(тамаша залына карап)*. Проводница, доченька, шестой вагон где, шестой? *(Башы белән уңга ымлап.)* Там! Там да... Спасибо кызым! Спасибо, доченька!

*Ашыга-ашыга арткы планга китеп югала. Бераздан, Мөхәммәтне толыбына төреп күтәргән хәлдә, алгы планга килә. Җиргә куя. Тезләнә дә күкрәгенә кыса. Икесе дә үкси-үкси, бер-берсенә капланып елыйлар.*

Мөхәммәт. Әткәй, янәдән бишек баласы булып кайттым бит. Бишек баласы аякка бер басып, тәпи атлап китә, мин кабат атлап китә алмаячакмын. Мин бит сиңа гомерлек бәла.

Әлмөхәммәт. Дәшмә! Үз сөягем. Әнә, Галиулланың дүртәү китеп, берсе дә кайтмады. Әсрарның өчтән берсе дә юк. Ә Габдулланың... Минем өчтән берсе бар бит әле. Юанычым бар бит әле.

*Музыка. Ут сүнә.*

**III күренеш**

*Мөхәммәтләрнең авылдагы кечкенә өй эче. Әлмөхәммәт карт мич каршында киез итеккә олтан салып утыра. Габдулла килеп керә.*

Габдулла. Нихәлләрең бар, Әлмөхәммәт яшьти?

Әлмөхәммәт. Алланың биргәненә шөкер. Үзең нәрсәләр җимерәсең, Габдулла яшьти?

Габдулла. Җимерәсең, дип...

Әлләни җимереп булмый инде хәзер. Тормыш үзебезне җимергәч. Мөхәммәт кая соң? Актеләк тә күренми.

Ә л м ө х ә м м ә т . Землянка абзарда орлыкка бәрәңге аералар. Хәернисаңның хәлләре ничек?

Г а б д у л л а . Шәптән түгел. Шәптән түгел шул, яшьти. Дүрт өрлектәй малаеңны сугышка чыгарып җибәр дә, шуларның берсе дә кайтмасын.

Ә л м ө х ә м м ә т . Безнең Мөхәммәт белән сабакташы Габделфәрих бит әле. Анысыннан үлем хәбәре килмәде бугай, хәбәрсез югалды түгелме соң ул?

Г а б д у л л а . Әй, Әлмөхәммәт туган, Әлмөхәммәт яшьти. Авыл халкына гына сиздермибез. Килүемнең дә сәбәбе шул. Габделфәрихемнең үле хәбәрен алганга сигез ай булды инде. Минекеләр беттеләр инде, Әлмөхәммәт. Беттеләр. Сигез ай элек соңгысын да җир куенына салганнар. Үле гәүдәләрен дә күрми калдым.

Ә л м ө х ә м м ә т . Нишлисең бит инде, нишлисең?! Ил белән килде, ил белән. Күрәчәкне күрми, гүргә кереп булмый, дигәннәр.

Г а б д у л л а . Оят булса да әйтим. Үзе өчен йөри карт шайтан дип уйлама. Уйласаң да, үпкәм юк. Син хаклы, Габделфәрихемнең җәмәгате, килен Айзирәк китәм ди.

Ә л м ө х ә м м ә т . Кая?

Г а б д у л л а . Калага. Китәр дә инде, яшьти. Яшь бит әле. Габделфәрихен туйларының икенче көнендә үк алып киттеләр.

Ә л м ө х ә м м ә т . Шулай булды бугай шул. Шулай булды бугай. Миннән нәрсә көтеп килдең инде, Габдулла яшьти?

Г а б д у л л а . Син, Әлмөхәммәт яшьти, минем капка-тәрәзәләремә аркылы такта суктырма инде. Бар өметем синдә. Синең улың Мөхәммәт белән безнең киленне кавыштырыйк.

Ә л м ө х ә м м ә т . Шулай дисеңме яшьти?..

Г а б д у л л а . Шулай димен. Картаеп барабыз, яшьти, картаеп. Картлык чапаннан сөйрәлә. Оныклар алып кайтып бирсәләр, безнең өйгә дә хуҗа булыр иде. Соңгы сулышны алганда, шуларның берәрсе иренгә су тидермәс иде микән, дим.

Ә л м ө х ә м м ә т . Авылдан 78 егет китеп, шуларның җидесе генә кайткан булса да ярар иде әле. Адәм көлкесе, икәү кайттылар. Әсрарныкы кайтты да өч ай да тормады, авыр яраларыннан китеп барды. Ә минеке ике аяксыз кайтып егылды.

Г а б д у л л а . Ике аяксыз булсалар да, кайтсыннар иде әле.

Ә л м ө х ә м м ә т . Булмый яшьти, булмый Габдулла туган, булмый. Күңелеңә авыр алма. Мин Мөхәммәтемне синең килененә өйләндерә алмыйм.

*Ишектән А к т е л ә к килеп керә.*

А к т е л ә к . Өйдә кунак бар икән. Нихәлләрдә яшисез, Габдулла? Хәернисаның хәлләре ничек?

Г а б д у л л а . Рәхмәт. Актеләк, рәхмәт. Илдәгечә. Хәзер сайлана торган чак түгел. Безнең килен бик уңган ул, Әлмөхәммәт. Аш-суга дисеңме, дөнья күтәргә. Миңа алардан бернәрсә дә кирәкми. Йорт-җиребез Аллага шөкер. Юаныр кешесе булса, килен китмәс иде.

А к т е л ә к . Бик әйбәт булыр. Мөхәммәтнең үзенең дә өйләнәсе килми түгел.

Әлмөхәммәт *(йодрыгы белән өстәлгә сугып)*. Дәшмә! Ирләр сөйләшкәндә дәшмә! Мөхәммәт өйләнми! Мөхәммәт хәтта сугышка озатып, сугыштан каршы алган яраткан кызы Иделбикәгә дә өйләнми. Мин әйттем. Мөхәммәт өйләнми! Мөхәммәтнең өйләнергә хакы юк!

*Шулвакыт ишектән М ө х ә м - м ә т килеп керә.*

М ө х ә м м ә т. Исәнме, Габдулла агай. *(Мич арасына кереп китә.)*

Г а б д у л л а. Әйбәт кенә әле, әйбәт кенә әле, кем энем, Мөхәммәт. *(Утырган урыныннан торып.)* Ярый. Вакытсызрак килдем, ахрысы. Гафу итегез.

*Башын түбән иеп чыгып китә.*

А к т е л ә к *(Әлмөхәммәткә пышылдап)*. Ай шул телкәйләреңне... Шул телкәйләреңә ярып тоз сибәргә.

Ә л м ө х ә м м ә т. Минем телемдә эшең булмасын. *(Үзалдына мыгырданып сөйләнеп.)* Аның капкасы ябыла, имеш. Аның тәрәзәсенә аркылы такта сугыла. Үзләре турында гына уйлыйлар.

М ө х ә м м ә т *(мич арасыннан)*.Әткәй, үз-үзеңне битәрләмә. Мин кемгә кирәк? Кем мине ир итеп яшәсен?

Ә л м ө х ә м м ә т. Монысына да тел чыга башлады. Кирәк булмаса, килмәсләр иде. *(Җикеренеп.)* Актеләк, бар, сарыкларга су бир!

А к т е л ә к. Хәзер. *(Чыгып китә.)*

Ә л м ө х ә м м ә т *(озак кына паузадан соң)*. Үпкәләмә миңа, улым, үпкәләмә. Рәнҗемә, Мөхәммәт. Син Габдуллалар кебек уйларга тиеш түгел. Тәккә мин сиңа Мөхәммәт дип исем куштыммыни?! Синең исемең – Мөхәммәт! Ә минеке – Әлмөхәммәт. Без синең белән алга карап яшәргә тиеш.

М ө х ә м м ә т *(мич арасыннан чыгып)*. Ике аяксыз бик алга карап булмый шул.

Ә л м ө х ә м м ә т. Әнә, авылдагы һәр ике капканың берсенә аркылы такта сугылырга торганда, аяк әһәмиятле түгел, улым. Сиңа өйләнергә ярамый. Ярамый, улым. Ярамый! Нәрсә?! Габдулла киленле, йә булмаса, Миңнулла кызы Иделбикә кияүле булып, авылның калган ятимнәре нишләргә тиеш? Нәрсә, алар картлык көннәрендә баласыз, караучысыз калып, мәңгелеккә аларны кем озатыр?! Авыл турында уйларга кирәк. Адәм баласы шундый ул, минеке генә, дияргә ярата. Берәрсе сине үзенеке итсә, син аныкы гына. Бары тик аныкы гына.

*Кабаланып А к т е л ә к килеп керә.*

А к т е л ә к. Әлмөхәммәт, Әлмөхәммәт, дим. Сиңа әйтәм. Бар әле, бар, чык. Тыкрык буенда коймага көчхәл белән тотынып Габдулла басып тора. Ул-бу хәл булмасын.

Ә л м ө х ә м м ә т *(сырмасын иңсәсенә сала-сала)*. Катырак әйтеп ташладым ахрысы үзенә. *(Чыгып китә.)*

А к т е л ә к. Улым Мөхәммәт, атаңа рәнҗемә. Ике улын сугышта югалтты. Өченчесен дә кемдер белән бүлешәсе килмидер.

М ө х ә м м ә т. Мин әткәйне аңлыйм. Ул мине аңлый микән? Аның яшенә җиткәндә, мин кайда булырмын? Минем үз капкам булырмы?! Тәрәзәмнән ут яктысы саркырмы?! Үз нигеземдә балаларымның тавышлары яңгырармы?! Менә нәрсә борчый мине, әнкәй. Ике куллы, ике аяклы кеше яши ул. Сез мине ташлап китсәгез, кая барырмын, кемгә сыенырмын?

*Ә л м ө х ә м м ә т керә.*

А к т е л ә к. Нәрсә булган, атасы? Андый-мондый авырып китмәгәндер бит?

Ә л м ө х ә м м ә т. Юк ла. Итек балтырына кар кергән. Коймага сөялеп, шуны кага иде. Менә әйт әле, Мөхәммәт, нәрсә өчен син сугышка киттең?! Көтүегез белән киттегез. Күпләрегез кайтмады. Син...

М ө х ә м м ә т. Әткәй, син миңа шундый пүчтәк сораулар бирәсең. Туган җирем өчен киттем.

Ә л м ө х ә м м ә т. Менә минем сиңа әйткән сүзләрем дә, теләкләрем дә, синең алда кылачак эшләрең дә

шул туган җир, туган авыл өчен инде, улым... Шул илне, шул җирне, шул авылга сулыш өрер өчен. Ә Габдулла кебекләр үзләре өчен генә.

А к т е л ә к . Ярар инде. Ярар инде, атасы. Олы кеше була бел.

Ә л м ө х ә м м ә т . Өйләнмисең!

А к т е л ә к . Булды, Әлмөхәммәт. Булды, атасы.

Ә л м ө х ә м м ә т . Буран күтәрелә. Сарыкларны утардан абзарга кертергә кирәк. Сиңа әйтәм, Актеләк. Лампага керосин салып куярга онытма.

А к т е л ә к . Керосин мәчтере син бит. Әле генә керосин сибүеңнән туктадың.

Ә л м ө х ә м м ә т . Телеңә салынма.

А к т е л ә к . Ярар, атасы.

Ә л м ө х ә м м ә т . Мөхәммәт, анда олтан салырга җеп бетеп килә. Бераз кич утырырбыз. Теге җепләрне сумалалап аласыңмы әллә?

М ө х ә м м ә т . Ярар, әткәй.

Ә л м ө х ә м м ә т . Кибеткә сугышта үлгән түбән оч Гависның төпчек кызы килгән. Балакаемның киез итеге үкчәсеннән аягы күренеп тора. Ул баланың да итеген карап бирербез.

М ө х ә м м ә т . Бирербез, әткәй.

*Музыка. Ут сүнә.*

**IV күренеш**

*Ут янганда, сукыр лампа яктысында, А к т е л ә к кабада җеп эрли. М ө х ә м м ә т олтан сала. Ә л м ө х ә м м ә т җырлый-җырлый, матчага җеп бәйләгән дә, шуны сумалалый.*

Ә л м ө х ә м м ә т .

Телеграм баганасы
Олы юлга маяк ул.
Сагынасыңмы, дип сорыйсыз,
Сагынмаган кая ул?!

*Кушымтага Актеләк белән Мөхәммәт тә кушыла.*

Сагынасызмы, дип сорыйсыз,
Сагынмаган кая ул?!

*Тәрәзә шакыган тавыш ишетелә.*

А к т е л ә к . Әллә тәрәзә шакыдылар инде?

Ә л м ө х ә м м ә т . *(Урлап кына тәрәзәгә карап, исе китмәгән булып.)* Юктыр.

*Тагын тәрәзә шакыган тавыш ишетелә.*

М ө х ә м м ә т . Тәрәзәдә кеше бар.

Ә л м ө х ә м м ә т *(тәрәзәгә карап, исе китмәгән булып.)* Юктыр.

А к т е л ә к . Әй, Ходаем. Юньле хуҗа мондый котырган буранда этен дә урамга чыгармаганда, кем булыр?

Ә л м ө х ә м м ә т . Буран дип, тормыш, яшәеш туктамый ул, карчык.

А к т е л ә к . Яхшы хәбәр генә алып килсен, Ходаем.

Ә л м ө х ә м м ә т . Ярар! Булды. Юрама! *(Тәрәзә кагалар.)* Бар. Кара, кем анда?

*Актеләк, тәрәзә кырыена килеп, пәрдәне тарта.*

А к т е л ә к . Анда, кулына чана тотып, Габдулла басып тора.

Ә л м ө х ә м м ә т . Хәзер ачам. *(Өстенә сырмасын бөркәнә дә чыгып китә.)*

М ө х ә м м ә т . Нәрсә булды икән?

*Әлмөхәммәт белән Габдулла керәләр.*

Г а б д у л л а . Котырган буранда борчып йөргәнем өчен кичерегез инде.

Ә л м ө х ә м м ә т . Зыян юк. Зыян юк, яшьти. Әле соң түгел. Җәй көне

бу вакытта әле җиң сызганып эшләп йөрибез.

Габдулла. Аның бураны да мин мунча ягып җибәргәч кенә чыкты бит.

Әлмөхәммәт. Нинди йомыш белән идең, яшьти?

Актеләк. Авылда ул-ни юктыр бит? Тынычлыктыр?

Габдулла. Тынычлык, Актеләк, тынычлык. Аның бураны да сезнең очта гына. Безнең башта болай ук түгел ул. Әлмөхәммәт яшьти, Мөхәммәт энекәшнең кайтканына да шактый, Хәерниса: шул баланы чакырып, бер чынаяк чәй эчертәлгәнебез юк, улыбыз Габделфәрихнең сабакташы, иң якын дусты иде, ди. Мунча яккан идем, суы да күп, эссесе дә шәп, әллә алып киләсеңме, дигәч, чана өстерәдем дә сезгә чаптым. Әлмөхәммәт яшьти, әйдә, улың белән җыен. Безгә мунчага барып чабынып кайтыгыз.

Актеләк. Габдулла, әле үзебез дә кичә генә мунча яккан идек шул. Мәшәкатьләнеп, Хәернисаны борчып йөрмә әле.

Әлмөхәммәт. Борчып, дип... Борчыласы калмаган бит инде. Үзе чакырган. Мунчасы ягылган.

Актеләк. Сиңа әйтәм. Синең авызыңнан чыккан сүзне колагың ишетәме?

Әлмөхәммәт. Мин бит авызымнан сүзне, үз колагыма дип чыгармыйм, чит кеше колагына дип чыгарам.

Актеләк. Шушындый котырган буранда кеше борчып йөриләрме?

Әлмөхәммәт. Мунчаны буранда керәләр инде аны. Җыен, улым.

Мөхәммәт. Юк. Рәхмәт. Бармыйм.

Әлмөхәммәт. Син нәрсә?! Габдулла абыең, олы башын кече итеп, шушы буранда сине кунакка чакырып килгән, ә син...

Мөхәммәт. Юк. Бармыйм. Әле кичә генә юындык бит.

Габдулла. Нигә алай дисең, Мөхәммәт? Мунчаны мин аны көн дә керер идем.

Әлмөхәммәт. Мин үзем дә шулай. Өелеп торсын иде утыным, көн дә ягар идем.

Мөхәммәт. Бик зур рәхмәт, Габдулла абый, сезне борчып йөрмим инде.

Актеләк. Улым, олы кешенең сүзен аяк астына салып таптамыйлар. Хәерниса апаң хакы да бар. Җыеныгыз.

Әлмөхәммәт. Яшьти Габдулла, мин баралмам инде. Нәрсәдер, бурангамы, иңбашым сызларга әйтеп тора.

Мөхәммәт. Габдулла абый, Хәерниса апага кайтып әйтегез, чакыруы өчен рәхмәт, мин дә баралмыйм.

Әлмөхәммәт. Юк инде. Барасың булгач барасың! Кара буранда олы кеше сиңа, үз фатихасын биреп, тәрәзә чирткән икән, барасың. Җыен. Яшь чагым булсамы. Чабына-чабына ләүкәсен җимереп кайтыр идем әле. Барасың булгач барасың! Дошманнардан Габдулла малайлары өчен үч алып, Габделфәрих истәлегенә эссе салып, чабынып кайтасың. Уйламасын дошман безне бик тиз генә бетереп була дип. Габделфәрих, Габделфаяз, Габделфәезләр урынына бүтәннәр туа.

*Музыка. Ут сүнә.*

**V күренеш**

*Ут янганда, шул ук өй эче. Берничә сәгать вакыт узган. Актеләк тәрәзә янына терәлеп баскан да урамнан күзен алмый. Әлмөхәммәт сәкедә гырлап йоклап ята.*

Актеләк. Әлмөхәммәт, Әлмөхәммәт...

Әлмөхәммәт. *(Сискәнеп уяна.)* Ә?! Бүген ничәсе?

А к т е л ә к . Бүген, этисе, гыйнварның соңгы атнасы – 24е.

Ә л м ө х ә м м ә т . Гыйнвар, дисең инде.

А к т е л ә к . Теге баланы һаман кайтармыйлар, әллә мин әйтәм, үзең барып аласыңмы.

Ә л м ө х ә м м ә т . Нинди баланы?

А к т е л ә к . Мөхәммәтне.

Ә л м ө х ә м м ә т . Гыйнвар ае – муллык ае. Ходаем, тулы амбарларга килсен инде.

А к т е л ә к . Кем?

Ә л м ө х ә м м ә т . Кем булсын инде. Егет – Галинур!

А к т е л ә к . Ә, бәлки, Сәрбиназдыр.

Ә л м ө х ә м м ә т . Авызыңнан җил алсын. Сабан тартырга Галинурлар кирәк.

А к т е л ә к . Атасы, саташып ятма әле. Баланы алып кайт.

Ә л м ө х ә м м ә т . Тик кенә ят! Күкрәгеңә сөт төшмәгәндер!

А к т е л ә к . Чишмәсенең корыганына илле ел.

Ә л м ө х ә м м ә т . Шулай булгач. Ул чишмәдән авыз иткән егет ата булырга җыена. Сүндер утны. Тиз генә кайтмый ул. Тәнендә җаны булган ир-ат җылы мунчадан тиз генә кайта димени?!

*Музыка. Ут сүнә.*

**VI күренеш**

*Ут янганда, С ы н ч ы чәчәкләргә су сибә дә утыргычка барып утыра. Карашын еракка, чиксезлеккә төбәп, тирән уйга бата. Янына килеп утырган Ж у р н а л и с т н ы тоеп, үзенә кайта.*

Ж у р н а л и с т . Сезнең янга утырсам ярыймы?

С ы н ч ы . Журналистка барысы да ярый.

Ж у р н а л и с т . Мин бит Сезнең кем икәнегезне белдем. Сез – Сынчы!

С ы н ч ы . Ә мин үземнең кем икәнлегемне яшермәдем дә кебек.

Ж у р н а л и с т . Сезнең хезмәтләрегез белән өстән генә булса да танышып чыктым. Утыздан артык хезмәтегез бар икән.

С ы н ч ы . Шулар арасында иң ошаганы кайсы булды соң?

Ж у р н а л и с т . *(Мөхәммәткә күрсәтеп.)* Әлбәттә, монысы түгел.

С ы н ч ы . Ә минем өчен иң уңышлысы һәм иң кадерлесе – монысы.

Ж у р н а л и с т . Нәрсә өчен?

С ы н ч ы . Чәчәкләр янында торган өчен.

Ж у р н а л и с т . Ә минем өчен бу эшегез, ягъни хезмәтегез өйрәнчек кенә. Ә бүтәннәр нинди фикердә?

С ы н ч ы . Элек бу хезмәтемне һавага чөяләр иде. Мине бары тик шушы хезмәтем генә яшәтте. Ә хәзер...

Ж у р н а л и с т . Әйе. Ә хәзер?

С ы н ч ы . Ә хәзер шуңа да көн саен сын янындагы чәчәкләргә су сибәм. Сәерме?

Ж у р н а л и с т . Сәер шул. Әйтегез әле. Сезнең менә бу хезмәтегезнең урыны нигә биредә?

С ы н ч ы . Элек менә бу мәктәп урынында картлар йорты иде. Культурный итеп әйтсәк, өлкәннәр интернаты. Мин бу хезмәтемне картлар йортының бакчасына, ягъни менә шушы скверга урнаштырсам, бу йорт мәктәпкә әйләнер дип уйлаган идем.

Ж у р н а л и с т . Шулай килеп чыга да түгелме соң?

С ы н ч ы . Юк шул. Мәктәптә балалар тавышы ишетәсеңме?

Ж у р н а л и с т . Кызганыч ки. Юк шул.

С ы н ч ы . Шуңа күрә көн дә бирегә килеп чәчәкләргә су сибәм дә.

Ж у р н а л и с т . Һични аңламыйм.

С ы н ч ы . Сәерме?

Ж у р н а л и с т . Хикмәт нәрсәдә?..

С ы н ч ы . Бәлки, сындагы арбага бәйләнгән бауның өзелеп калган очларындадыр.

Ж у р н а л и с т *(тирән уйга батып, үз-үзе белән сөйләшеп)*. Бауның икенче очы кем кулында?..

**VII күренеш**

*Музыка. Ут сүнә. Сын алына. Аның урынына, шул ук позада, чын М ө х ә м м ә т килеп утыра. С ы н ч ы белән Ж у р н а л и с т юкка чыгалар. Ут кабына. Сәхнәнең кыл уртасында хур кызлары киеменнән яшь И д е л б и к ә таганда атына. Үзе шат. Шаркылдап көлә. Бераздан Мөхәммәт хәрәкәткә килә. Ул арбасын кулы белән этеп, Иделбикәгә якыная. Иделбикәне атындырмакчы була.*

И д е л б и к ә . Кирәкми, кирәкми. Мөхәммәт, атындырма. Син минеке түгел. Син башкаларныкы.

М ө х ә м м ә т . Иделбикә, син ни өчен шулкадәр каты атынасың?

И д е л б и к ә . Ә минем күккә менеп җитәсем килә.

М ө х ә м м ә т . Нигә, Иделбикәм?

И д е л б и к ә . Йолдызымны табарга.

М ө х ә м м ә т . Йолдызың менә мин бит инде синең, Иделбикә.

И д е л б и к ә . Юк. Минем җирдәге йолдызым сүнде.

М ө х ә м м ә т . Шулай шул. Ике аяксыз шайтанга әверелде.

И д е л б и к ә . Мин сине көтмәдем түгел, көттем Мөхәммәт. Вәгъдәмә тугры калдым. Ике кулсыз, ике аяксыз кайтсаң да, көтәрмен, дидем, көттем.

М ө х ә м м ә т . Мин дә сине өзелеп, саргаеп көттем, Иделем. Килмәдең бит, килмәдең, бусагамны атлап кермәдең.

И д е л б и к ә . Ә үзең нигә килмәдең?!

М ө х ә м м ә т . Ике аяксызлыгымнан оялып, уңайсызланып килмәдем. Тиң итмәссең дип уйладым.

И д е л б и к ә . Куркаклыгыңны җиңә алмадың.

М ө х ә м м ә т . Юк, егетлегемне җиңә алмадым.

И д е л б и к ә . Ә мин килдем. Айлы аяз төндә дә, болытлы кара төндә дә, яңгырлы, шыксыз төндә дә. Соңгы килүем буранлы кышкы салкын кара төн иде. Син утырган кечкенә чананы мин авылның икенче башына, икенче урамына үкси-үкси елап озатып калдым.

М ө х ә м м ә т . Кичер. Син әйткән төн – кырык алтының гыйнвары, ягъни гыйнварның кара буранлы төнендә тәрәзәмә килеп каккан авылдашымның, ак сакаллы аганың йөзендә яшәү нуры сүнгән төне иде. Минем барыр юлым юк иде. Минем чигенергә хакым юк иде. Мин аларны ялгызлыктан, үзем күргән газаплардан коткарасым килде. Кичер мине, Иделбикәм.

*Музыка. Ут сүнә.*

**VIII күренеш**

*Мөхәммәтләргә Г а б д у л л а килеп керә.*

Г а б д у л л а . Исәннәрмесез, авылдашлар.

Ә л м ө х ә м м ә т . Ходайның биргәненә шөкер.

Габдулла. Нихәл, энем Мөхәммәт?

Мөхәммәт. Әйбәт кенә, Габдулла абый. *(Оялып мич арасына кереп китә).*

Актеләк. Әйдә, чәй өстәленә утыр, авылдаш.

Габдулла. Рәхмәт. Табын артыннан гына кузгалып килдем.

Әлмөхәммәт. Яшьти, нинди хәбәрләр бар?

Габдулла. Бик матур хәбәрләр алып килдем, яшьти Әлмөхәммәт. Берсеннән-берсе матур хәбәрләр.

Актеләк. Бирсен Ходай. Халыкка гел начар хәбәр генә ишетергә язмагандыр. Яхшысы да ярыйдыр.

Габдулла. Мөхәммәт тә бирегә чыксын иде. Берсе аңа кагыла.

Әлмөхәммәт. Улым Мөхәммәт, монда чык.

Мөхәммәт. Мин моннан да ишетәм.

Габдулла. Юк. Чык әле монда. Сүз синең турыда булачак. Шулай, авылдашлар. Шатлыклы хәбәрнең үземә кагылганыннан башлыйм. Кичә, Габделфәрихемнең командирыннан хат алдык. Габделфәрихебез исән. Ижау гуспителендә ята икән.

Әлмөхәммәт. Вәт идрит-кудрить! Мать якасын! Иске авыздан яңа сүз. Булган бит бу. Барып чыккан бит бу.

Актеләк. Хәерниса кая басканын белми торгандыр инде, Хәерниса...

Әлмөхәммәт. Хәернисасын кем белгән?! Килен ничек, килен?.. Килен довольныймы?

Габдулла. Алагаем гына әйтеп булмый инде аны. Ышанырга да белми, ышанмаска да белми. Янына гуспительгә барып, үзен күреп кайтмыйча, әлегә берни дә әйтеп булмый.

Актеләк. Барасыздыр бит янына.

Габдулла. Үзем баралмыйм. Килен бара инде. Февраль бураннары, дип тормый, бара. Икенче шатлыклы хәбәр сезгә кагыла. Әлмөхәммәт яшьти, тәрәзәңә кара әле.

Әлмөхәммәт. Минем тәрәзәмә нәрсә булган? Кая, карыйм әле. *(Тәрәзәдән карый.)* Минем капкама бәйләнгән нинди җигүле ат ул?

Габдулла. Минем килүемнең төп сәбәбе Мөхәммәткә бәйле иде. Раюннан өч авылга почта ташырга ат бирделәр. Менә шул эшкә Мөхәммәт алынса, әйбәт булыр иде. Ат үзегездә торыр, диделәр. Иртә белән үзең, яшьти, атны җигеп, Мөхәммәткә дилбегәне тоттырып чыгарып җибәрерсең, кич белән тугарырсың.

Әлмөхәммәт. Анысына гына калса. Көненә җиде тугарып, җиде җигәм.

Актеләк *(шатланып)*. Алланың биргәненә шөкер, куллары исән, дилбегә генә тотала. Безнең Мөхәммәт эшкә нык ул.

Әлмөхәммәт. Нык, нык, гөнаһысына керә алмыйм.

Габдулла. Син үзең дә, яшьти, яшь чагында бассаң тимер өзә идең бит.

Әлмөхәммәт. Мин аны хәзер дә булдыралам, яшьти. Малай кул арасына керсен, дип кенә иркәләнәм.

Актеләк. Бумы? Теләсә, хәзер дә булдыра бу.

Габдулла. Ничегрәк уйлыйсың, Мөхәммәт?

Әлмөхәммәт. Монда уйлыйсы юк. *(Күңеле тулып.)* Рәхмәт, туган, Габдулла, рәхмәт, яшьти. Бу сүзләрең, бу эшең күңелемә җылы май булып ятты. Баламның авырткан җирен күргәнең өчен рәхмәт. Улымның, Мөхәммәтемнең авырткан җиренә дәва булганың өчен рәхмәт. Үзеңә көтмәгән җирләрдән уңыш, шатлык бирсен. *(Ишек төбендә киенеп яткан Мөхәммәткә ымлап күрсәтә, пышылдап.)* Ишек катына карагыз. *(Мөхәммәткә.)* Барырсың бит, улым?

Мөхәммәт. Киенәм бит.

Габдулла. Хәзер, Мөхәммәт энем, атны кабул итеп алып калырсың.

Районда безнең бер агайне шушы эшләрнең нәчәльнигы.

Мөхәммәт. Районда почта нәчальнигыдыр.

Габдулла. Әйе. Әйе, нәкъ үзе! Өстенә бастың. Шул әйтә, авылыгызда шушы эшкә алынырлык кешең юкмы, ди. Нишләп булмасын, мин әйтәм, әлбәттә, бар. Аяксыз булуына карама, мин әйтәм. Ул бар эшне дә булдыра, дидем. Ну шулай да атны рәспискәсез бирмәде. Иртәгә иртәнге сәгатьтән районга почта килсен инде, диде.

Әлмөхәммәт. Рәхмәт! Яшьти, без инде гомеребездә дә дилбегә, йөгән тоталмабыз дип уйлый идем. Рәхмәт сиңа.

Габдулла. Әз генә солы арттырырмын, диде. Печәнне үзләренә табарга туры килә инде, ди.

Әлмөхәммәт. Илдә чыпчык үлми, табарбыз.

Габдулла. Яз исе керде инде. Мин дә бераз арттырырмын.

Актеләк. Хәзер уникеле чалгы белән киерелеп печән чаба торган ирләребез юк инде. Сугыш кырды аларны.

Мөхәммәт. Аты гына булсын. Арбага ияреп кайта ул. Йолкып булса да туйдырам мин аны. Рәхмәт, Габдулла абзый, рәхмәт. Әйдә, мин әзер. Атыңны күрсәт.

Габдулла. Онытып торам икән. Йомышым да бар бит әле минем. Иртәгә, шул районга барышлый, минем киленне дә алып киталмассыңмикән? Ижауга китеп барышы.

Әлмөхәммәт. Сүз дә булдымы инде бу, Габдулла яшьти. Бер-берсенә юлдаш булырлар. Беренче баруы. Нәрсә булмас. Сүз итеп сөйләп торма син моны, яшьти.

Габдулла. Йә, нәрсә диярсең, Мөхәммәт?

Мөхәммәт. Минем өчен әткәй әйтте бит инде. Миңа әйтергә урын калдырмады.

Актеләк. Ярый, Габдулла, бик матур хәбәрләр белән кергәнсең. Алланың рәхмәте яусын сиңа. Мин сезне калдырам әле. Кәҗә савылмаган *(Чыгып китә.)*

Мөхәммәт. Әткәй, Габдулла ага, мин Габделфәрих белән бер класста, бер партада утырып укыдым. Дуслар идек. Сез инде аның хатынын минем чанага салмагыз.

Габдулла. Киленнең утырырга чанасы калмады. Кеше чанасына утыртып, нәселне сакламакчы булабыз. Исән булыгыз. Ат капкага бәйләнгән. *(Чыгып китә.)*

Әлмөхәммәт *(озак кына паузадан соң)*. Әй улым, улым Мөхәммәт. Габдулла нәселе чит чанага утыра торганнардан түгел иде. Дүрт улын сугышка җибәреп, дүртесенең берсе дә кайтмады. Исән түгел аның Габделфәрихы, исән түгел. Моннан сигез ай элек үле хәбәрен алды ул аның.

Мөхәммәт. Әткәй, мин яраткан кешемә хыянәт италмыйм. Мин Иделбикәне яратам.

Әлмөхәммәт. Ә ул сине яратамы соң? Кайтканыңа күпме?! Килергә вакыт иде. Мин дә көттем аны. Син кайтып төшүгә үк, бусагабыздан атлап ул керер дип көттем. Ай көттек без аны анаң белән, ел көттек!

Мөхәммәт. Ә, бәлки, минем үземә барасы калгандыр.

Әлмөхәммәт. Шулай итәрсең. Бер ирне бишкә бүлердәй заманда, шулай итәрсең. *(Озак кына паузадан соң.)* Бер класста, бер партада утырып укыдык, дисең инде. Син иртәгә иртә белән районга киткәндә, Габдулла абзаңның капка төбенә күз сал. Сугышта үлеп калган дустыңның юрган астына керү хыянәт түгел. Ә менә исән кайтып та, аның нигезенә, ата-анасы яшәгән йортның капкасына аркылы такта сугылуына юл куеп тору, бәлки, хыянәттер. Авылның, милләтнең бетүен карап тору, бәлки, хыянәттер.

*Музыка. Ут сүнә.*

**XI күренеш**

*Ут янганда, Сынчы, чәчәкләргә су сибеп йөри. Утыргычтагы Журналист янына килә.*

Журналист. Су сибеп азапланасыгыз юк иде. Әнә күк йөзе кап-кара болытта. Озакламый яңгыр явар.

Сынчы. Ява-яумый, ява-яумый, дип, үз-үземне азаплап утырганчы, мин үз эшемне эшләдем.

Журналист. Әйтегез әле, әгәр дә мин сезнең шушы хезмәтегез турында язсам, сез моңа ничек карыйсыз?

Сынчы *(сискәнеп китә)*. Барып чыкмаган, димәк. Барып чыкмаган.

Журналист. Нәрсә?

Сынчы. Барып чыкмаган. Барып чыкмаган минем хезмәтем, барып чыкмаган.

Журналист. Нинди хезмәтегез?

Сынчы. Сез язарга теләгән хезмәтем.

Журналист. Монда мин бернинди дә хилафлык күрмим.

Сынчы. Журналист иптәш! Чын мастердан соң төзәтмә кертмиләр! Чын художниктан соң аның эшен бүтәннәр язмый. Бу – закон! Бу – язылмаган, кешелек тудырган закон! *(Шашып йөгереп, чәчәкләр янына бара. Аллея арасына керә, тезләнә. Чәчәкләрне төбе-тамыры белән йолкый башлый. Үзалдына сөйләшеп.)* Ул хаклы булган. Ул әйтте бит. Ул хаклы булган. *(Ике кулы белән тамырлары белән йолкынган чәчәкләрне күкрәгенә кысып, ике катлы йортка, мәктәпкә карый.)* Ул хаклы булган.

Журналист. Тынычланыгыз. Зинһар, тынычланыгыз.

Сынчы. Әйе, әйе, ул хаклы булган.

Журналист. Кем?

Сынчы. Ул хаклы булган. Куйдырасы килмәде. Бу хезмәтемне бирегә, бу бакчага куйдырасы килмәде. Әнә мәктәп. Балалар тавышы юк. Ул хаклы булган. *(Тагын чәчәкләр йолкый башлый. Журналист аны тотып ала.)*

Журналист. Туктагыз! Нишләвегез бу? Чәчәкләрнең гаебе нидә? *(Җайлап кына Сынчыны бастыра. Утыргычка алып килә. Утырта.)*

Сынчы. Әйтте бит. Ялварды бит. Куймыйк, диде. Исәннәрне тереләй күммик, диде.

Журналист. Кем?

Сынчы. Ә ул бүген дә исән! Ә ул бүген дә безнең арада.

Журналист. Арба бавының икенче өлешендә калган кешеме?

Сынчы. Күпмеләр куйдырмас өчен, югары органнарга барып җитте.

Журналист. Димәк, чынында сезнең бу әсәрегез могҗиза.

Сынчы. Нигә?

Журналист. Әсәрнең бит бар сере тирәндә. Арбада утырган ике аяксыз түгел. Бауның өзелеп калган икенче очында.

Сынчы. Хәтта Мәскәүгә кадәр барып җитте.

Журналист. Өзелеп калган арба бавымы?

Сынчы. Совет солдатын гарип хәлдә фаш итәргә тели, дип, шелтә дә язды.

Журналист. Шелтә язды?!.

Сынчы. Себердә йөртте. Биш ел, биш ел ГУЛАГ! *(Шаркылдап көләргә тотына. Кинәт туктап кала. Җитдиләнеп.)* Ул гомере буе шушы ике аяксыздан курыкты. Ә ике аяксыз аннан курыкты.

*Музыка. Ут сүнә.*

**X күренеш**

*Бала елаган тавышка сәхнәдә ут кабына. Әлмөхәммәт, Актеләк, Мөхәммәт чәй эчеп утыралар.*

Актеләк. Бала тавышы ишетелдеме?

Әлмөхәммәт. Юк, мәче тавышы. Алар да саташкан. Ноябрь аенда...

Мөхәммәт. Бала тавышы ишетелде. Әнкәй, бар әле?

Актеләк *(ишек төбенә килеп)*. Кем бар анда? *(Тагын бала елаган тавыш ишетелә.)* Кем бар?

Әлмөхәммәт. Сиңа әйтәм. Син нәрсә стена аша бүре куасың? Нәрсә карап каттың? Бар чык, кеше бар анда.

*Актеләк ишекне ачып җибәрә, ишек артында юрганга төрелгән бала күтәреп Айзирәк басып тора.*

Актеләк. Айзирәк сеңлем, син түгелме соң бу?

Айзирәк. Мин идем әле, Актеләк апа.

Актеләк. Нишләп анда басып торасың. Өйгә үт.

Айзирәк. Гафу итегез инде.

Әлмөхәммәт. Син нәрсә?! Булмаганны, чит кеше кебек, өйалдында басып торасың. Кер, дигәннәр бит сиңа. Өйне суытасың.

Айзирәк *(бусаганы атлап керә)*. Исәнме, Мөхәммәт!

Мөхәммәт. Әйбәт кенә әле. *(Мич арасына кереп югала.)*

Айзирәк. Йомышым синдә иде, Әлмөхәммәт абзый. Әткәй җибәрде. Кичә улыма, Галинурыма кырык көн тулды. Чәчен алдырырга, дип әткәйгә тоттырган идем дә, кулым калтырый, ди.

Әлмөхәммәт. Габдулланың кулы калтырый аның, калтырый.

Айзирәк. Бар Әлмөхәммәт янына, булдырса, ул гына булдыра инде аны ди.

Әлмөхәммәт. Минме?! Әлмөхәммәтме?! Әй бу Габдулланы, ну бу Габдулланы... *(Ике кулын алга сузып, калтыратып.)* Кара, кара, бу рәзве калтырамый. Оят булса да әйтим, әнә Актеләк апагызның түшлеген дә ычкындыралмыйм.

Актеләк. Карт тиле, карт тиле. Өйләндерерлек улыңнан оялмасаң, юрганга төрелгәненнән оял.

Әлмөхәммәт. Аның нәрсәсеннән ояласың. Адәм баласын Ходай сөеп-сөелергә яраткан. Ул сабыйның да уенда шул. Ике куллап тотарга күкрәк булсын да, арт саны коры булсын. Чәч алулар, каш куюлар бетте инде ул безгә, кем, килен... ту есть, Габдулла яшьти килене, Айзирәк сеңлем. Артка борылып карарга куркам. Комым коелып бара. *(Мич арасына төртеп күрсәтеп, пышылдабрак.)* Әнә, чәчне кем ала... Мич арасында утырган кеше ала инде аны. Улым Мөхәммәт, чык әле. Әнә бер Галинур исемле егет сиңа йомыш белән килгән.

Мөхәммәт. Әнкәй, җылы суың бармы?

Актеләк. Мондый егеткә җылы су тапмыйммы соң?! Булыр. Җылы суы да булыр, исле сабыны да булыр. Кая, кая, бир әле. Үзем юрганын таратыйм әле?! *(Төрелгән баланы сәкегә салалар. Актеләк юрганын сүтә. Аның янына Әлмөхәммәт тә килә.)*

Әлмөхәммәт. Эре сөякле. Нәселе затлы! *(Чеметмәкче була.)*

Актеләк. Кая әле, кая, йә имгәтерсең. Бала караган кеше төсле.

Кая, кая әле, кемгә охшаган икән бу егет?

Ә л м ө х ә м м ә т. Егетнең Әлмөхәммәт бабасы кушкан исеме бар, Актеләк әбисе. Галинур булыр бу.

А й з и р ә к . Әнкәй, аяклары, тез буыннары гел Габделфәрихыма охшаган, дип сөя.

Ә л м ө х ә м м ә т. Кемгә генә охшаса да, Габдулла яшьти оныгы инде. *(Чеметә. Ярсып елаган бала тавышы ишетелә.)*

А к т е л ә к . Нишлисең син, карт тиле!

Ә л м ө х ә м м ә т. Чеметеп елатам.

А й з и р ә к . Әлмөхәммәт абзый, нишләвең бу?!

Ә л м ө х ә м м ә т. Ела, ела, улым, Галинур! Бөтен җиһанга ишетелерлек итеп ела. Безгә, бу җиргә яңа туган балаларның авазлары бик кирәк. Ишетсеннәр, ишетсеннәр, улым. Татарча итеп ела, улым!

*Музыка. Ут сүнә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### XI күренеш

*Сәхнәдә якты. С ы н ч ы коеп яуган яңгыр астында гөлләргә су сибеп йөри. Зонтик тоткан Ж у р н а л и с т чыга да Сынчы янына килә.*

Ж у р н а л и с т. Коеп яңгыр ява. Ә сез чәчәкләргә су сибәсез.

С ы н ч ы . Сәерме?

Ж у р н а л и с т. Сәер генәме...

С ы н ч ы *(пышылдап)*. Янымарак килегез әле. *(Пышылдабрак, колагына.)* Әнә узып баручыларның барысының да күзе биредә. Күрәсеңме?

Ж у р н а л и с т *(пышылдап)*. Күрәм.

С ы н ч ы . Сәерме?

Ж у р н а л и с т. Сәер.

С ы н ч ы . Ни өчен карап узалар?

Ж у р н а л и с т. Сине дә, мине дә дивана дип уйлыйлар.

С ы н ч ы . Димәк, бу минутларда кем көчле?

Ж у р н а л и с т. Аңлаешсыз сәер кеше сез.

С ы н ч ы . Юк, Сез минем соравыма җавап бирмәдегез. Бәлки, биралмагансыздыр.

Ж у р н а л и с т. Бәлкем.

С ы н ч ы . Бу минутларда мин алардан көчле. Мин аларны күзәтмим, алар мине күзәтә. Димәк, мин аларны буйсындырганмын.

Ж у р н а л и с т. Ә аларны нәрсә өчен буйсындырырга?

С ы н ч ы . Игътибарлы булсыннар өчен. Менә шушы мәктәп тәрәзәләреннән балаларның шат авазлары ишетелеп торсын өчен буйсындырырга.

Ж у р н а л и с т. Мәктәп, чәчәкләр, картлар йорты, ике аяксыз фронтовик... Мәктәп, чәчәкләр, картлар йорты, ике аяксыз фронтовик, һичнәрсә дә аңламыйм. Көн дә бер үк сүзләр, көн дә чәчәкләргә су сибү... Сәер! Сәер өстенә сәер! Әйтегез әле, элек сез бу ике катлы йортны картлар йорты иде, дисез. Чыннан да, ул шулай булган. Интернатның директоры кем иде?

С ы н ч ы . Минем хезмәтемне бирегә, картлар йортының бакчасына куйдырырга теләмәгән бәндә иде. Ә ул бит ялгышты. Ул елларда шушы «сын» бирегә куелгач, күп картларны алып киттеләр. Картлар йорты ябылды.

Ж у р н а л и с т. Мәктәп булды.

С ы н ч ы . Мәктәп булды. Икешәр смена укыйлар иде.

Журналист. Ике аяксыз Мөхәммәт утыра, мәктәп ябыла.

Сынчы. Чәчәкләргә су сибәргә кирәк, чәчәкләргә.

Журналист. *(Үртәлеп, ачыргаланып.)* Ни өчен? Нәрсәгә?! Күпме артыңнан тагылган эт кебек йөрим, ә бернәрсә дә язалмыйм.

Сынчы. Чәчәкләр сулса, чәчәкләр шиңсә, бирегә килүчеләр булмаячак. Адәм баласы матурлыкны күрергә ярата. Минем хезмәтем аңа ят булачак. Тарих арбасын тартып барган бау өзелә. Тарих онытыла. Тарихын оныткан халык үлә. Мәктәбе ябыла. Тел чишмәсе кибә, гореф-гадәтләре югала.

Журналист. Ә бу син иҗат иткән тарих арбасын сөйрәп барган бауның икенче очы кем кулында... Бәлки, шушы картлар йортының мөдире...

Сынчы. Галинур, дисеңме?! Ул арбаны бер Галинурлар гына тартып баралмый.

Журналист. Аксак арбасының бавы кем кулында?!

**XII күренеш**

*(Төн. Мөхәммәт сыны урынында хәрәкәтсез, катып калган хәлдә Мөхәммәт үзе утыра. Ул – прожектор яктысында. Арткы планнан өстенә озын плащ, башына капюшон, бер кулына кувалда, икенче кулына көрәк тоткан Галинур бюст (сын) янына килә дә көрәгеен җиргә кадый. Башындагы капюшонын төшерә, уч төбенә төкерә дә, кувалданы алып, бронза сынга (бюстка) кизәнә. Кувалдасы өскә һавага күтәрелә.*

Мөхәммәт *(телгә килә)*. Нишләвең бу, улым Галинур?

Галинур *(куркып, калтыранып, кувалдасын төшерә, як-ягын күзәтә. Пышылдап)*. Әйтмә, әйтмә миңа «улым» дип. Үскәндә мыскыл иткәннәре дә җиткән.

Мөхәммәт. Син минем улым булудан ояласыңмы әллә?

Галинур. Мин Габделфәрих улы. Габдулла улы Габделфәрих минем әти. Соңгы сулышын алган чагында, бабам Габдулла, син бары тик минем онычым, син бары тик минеке генә, син Әлмөхәммәт онычы түгел, ишетсен колагың, син Габдулла карт улы Габделфәрих улы Галинур – минем онычым, дип, кулымда җан бирде.

Мөхәммәт. Шулай булгач, миндә нинди ачуың бар, балам?

Галинур. Улым... Балам... Әйтмә миңа шул сүзне, әйтмә. Миңа хәзер озакламый җитмеш тула. Җитмеш ел буе син мине каһәрлисең.

Мөхәммәт. Кичер, Галинур.

Галинур. Мәктәптә укыганда, Айзирәкнең Мөхәммәт белән уйнаштан туган баласы, дип, күз ачырмадылар. Инде үстем, котылдым, кеше булдым, дигәндә генә, мин мөдир булып эшләгән картлар йортына күз өстенә каш булып килеп төштең. Нигә... Нигә син... Мин синең арбаңның бавын кисеп, бер башын кулыңа тоттырган идем бит инде. Нигә... Нигә син?!

Мөхәммәт. Бауга менәргә дә аяк кирәк икән шул, балам.

Галинур. Син сугыштан мине каһәрләр өчен кайткансың. Син минем юлыма таш сын булып бастың. Иртә белән эшкә каршы алдың, кич белән озаттың. Төшләремә кереп азапладың. Синең аркаңда мин үсәлмәдым. Китәр вакытым якыная. Сине

дә бередә калдырмыйм. *(Арбага бау бәйләмәкче була. Сулъяктан кулына бау тоткан, ап-ак күлмәк-яулыктан Айзирәк күренә. Ул – прожектор яктысында).*

А й з и р ә к . Бәйләмә, бала, бәйләмә! Калтыранган кул белән намусны бәйләп булмый. Күземнән югал, бала, күземнән. *(Галинур курка-курка гына караңгылыкка кереп югала. Уң як парталдан шулай ук киенгән Ак әби. Аның да кулында бауның бер очы. Ул да прожектор яктысында.)*

А к ә б и (*Галинурга*). Бәйләнгәч сөйрәргә, тартырга кирәк.

*(Арткы планнан И д е л б и к ә күренә. Ул да нәкъ шундый киемнән. Айзирәк белән Ак әби кулындагы бауның уртасыннан тоткан.)*

И д е л б и к ә . Мөхәммәт, вакыт! Вакыт, Мөхәммәт!

М ө х ә м м ә т . Кая?

И д е л б и к ә . Китәргә вакыт.

М ө х ә м м ә т . Кая?

И д е л б и к ә . Мәңгелеккә, Мөхәммәт, мәңгелеккә!

М ө х ә м м ә т . Мин адаштым бугай, Иделем, мин саташтым бугай, Иделбикәм. Җир өстендә өзелеп калган язмыш җебемнең очын табалмыйм.

И д е л б и к ә . Язмыш бавыңның түгел, язмыш кылыңның бер очы минем кулда, Мөхәммәт.

М ө х ә м м ә т . Рәхмәт, Иделем, рәхмәт, Иделбикәм.

*(Ак әби белән Айзирәк бауның очларын Мөхәммәт арбасына бәйлиләр дә юкка чыгалар. Иделбикә арбага җигелеп, алгы планда тамашачыга карап басып кала.)*

М ө х ә м м ә т . Иделем! Чү, чү, Иделбикәм! Ә чәчәкләр?! Әнә, күрәсең ич, алар тамырлары белән йолкынган.

И д е л б и к ә . Билчән үскән җирдә чәчәк үсми, Мөхәммәт. Яңадан шытарбыз, шытарбыз да чәчәк атарбыз.

*Музыка. Ут сүнә.*

**Пәрдә.**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Эльмира
Шәрифуллина

# СҮЗ – ӘҖӘЛГӘ ДАРУ ДА...

ДҮРТЬЮЛЛЫКЛАР

## Зиһенеңдә – татар теле

Колачыңда – татар иле,
Зиһенеңдә – татар теле,
Күз алдыңда – ачы җиле...
Нәсел-ыру, шөкер, тере!

## Сүз көче

Сүз – әҗәлгә дару да,
Сүз – гомергә агу да.
Дару – сеңә дә эри,
Агу – кабергә сөйри.

## Әниләр елмаюы

Бүләк иткән гөлләр шиңә,
Гүя, кояш баюы.
Бәйрәмнәрне бизи фәкать,
Әниләр елмаюы.

## Сорау белән

Ыңгырашып чайкаласың,
Моң төштеме башыңа?
Шундый сорау белән, Нарат,
Басып торам каршыңда.

---

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА (1947) – *шагыйрә; «Яңгыр җиле», «Сөюемнән мин бер чибәр идем», «Тамды яшем» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

## Нәкъ безнеңчә

Карап йөрим, нәкъ безнеңчә
Яши икән урман җаны.
Агачның бар пәһлеваны,
Меңьяшәре – ветераны...

## Иген кырында

Каерылып уңган игенең
Җыелмаган, сукмаган –
Гомер юлың кыл урталай
Өзелгән шул, туктаган.

## Өстәлеңне ямьләр

Эше күп, анысы, бакчаның...
Тот йә тотма – ихтыярың.
Өстәлеңне ямьләр көзен
Үз кишерең, үз кыярың.

## Әйләнмәсен чүплеккә

Әдәби сүз өлгералмый
Илдә барган тизлеккә.
Матбугатның гайбәт кыры
Әйләнмәсен чүплеккә.

## Затсызлык

«Әдәп» сүзе ыңгыраша,
Сулкылдый, сызлый бүген.
Хәерчелек һәм затсызлык
Каплады заман күген.

## Зиндан кирмәне кирәкми

Кирегә китмә, тарихым,
Кайтарма шәхес культын.
Рухи зиндан кирмәненә
Бирмә гаделлек пультын!

## Үкенечле кайгы

Кайчакларда елны түгел,
Үткәреп булмый айны.
Үкенечле кайгы шулдыр –
Үзеңә килгән кайгы.

## Алла белә

Бала үлә икән – ана «үлә»,
Җәбер хакын бары Алла белә.
Ишеттеңме Ана сүзен, түрә?
Без дә кеше, үзебезгә күрә!..

## Каенана туфрагыннан...

Киленле йорт ким булмасын,
Киленле йорт киң булсын.
Шул туфрактан туган килен
Каенанага тиң булсын!

## Кадерле кунаккаем

Түремнән уз, түргә утыр,
Мә мендәр, кунаккаем.
Итәк-җиңең җыярак төш,
Яныңа кунаклаем...

## Көчсезлекнең көче

Ирдавайлап, төкерек чәчеп,
Торып булмый ул ирдә.
Хатын-кызның бөтен көче –
Бары көчсезлегендә.

## Дигән идең

Син бит мине әҗәлеңнән
Урлап качам, дигән идең.
Картлык җитте, иртә дә кич
Сине көтеп яткан көнем...

## Язларда калды

Тамыр җибәрмәде талым,
Бөресе бүрталмады.
Язларда калды язмышлар,
Яшәреп киталмады.

## Шарлавык

Кыяларны кыл урталай бүлгән
Котсыз, өнсез кара тарлавык.
Ике як та биек, бөек тә бит...
Ә уртада – төпсез шарлавык.

## Шатлык

Хатың алдым да мин, и сөендем,
Шылтыравык тапкан баладай.
Басып торган җирем кысан иде –
Иркенәйде чиксез даладай.

## Өн һәм төн

Мин төшемдә бүген сине күрдем... –
Аккош булып кайттың күлемә.
Өннәремдә кара көйгән йөрәк,
Күр, төннәрдә нурга күмелә.

## Ысланган бу...

Сүз дә җитми, теш тә үтми –
Ысланган бу, какланган.
Кешелеге күптән беткән,
Кабихлеге сакланган.

## Имансызга

Ашыңны да ашар ул,
Башыңны да ашар ул.
Үз өеңдә, үз түреңдә
Сиңа тәмуг ясар ул.

## Рас килү

Җилпенә җил, тибрәнә җил,
Чайкала су өсләре.
Дөнья күргән кешеләрнең
Рас килүчән төшләре.

## Хуҗабикә сүзе

«Очын очка ялгый алмый
Яшәүләре бик кыен».
...Сыгылып төшкән өстәле,
Кызганып куйдым сыен.

## Чын җырларны сагыну

Язып бара күңел, теркәп бара
Кайчан нинди җырлар кергән.
Такмаклар күп, әмма чын җыр, диеп
Атап була бүген сирәген.



Айгиз
Баймөхәммәтов

# ӘКИЯТСЕЗ БАЛАЧАК

ПОВЕСТЬ

## Әни тавышы

Детдомда яши башлавыбызга атна чамасы вакыт үтте. Ничектер авыр мондагы тормышка өйрәнү. Күңелсез дә, кулга эш тә бармый. Бар уебыз – туган авылыбызга, йортыбызга тоташа. Эх, тормыш! Нигә шулай килеп чыкты икән? Нигә генә әти-әниебез безне иртә калдырып китте? Аларсыз яшәве кыен. Якыннарыбызга бәйле берәр нәрсә искә төшсә, күзгә яшь килә. Тик монда күз яшьләрен күрсәтергә ярамый. Башка малайлар сине әләкләп, оялтырга гына тора. Шуңа мин детдом артындагы каенлыкка чыгам да, берәү дә күрмәгәндә, туйганчы елыйм.

Шушы арада төшләр дә әллә нинди булып керә. Имеш, әниебез тере икән! Ул кайдадыр эш белән генә киткән дә менә-менә кайтырга тиеш. Ә без апаларым белән өйне җыештырып, аның кайтуын көтәбез. Беләм, әни берәр кая барса, буш кул белән йөрми. Менә ул күчтәнәч тулы сумка күтәреп килеп керәчәк. Хәзер кайтыр, хәзер. Шулчак дертләп уянып китәм дә чарасызлыктан тешләремне кысам. Кире кайтмас шул инде безнең әниебез, дим.

Берзаман бүлмәгә Алия апам атылып килеп керде:

– Ильяс, кара, нәрсә таптым! – Кулындагы соры кассетаны болгый-болгый, яныма килеп басты. Үзе шултиклем куана. Шатлыгыннан нәрсә эшләргә белми, урынында сикергәләп-сикергәләп ала.

– Нәрсә соң ул?

– Хәтерлисеңме, мин элек әнинең җырлаганын яздырган идем. – Ул йотлыга-йотлыга әйтеп бирде. – Әле өйдән алып килгән әйберләремне карап утырсам, шул кассета килеп чыкты. Ышанасыңмы?

Куанычыбыздан кочаклашып алдык. Нинди бәхет! Әниебезнең тавышы калган. Хәзер аны ишетәчәкбез. Дулкынлануымнан нәрсә әйтергә дә белмим. Куллар калтырый. Ә күңелдә шундый рәхәтлек.

– Шаяртмыйсыңмы? – дип кабаттан сорап куйдым. Апамның шушы сөенчесе шаярту булудан нык курыктым. Менә-менә минем күз алдыма әнием килеп баскандай. Хәзер ул безгә эндәшәчәк. Ә без аны йотлыгып тыңларбыз.

---

Айгиз БАЙМӨХӘММӘТОВ (1988) – *язучы, журналист; татар, рус, башкорт, казакъ телләрендә чыккан «Калдырма, әнкәй!», «Урам балалары», «Кызык бу тормыш...» кебек китаплар авторы. Шәехзадә Бабич исемендәге Башкортстан Дәүләт республика яшьләр премиясе лауреаты. Уфада яши.*

– Кеше шундый нәрсә белән шаяртамы инде!..

Тиз генә тәрбиячебезгә барып, магнитофон сорап алдык. Безнең төркемдә ул берәү, төрле бәйрәмнәрдә генә чыгаралар аны. Тәрбияче безгә бер генә сәгатькә биреп торды.

Апамның бүлмәсенә кердек, магнитофонны кабыздык та кассетаны куйдык. Икебез генә тын да алмый язманы тыңлый башладык. Тәүдә ниндидер шатыр-шотыр иткән тавыш ишетелде. Тик әнинең җыры гына һаман юк. Шушы минутларда йөрәгемнең ярсып тибүе. Әйтерсең лә без әниебез белән кабаттан очрашырга җыенабыз. Күз ачып йомарбыз да, иң газиз кешебез безнең алга килеп басар.

Алия апам нинди башлы булып чыкты. Ул элек өйдә гел шулай шаяра иде. Безне йә җырлата, йә шигырь сөйләтә дә – шуны магнитофонга яздыра. Менә бит, әниебезнең тавышын яздырырга кемнең башына килсен?

О-о-о... Теге язма башланды...

« – Әни, әйдә теге яраткан җырыңны җырла әле.

– Әй, балакаем. Гел җырлап яшәп булмый. Өй тулы эш. Менә тиздән әтиегез кайтырга тиеш.

– Ән-ни, җырла инде...

– Әбзәлил бәетенме?

– Әйе.

– Ярар, күгәрченкәем. Башта чак кына тарихын сөйләп үтим. Бу бәет безнең авылдан чыккан. Аны Шөгәеп чәчән Роза Аккучуковага багышлаган. Хәзер бу бәетне радиодан еш кына җырлаталар».

Шушы урында язманы туктатып тордык. Тын алып өлгерергә кирәк. Тамакка төер тыгылгандай булды. Әнинең тәүге сүзен ишеткәч, тән чымырдап китте. Икебезнең дә күзгә яшь килде, тик моны бер-беребезгә күрсәтергә тырышмадык. Күзгә-күз карамадык та. Оялдык. Шулчак үзебезне әниебез белән аралашкандай хис иттем. Бу безнең әни. Тере! Аның тавышы шултиклем йомшак, ягымлы. Һәр сүзе колакны иркәли. Әниемнең «балакаем» дигән сүзен ишетер өчен, тоташ җир шарын җәяүләп үтәргә әзермен. Әни... Апам, мыш-мыш килеп, магнитофонның төймәсенә басты, һәм бүлмәгә моңлы тавыш таралды:

Сандугачлар тавышына нигә кинәндем икән?
Моңы барның бәхете күбен алдан күргәнмен икән!
Әй, сандугач моңнары... Йөрәгем ярсулары...
Сандугачлар сайраганда – йөрәгем янулары...

Бу бәетне тыңлагач, эчкә шултиклем җылы йөгерде. Күңелгә дә җиңел булып китте! Аңлата алмаслык рәхәтлек кичердем. Барлык кайгылар да, көндәлек мәшәкатьләр дә онытылгандай булды. Менә никадәр шифалы икән әниебезнең тавышы. Күңелем белән шушы мәлдә үземне балалар йортында түгел, ә өебездә чәй эчеп утыргандай хис иттем. Хыялым белән туган йортка, якыннарым янына очтым. Ә әнинең татлы тавышы дәвам итте:

«Менә шулай, балакайларым. Иманлы булып үсегез. Шул вакытта сездән дә шәп кеше булмас дөньяда...»

Тавыш өзелде... Эх, нигә күбрәк яздырмаган икән Алия?! Әнинең соңгы сүзләреннән дертләп киттем. Иреннәр калтырый. Ул сүзләрдә үгет-нәсихәт тә, сагыш та, хушлашу билгесе дә бар сымак.

Без озак кына шым утырдык. Әнине югалтуыбыз шулкадәр авыр булса да, аның тавышын ишетү – безнең өчен олы бәхет. Әйе, әни тавышы шундый кадерле икән! Аның сүзләрен ишетү белән күңел күтәрелеп китте, бу дөньяда әле без ялгыз түгелбез. Әнинең тере тавышы бар! Ә теге йөрәкне өзгеч моңлы бәет һаман баштан чыкмый. Юк, без барыбер бәхетле... Әни тавышы белән!

Хәзер безнең көннәр яктырак булып китте. Туганнарым белән бер бүлмәгә җыелабыз да теге кассетаны тыңлыйбыз. Зөлфирә сеңлебез бигрәк йотылып тыңлый аны. Чөнки әни «күгәрченкәем» дип еш кына аңа әйтә иде. Шул сүзне ишеттеме – түгелеп елый. Без дә битебезне каплыйбыз – бер-беребезгә күрсәтмәс өчен. Бәетне тыңлыйбыз, «иманлы булыгыз» дигән васыятен ишетәбез дә – тасма бетә...

– Әнине тагын ишетәсе килә, – дип, Зөлфирә кабаттан куюны сорый. Кадерлебез белән «очрашу» янә кабатлана.

Әнинең «иманлы булыгыз» дип әйтүе генә дә нинди көч бирә! Укырга барсаң да, шул сүз колактан чыкмый. Әни тавышы безне курчалап, бөтен җирдә озатып йөргәндәй тоела. Шуңадыр да, мәктәптә укыганда, тырыш булдык, икеле алып кайту оятның-ояты иде.

Берзаман Даян безнең кассета турында ишетеп калган. Ә ул вакытта радиодан яңгыраган шәп җырларны магнитофон аша кассетага яздыралар иде. Даян тәрбиячедән магнитофон алып торган, тик кассетасы юк. Шуңа безнекенә яман кызыккан.

– Синдә кассета бар дип ишеттем. Шуны миңа бирәсең! – диде башлык, каты тавышы белән боерып. Аннан ничек кенә шүрләсәм дә, тын калмадым:

– Ул кассета үзебезгә кирәк. Анда әниебезнең тавышы яздырылган.

– Кемнең тавышы яздырылган – анысы миңа кызык түгел. Әгәр тукмалмаем дисәң, тиз генә алып киләсең...

Шулчак Алия апа килеп чыкты. Күрәсең, Даянның миңа усал итеп каравыннан эшнең нидә икәнен аңлаган.

– Нигә бәйләнәсең энемә? – Апам яклашырга тотынды.

– Ә син нигә, кыз башың белән, кысылып йөрисең? – Даян урыныннан сикереп торды, менә-менә сугыша башларга әзер. – Мин аңардан кассета сорадым. Табачак... Тапмый гына карасын!

– Ильяска тиеп кенә кара. Абыйларым килсә, кирәгеңне бирәчәк. Ул сиңа кассетаны каян алсын? Үземдә генә бар, тик аны үлсәм дә, бирәүгә дә бирмим! Әйдә, киттек моннан, – дип, апам мине алып китте.

– Күрсәтермен әле... – Даян кырын карап торып калды.

...Алия апа белән, шатланышып, мәктәптән кайтып киләбез. Куанырлык та шул. Бүген апам «бишле»ләр алган. Минем дә көндәлеккә яхшы билгеләр кунаклады! Әгәр укулар шулай яхшы барса, «хорошист» та булырбыз әле!

– Ильяс, ә син беләсеңме бүген нинди көн? – Апам имтихан алгандай сорап куйды.

– Әлләче... – кинәт нәрсә дип җавап бирергә белмәдем.

– Кит! Оят! Бүген әниебезнең туган көне!

Чынлап та, ничек шул көн баштан чыккан икән! Әйе, әнием исән булса, бүген аңа 44 яшь тулыр иде.

– Әниебез шуны күрсә, ничек куаныр иде, – дип, авыр көрсенеп куйды апам.

Бу матур көнне әнине ешрак искә алырга кирәк. Шуңа төшке аштан соң, бөтенебез дә Алия бүлмәсенә җыелып, теге кассетаны тыңларга килештек. Әни тавышын көн дә тыңларга әзер без.

Төркемебезгә кергәч, Алия үзенең бүлмәсенә юнәлде. Мин дә үземә кереп, мәктәп костюмын алыштырырга булдым. Биш минут чамасы үттеме-юкмы, кызлар бүлмәсеннән берәүнең кычкырып елаганы ишетелде. Дерт итеп калдым. Нәрсә булган икән дип, шул бүлмәгә омтылдым. Карасам, Алия апам идәнгә утырган да нәрсәдер актарып эзли, үзе туктаусыз елый. Тумбочкадагы барлык китаплары, дәфтәрләре һәм башка әйберләре идәндә тузышып ята.

− Нәрсә булды? – дим аптырап.

− Урлаган... Шушында гына ята иде... – үзе яхшылап бернәрсә дә әйтә алмый, туктый алмый түгелеп елый.

− Нәрсәне? Кешечә аңлат әле...

− Безнең кассета! Әнинең тавышы! – Апамның бу хәбәреннән иреннәрем калтырап китте, башка эссе йөгерде. Әйтерсең лә тәннән электр уты үткәрәләр! Шунда ук Даян искә килеп төште. Аның гына эшедер. Мондый мәлдә үземнең нәрсә эшләгәнемне белми идем. Минем белән әллә кем идарә иткән кебек тоелды. Бер минутны да югалтырга ярамый. Чаптым Даянның бүлмәсенә. Ишеген шакып тормаенча, ук кебек атылып килеп кердем. Карасам, ул караватына сузылып яткан да музыка тыңлап кинәнә. Аңа бер сүз әйтмичә, җан көчем белән магнитофонга барып ябыштым. Башлык, аптырап, урыныннан сикереп торды.

− Син нәрсә, салага, акылдан яздыңмы?

− Бир кассетаны. Анда – әнием! – ачуымнан җан көчемә кычкырдым. Мондый гамәлемнән Даянның күзләре акайды. Йодрыкларын төйнәп, сугышырга омтылды. Ярдәмгә апам килеп керде дә тырнаклары белән аның битенә ябышты. Китте талаш, тартыш, кычкырыш... Әгәр шау-шуга тәрбияче килеп кермәсә, бу алышның нәрсә белән бетәсен белерлек түгел иде.

− Нәрсә өчен үлешәсез хәзер? – дип туктатырга тотынды тәрбиячебез.

− Ул безнең кассетаны урлаган. – Алия күз яшен тыя алмый сөйләп бирде. – Анда әниебезнең тавышы яздырылган.

Тәрбияченең җавабы кыска булды. Шулай да ул безнең яклы иде:

− Хәзер үк кире бир! – диде Даянга. – Ә магнитофонны башка сорап йөрмәгез. Кабинетыма бикләп куям.

Без теге соры кассетаны алып чыгып киттек. Шулай җиңел кайтара алуыбызга куанып бетә алмадык. Әгәр шунда авызыбызны йомып йөрсәк, иң кадерле әйберебездән колак кагар идек. Азак, тәрбияче булмаган чакта, Даян хет әллә нәрсә эшләсен. Тукмалсам да курыкмадым. Иң мөһиме – әниебезнең тавышы безнең белән.

Үзебездәге магнитофонны бикләп куйгач, икенче төркемгә сорап бардык. Шунда ук тыңларга булдык. Тик... без иртә шатланганбыз икән. Кассетаның теге ягын да, бу ягын да әйләндереп тыңлап карадык. Әниебезнең генә тавышы табылмады. Даян аның өстенә әллә нинди рок җырлары яздырып бетергән. Шушы мәлдә нинди тетрәнү кичергәнебезне аңлыйсыздыр.

Әнә шулай соңгы шатлыгыбыздан мәхрүм булдык. Без инде әниебезне икенче тапкыр югалттык. Мәңгегә.

## Сынау

Соңгы арада безнең төркемдәге малай-кызларның укуы хөртиләште. Йә тегесе, йә монысы мәктәптән «икеле» алып кайта. Моның өчен детдом директоры тәрбиячебезгә шелтә ясар, ә ул балаларның иманын укытыр. Бу юлы тәрбиячебез Рәйфә апа, барыбызны җыеп, соңгы арада икеле алганнарның кирәген бирде.

– Икмәк череткечләр сез! – диде, төкереген чәчә-чәчә. Җылыда йоклаудан, эчегез шартлардай булып ашаудан башка бернәрсә дә белмисез. Хөкүмәт сезне асраганчы, берәр чучка фермасы ачса, файдасы күбрәк булыр иде. Сез бит безнең балалар күрмәгән рәхәтлектә яшисез. Ә үзегездән тырнак очыдай булса да файда килсәче...

– Булыр әле берәр заман, – бу сүзне әче телле Әмилә ычкындырды.

Көтмәгәндә шулай бүлдерүләренә Рәйфә апа чыгырыннан чыкты:

– Ах, син шайтан таягы! Мин сөйләгәндә, авызыңны учың белән йомып утыр, йолкыш.

– Мин шайтан таягы түгел...

– Бияләй авызыңа хуҗа була алмасаң – мә сиңа! – Рәйфә апа калын табанлы тапочкасын салды да Әмиләгә очырды. Тәрбиячебезнең бу «коралы» чәпкә тиде, кызның кулында шак итеп калды. Авыртуга түзә алмыйча, ул елап чыгып китте. Барыбыз алдында берәүнең авызын шулай япкач, аның кәефе күтәрелде. Ул үзен тагын да иркенләбрәк тотып, безне олы ләззәт белән әрләргә кереште. Шулай итеп, берәү дә өлешсез калмады.

– Уйлап йөрдем-йөрдем дә шундый карарга килдем әле, – диде ул, туктаусыз әрләшүдән тирләп беткән зур күзлеген сөртеп, – кем эшләми – шул ашамый, диләр халыкта. Мин бу мәкальне «кем укымый – шул ашамый» дип үзгәртер идем. Шуңа күрә бүгеннән алып конкурс үткәрергә булдым. Кем дә кем шушы чирекне «өчле»сез тәмамлый, шул бөтен төркемнең бер көнлек полднигын ашаячак. Сез ризамы шушы шартка?

Күпләре ризалыгын белдерде. Тик Динар исемле малай гына өнсез калды. Дөресен әйткәндә, аның башы шул икелеләрдән чыкканы юк. Көн дә диярлек мәктәптән бер сумка икеле тутырып кайта. Күпләр, аңардан көлеп, «Академик» дигән кушамат та тагып куйган.

– Ә син нигә эндәшмисең, Академик? – Рәйфә апаның соравы мыскыллы яңгырады.

– Әлләче... – Динар аптырап калды. – Әгәр дә полдникка берәр җимеш бирелсә, шулар барысы да ботаникка гына эләгәме?

– Хәлеңнән килсә, син дә ботаник бул, – диде тәрбияче.

– Ярар, Академик, инәлтмә инде. Ризалаш та куй, барыбер син җиңеп чыгасың бит, – балалар арасыннан берәүнең шулай әйтүе булды, барысы да шаркылдап көләргә тотынды.

Тәрбиячебезнең бу конкурсын берәүләр уңай кабул итсә, кемдер авыр көрсенеп куйды. Тик ничек кенә булмасын, Рәйфә апаның сүзен егып кара! Аның кигән тапочкасы йә кулындагы ачкычлар бәйләме синең арт сабагыңны укытырга әзер генә тора.

Тәмле-татлы белән балалар йортында безне әллә ни иркәләмиләр. Башкаладан дәү-дәү кунаклар килгәндә генә рәхәтләнеп калабыз. Ә болай сирәк-саяк алма бирелсә дә, аны көчлерәкләр тартып ала, йә мәктәптән соңлабрак кайтсаң, урлап ашап куялар. Кайсы вакытта алманы чиләге белән ашыйсы килеп китә...

Безнең төркемдә әлеге көндә егермеләп бала тәрбияләнә. Әгәр дә мәгәр мин тик яхшы билгеләргә генә чирекне тәмамласам.... ай, күз алдына китерүе дә кыен. Шулкадәр алманы миңа тоттырсыннар әле! Менә мин кызарып пешкәнен алып, шатырдатып тешлим. Вәт булыр иде бәйрәм! Шушыларны күз алдыма китереп, авызыма әчкелтем сыекча йөгерде. Куй, юк белән котырынып, нәфесемне198 аздырмыйм әле. Әллә эләгә сиңа, әллә юк. Үз өлешеңнән колак

какмасаң, бик хуш инде. Ничек кенә булмасын, укуда алган яхшы белгеләрең үзең өчен. Тырышып карарга кирәк...

Рәйфә апа игълан иткән шушы конкурс башланып китте. Кемдер укуга җаваплырак карый башлады, ә кемнәрдер өчен бу сөйләшү булды ни, юк ни. Болында үскән чәчкәләрнең күп төсле булуы кебек, безнең төркемдәге балаларның да холык-фигыле төрлечә. Арада тәртиплеләре, эт ялкаулары да, аз сүзлеләре дә, гайбәт капчыклары да бар.

Безнекеләр, мәктәпкә барган саен, төрле маҗараларга очрап кына тора. Ул вакыйганың шаһитлары, детдомга кайтуга, барысын да түкми-чәчми ачып сала.

Академик-Динар белән булган кызыклы хәлне ишетмәгән кеше юктыр. Ул да укуга салкын караганы өчен, шундый хәлләргә тарып кына тора. Динар мәктәпкә беркайчан да китап-дәфтәр күтәреп йөрми. Аның сумкасында ел буена бердәнбер «общий» дәфтәр ята. Шунда, искә төшкәндә бер, математикадан да, физикадан да, географиядән дә бер-ике юл язып куя. Күрәсең, ул «общий дәфтәр» дигәнне шулай аңлый.

Математика дәресе бара икән. Динар класска кергән дә, соңгы рәткә үтеп, дүрт утыргычны янәшә куеп йокларга яткан. Моны укытучы да күрмәгән. Шулай итеп, дәрес кызганнан-кыза, ди. Укучылар, чиратлап такта алдына чыгып, төрле мәсьәлә чишә. Берзаман бәхәсләшеп китәләр. Берәү классташының эшен дөрес дип таный, кемдер исә хатасын исбатлый.

– Апа ул дөрес эшләде. Сез өйрәткән формула буенча бит!

– Кит, юкны сөйлисең! Шыр хата!

Укучылар арасында бәхәс әллә күпме дәвам итәр иде. Шул арада иң соңгы рәттән кемдер сөрән сала:

– Нәрсә каркылдашасыз анда?! Ичмасам, кешечә йокларга пакуй бирегез!

Укытучы да, малай-кызлар да тынып кала. Эшнең нидә икәненә төшенгәч кенә, рәхәтләнеп көләргә тотыналар. Баксаң, безнең Академик дәрестә икәнен бөтенләй оныткан.

Динар, ничек кенә булса да, дәрескә йөри әле. Ә менә Даянның уку дип исе дә китми. Исем өчен генә мәктәпкә барып кайта. Бик теләмәсә, барып та тормый. Иртәнчәк детдомнан чыгып китә дә юл уңае таныш-белешләренә сугыла. Шунда туйганчы тәмәке борхылдатып ала. Анда-монда йөреп вакыт үткәрә дә төшке ашка тып итеп кайтып та җитә.

Укуга шулай талпынып тормавының сәбәбен дә аңлата.

– Ә мин физкультура техникумына укырга барам, – ди ул, исе дә китмичә. – Анда барыр өчен әллә нәрсә белергә кирәкми. Бары көчең генә булсын. Менә күрерсез: берничә ел башкала техникумында укырмын да авылыбызның мәктәбенә директор булып килеп төшермен әле. Ну шулвакыт миңа «икеле» куеп җәфалаткан укытучыларга көн бетәчәк. Үзләрен яланаяк кузга бастырачакмын.

Ә менә Әмилә соңгы арада яхшы укый башлады. Өй эшенә ниндидер җаваплылык белән карый ул. Мәктәптә сине бар дип тә белми, эргәңә килеп сөйләшми, өйгә эшне эшләргә тотынса, артыңнан калмый. Күрсәтеп, аңлатып бирүне сорый.

Мәктәптә Әмилә үзен эре тота. Шуңадыр да класстагы укучылар аның белән аралашуны мәртәбә дип саный. Барысы да белә – Әмилә әкәм-төкәм белән сөйләшеп тә тормый. Җитмәсә, аның теле ачы.

Әмилә гәүдәгә юантык кына. Мәктәптә бер кыз аны кимсетмәкче булып болай дигән:

– Юан кызларны шултиклем кызганам. Аларга егетләр ничек карый икән...

Әмилә һич тә югалып калмаган:

– Егетләр эт түгел, сөяккә ташланмыйлар. Мин, киресенчә, ябыкларны кызганам, – дигән ул, исе дә китмичә.

Беркөнне тәнәфес вакытында Әмилә яныма килеп утырды. Кәефең ничек дип сорады, нинди уй-хыяллар белән йөрүемне дә белеште.

– Менә мин сиңа карыйм да сокланып туя алмыйм, – диде классташым, елмаеп, – мәктәпкә көн дә вакытында киләсең. Белмәгән нәрсәң юк – укытучының һәр соравына дөрес җавап бирәсең...

– Куй, шаштырма.

– Нишләп шаштырыйм, ди! Синең кебекләрне очратканым юк әле. Беләсең килсә, Ильяс, синең белән аралашу үзе зур бәхет! – дип, ут өстәп җибәрде Әмилә.

Тик торганнан классташымның мине мактавына аптырап куйдым. Бигрәк татлы телгә әйләнгән бит!

Тәнәфестә Әмилә янә яныма килде дә:

– Кара әле, Ильяс, синең башыңда әллә компьютер утырамы? Каян шултиклем күпне беләсең? – дип сорады.

– Дәресләрне калдырмасаң, аны гына барысы да белә инде...

– Әйдә, башыбызны алмашып торыйк, – диде ул, мут елмаеп.

Әмиләнең нигә үзен болай тотуын озак кына төшенми йөрдем. Исе китеп, мине мактай бит! Булмаган хәл! Берәр «әтнәкесе» бардыр, мөгаен. Иң соңгы дәрес – математика башланыр алдыннан гына төшендем.

– Ильяс, акыллым, сиңа бер үтенечем бар иде, – Әмилә, уңайсызланган булып, минем яныма килде, – хәзер математикадан имтихан булачак. Шул, кайсыбер формулаларда буталам да куям. Әллә синең белән бер партага утырыйм микән?! Шунда, бер-ике урында, ярдәмләшеп җибәрерсең...

Менә нәрсәдә икән Әмиләнең киң күңеллелегенең сәбәбе. Ә мин, исәр, җылы сүзгә эреп, аның максаты турында уйлап та бирмәгәнмен. Үземне чынлап та җылы сүзләргә лаек дип ышанып йөрдем. Әмма бу хакта соңыннан гына аңладым.

– Әйдә, утыр! Миңа бер тамчы да авырлыгы юк, – дип әйткәнемне сизми дә калдым...

Дәресләр бетәр-бетмәс, «кем узар»дан детдомга йөгерәбез. Моның сәбәбе дә бар. Гадәттә, төркемдә дежур кеше, төшке аш вакыты җиткәч, барысына да өстәл әзерли. Ашын сала, һәр кешегә исәпләп, икмәк тарата.

Соңлап килсәң – ашың күптән суынган инде. Салкын ашның ни тәме, ни бәрәкәте юк. Авызыңны ачып, аягыңны көчкә сөйрәп йөрсәң – бөтенләй ашсыз калуың да бар. Шулай булгач, йөгерми кая барасың?!

Бүген классташым Әмилә тагы да сөенечле хәбәр сөйләп китте. Чын булса – төшке ашка груша бирәләр икән! Ур-ра-ааа! У-уух, тизрәк кайтырга иде. Менә шул татлы җимешне рәхәтләнеп тешләячәгемне күз алдыма китерәм... Иреннәрем буйлап аның тәмле суты ага, имеш. Татлы хыяллардан авызда бал тәме барлыкка килгәндәй булды. Шундый вакытта гелән берәр каршылыгы чыгып тора. Ичмасам, дәресләре азрак түгел. Башкалар күптән кайтып китте. Ничек кенә түзәргә икән? Әллә соңгы дәрестән качып кайтыйм микән? Алай итсәң, азак укытучыдан эләгәчәк. Ә груша, агачтагы алланып пешкән җимеш кебек, күңелне ымсындырып тора...

Хәерчегә җил каршы дигәндәй, мәктәптән соңлап кайтырга туры килде.

Өстемне дә алыштырмый, ашханәгә чаптым. Ох! Хәзер теге грушаны ашаячакмын. Ашыйм дигәч тә, умырып кабарга мин ул тиклем үк комсыз түгел. Җимешнең тәмен татып, ләззәтләнеп сутын суырачакмын...

Өстәл янына тиз генә килеп җиттем дә аптыраштан катып калдым. Мин көн буена хыялланган, балланып пешкән груша урынына алдымда күгәреп, бәлҗерәп беткән җимеш ята иде. Үз күзләремә үзем ышанмый, кулыма алган идем, җимеш сытылып китте дә, бармакларыма сыек лайла ябышты. Әйтерсең, баядан бирле йөргән хыялым сытылды. Кулымдагы черек җимешне өстәлгә ташладым да ашханәдән чыгу ягына юнәлдем...

Берничә көн үткәч, җимешнең череккә әйләнү серенә төшендем. Баксаң, Даянның этлеге икән. Җитмәсә, мыскыл итеп, детдомдагы чүплектән черек грушаны алып, өстәлемә куйган. Шул көндә груша ашамаганым өчен түгел, черек җимеш салуы өчен җаным көйде.

Нindидер татлы ризыктан мәхрүм калу тойгысы күңелдә озак сакланмый ул, кайберәүләрнең күңел череклеге гомер буена истән чыкмый. Ярый әле ул «череклек» тик үзендә генә калса. Теге чактагы сытылган груша кебек исе дөньяга таралучан шул…

Уку чиреге «һә» дигәнче үтте дә китте. Груша тарихы да, иртәнге томан кебек хәтер күгендә эреп, күптән юкка чыккан иде. Беркөн төшке аштан соң барыбыз да бүлмәгә җыелдык. Сәбәбе күптән билгеле. Рәйфә апа чирек тәмамлану уңаеннан җыелыш үткәрә.

– Мин үз сүземдә торам, – дип башлады тәрбиячебез. – Әгәр исегездә булса, бергәләп конкурс игълан иткән идек. Шунда җиңүчегә төркемнең полдникка бирелгән алмаларын тапшырырга сүз бирдек. Сез дә ризалаштыгыз. Вәгъдәне үтим, – дип, Рәйфә апа алдыма бер пакет алма куйды. – Үпкәләштән булмасын, бу чиректә Ильясның гына «өчле»ләре чыкмады. Рәхәтләнеп сыйлан, Ильяс!

Авыз ачып, бер сүз дә әйтә алмый калдым, Рәйфә апа чыгып киткән иде инде. Төркемдәшләрнең барысы да миңа текәлгән. Аларның карашлары җанымны кимергәндәй тоелды. Көн саен чирекне яхшы тәмамлау хакында хыяллансам, хәзер килеп «өчле» чыкмау өчен үкенеч тойгысы биләде. Пакетны алдым да алмаларымны таратырга тотындым. Шулчак кемдер:

– Даянга бирмә! Ул теге чакта сиңа черек груша салды, – дип пышылдады.

Чират иң артта утырган Даянга җиткәндә, пакетта нибары бер генә алма калган иде. Кызарып пешкән зур соңгы алманы мин аның учына салдым.

### Бәйрәм

8 март бәйрәме уңаеннан мәктәптә табын оештырырга булдылар.

– Иртәгә чәй эчәбез. Һәркем тәм-том алып килсен, – диде класс җитәкчесе. Бу сүзләрне ишеткәч, без – детдом балалары аптырашта калдык.

– Ә без авыз күтәреп килә алмыйбыз бит, – дип сөйләнде Әмилә. – Кем безгә кәнфит тоттырсын?

Детдом директорына шалтыратып сөйләшермен. Мөгаен, берәр әмәлен табар, – дип тынычландырды укытучыбыз.

Чынлап та, аның әйткән сүзләре раска чыкты. Келәт мөдире, безне чакырып, бер кило кәнфит, бер кило печенье бирде. Башкалар алдында үзебезне ким тоймаячакбыз хәзер. Шуңа шатланып бетә алмадык.

Әмилә, Фәрит, мин мәктәптәге бу табын артында үзебезне бик иркен тоттык. Шулай булмыйча ни: буш кул белән килмәдек бит! И рәхәтләнеп сыйландык

шунда. Кемнеңдер әнисе пәрәмәчләр пешергән, икенчесенеке чәкчәк ясаган, бавырсаклар, төрле бәлешләр... телеңне йотарлык! Ашап өлгер генә! Күңел булып, туенып кайттык мәктәптән. Вәт, көн дә бәйрәм булсын иде дә ул.

Бу көннән соң бер атна вакыт үтте. Ә өстәлдәге тәм-томнар һаман истән чыкмый. Бигрәк тә, кайсысын ашамый калгансың, шунысы үкендерә. Гел шулай бит. «Нигә теге мәлдә шул тәм-томны ашамадым икән, исәр», дип уйлыйсың соңыннан.

Мәктәптән кайтып барышлый, тагы ашау хакында сүз чыкты:

− Теге көнне ничек шәп бәйрәм булды, − дип, ярага тоз салды Әмилә. – Өстәл сыйдан сыгылып торды. М-м-м...

− Куй, эчне кыздырып, искә төшермә әле, − дидем, ачу килеп.

− Инде киләсе бәйрәм кайчан булыр икән? – Бу сорау Фәритне нык борчый, күрәсең.

− Ул әле генә түгел. – Әмилә кулын селтәп куйды. – 1 Май гына. Анысында да барысы да ял итә. Мәктәптә чәй кайгысы булмый анда.

Шым гына күпмедер бара бирдек.

− Башка бик шәп идея килде, − Әмилә, шатланып, учын-учка сукты.

− Берәр бәйрәм көнен билгеләү турында закон чыгарасыңмы әллә? − Фәрит көлеп куйды.

− Бәйрәм иртәгә булачак, − дип, катгый әйтте Әмилә.

− Ничек инде алай? – Аптыравымны яшерә алмадым.

− Ә менә шулай! – Классташыбыз туктады да, бүтәннәр ишетеп калмасын дипме, тавышын киметте. Безне үзенә якынрак чакырып алды. – Хәзер детдомга кайткач, тагын да чәй эчү булачак, дип әйтәбез. Ә тәрбиячебез шуның өчен келәттән тәм-том алып бирәчәк.

− Иртәгә мәктәптә бернинди дә табын оештырылмый бит, − дигән булдым.

− Булмаса ни! Ә сез мин әйткәнне куәтләп торыгыз! Укытучыбызга шалтыратып, кем белешеп торсын инде?!

− Тотылмасак ярар да ул. Ә нинди бәйрәм уңаеннан чәй эчәбез соң?

Әмилә җавапны озак уйламады:

− Классыбыз республика конкурсында беренче урын алган. Шуның хөрмәтенә!

Күпме беләм шушы Әмиләне, ләкин аның үткерлегенә, җорлыгына сокланып бетә алмыйм. Чынлап та, барысы да ул әйткәнчә килеп чыкты. Тәрбиячебезгә йомыш белән ул эндәште. Шуннан, безне ияртеп, келәт мөдиренә алып бардылар. Өчебезнең исеменнән гариза язарга кушты мөдир. Әмилә язмада иртәгә мәктәптә бәйрәм табыны оештырыла, шуңа кәнфит, печенье бирүләрен сорады. Булды. Үтенечебезне кире какмадылар.

Иртәгесе көнне рәхәтләндек кенә. Төштән соң мәктәпкә бәйрәм табынына дип чыгып киттек тә – юк булдык. Авыл урамнары буйлап тәм-том ашап тик йөрдек. Эч күпкәнче ашадык. Ә тәрбиячебез, без мәктәптә утыра дип уйлагандыр әле. Тегеләрне төп башына утырта алганыбызга туктаусыз шаркылдап көлештек.

− Әнә шулай кыю булырга кирәк! – дип акыл өйрәтә Әмилә. – Әгәр оялып кына читтә йөрсәгез – ач калырсыз. Мин менә бер дә тартынып тормыйм. Ашауның ояты юк...

Янә ару гына вакыт үтте. Теге хәйләбез хакында берәү дә белмәде. Ә нәфес һаман үзенекен итә.

− Әллә тагы бәйрәм оештырыргамы? – ди мәктәптән кайтышлый Әмилә.

− Әлләче...

− Тик алдан ук әйтеп куям: бу юлы Фәритнең чираты. Гаризаны ул яза.

− Ә нинди бәйрәм, диярбез?

Әмилә җавапны тиз тапты:

− Классыбызда «Шаяннар һәм үткерләр» конкурсы үтәчәк. Шуннан соң чәй эчәбез. Бу класс җитәкчесенең тәкъдиме, диярбез.

Теге хәл янә кабатланды. Бу юлы тәрбиячегә Фәрит эндәште. Ул тәртипле, тыйнак малай, укуы да яхшы. Шундый самими бала ничек алдашып йөрсен ди?! Шуңа аңа ышандылар да.

Келәт мөдиренә бардык. Гариза яздык. Тәм-томнар белән тулган ике капчыкны кулга эләктердек. Иртәгесе көнне «бәйрәмебез» янә кабатланды. Монысында инде авыл китапханәсенә бардык. Китап та укыдык, сыйландык та. Тик печеньене коры көенә ашау кыенрак икән.

− Киләсе тапкыр бәйрәм була калса – сут сорап алырга кирәк. Әтү болай тамак кибә, − дип көлештек.

Тагын ике атна вакыт үтте. Ә Әмиләнең теге шәп тәкъдиме һаман баштан чыкмый. Хәйләбез хакында бүтәннәрнең җиде ятып бер төшенә дә кермидер әле. Йөриләр инде шунда кайчан чәйгә бер-ике печенье бирерләр, дип. Ярый, бераз хәрәмләшеп алдык − җиткән. Көн дә бәйрәм, көн дә туй булмый. Шундый уйлар белән мин үземне тынычландырган идем. Фәрит кенә котыртып җибәрде:

− Ильяс, кәнфит ашыйсың киләме? – Сүзнең нәрсә хакында икәненә шунда ук төшендем. Тик чама кирәк ласа. Тотылуыбыз бар.

− Килә дә ул. Әлегә җитеп торыр инде, − дигән булдым.

− Ничек кенә котылырга уйлыйсың! − сүзгә Әмилә кушылды. – Мин дә, Фәрит тә сорады, инде синең чират.

− Сорар идем дә ул, − дидем уңайсызланып. – Тик әле бернинди дә бәйрәм юк бит...

Әмилә әйтеп бетерергә дә ирек бирмәде:

− Мәктәптә сугыш ветераны белән очрашу булачак. Аксакал белән сөйләшү табын артында барачак.

Ничек кенә киреләнеп маташсам да, барыбер тегеләрнең сүзен егып булмады. Хәзер инде минем чират...

Келәт мөдиренә аяк тартмады. Ләкин классташлар алдында бурычлы калырга тиеш түгелмен. Инде тәрбиячебезне борчып тормадык – туры келәткә киттек.

− Сут сорарга онытма әле! Әтү коры көенә ашасаң, тамак кибә, − дип акыл өйрәтте тегеләр.

Ишек төбенә килеп баскач, нәрсәдер чутлап утырган мөдир өчебезгә дә сынаулы карап алды.

− Тагын килдегезме? Нәрсә кирәк?

Аның катырак эндәшүеннән буыннар җебеп төште. Нәрсә әйтергә дә белми тынып калдым. Авызыңны ачып тик торма, дигәндәй, Әмилә җиңемнән тартты.

− Апа, мәктәптә классыбызда чәй эчү була, – дидем көчкә-көчкә.

Бу сүзләрне ишетеп, мөдирнең коты очты. Урыныннан ыргып торды да әрләргә тотынды:

− Нинди бетмәс табын ул?!

− Әллә. Мәктәптә шулай хәл иткәннәр бит, − дип, Әмилә яклашырга тотынды.

– Кара син аларны! – Мөдир йомшарырга теләмәде. – Болай булса, хөкүмәтне такырына таяндырасыз бит!

Башка әйтер сүзем калмады. Юкка килгән көнгә калдым дип, эчтән генә үземне әрләдем. Мөдирләрнең безгә тәм-том бирмәячәге көн кебек ачык. Тик эшне зурга җибәрмәскә иде. Ничек кенә булса да шушы хәлдән котылу ягын уйларга кирәк. «Шаярттык» дип кенә чыгып китеп булмый бит.

Хәерчегә җил каршы, дип, бушка әйтмәгәннәр икән. Нәкъ шул вакытта келәткә детдом директоры Мәүлидә Нургалиевна килеп керде. Бик теләсәң дә, шулай килеп чыкмас...

– Бәй, сез монда нишләп торасыз? – дип кызыксынды ул.

Шуны гына көткәндәй, мөдир ачуын ярып салды:

– Мәүлидә Нургалиевна, шушы балалар белән нишләргә икән? Киләләр дә кәнфит сорыйлар. Классларында әллә атна саен бәйрәм оештыралар. Соңгы арада гына дүртенче тапкыр килделәр.

– Бу дөресме? – дип сорады директор.

– Әйе, – дидек бертавыштан. Башка нәрсә дип әйтәсең инде?!

Директорыбызның йөзе үзгәрде. Нәрсәдер уйлап, бераз читкә карап торды да безгә эндәште:

– Укытучылары әллә акылдан язганмы? Хәзер мәктәпкә шалтыратып тиргим әле. Безнең балаларны шаштырып ятмасын!

Директор тыкылдатып басып чыгып китте. Ә без кәеф кырылып, кире төркемебезгә юнәлдек. Менә сиңа «мә»! Хәзер нәрсә булыр икән? Ичмасам, укытучы белән бәйләнешкә керә алмаса ярар иде, дип, эчтән теләдем.

Ун минут үттеме-юкмы, төркемебезгә директор атылып килеп керде:

– Ач каргалар! Туймас тамаклар! Икмәк череткечләр!

Тәүдә залда телевизор карап утырган Әмиләнең чәчен җыеп тотып алды:

– Кара син аларны! Алдап маташалар! Тагын нәрсә җитми сезгә? – Классташыбыз бары авыртудан кычкырды гына.

Шуннан зур балдаклы бармагы белән Фәритнең һәм минем чигәне төйде. Башкалар аптырап карап каткан.

– Нәрсә булды соң, апа? – дип кызыксынды берәү.

– Шушы ач бетләр сезнең айлык өлешегезне ашаган! Хәзер берегезгә дә тәм-том тәтемәячәк, – диде ярсып Мәүлидә Нургалиевна. – Инде үзегез уйлагыз: нәрсә эшләтергә аларны.

Шулчак йөрәгемне нидер чеметеп алгандай булды: җимгә алданып, кармакка эләккән балык сыман тойдым үземне. Тәмле әйбернең дә йөрәк болгандыргыч тәмсезлеге була икән...

## Хыял

Күрше бүлмәдә берәүнең сулкылдап елаганы ишетелде. Йөрәк жу итте. Нәрсә булды икән? Барыбыз да шунда атылып барып кердек. Караватның почмагында, куллары белән тубыгын кочаклап, башын түбән игән Рөстәм утыра иде. Ул детдомда икенче ел гына яши. Бишенче класста укый. Малайның чем-кара күзләрендә һәрвакыт нindидер сагыш чагылгандай. Аның елмайган чагын бер дә күргәнем юк.

– Рөстәм, нәрсә булды? Нигә елыйсың? – Без малайны тынычландырырга тырыштык.

– Йә, берәрсе тидеме әллә? – Шешенеп беткән малай һаман селкенә-селкенә сыктавын дәвам итте.

– Кем тукмады?

– Әйт әле миңа, хәзер измәсен изәм, – дип, малайларның зуррагы, кесәсеннән чыгарып, кәнфит сузды. Әмма Рөстәм башын күтәреп тә карамады.

Шулчак шар итеп ишек ачылып китте дә, бүлмәгә тәрбиячебез Рәйфә апа атылып килеп керде.

– Монда нинди тавыш! Чак читкә китәр әмәл юк, тотынасыз үтерешергә. Яныгыздан китми, сезне каравыллап утырыйммы? Үземнең дөньям юкмыни? Сыерларым акырыша. Кеше баласын кеше итәм дип, үземнекеләрне күргән дә юк. – Тәрбиячебез, көрәктәй йодрыгы белән чигәбезгә менә-менә тондырам дигәндәй, омтылып-омтылып безгә зәһәр итеп карады. – Йә, кемнең кулы кычытып тора? Хәзер бәләкәйләргә көчегез җитәме?

– Юк, апа, без тимәдек.

Рәйфә апа алга атлады да каты үкчәле итеге белән идәнгә шакылдатып басты:

– Алдашмагыз! Тиктомалдан кеше елыймы?

– Үзебез дә елаган тавышны ишетеп кенә кердек. Рөстәм үзе генә утыра иде. Ә нәрсә булганын без дә белмибез...

Рөстәм – йомыграк малай. Детдомга килгәч тә, авызына су капкандай, бер сүз дә эндәшми йөрде. Исемен сорасаң да, кайдан килгәнен белешсәң дә, йә башын ия, йә бөтенләй ишетмәмешкә салыша. Әллә телсезме икән дип аптырашып куйдык. Ул акылга бертөрле шикеллерәк дигән хәбәр дә йөрде.

Соңыннан гына ишеттек. Тәрбиячебез сөйләде. Рөстәмне нәни генә көенә буранлы көндә чүплек яныннан урам себерүче табып алган. Песи тавышы ишетелгәнгә барып караса, төргәктә сабый ята, ди. Үзе белән бер документы да булмаган. Ул тәүдә сабыйлар йортында, соңыннан приютта яшәгән. Мәктәптә укый башлагач кына детдомга күчергәннәр.

Күпме генә тырышсак та, малайның исемен барыбер белә алмадык. Ә аңа ничектер эндәшергә кирәк иде бит. «Аның исеме Рөстәм шикелле», – диде берәү, зур ачыш ясагандай.

Шулай итеп, яңа гына килгән малайны Рөстәм дип атадык. Алай эндәшсәк, ул да безгә игътибар итә. Айдан артык вакыт үткәч, малай җайлап кына сөйләшә башлады.

Тик документлар килгәч, барыбыз да аптырашта калдык. Малай Рөстәм түгел, ә Илнур Буранов булып чыкты. Исемен – табып алган кеше хөрмәтенә, ә фамилиясен ажгыр буранлы көнгә бәйләп кушканнар икән!

Детдомда бирелгән исемгә ул да, без дә өйрәнгән идек. Барыбер Рөстәм дип йөрттек.

Бер заман шундый хәл булды...

Төштән соң, ашап алгач, Рөстәм каядыр юкка чыга. Сәгатьтән артык йөреп, күңеле күтәрелеп кайта. Бу хәл еш кабатланды. Малайның нәрсә белән булышканын беләсем килде. Шуңа, сиздерми генә, аны күзәтергә булдым.

Менә Рөстәм балалар йортыннан чыкты. Шунда ук уң якка борылып, туп-туры каенлыкка юнәлде. Мин шым гына артыннан бара бирдем, ул моны шәйләмәде дә. Урман эченә төпкәрәк үткәч, малай сомгыл гына каенны кочаклады да нидер пышылдарга тотынды. Күпме тырышсам да, барыбер авызыннан чыккан сүзләрен ишетә алмадым. Озак кына шулай каенга ниндидер серен сөйләде. Рөстәм берчә күккә карап елмайды, берчә аккан күз яшьләрен сөртеп алды. Мин, комачауламаска тырышып, иплән кенә кайту ягын карадым.

Шул арада малай мине шәйләп калды. Көтмәгәндә, урманда бүтәнне күргәч, сискәнеп куйды, йөзе үзгәрде.

− Агай, син бу турыда беркемгә дә сөйләмә инде. – Рөстәмнең тәүге сүзе шул булды.

− Ярар, әйтмәм. Ә син монда ялгызың нишләп йөрисең?

− Детдомда мин уйларымны сөйләргә куркам. – Уңайсызлануы малайның йөзенә чыккан иде. Иреннәре калтырап, гаепле тавыш белән җавап кайтарды. – Берәүгә әйтсәм, азак аптыратып, бөтен кешегә сөйләп йөриячәк. Ә шушы каенкай миңа тугры. Аңа бөтен серләремне сөйли алам. Ни өчендер урманда гына үземне иркен тотам. Монда килсәм, рәхәтләнеп хыяллана алам, киләчәгем дә күз алдына килеп баскандай тоела.

− Ә ниндирәк хыялың бар соң? – дип, кызыксынуымны дәвам иттем.

− Абый, беләсеңме, киләчәктә зу-у-ур кеше буласым килә! – Малайның күзләре очкынланып китте. – Менә мин Уфа урамыннан атлап китеп барам. Кулымда – кара төстәге портфель, өстемдә – күз явын алырлык костюм, ак күлмәк, хәтта галстук такканмын, ә инде ботинкам әллә каян күзгә кебек ялтырап тора. – Теләкләрен әйткәндә, малай калкынып киткәндәй булды. Үзен чынлап та шушы минутта зур җитәкче итеп тойды шикелле. – Таныганнары туктап исәнлек сораша, хәл-әхвәл белешә. Ә мин, шатланып, атлавымны һаман дәвам итәм. Бу дөньяда миннән дә бәхетлерәк кеше юктыр. Өйдә кайтуымны түземсезләнеп кәләшем белән балам көтә... – Шулчак Рөстәм тынып калды да елап җибәрде.

− Ярар, елама инде, тынычлан. Барысы да синеңчә булачак, мин әйтте диярсең. Барысы да алда бит... Малайны шулай юатырга тырыштым.

− Анысы шулай да... Тик өйдә балаларым нәнәсен таптыра башласа, нәрсә дип әйтермен?

Рөстәмне юатырлык бер сүз дә таба алмадым. Аның хәлен яхшы аңлыйм да, тик ни хәл итәсең. Үз әти-әнием үлгәнгә дә байтак еллар үтте. Ә шулай да Рөстәм миннән күпкә бәхетлерәк. Аның әтисе дә, әнисе дә бар, диләр. Тик улларын таба алмый гына йөриләрдер. Бермәл очрашырлар әле.

− Ә шулай да өметемне өзмим, Ильяс агай. – Малайның йөзе яктырып киткәндәй булды. – Мине барыбер детдомнан килеп алачаклар. Чак кына көтәргә кирәк.

− Әйе шул, синең кебек акыллы малайны ничек килеп алмасыннар ди!

− Кайчанрак килерләр икән? Алар килгән чакта лагерьда булып калмасам ярый да ул. Югыйсә, таба алмый йончып бетәрләр. Мине күрмәсә, әниемә кыен булыр. – Малай иркенләп сөйләргә тотынды. – «Әни» дигән сүзне күптән әйткәнем юк. Ул сүз хәзер ничек әйтелгәнен дә оныта башладым. Шуңа кеше юкта гына урманга, каен алдына килеп, «әни», «әти», дип әйтеп карыйм. Бик матур сүзләр, әйе бит, абый! – Малай яшьле күзләре белән миңа төбәлде. Шуннан теге сүзләрне янә кабатлады. – Әти, әни, мин сезне яратам!

Рөстәмнең сүзләре йөрәгемне өтеп алгандай булды.

− Тик бу турыда берәүгә дә сөйләмә инде, − дип үтенде кабат.

− Ярый, ярый.

Без әкренләп кенә детдомга таба атладык.

...Караватта елап утырган Рөстәм тынычлангандай булды. Без дә, тәрбияче дә, сәбәбен белмичә, бүлмәдән чыгарга ашыкмадык. Малай башын калкытты да, туктаусыз елаудан кызарып беткән күзләрен сөртеп, безгә карады.

– Ыж-ди, ыж-дии… − дип, нәрсәдер әйтергә теләде дә әйтеп бетерә алмады. Без аптырап калдык. Тагы да ныграк елап җибәрде.

– Йә, тынычлан инде. Телисеңме, сиңа бейсболкамны бирәм. – Яңарак кына туганнары алып килгән әйберне классташым аның башына кидерде. Берәү стакан белән су алып килгәч, шуны эчеп, бераз тынычланды Рөстәм. Тынып торганнан соң, елавының сәбәбен аңлата алды:

– Телевизордан гел «Жди меня» тапшыруын карадым. Берсен дә калдырганым юк, – диде, үпкәләгәндәй мыш-мыш итеп, малай. – Нигәдер кешеләрне гел кемдер эзли, шуны табалар да. Менә баягы тапшыруда да бер малайны әнисе табып, кочагына алды. Телевизор аша мине дә эзлиячәкләр дип гел хыялландым. Тик ни өчен мине беркем дә эзләми икән? Берәүгә дә кирәк түгелмен микәнни инде...

Бүлмәдә авыр тынлык урнашты.

## Комак

Класска керүгә, барысы да мине сырып алды. Балга омтылган сагызактай, төрле яктан атылдылар.

– Шул хәбәр дөресме ул, Ильяс? – Кызларның берсе төпченергә үк тотынды.

– Ничек шулай килеп чыкты соң? Әмилә өзек-өзек кенә сөйләде шунда. Бернәрсә дә аңламадык...

– Әйе шул! – Күрше партада утырган малай кулын беләгемә салды. – Әйдә, үзең сөйләп бир әле.

– Сез нәрсә турында сорыйсыз ул? – Бернәрсә дә аңламаган булып кыландым. Тик кызыксынулары чамадан ашкан классташларым күз дә ачтырмый.

– Куй! Белмәмешкә салышма!

– Инәлттермә инде...

– Нигә, безне дуска санамыйсыңмы әллә?

Хәтта гел «бишле»гә укып, үтә басынкы дип йөргән кыз да төпченергә тотынды:

– Комак белән чынлап шулай булдымы ул?

Болардан җиңел генә котыла алмасым көн кебек ачык. Нихәл итәсең – сөйләргә туры килә. Бу турыда берәүгә дә әйтмәм дип уйлаган идем дә бит. Ну, шушы Әмиләне! Бер сүз тормый. Иләк авыз! Мәктәптән миннән алда килеп, бөтенесенә дә сөйләп өлгергән.

Моннан бер ай элек туган көнем булган иде. Дусларым, классташларым үзенчә котлады. Тәрбияче Хәкимә апа кызарып пешкән алма бирде. Әмилә ручка бүләк итте, берәүләре – кәнфит, икенчеләре, теләкләрен әйтә-әйтә, дәфтәр тоттырды. Бу тиклем дә котлаулардан башым әйләнеп китте хәтта.

Телгә әвәс, зирәк Фаяз исемле классташым барысын да уздырды:

– Ильяс, мәктәптән соң безнең өйгә барырбыз, – диде ул, мут елмаеп. – Сиңа шундый бүләк әзерләдем! Баргач күрерсең...

Классташымның бу сүзләре түземлекне җуйдырды. Кайчан гына дәресләр бетәр. Көткәндә вакыт шултиклем җай ага. Нәрсә белән аптыратырга булды икән Фаяз? Зур әйбердер. Җиңел булса, мөгаен, портфеленә салыр иде...

Фаязның өенә кергәч тә, бер якта көтеп торырга кушты:

– Күзеңне йом! Ату кызык булмаячак. – Бераз эчке бүлмәсендә кыштырдый торгач, яныма килеп, кулыма йомшак кына нәрсә салды. – Инде карасаң да була...

Учымда кече генә җан иясенең иснәнеп утырганын күреп, куркуымнан аны идәнгә ыргытканымны сизми дә калдым. Үзем читкә сикердем:

– Исә-ә-әр! Кеше шулай шаяртамы?

Кулларым туктаусыз калтырый, куркуымнан бер сүз дә әйтә алмыйм. Ә Фаяз, берни булмагандай, рәхәтләнеп көлә.

– Көлке сиңа! Тапкансың ничек шаяртырга! Тешләп алса? – Бу сүзләремдә үпкә дә, ачу да бар иде.

– Кит, кеше шуннан куркамы?

– Шундый комак кулыңда утырса, курыкмас җиреңнән куркырсың! – Кәефем кырылып, чыгу ягына юнәлдем. Классташым туктатырга ашыкты:

– Ярый, үпкәләмә, Ильяс. Бу бит баз астында, сарайларда яшәгән комак түгел. Ә кулга ияләшкән. Диңгез аръягыннан китерелгән токым. Шәһәрдә булганың юкмыни? Һәр фатирда диярлек шушындыйларны тоталар. Мода бит!

– Кит, юкны сөйләмә! Аңардан кеше ничек котылырга белми.

– Чын, менә, күрсәтәм. – Фаяз карават астына яшеренгән ап-ак комакны чыгарды. Сөйләгәнен акларга теләгәндәй, аны сыйпап алды, беләгенә утыртты. Шуны гына көткән җан иясе, койрыгын болгый-болгый, аның башына үрмәләде. – Бер зыяны да юк. Күпләр шундыйны өендә тотарга хыяллана. Ә миндә берәү түгел – өчәү!

Үземә дә кызык булып китте. Комакның шултиклем иркәләнүен күреп, тынычлана төштем.

– Тагын бер нәрсә күрсәтимме? – Фаяз кызып китеп сөйләргә тотынды. – Шушы бәләкәй комак су эчә белә! Үзем өйрәттем. Әгәр төнен сусаса, түшеңә баса да иреннәреңне ипләп кенә тырный. Акыллы ул – димәк, су сорый.

Вәт кызык! Комакларның мондый төрен күргәнем юк минем! Алар кешегә зыян китереп, ризыкларын урлый, әйберләрне тишкәләп йөри, дип уйладым. Хәтта берәүләрнең галушын кимереп бетергән, дип тә ишеткән идем.

Ничек шәп булды бу! Дустыма рәхмәтләр әйтә-әйтә, комакны портфелемә тыктым да детдомга ашыктым. Бүтәннәрне дә аптыратыйм әле.

Балалар йортына якынлашкан саен, шатлыгым сүрелә барды. Ул комакны алуын алдым да, ә кайда асрарга соң? Бездә бит бер җан иясен дә тотарга кушмыйлар. Хәтта мәчене дә кертмиләр. Санитар таләпләргә каршы килә, диләр. Шулай булгач, комакны бүлмәмдә ничек яшәтим? Тыңлап та тормаячаклар! Тәүдә чиксез шатлансам да, детдом тупсасына җитәр чакта шомым гына артты. Әгәр тәрбиячеләр аны күреп калса, үзеңне эттән алып, этк̌ә салып әрләр, кече дустымны тышка чыгарып ыргытырга кушарлар... Нәрсә эшләргә? Йомшаккайдан һич тә аерыласы килми. Ни булса да булыр, дип, комакны беркемгә дә күрсәтмичә генә, бүлмәгә алып кердем.

Озын койрыклы, елтыр кара күзле, мамыктай ап-ак комакны күргәч, бүлмәдәш малайлар «аһ» итеп калды. Нәрсә икәнен аңлаткач, тынычландылар. Тик бу турыда беркемгә дә сөйләмәүләрен үтендем.

Комак тиз арада безнең иң якын дустыбызга әйләнде. Мәктәпкә китсәк – аны тумбочкада бикләп калдырабыз. Ризыкны да аш бүлмәсеннән чиратлап ташыйбыз. Ә кичен, йокларга ятканда, комакны тумбочкадан чыгарабыз. Ул рәхәтләнеп бүлмә буйлап йөри. Йә теге очка, йә бу якка йөгерә. Караватка менеп, безгә иркәләнә: юрган астына кереп китә дә аяк очына барып чыга. Әй кытык килә! Аның холкын күзәтү – үзе бер тамаша.

Ул төндә төркемдә Тәгъзимә апа эшли иде. Апа эшкә килсә, төркемдә тынлык урнаша. Барысы да аңа ярдәмләшә, ничек булса да аңа ярарга тырыша. Моның сәбәбе дә бар. Телевизорда бик шәп сериал башланды. Бер гаиләнең язмышы турындагы киноны карарга барыбыз да экран янына җыелабыз. Берәү

дә тавышланмый. Мавыктыргыч сериалны карар өчен көне буе көтеп йөрибез. Тик шунысы гына ачуны китерә: кино бик соң, сәгать унбердә башлана. Ә режим буенча бу вакытта йокларга тиешбез.

Төнгелектә эшләгән тәрбиячеләр алышынып тора. Флүрә апа булганда – рәхәтләнеп телевизор карый алабыз. Ә менә Тәгъзимә апага шактый гына инәлергә туры килә.

– Юк, юк, юк! – ди ул, кул селтәп. – Нинди кино ди бу вакытта? Йокларга!..

– Апа, без шым гына утырачакбыз. Зинһар өчен каратыгыз инде, – дип инәлә кызлар.

– Детдом директоры моннан ерак яшәми, – тәрбияче тәрәзәгә ымлый. – Әнә, аның өе. Монда нәрсә булганын сизеп тора. Залда яктылыкны күрсә, шалтыратып әрләячәк. Куй, юк белән булышмагыз. Ятыгыз йокларга...

Әмма сериалның тәмен татып алган балалар да тиз генә бирешергә теләми. Җавабын шунда ук таба:

– Мәүлидә Нургалиевна бүген Уфага китте, – дип алдаштыра малайларның берсе. Директорыбызның башкалага еш йөрергә яратканын белгәнгә күрә, тәрбияче ышана.

– Соң ятсагыз, иртән укуга тора алмыйсыз бит! – ди ул.

– Тора-бы-ы-з! – шуны гына көткән балалар бертавыштан җавап бирә.

– Әгәр кемебездер тора алмаса, ул башкача кино карамый! – дип, үз шартын куючылар да табыла.

Бер инәлгәннән соң, Тәгъзимә апа рөхсәт бирә. Тик моның өчен бурычлы булып калабыз. Аның кайбер эшен эшләшәбез, һәр кушканын тыңлап кына торабыз.

Беркөнне дә бик җиңел килеп чыкты. Тәгъзимә апаның йөзе нигәдер борчулы иде. Үзенә урын таба алмый.

– Берәр хәл булдымы әллә, апа? – дип сорап куйдым.

– И, сыерым өчен борчылам, – диде ул, уфтанып. – Бүгенме, иртәгәме бозауларга тиеш. Әгәр бүген төнен булса, бозау туңачак. Өйдә беркем юк.

Тышта, чынлап та, суык иде. Борчылырлык та шул. Тәгъзимә апа минем яныма килде.

– Ильяс, әйдә безгә барып килик әле. Сыерымны карамыйча үземә урын тапмыйм. – Мин куш куллап ризалаштым. Йоклар алдыннан тышта йөреп алсаң, рәхәт ул.

Тәгъзимә апаның сараена кердек. Авыр сулап кара сыер ята. Тәрбиячем тегенең эчен тотып карады, аркасын сыйпаштырды.

– Ни, эшне калдырып китеп булмый, – дип авыр көрсенде ул.

– Әгәр без киткәч, сыер төнен бозауласа? – дип сорадым кинәттән. Тәгъзимә апа янә аптыраашта калды:

– Кит, начарга юрама! Син каян беләсең? – дип ачуланды ул.

Мин мал караган кеше түгел. Шулай да эчке тоемлау бар. Әнә, малкай ничек авыр тын ала. Менә-менә бозаулар сыман. Шулай дип уйлаган булам. Тик икеләнүемне белдермәскә тырышам. Күпне белгәндәй, сарай буйлап йөрим. Тәүдә сыерның уң ягына чыгып, эчен тотып карадым, шуннан сул ягына чыктым. Муенын сыйпаштырдым. Тын алышын да тыңлаган булдым.

– Тәгъзимә апа, сыер тиздән бозаулар! – дидем, белдекле кешедәй.

– Шулай укмыни?

– Шулай. Менә мин әйтте диярсез.

– И Аллам! Алайса, ничек итим икән? Сезне калдырып китеп булмый бит.

– Ә сез, апа, борчылмагыз. Үзегез монда калыгыз. Ә без бер дә тәртип

бозмабыз. Утларны сүндереп, шым гына йокларга ятарбыз. Ә сез иртән сменаны тапшырыр алдыннан гына килсәгез дә була.

Тәгъзимә апа бераз уйланып торды да ризалашты.

– Тик бу турыда берәү дә белмәсен. Эш урынын калдырып киткән, дип, күзне дә ачырмаслар.

Мин җан-фәрманга детдомга чаптым. И, шатланам! Минем күрәзәчелек сәләтем юк. Сыер бозаулармы бүген, юкмы – анысын белмим. Ә менә без туйганчы телевизор караячакбыз! Тик тәрбияче юк, дип, үрле-кырлы сикермәбез. Берәр кино карарбыз да йокларга ятарбыз. Шуның өчен Тәгъзимә апаны өендә калырга күндердем дә инде.

Барысы да мин уйлаганча килеп чыкты. Ә иртәнчәк тәрбиячебез уятты. Тәгъзимә апаның йөзе балкый иде:

– Ильяс, сиңа рәхмәт! – дип, аркамнан тупылдатып сөеп алды. – Сыерым тәки бозаулады!

Гадәттә, иртә белән ашханәдән ашны Тәгъзимә апа үзе барып ала да һәркемгә таратып чыга. Ул өстәл әзерләгәндә, беребезне дә аш бүлмәсенә кертми. Әзер булгач кына чакыра.

Нишләп алай икән? Тәгъзимә апа эшләгән көнне гел безгә аш әз эләгә. Берәр телем икмәк – анысы да юка гына, үтә күренеп тора. Май да калакның очыннан гына тәти. Булган ашамлыкны «һә» дигәнче йотасың да аш бүлмәсеннән чыгып китәсең. Ярый, без ничек тә булса өйрәнәбез шуңа. Ә менә зур гәүдәле Динар этләнә. Ул юри иң соңгы булып өстәл янынннан кузгала. Берәрсе ашап бетермәгәндер әле дигәндәй, ян-якны караштыра.

– Апа, нигә ашны аз бирәләр ул? – дип сорап куябыз тәрбиячедән. Тәгъзимә апаның җавабы әзер:

– Булганына шөкер итегез! Үзегез эшли башлагач, туйганчы ашарсыз...

Беркөн иртәнгелеккә алма бирделәр. Тәгъзимә апа эшләгән вакытка туры килде. Тик аш бүлмәсенә керсәк – һәркемгә яртышар алма куелган. Моны күргәч, кәеф кырылды. Шулай булмыйча ни! Сирәк кенә тәтегән җимеш тә яртышар эләксен әле.

– Берәрне бирсәләр дә булыр иде, – дип, ризасызлыгын белдерде Әмилә. Бүтәннәр эндәшмәде, чөнки моның өчен Тәгъзимә апа телевизор янына якын да китермәячәк. Кыю кыз гына үзалдына сөйләнә бирде:

– Бер туйганчы ашаган юк, – диде ул, иренен турсайтып. – Икмәкне дә чеметем генә бирәләр, кече телгә дә йокмый. Мәчеләргә дә күбрәк ашаталардыр...

Тәгъзимә апа, бернәрсә ишетмәгәндәй, савыт-саба җыештыра. Ә без баш күтәрми ашарга тотынабыз. Тизрәк тамак ялгарга да мәктәпкә йөгерергә кирәк.

Бүген ботканың тозы азрак булган. Шуңа Динар, тоз алам, дип урыныннан торды да шкафка үрелде. Тәгъзимә апа аны шәйләми калды. Малайның шкафны ачуы булды, идәнгә тыпыр-тыпыр алмалар тәгәрәде!

– Бәтәч, болар кемнеке ул? – дип кычкырып җибәрде Динар. Шуннан нидер эзләгәндәй, шкафның бүтән ишекләрен дә ачкалады:

– О-о-о, монда икмәк тә күп икән! – диде шатланып. Барысы да аптырап калды. Ачуы кабарган тәрбияче Динарның җиңенә ябышты.

– Ач карга, нигә кирәкмәгән җирдә чокынып йөрисең?!

Моны күреп гуләшә башладылар. Эшнең нидә икәнен аңладык. Димәк, тәрбияче безгә дигән өлешне үзенә алган.

Башкалар аптырап торганда, Әмилә урыныннан сикереп торды да теге алмаларны җыярга тотынды.

− Бишәү, алтау, ... унау, − дип санап барды.

− Башкача телевизор дип авызыгызны да ачмагыз! Күрсәтермен мин сезгә киноны! − Тәгъзимә апа, безне әрли-әрли, аш бүлмәсеннән чыгып китте.

Бу вакыйга көне буена баштан чыкмады. Ничек алай булды соң? Тәгъзимә апа бер дә андый кешегә охшамаган бит! Бәлки, ул бүлеп ашатырга җыенгандыр. Ә Динар шкафны ачты да эшне бозды да куйды. Җитмәсә, Әмилә бөтенесен дә котыртып сөрән салды. Әгәр шушы уйларым дөрес булса, без Тәгъзимә апаны нахакка рәнҗеткәнбез түгелме?!

Кайберәүләрнең балалар йортыннан ризык ташулары турында электән ишеткән бар иде. Тик мондый эш, гадәттә, ашханәдә эшләгән апаларның гына кулыннан килә. Ярар, бәлки, артып калганын ташыйлардыр. Ә инде ашханәдән һәр балага исәпләп бирелгән тәгамнең тагын нәрсәсен алмак кирәк? Иртән дә, төшен дә, кичен дә ашарга әлләни күп бирмиләр бит.

Уйларга чумып, әллә кайчангы вакыйгалар хәтергә төште.

Бермәл кичен Динар белән икебезне аш пешерүче апа чакыртып алды.

− Малайлар, шушыларны өемә алып барышыгыз әле, − дип, безгә пакет бирде. Үзе дә ике сумка тоткан. И, авыр иде әйберләре. Өенә алып барып җиткәнче, куллар талып бетте. Шулай да теге йөкне бер кулдан икенчесенә күчерә-күчерә, көчкә барып җиттек. Аш пешерүче рәхмәт әйтеп, пакетыннан берәр уч кәнфит өләште. И, шатландык шунда! Ул көнне кичке ашка шул кәнфитне берәрне генә бирделәр шул...

Идәнгә тәгәрәгән алмалар... Тәгъзимә апаның шундагы аптыраган йөзе һаман күз алдыннан китми. Димәк, тәрбиячебез дә шул өлешне үзенә... юк, юк! Мондый кяфер уйлар ничек керә башыма?!

Әйе, тәрбиячебез кайчак катырак та булып китә. Шулай да явыз затлардан түгел. Әгәр ипләп сорасаң, соң булса да, киносын да карата. Тәүдә инәлдереп алган була инде. Нәрсә генә дисәң дә, Тәгъзимә апа әйбәт кеше. Ничәдер бөртек алма өчен апаның йөрәгенә яра салдык шикелле.

Шул ук көндә төркемдә үзара сөйләшеп алдык. Иртәнге аш вакытындагы саксыз кылануыбыз өчен гафу үтенергә булдык. Әлбәттә, Әмилә дә, Динар да озак карышып маташтылар.

− Үзе гафу үтенсен! Мин аның алмасын урламаган! – дип кырт кисте Динар.

− Әйе, аны элек тә шулай ташый диләр иде. Хәзер үзебез күрдек. – Әмилә аны җөпләп куйды. Ләкин без аларны барыбер күндердек.

Эшкә килгәндә, Тәгъзимә апаның йөзендә нур юк иде. Нык үпкәләгән, күрәсең.

− Апа, сез безгә ачуланмагыз инде!.. – дип сүзне башлаган идем, тәрбияче шунда ук бүлдерде:

− Кит, ачуымны китереп, өерелеп йөрмәгезче янымда!

− Тәгъзимә апа, – барысыннан да кыюрак, моңача ачуы кабарып йөргән Әмилә дә йомшак кына эндәште. – Беләбез бит инде, ул алмалар сезгә кирәк түгеллеген. Икмәкне, майны да без соңрак ашасыннар, дип, шкафта калдыргансыздыр, дип уйлыйм.

Бу сүзләр Тәгъзимә апаның күңелен эретмәде, киресенчә, ачуландырды гына:

− Кара син аларны! Җитмәсә, мыскыл итеп маташалар. Апа безнең өлешне ташый, дип, бөтен детдомга хәбәр салгансыздыр әле. Югалыгыз күземнән!

− Юк-чы-ы, − дидем, көтелмәгән җавапны ишетеп. – Алай түгел, апа!

− Рәхмәтне аңлый торганнардан түгел сез. Моннан соң телевизор дип авыз

ачып кына карагыз! – Тәрбияче бармагы белән безгә янады да урыныннан торып китте. Артабан сөйләшүнең мәгънәсе юк иде. Шул шкафны ачып, Динар безгә күпме бәла өйде.

Сәгать тугыз тулуга Тәгъзимә апа барыбызны да бүлмәләребезгә куа башлады. Ә безнең теге шәп сериалның дәвамын карыйсы килә.

– Никаких! – дип кырт кисте ул. – Моннан ары сезнең сымак булам. Хәзер үк йокларга ятыгыз! – Тәрбияче, шарт итеп, телевизорның шнурын тартып алды. Теләмәсәк тә, бүлмәләребезгә кереп, йокларга ятудан башка чара калмады.

– Каравыл. Кара-выл! – берәүнең җан өзгеч тавышына дерт итеп уянып киттем. Башка малайлар да сикереп торды. Нәрсә булган икән дип залга йөгереп чыктык.

– Кот-ка-ры-гыз! Үлә-әм! – Карасак, чәче тузган Тәгъзимә апа өстәлгә менеп баскан. Безне күрде дә янә кычкырды:

– Коткарыгыз! Ул монда гына яшеренде! – Апаның йөзе качкан, үзе дер калтырый. Билләһи, йөрәкне яра язды бит. Аның шушы кыланышын күреп, каушап калдык.

– Нәрсә булды, апа? – Уянып бетмәгән балалар эшнең нәрсәдә икәнен белергә тырышты. Ә Тәгъзимә апа, агулы еланнан качкандай, өстәлдән төшәргә дә уйламый. Үзе елый, калтырана-калтырана аңлатып маташа:

– Ул ка-бә-хәт... монда! Әле генә күрдем!

– Кем тиде? – Әмилә, аны тынычландырырга тырышып, кулыннан сак кына тотып алды.

– Ко-ко-мак! Комак иярлэнгән монда! – Апаның әйткәненнән тәннәр чымырдап китте. Минем комагым!

Берсенә дә борчылуымны белдерми, бүлмәгә йөгердем. Җәһәт кенә тумбочканы ачып карадым. Юк! Без йокларга ятканда, гел ишекне яба идек. Күрәсең, малайларның берсе төнлә торып, ябарга оныткан. Качкан чукынчык.

Янә залга чыктым. Балалар барысы да Тәгъзимә апаны уратып алган. Аның кычкыруын ишетеп, беренче катта утырган вахтёр да менеп җиткән. «Ашыгыч ярдәм»не дә ул чакырган.

Тәгъзимә апа йөрәген тоткан да, сыктый-сыктый, күргәнен ак халатлы апага сөйли.

– Давлениегез югары! Йөрәк тә дулый. Ничек инфаркт булмаган... – ди табиб.

– Нәрсәдер иренемне тырный, – дип сөйли аңа тәрбияче. – Күземне ачсам – зу-ур комак! Ул минем күкрәгемә баскан иде!

– Бәлки, күзегезгә күренгәндер? – дип тынычландырырга тырыша табиб. – Берәр мәче баласы булмадымы?

– Нәрсә, мин комактан мәчене аера алмыйммы? – Шулай җикеренде дә еларга тотынды. – Корып киткере шушы детдом. Күрәселәрем бар икән...

Тәгъзимә апаны «Ашыгыч ярдәм» белән шәһәргә алып киттеләр. Төнге сәгать дүрт иде. Моннан соң озак кына йоклый алмый этләндем. Җитмәсә, хәлнең нәрсәдә икәнен төшенгән малайлар рәхәтләнеп көлә.

Менә сиңа комак! Каян гына алып кайтканмын дигән көнгә төштем! Бүләк иткәндә, Фаяз комакның авыздан су эчәргә яратканы турында әйткән иде бит. Бахыркайның су эчәсе килгәндер. Котың очмас җирдән очар! Ярый әле апаның йөрәге ярылмаган.

Бүтәннәр яткач, комакны эзләп таптым да тумбочкага бикләп куйдым. Әгәр ул җан иясе минеке икәнен белеп алсалар, кирәкне бирерләр. Бәласеннән баш-

аяк, дигәндәй, минем өчен кадерле бүләктән котылырга туры килде. Таң ату белән, комакны элекке хуҗасына алып барып бирдем. Малайлардан бу турыда берәүгә дә сөйләмәүне үтендем.

Тәгъзимә апа ике атна дәваханәдә ятып чыкты. Детдомда бүтән эшләмәде, үз теләге белән китте.

– Комаклар янына комаклар ияләшә. Бүтән анда аяк басасым юк! – дигән ул, документларын алырга килгәндә.

Тәгъзимә апа белән дә, теге комак белән дә шулай аерылышырга туры килде...

## Бур

Бу юлы җәйге лагерьда тыныч кына ял итеп булмады. Син дә мин дигәндәй, яшәп ятканда, көтелмәгән хәл килеп чыкты. Лагерь сакчысының әйберләре югалган! Кемдер, аның бүлмәсенә кереп, мең сум акчасын һәм пәкесен чәлдергән! Монда ял итүчеләр күп: бездән кала шәһәр балалары да, төрле районнардан килгәннәр дә байтак. Әмма угрылар хакында сүз чыккач, тәүдә детдом балаларына шик төште.

– Әгәр гаеплене табып бирмәсәгез, үзегезгә үпкәләгез! – Сакчы каты кисәтеп куйды. – Сез генә шул тирәдә өереләсез, башкалар анда йөрми.

Вожатыебыз Рәфис абый да үзенә урын таба алмады. Ни дисәң дә, безнең тәртип өчен ул җаваплы. Эш зурга китсә, тәүдә аннан сорау алачаклар. Детдом директоры да, лагерь җитәкчәсе дә, начар карыйсың, дип аны шелтәләячәк.

Рәфис абый безгә ят кеше түгел. Ул үзе дә безнең балалар йортында тәрбияләнгән. Әле шәһәрдә ГПТУда укып йөри. Ә җәйге каникулда аны безнең вожатый итеп җибәрәләр. Директорыбыз Мәүлидә Нургалиевна гел шулай итә: лагерьга безнең тәрбиячеләрне түгел, ә элек тәрбияләнгән абыйларны җибәрә. Моның сәбәбе дә бар: беренчедән, Рәфис абый безнең белән җиңел уртак тел таба. Икенчедән, үзебезнең кеше булгач, балалар аңардан куркып тора. Әгәр ялгыш адым ясасаң, абыебыз ничек урыныңа утырту алымын яхшы белә. Элек монда тәрбияләнгәндә, аның «башлык» буларак даны таралган.

Угрылык турындагы хәбәрне вожатыебыз бик авыр кабул итте. Барыбызны да җыеп алды да тиз арада бурны табу кирәклеген әйтте.

Башланды чокынулар! Һәр бүлмәгә кереп, әйберләрне тентеделәр. Һәркемебездән җентекле сорау алдылар, кесәләрне капшап чыктылар, хәтта сумкаларны актардылар. Тиз эзләү нәтиҗә бирмәде: пәке дә, акча да табылмады.

Шушы эзләүләрдә Динар барысыннан да әүдемрәк булып чыкты. Чокынулар башланганнан бирле Рәфис абый тирәсендә уралды. Әллә үзенең шәплеген күрсәтергә тырышты, әллә чынлап та теге бурга нәфрәте ташып тора... Ул малай элек Даянның уң кулы булып йөрде. Шул чакта аның этлекләрен күп күрдек инде!

Кичкә тиклем карак табылмагач, мөгаен, башка балалар аю мае сөрткәннәр, дип уйладык. Ә нигә, детдом балалары гына урлашамы? Берәр нәрсә булса, гел бездән күрәләр, дип эчтән генә ачуландык. Шул сакчысын да әйтим инде! Үз әйберенә хуҗа була алмагач, нинди сакчы инде ул?! Шәп булгач, бөтен лагерьны тентеп, үзе эзләсен. Ярый әле монда без дә бар. Без булмасак, кемнән күрер иде?

Бу сүзләр белән артык ашыкканмын икән... Иртәгесен таралган хәбәр күпләрне шаккатырды. Бур табылган. Һәм ул безнең детдом малае булып

чыккан. Зык кубып, бөтенесенең дә әйберен тентегән Динар бүген иртән Альбертның ястыгы астыннан югалган пәкене табып алган!

Төшке аш алдыннан безне вожатыебыз яшәгән йорт алдына җыйдылар. Бу чарадан берәү дә читтә калмады: кечеләре дә, өлкәннәре дә килеп җиткән иде. Инде барысы да урынында булгач, вожатыебыз бүлмәсеннән Альбертны җилтерәтеп алып чыктылар.

Аны күрүгә башкалар шаркылдап көләргә, төрле әрсез сүзләр белән кычкырырга тотынды. Малайның йөзе качкан, туктаусыз елаудан бите шешенеп беткән. Бер-ике тапкыр сугып та алганнардыр, битендә уелган урыны да бар иде. Ул, башкаларның күзенә күренмәскә теләптер, башын игән.

− Менә, балалар, бур табылды. Безнең исемне чыгаручы угры шушы инде! – дип, вожатыйның әйтүе булды, башкалар гүләргә тотынды.

− У-у-у – крыса! – дип кычкырды берәү.

− Кирәген бирергә кирәк аның. Бүтән урлашмас!

− Нинди оятсыз бәндә булып чыкты! Җитмәсә, бернәрсә дә булмагандай йөреп ята бит әле!

− Әйе, аның аркасында кемне генә гаепләп бетермәделәр. Азак үзем шуның өчен башын төеп алачакмын.

− Мин-мин ал-ма... − Калтырана-калтырана, Альберт, гаепсезлеген аңлатып, нәрсәдер әйтергә теләгән иде, аны тыңлаучы булмады. Мондый холкы белән, киресенчә, Рәфис абыйның ачуын көчәйтте генә:

− Шым тор! − Вожатый аның колагын борып алды. − Бу синең генә этлегең икәнен бөтенесе дә белә. Күргән кешеләр дә бар.

− Шуның гына эше! − Сүзгә Динар да кушылды. − Кичә генә шул туймас тамакның, авызын шапылдатып, сагыз чәйнәп йөргәнен күрдем! Акчасы булмаса, бетенә алсынмы?

− Ул карагай сагызы иде. Шуны чәйнәдем... − диде Альберт, башын күтәрми генә.

− Ну, алдаша белә. Остарып беткән. Үзем күрдем – ап-ак сагыз иде, − дип, үзенекен талкыды Динар.

Аның бу сүзләре инде бөтенесен дә куәтләп куйды. Димәк, шул малайның гына эше булып чыккан. Әнә бит, Динар сагыз чәйнәп йөргәнен күргән. Хәзер инде Альберт нәрсә генә әйтсә дә, аңа ышанучы булмас. Шул шым гына йөргән малай урлаша дип уйламас та идем.

− Нинди уңайсыз хәлгә калдык, − вожатый авыр көрсенеп куйды. − Хәзер кеше күзенә күренерлек түгел. Әнә, башка балалар бер дә кеше кесәсенә керми. Сезгә нәрсә җитми тагын?

− Ну, абый, бер ала сыер өчен барыбызны да гаепләмәгез инде! − дип, үз алдына сөйләнде Әмилә.

Рәфис абый сүзен дәвам итте:

− Мондый бурларның башыннан сыйпамыйбыз. Шушы хәл башкаларга сабак булырга тиеш. Беләсегез килсә, борынгы заманда урлашкан кешеләр өчен каты җәза булган. Беренче тапкыр урлашса − бармагын кисәннәр, тагы тотылса − тоташ кулын чапканнар.

− Хәтәр, әй! Альберт бер бармагың белән хушлашасың инде! − Арткы рәттән кемдер мыскыллы сүз ташлады. Бүтәннәр хихылдашырга тотынды. Уртада торган карак тагын да көчлерәк елый башлады.

− Ә мин Альберт өчен башкача җәза уйлап куйдым. − Вожатый пакетыннан катыргы белән кара фломастер чыгарды. Бу әйберләрнең нигә кирәк икәнен

озак төшенә алмый тордым. Бүтәннәр, шатлыгыннан сикергәләп, вожатыйны уратып алды. Шуннан Рәфис теге катыргыга зур итеп «Я – ВОР» дип язды. Малайлар тиз арада бау тапты. Һәм шуны Альбертның муенына элеп тә куйдылар. Анда нәрсә язылганын күргәч, малай тагын еларга тотынды.

− Ва-уу! Шәп ысул тапкансыз, абый! – дип хуплап алдылар.

− Ха-ха, менә кайда ул бур! Акча буры! Пәке буры!

− Йөрсен шулай! Башкалар белеп торсын! Урлашканда бик тә оста иде...

− Ике көн буена шушы язу белән йөрергә тиешсең, − вожатый бармагы белән кисәтеп куйды. − Әгәр чишсәң, кирәгеңне аласың. Ә сез, балалар, ул чишмәсен өчен, карап йөрегез!

− Ашханәгә барганда да, шул язу белән йөрергә тиешме? – Динар, көлүеннән туктый алмыйча, сорап куйды.

− Әйе, йоклаганда да чишмәскә тиеш! – дигән җавап булды.

Вожатый җыелышның тәмам икәнен әйткәч, балалар җайлап таралыша башлады. Тик күпләре болай гына китәргә ашыкмады. Кемдер Альбертның чәченнән тартты, икенчесе сөзешкән үгез сыман төртеп китте. Алдына килеп, «Мин – бур! Мин – карак!» дип үчекләшүчеләр дә табылды.

− Бар − югал күземнән! Йөгер! − сулкылдап торган малайны Рәфис абый куып җибәрде.

Теге язу белән йөгереп киткән Альбертны Динар куып җитте дә арт ягына шапылдатып тибеп җибәрде. Бур шул тиклем тибүдән тәкмәч атып барып төште. Әмма бер сүз дә әйтмәде. Торды да тагын йөгерде...

Моннан соң Альбертка тынгылык булмады. Шул язу белән иртән гимнастика ясарга да чыга. Ашханәгә дә барган иде. Анда да малайга тыныч кына ашарга бирмәделәр. Өстәле янынннан үткән бере аңа кагылмый калмый. Берәве башына калак белән шакылдатып сугып китте, икенчесе компотына бармагын тыкты, өченчесе икмәген тартып алды... Безнең детдомныкы булмаган балалар да бу хәлне күреп аптырый. Кемедер җәлләп карый, кем өчендер мәрәкә. Ә инде Альбертның гаепле башы иелгәннән иелде. Беркем белән дә сөйләшмәс булды. Сорау бирсәң дә, җавап кайтармый. Шул язуын ташлар иде, Рәфис абый кушканга, бүтәннәр күзәтеп йөри. Алай гына да түгел, уңае чыккан саен сугып китәләр, төрлечә мыскыл итәләр. Ә каракны кем якласын инде? Үзе гаепле, дип кенә куялар.

Өченче көнне Альберт юк булды! Качкан!.. Барысы да йоклаган чакта, шым гына чыгып тайган икән. Кая барасын да беркемгә дә әйтмәгән.

− Кача инде! − диде берәүләр. − Мең сум акчасы бар! Аны бит карак кире кайтармады. Читкә китеп, туйганчы тәмле ашарга булгандыр.

Атаклы каракның качуы лагерь тормышына тагы борыч өстәп җибәрде. Кырмыска оясына таяк тыккандай, тәрбиячеләр кем узардан йөгерешә башладылар. Шул ук көнне детдомга да шалтыраттылар, милиция дә чакырттылар. Пагонлы абый озак төпченде, барыбыздан да сорау алдылар: кемгәдер китәм, дип әйтмәдеме, нинди туганнарын беләсез, качу турында бернинди дә хәбәр сөйләмәдеме?

− Авыртмаган башка – тимер таяк! − Ачуыннан кызарып беткән вожатыебыз сукранды гына. − Ну, табылсын әле. Аягын кыскартырмын!

...Бер атнадан соң Альбертны тотып алып килделәр. Күрше районда гына яшәгән әнисенә качкан икән. Ә ул ара бик ерак: йөз километр чамасы! Шулкадәр еракка качар өчен нинди йөрәк, нинди батырлык кирәк!

Башкалар күрмәгән чакта, аның белән сөйләшеп тә өлгердем. Янымда

бүтәннәр булса, Альберт ачылмас та иде. Мин аның былтыр балалар йортыннан олы тормышка киткән абыйсы белән яхшы аралаштым. Бәлки, шуңадыр да, ул миңа нindидер ышаныч белән карый, җавап бирергә тартынмый иде.

– Нәрсә белән бардың соң? – дим төпчендем.

– Тәүдә җәяү атладым. Бүтәннәр күрмәсен өчен, көне буена урманнан бардым. Артымнан эзләп чыгарлар дип курыктым. Шулай караңгы җиткәнен сизми дә калдым. Ахырда, бер каен төбенә куыш корып йокладым. Ә иртәгесенә олы юлга чыктым да машина туктаттым. Алар мине авылга тикле алып барды...

– Хәтәр икән. Ә нәрсә ашадың соң? Ачыккансыңдыр?

– Кайдан! Җәй көне кеше ачыга диме? Урманда җиләктән күп нәрсә юк.

Малайның өс-башыннан ук күренеп тора, өендә аңа әллә ни игътибар булмаган. Киеме пычранып беткән, тырнаклары керләнгән, чәче дә майланып тора...

– Син кайтып төшкәч, әниең куангандыр, – дим, малайны шатландырырга тырышып.

Альбертның йөзе үзгәрде, күземә карарга уңайсызланып, башын читкә борды.

– Юк шул, – дип, авыр сулап куйды ул. – Мин өйгә кайтып кергәндә, өй тулы кеше иде. Әни әллә кемнәр белән эчә. Ашарга бернәрсә дә юк. Аптырагач, туганнарыма барып йокладым. Ә әнием минем кайтуга әллә ни куанмады да...

– Өйдә начар булгач, нигә качып кайтасың соң? Монда ашарга бар, киендерәләр.

– Анда ач булсам да – күңелем тыныч. Берәү дә җәберләми, тукмамый да. Үзеңә үзең хуҗа! Беләсеңме, Ильяс абый, мин мондый тормыштан арыдым. Хәтта кайсы вакытта яшисе дә килми. Көн дә талаш, көн дә тартыш. Минем иң яратканым – төн! Төштә генә мин бәхетле кеше: йөгерәм, елмаям, шаярам... Нәкъ әкияттәге кебек – барысы да яхшы, барысы да бәхетле. Шуңа уянырга куркам. Уянсам, икенче тормыш башлана. Монда әкият кайгысы юк. Арыдым мин...

– Урлашмасаң, андый бәлагә тарымас идең! Нәрсәгә кирәк булды сиңа ул пәке? Үз исемеңне шуның өчен сатып...

Альберт кинәт кызарынды, менә-менә елар төсле иде:

– Ильяс абый, син шуңа ышанасыңмы? Урламадым мин, ур-ла-ма-дым! – Малай башын түбән иде дә чыгып китте.

Урлашканы – бер хәл, качканы өчен Альбертка эләкте генә! Рәфис абый да бер җәзасыз калдырыр иде – бүтәннәр котырачак. Балалар да, нәрсә булыр да нәрсә булыр дип кабатлап йөриләр. Шуңа да барысы алдында качкынга сабак бирү мөһим булгандыр. Җитмәсә, вожатый янында уралып йөргән малайлар да тик тормый. Әллә нинди этлекләр уйлап чыгарып, бүтәннәрне котыртырга гына торалар.

Альбертка кем ул җәзаны уйлап чыгаргандыр, белмим. Тик лагерьдан ул буш кайтмады. Малайлар аның җилкәсенә «ВОР» дигән наколка эшләгән. Кайдан кирәк-ярагын табарга дип тә аптырамаганнар: гади энә белән яшел төстәге ручка да җиткән. Шул энәне буяуга манчып, тәненә язу чыгарырлык итеп чәнечкәннәр.

Наколка безнең детдомда ят күренеш түгел. Күпләр эшләтә аны. Аның буенча берничә оста да бар. Кемнәрдер хәтта шуның өчен алма йә кием белән түләргә әзер. Андагы язулар да төрлечә: берәү түшенә яратып йөргән кызының исемен яздырта, икенчесе кулына туган елын терки, өченчесе балалар

йортында яшәгән елларны күрсәтә... Аждаһа, елан, бүре сурәтен төшергәннәре дә очрый. Тәмәке тартып, гел сугышып йөргән малайлар өчен ул ниндидер горурлык, югарылык билгесе. Төрле наколкалар бар... Тик Альбертныкы кебекне тәүге күрдем монда... Ничек котылыр икән шул язудан?

Шушы хәлдән соң Альберт безнең белән аралашмады. Еш кына почта ягына йөри башлады. Еракта яшәгән туганнарына бертуктаусыз хат яза дип ишеттек. Һәм Яңа ел алдыннан аның туганнары килеп төште! Әнисенең якыннары аны уллыкка алырга булган икән! Белсәгезче, малайның ничек шатланганын!

Альбертны шуннан соң башкача күрмәдем. Теге наколка хакында да онытылды. Тик киләсе ел без янә шул лагерьга ял итәргә бардык. Шунда бер шәһәр малае белән аралашып киттем. Ул да былтыр монда ял иткән иде, әмма нигәдер сөйләшкән булмады.

− Сез детдомда булсагыз да, бик яхшы яшисез, − диде ул, көнләшеп.

− Ә нигә алай дип уйлыйсың?

− Менә сез җәйге лагерьга килсәгез, барыгызга да акча биреп җибәрәләр. Авыл магазинына барып, нәрсә телисез – шуны аласыз. Ә миңа әнием акча бирмәде.

Көтелмәгән хәбәрдән аптырап калдым:

− Кит, юкны сөйләмә! Кем безгә акча бирсен ди?! − Чынлап та, үзем кайчан соңгы тапкыр акча тотканны да исләмим. Ә бу әллә нәрсә сөйләп утырачы.

− Бер дә әкият сөйләмим. Күргәнем бар, шуңа әйтәм...

− Нәрсәне күрдең?

− Былтыр сезнең бер малаегыз мине үзе белән, иптәш итеп, магазинга алып барган иде. Кибеткә кергәч, ул өстәлгә шап иттереп меӊ сум акча салды. Мондый байлыкны күргәч, күзләрем чагылып китте. «Безнең детдомда һәркемгә җәйгә шулай акча бирделәр», − дип мактанды ул.

Нәрсә әйтергә дә белми, авызымны ачып, өнсез калдым. Шулай да көч табып, сөйләшүне дәвам иттем:

− Кем иде соң ул малай?

− Динар!..

## Сөяк

Уф, ачыктым! Нәрсә булса да табып ашарга иде. Эчтә ач бүреләр улый! Шуның өчен дә ял көнен яратмыйм.

Бүген иртәнге сигездә тордык. Ботка ашаттылар, чәй, икешәр телем икмәк эләкте. Шуннан җыелыш булды. Аннан соң малайларны кар көрәргә чыгардылар. Эш беткәч, яшәгән бүлмәләребезне җыештырырга куштылар. Паласны чыгарып кактык, шифоньерларны, диваннарны күчереп, бөтен җирдәге тузанны сөртеп чыктык, соңыннан идән юдык. И, хәл бетте шушы эшләр белән. Җитмәсә, шултиклем ачыгылды. Иртәнге ризык тамакка да барып җитмәде дигәндәй. Мәктәптә булсак, дүртенче дәрестән соң да ашаталар әле. Хәзер сәгать икегә кадәр төшке ашны көтәргә кирәк. Әле уникe генә... Ничек түзәргә икән? Их, хәзер берәр ничек тамак ялгап алганда...

Шулчак бүлмәгә Айнур атылып килеп керде:

− Ильяс, әйдә ашханәгә барып килик!

− Анда нәрсәгә?

− Аш пешерүче Зиләападан сөяк сорап алабыз...

− Юк, бармыйм. Ул барыбер бирмәс, − дип, кулымны селтәп куйдым.

Детдом балаларының шундый гадәте бар. Әгәр ял көнне нык ачыксалар, ашханә ишеге алдына өерелә башлыйлар. Төшке ашка әле иртә, ә менә ул вакытка ит пешкән була. Итен аерып алгач, сөяген барыбер ташлыйлар. Әнә шуңа өмет итәләр дә инде малайлар. Төшкә кадәр шул сөякне кимереп тамак ялгыйлар. Тик ул сөякне болай гына алып булмый. Кешесенә карап кына бирәләр.

Бүген Зилә апа пешерә. Ул эшләгәнне белгәч, бармыйм, дип кырт кистем. Барыбер кире борып чыгарачак. Беркөнне соң:

– Директор кушмый! Әгәр шул сөяккә карлыгып ятсагыз, башымны ашарлар. Йөрмәгез теләнеп! – дип куып чыгарды.

Шулай кырысрак булганы өчен балалар аңа кушамат та таккан – Карлсон. Әйе, ул әкият героена Зилә апа ничектер буй-сыны белән дә охшаган.

– Мин әйтте диярсең, бирәчәк, – ди Айнур, ныкышып.

– Ничек инде бүтәннәргә кукиш күрсәткәндә, безгә сөяк тоттырып куйсын?

– Ә минем аңа сюрпризым бар, – ди дустым, елмаеп. – Хәзер, баргач, үзең күрерсең.

Барыбер көндерде Айнур. Киттем ияреп. Ашханәгә керүебез булды, Зилә апа сөйләргә тотынды:

– Сезгә нәрсә кирәк? Әле генә бишенче төркем малайларыннан чак котылган идем. Ишек төбенә хет охрана куй...

Мин инде сүзсез генә чыгу ягына уңайладым. Ә Айнур югалып калмады:

– Апа, ә мин сезгә җыр бүләк итәм! – диде горур гына.

– Нинди җыр? – Аш пешерүче йомшара төште. Бу аның тавышыннан сизелә иде.

– Сезгә багышланган. Радиодан отып алган идем...

Айнур бераз тынып торды да яңгыратып җырлап җибәрде:

Бер карыйсың йөрәгемә –
Мәхәббәт күзләреңдә.
Күңелемдә тик син генә,
Сагышлы йөрәгемдә.
Сине гел күрәсем килә,
Елмаеп яшә, Зилә.
Үзәгемне өзмә генә –
Гүзәлем, Зилә, Зилә!

Аш пешерүче дә, мин дә тын калып тыңладык. Тавышы ничек матур икән! Җитмәсә, нәкъ Зилә апага дип шул җырны отып алуын әйт әле. Ә Айнур туктарга уйламый да, бирелеп китеп җырлый. Берәү дә бүлдерергә кыймады.

Үзәгемне өзмә генә –
Гүзәлем, Зилә, Зилә!

– дип тәмамлап куйгач кына, без кул чабып җибәрдек. Бу бүләк, чынлап та, ошады аш пешерүчегә. Кәефе йөзенә чыккан иде. Уңдык болай булгач, дип, эчтән генә уйлап куйдым.

– Рәхмәт, Айнур! Эчең тулы моң икән. Сиңа җырчы булырга кирәк, – дип мактап алды Зилә апа.

Шуннан безнең алга бер савыт китереп куйды. Эче тулы сөяк! Белгән инде безнең нәрсәгә килгәнне:

– Иплəп кенə кимерегез. Бүтəннəр күреп калмасын.

Вəт, ичмасам, байлык! Хəзер туйганчы сыйланачакбыз. Башкалар күреп калмасын дип, шатлыгыбыздан көлешə-көлешə, тиз генə бүлмəбезгə сыпырттык.

Их, белсəгезче ничек куанганыбызны! Бер савыт сөяк! Хəзер без аны рəхəтлəнеп, тəмен белеп кимерəчəкбез. Ну, баш та инде Айнурда!

Без бүлмəгə кергəндə, анда дүрт малай көтеп утыра иде. Каян белеп алганнар икəн? Мондый тансык сыйны күргəч, аларның авызы ерылып китте. Шатлыкларын яшерə алмый, төрле тавышлар чыгарып, дүртесе дүрт яктан уратып та алды. Кемедер иң эре сөякне тизрəк элəктерергə дип, кулын савытка сузып маташты. Əмма Айнур мондый тəртипсезлеккə юл куймады. Чəп итеп теге үткернең кулына сугып җибəрде:

– Комсызланмагыз! Үзем бүлеп бирəм! – Айнур əүвəл караватына барып утырды, савытны тумбочкасына куйды. Шуннан җайлап кына сөяк өлəшергə тотынды. Бүлмəгə тəмле ис таралды.

Ризыкны тапкан кеше үзен мəхрүм итəргə тиеш түгел. Айнур да иң итле, зур сөякне үзенə тəгаенлəп, читкə алып куйды. Ашханəгə бергə баргач, миңа да ару гына өлеш чыкты.

– Ильяс белəн баргач, юл уңды, – дип шыттырып алырга да өлгерде.

Калганнары, кайчан чират җитəр икəн, дип, түземсезлəнеп, учын-учка ышкып ала. Һəркемнең күзе ялтырап яна, бар уйлары – тизрəк сөяк кимерү. Барысына да өлеш чыккач, тəүдə шым гына туена башладык. Моның сəбəбе дə аңлашыла. Йə сөйлисең, йə тамак ялгыйсың.

Савыттагы сый кими барды. Һəркем тавыш чыгармый гына кимерүен белде. Тик безнең арадагы иң кече Рөстəм генə шым утырып түзмəде:

– Айнур абый, син сөякне дөрес кимерə белмисең, – диде ул.

– Аның нəрсəсен белергə? Тотасың да ашыйсың. Бер чеметем итен дə калдырмадым шикелле...

Рөстəм, елмая биреп, яңа гына кимерелеп, читкə салынган сөякне кулына алды:

– Менə хəзер бер нəрсəгə өйрəтəм. Үзем белдем, диярсез.

«Укытучыбыз» бүлмə уртасына барып басты:

– Сөякне дөрес кимерə белү – үзе зур осталык. Сез аның итен ашыйсыз, соңыннан бернəрсə дə калмады дип ташлыйсыз. Ə ул дөрес түгел. Аның иң тəмлесе эченə яшеренгəн.

Рөстəм сөякне шак та шок итеп тумбочкага суга башлады. Шуннан сөяк эченнəн ап-ак куе мае агып чыкты.

– Менə шушы була инде иң тəмлесе! – Зур ачыш ясагандай, көлеп нəтиҗə ясады Рөстəм.

Кара син аны! Бəлəкəй генə булса да, белмəгəн нəрсəсе юк. Əллə шул Рөстəмнең тавышын ишетеп, чит бүлмəдəн ике малай килеп керде.

– О-һо! Сездə бəйрəм икəн лəса! – дип сөрəн салды көтелмəгəн кунакларның берсе. Аңа икенчесе дə кушылды:

– Кая, безгə дə бирегез əле.

Тик савытта бер генə кисəк калган иде. Бу байлыкка Айнур хуҗа. Без ансыз бернəрсə дə эшли алмыйбыз.

– Ашханəгə барыгыз да үзегез сорап алыгыз! Монда үземə дигəне генə калды.

– И, ул Карлсоннан алырсың! Саран бит ул, – дип, авызын очлайтты кунак.

− Иплəп сорасаң – нигə бирмəсен, − дип, сүзгə кушылды кечебез Рөстəм. Кире җавап алмасалар да, болар чыгарга ашыкмады:

– Ə тумбочкада нинди сөяклəр ята ул? – Кунак əрсезлəнүен дəвам итте.

– Алар кимерелгəн инде... – дип җаваплaverдык.

– Начар кимергəнсез. Итлəре калган бит! – Əллə үпкəле, əллə шатлыклы булды бу сүз. – Кая, кимерергə бирегез əле.

– Ал, – диде Айнур.

Тегелəр «кем узардан» шул сөяклəрне кимерергə тотынды. Без хəзер бүлмəдə сигезəү булып киттек. Сөйлəгəн һəр сүзебез дə шул ашау хакында иде.

– Кайчан гына шушы детдомнан котылырмын икəн! – Айнур авыр көрсенеп куйды. – Ичмасам, туйганчы бер ашар идем.

Аның сүзен кунакларның берсе куəтлəде:

– Əйтмə дə инде. Ни Карлсон юньлəп пешерə белми. Беркөнне аштан чəч килеп чыкты. Ə шуның өчен беркем тиргəми. Чөнки ул директорыбыз Мəүлидə Нургалиевнаның якын туганы...

– Көн дə кəбестə бирəлəр. Биздем тəмам...

– Күңелеңне киң тот. Бүген кичен дə кəбестə була, – дигəнемне сизми дə калдым.

– Без менə əле сөяк өчен талашабыз, ə өйдə яшəгəннəр ашның да кадерен белми, – дип, олыларча əйтеп куйды Айнур.

– Аштан олы булган кеше бармы соң?

– Бар ла андый исəрлəр, – бүгенге сый хуҗасы сүзен дəвам итте. – Менə безнең класста бер малай бар. И, дивана да инде. «Əнием көн дə иттəн аш пешерə, ялыктым. Хəзер иткə карый да алмыйм», дип сөйлəнгəн була. Ну, җаным көйде шул чүмечбашка. Бəреп очырырдай булдым. Үзе чучка сыман симез бит əле. Йөгергəндə, корсагы селкенеп-селкенеп куя.

– Безнең класста да бар шундый сантый. – Мин дə белгəнемне уртаклашырга булдым. – Мəктəп ашханəсенə барсак – кылана башлый. Ашта суган булса – җирəнə. Тəлинкəне читкə этеп җибəрə. Ярый, үзе ашамасын да! «Фу-у, мондый помойны ничек ашыйсыз ул?» дип безне мыскыл итə.

– Анысы əле пустяк! – Рөстəм дə хəбəрдəн читтə калмады, – ə минем классташым турында сөйлəсəм – ышанмассыз. Ул бөтенлəй туеп котырган. Ашаганы өчен акча сорый!

– Ничек була инде? Бер дə аңлашылмый!

– Ул шултиклем шашкан! Иртəнчəк əнисе ботка пешерсə − ашамый инəлтə. Төшкесен дə юньлəп ашамый ди. Нык сайлана икəн. Бар белгəне – кəнфит, печенье. Ахырда, əти-əнисе бер хəйлə уйлап тапкан: əгəр ботка ашаса – аңа ун сум бирəлəр. Төшке аш та шулай...

Көтелмəгəн хəлне ишетеп, һəркем хөкемен чыгарырга ашыкты:

− Мин аның атасы булсам, түзмəс идем. Иманын укытыр идем...

− Мəктəпкə барсак, күрсəт аны. Кирəген бирермен...

− Вəт, аны берəр айга детдомга бирсеннəр иде. Талашып ашый башлаганын сизми дə калыр. − Күрше бүлмəдəн килгəн малай ачулы итеп əйтеп куйды. Шуннан минем яныма килеп басты:

− Кая, Ильяс, миңа да калдыр əле. Син бит күп кимердең. − Ахырда кимерə башлаган сөякне аңа бирдем.

Тəүдə күңелле генə башланган табыныбыз шулай тоныкланып китте.

Бүлмəбезнең ишеген кемдер шап итеп тибеп җибəрде. Тəүдə Даянның башы күренде, аның артыннан ияреп ярдəмчесе Динар пəйда булды.

− О-һо-о! Сез монда ресторан ачып җибәргәнсез икән! − Башлыкка җавап бирүче булмады.

− Даян абыйдан алда сөякне нигә алдыгыз? Кем сезгә кушты?

Даянның ачуы кабарган. Авызы очлайган, барыбызны сөзәрдәй итеп карый. Ул кыю адымнар белән бүлмә уртасына килеп басты. Шуннан тумбочка өстендәге савытның эченә күз салды.

− Крысалар! – «Башлык» җан ачуына кычкырып, савытны тибеп очырды. Аның эчендәге кимерелгән сөякләр карават астына тәгәрәп китте. Динар, идәнгә ятып, теге сөякләрне табып алды да үзе кимерә башлады.

− Безгә Зилә апа үзе бирде бит... − Айнур калтыраулы тавыш белән акланасы итте.

− Ә мин рөхсәт бирдемме сезгә, салагалар? Туймастай булып, вич алып киткәннәр бит әле, − дип сөйләнде Даян.

− Ул сөякләрне без генә алырга тиеш идек, әйе бит, Даян абый? – дип, авызын шапылдатты Динар. Ул да шым тормый, утка керосинны өсти белә.

«Көчек»нең бу сүзләре аның ачуын арттырды гына.

− Кайсыгыз шундый кыю? Кем барып алды? – Даян, җавап эзләгәндәй, һәрберебезгә карап алды.

− Мин, − диде дә Айнур, карашын шым гына түбән төшерде.

− Бик яхшы! Хәзер акылга өйрәтәм! − диде, көлемсерәп башлык. Шуннан Динарның теге сөяген кулына алды. − Ничә сөяк ашагансыз, шулкадәрле башыгызга шуның белән сугам. Ә сез «башка алай итмим», дип әйтергә тиешсез. Тәүдә атаманыгыздан башлыйк... Даян Айнурның башына сөяк белән нык итеп сукты.

− Башка алай итмим дип әйт! – Ләкин Айнур аның кушканын үтәмәде. Теге тагын берне сукты. Авыртудан дустыбыз күзләрен йомды. Даян тагын сукты.

Ахыры утырып түзмәдем:

− Безнең нинди гаебебез бар? Зилә апа үзе бирде бит, − дидем, куркып кына.

− Шым утыр, кипкән балык! Әле сиңа чират җитмәгән.

Айнурның ныкышканына Даянның ачуы артканнан-артты:

− Башка алай итмим, дип әйтмисеңме? Синнән сорыйм, маңка!

Юк, дигәндәй, Айнур башын боргалады. Даян тагын берне сукты. Айнур ыргып килеп торды да аңа кычкырып җибәрде:

− Әйтмим! Мин шестёрка түгел сиңа! Ул сөякләрне урлап алмадым!

Мондый хәлне Даян көтмәгән иде. Аңа каршы әйткән, телләшкән малайлар бездә юк диярлек.

− Ах, паразит, телең ачылдымы? – Озынча сөякнең иң очлы ягы белән Даян Айнурның битенә томырды. Айнур авыртуга түзә алмый кычкырып елап җибәрде.

− Елама, дидем! − Даян янә йодырыгын йомарлады.

Бу тиклем дә ерткычлыкны күреп, эчемдә нидер өзелеп киткәндәй булды. Ни өчен алай итте соң Даян? Айнур бит урлашмады, хәйләкәрлек белән дә алмады. Сөяк эләксенгә, нинди матур җыр откан, безне сыйларга тырышкан. Һәм шуның өчен, мә сиңа...

Айнурның бите буйлап туктамый кан акты. Ярасы да зур гына күренә. Мин тастымал белән аның ярасын капладым. Кемдер су алып керергә йөгерде. Ә Айнур авыртуга түзә алмый ыңгыраша гына.

− Высох! – Гадәттә, кемдер еласа, күз яшен түкмәсен, дип, шулай боералар өлкәннәр. − Әгәр берәрсе сораса, үзем егылдым, диярсең. Попробуй, әләкләшеп кара!

− Бу сезгә дә кагыла, − әшнәсе Динар да кысылып өлгерде. − Югыйсә, барыгыз да тукмаласыз.

Бернәрсә булмагандай, тыныч кына, Динар белән Даян бүлмәдән чыгып китте.

Шуннан соң детдомда малайларга сөяк бирүне тыйдылар.

− Этләр! Кешечә кимерә дә белмисез! Тамак өчен бер-берегезне ашап барасыз! – дип тиргәде безне Зилә апа.

Вакыт үтү белән, бу хәл онытылды. Тик Айнур гына шул мәлне ачынып искә ала. Даян сөяк белән суккач, битендә гомерлеккә яра эзе калды.

## Бәхет

− Тик әлегә берәүгә дә бу турыда сөйләмә, − диде апа хушлашканда һәм трубканы куйды. Бәйләнеш өзелде. Аның ягымлы тавышын ишеткәч, ничектер рәхәт булып китте. Бүлмәгә атлап түгел, кыр кәҗәседәй сикеренгәләп бардым. Бүтәннәр мондый кыланышымны күрсә, әллә акылга бер төрлерәк була башлаган инде дип уйларлар. Малайлар, чигәсе тирәсендә бармагын әйләндереп, минем исәрлеккә ишарә ясый. Ярый, теләсә нәрсә уйласыннар! Анысы хәзер мөһим түгел.

Нигә шулкадәр куанганымны башкалар белми дә. Минем шундый серем бар! Әлегә берәүгә дә сөйләргә тиеш түгелмен. Берәүгә дә.

Бәхет бар икән шул дөньяда! Әллә каян, көтмәгән җирдән килә дә төшә. Кайчак, шул бәхетне көтеп, әллә күпме көннәр, айлар, еллар үтә. Син зарыгып бетәсең. «Уңнан бир, сулдан бир, уйламаган җирдән бир!» дип такмаклый иде әнием. Ә ул, юри, синең чыдамлыгыңны сынагандай юк та юк. Ахырда, җиңеләсең. Нәкъ шул вакытта, көтмәгәндә-уйламаганда, килеп чыга да инде!

Минем дә шул бәхетле мәлем җитте. Менә күрегез дә торыгыз – берничә көннән тормышым хәтәр шәп якка үзгәрәчәк.

...Бүлмәмдә китап укып утырганда, кинәт вахтага төшәргә куштылар. Кемдер сине телефонга чакыра, диделәр. Очтым җан-фәрманга! Моңарчы вахтага шалтыратып, эзләп йөрүче кеше юк иде. Кем икән, дип барып җиткәнче, мең төрле уйга калдым.

− Саумы, Ильяс, таныйсыңмы мине? – Чыбыкның теге очында ягымлы тавыш ишетелде. Тәүдә аптырап калдым. Кем икәнен шунда ук аңлап җиткермәдем. − Савыктыңмы инде? Еш авырмыйсыңмы? – дип сорагач, кем икәненә төшендем. Бәй, бу бит Наилә апа! Лагерьда медсестра! Быел җәй танышкан идек аның белән. Безне лагерьга ял итәргә җибәргәч, нигәдер көн дә авырдым. Районнан бик еракка барган идек шул. Әллә һавасы килешмәде, әллә үзебезнең якларны сагынудан. Медсестра көн дә карый, даруын бирә, киңәшләрен дә кызганмый. Хәстәрлекле кеше шул ул. Илле яшьләр тирәсендә. Бик ягымлы, ачык та. Шулай медпунктка йөри торгач, бик якын булып китте Наилә апа. Хәтта төрле тәмлекәчләр белән дә сыйлап ала.

«Ирем белән икебез генә торабыз. Балаларыбыз юк. Әллә сине уллыкка алырга инде...» – дигән иде берчак.

− Ә мин каршы түгел! − дидем, күп уйлап тормыйча.

Шушы сөйләшүдән соң без кире кайту ягына төштек. Наилә апа белән хушлашу бигрәк авыр булды. «Ильяс, мин сиңа килермен әле», − дип юатты ул, кочаклап.

Җәй үтеп китте, укулар башланды. Детдомга килгәч тә, шул Наилә апаны искә алудан туктамадым. Һәм менә ул үзе шалтырата!

Апа укудагы уңышларым, мондагы тормыш турында кызыксынды. Көзге каникулда нәрсә эшләргә ниятләвемне дә сорашты. Ә мин каникулда кайда булыйм – детдомда инде!

– Ильяс, мин сиңа тиккә генә шалтыратмыйм. Үземә алып кайтырга булдым. Ирем белән сөйләштем. Ул риза. – Наилә ападан бу хәбәрне ишеткәч, түбәм күккә тиде. Мине моннан алып китәргә уйлыйлар! Җиде ятып, бер төшемә кермәгән хәл бит!

– Каникулгамы? – дип сорадым, тотлыга-тотлыга.

– Юк, бөтенләйгә. Опека хезмәте белән алдан сөйләшенгән, кирәкле документларны җыярмын. Син ризамы?

– Ри-за! Ри-за! – Әллә апа ишетми калыр дипме, сүземне ике тапкыр кабатладым. Маңгайга тир бәреп чыкты. Ә шатлык эчемә сыймый. Чынмы соң, әллә юриме? Төш түгелме икән?

– Алайса, киләсе атнаны мине көт, – диде ул. – Тик әлегә берәүгә дә бу турыда сөйләмә...

Шушы бәхет булмый, нәрсә булсын инде?! Билләһи, шатлыгым ташып түгелә. Наилә апага рәхәт, берәүгә дә сөйләми тор, диде дә куйды. Ә син шул серне яшереп яшәп кара. Үзеңә бәйле шатлыклы хәбәрне бүтәннәргә әйтмичә ничек яшәмәк кирәк? И авыр, нык авыр бит ул! Менә шул шатлыклы яңалык ничектер эчемнән ташып чыгып барган сыман. Тизрәк балаларга сөйлисе, бөтен детдомга сайрыйсы иде. Әйдә, белсеннәр, эчләре кызсын! Күрсеннәр әле гаделлекнең барлыгын! Югыйсә, «Кипкән балык» дип миннән көлгән булалар. Әнә бит Наилә апа бүтәннәргә карамаган, ә мине сайлаган. Шул бәхет түгелме? Шатлыгымны кая түгәргә белми озак азапландым. Тик тыйдым үземне. Наилә апаның сүзен тыңларга кирәк.

Кичен телевизор карап утырганда, чак серемне ачмадым.

– Ә беләсезме нәрсә... – дип сөйли башлаган идем, чак тыелып калдым. Башка артык сүз әйтеп куймыйм дип, учым белән авызымны капладым.

Төне буена Наилә апаның хәбәре хакында уйлап, йоклый алмый чыктым. Башка төрле уйлар килә дә килә. Ничек йоклыйсың инде?

Мөгаен, Наилә апаның фатиры иркендер. Берүземә бүлмә биреп куйсалар – хәтәр бит. Аннан да бигрәк иркенлек. Кайчан, күпме телисең – шунда ашыйсың! Матур гына киемнәр дә алып бирерләр әле.

Велосипед! Наилә апа, мөгаен, миңа велосипед алып бирер. Вәт, җилдерәчәкмен. Югыйсә, мондагы малайлар иске-москыдан самокат эшләп алган, аңарда йөрер өчен дә су буе чират. Бушлай да түгел: йә алма, йә кәнфит бирергә кирәк.

Гаиләдә яши башласам, йон оек та кидерерләр әле. Әйе, ансыз кышны ничек чыгасың? Безнең детдомдагы төнге «няня»лар һәркемебезгә оек бәйли. Эшкә килә дә шул шөгыльгә тотына. Ә без ярдәм итәбез: йонны тетәбез, илибез. Тик без төркемдә егермеләп, ә бәйләүче апа берәү генә. Моннан тыш аның башка эшләре дә бар бит. Аена өч йон оек бәйләгән хәлдә дә, барыбызга да әзер булсын өчен, күпме вакыт кирәк. Шуңа да үз чиратыбызны түземсезләнеп көтәбез. Чөнки монда бирелгән носкилар белән ерак китеп булмый. Аяклар өши. Җитмәсә, ботинкалары да әллә нинди. Суыкта тышка чыксаң, табаны ярыла да куя.

Барыбер миңа да оек эләкте. Чиратым җитте... апрель аенда. Ул вакытта

көннәр җылынган иде. «Ярый, тагы әйбәт булды. Кемгә ноябрьдә эләккән, анысы тишелеп бетеп бара. Ә мин күзен киярмен. Ул чакта минеке яңа булачак», – дип, башкалар алдында үземне юаттым. Шулай дидем дә иплән кенә тумбочкага салып куйдым. Җәйге каникулдан соң алып караган идем, танырлык түгел. Күя ашаган, ян-яктан тишкәләнеп беткән.

Ә инде Наилә апада башкача булачак. Шул турыда уйлана торгач, йоклап та киткәнмен.

Иртәгесен серне сакларлык түземлегем калмады. Иң беренче булып классташым Әмиләгә сөйләдем.

Әмилә берәр нәрсәне белеп алдымы – бетте. Радиодан сөйләп тору кирәкми. Барысы да беләчәк! Шулай килеп чыкты да. Тәүдә үземә дә кызык булып китте: барысы да төпченә, тәфсилләп сөйләүне сорый, кайберләре көнләшеп карый. Иртән дә, кичен дә детдомда тикшерелгән хәбәр – Ильясны уллыкка алачаклары. Бу яңалык балалар йортының эченә генә сыеп җитмәде, мәктәпкә дә таралды.

Күтелгән хәбәргә Алия апам гына ышанмады:

– Юкны сөйләп, кеше күлдереп йөрмә! – дип кул селтәде.

Бер-ике көн шулай кукраеп йөрдем. Тора-бара серне таратуыма үкенә дә башладым. Сәбәбе дә бар иде...

Кичен бер төркем малайлар бүлмәмә җыелды. Ни өчен килүләре билгеле.

– Ә сине алырга кайчан киләләр? Кайсы көнне? – дип сүз башлады Динар.

– Әллә?! Каникул башланыр алдыннан шикелле...

Малайларның көнләшүләре йөзләренә чыккан. Минем шатлыгымны әллә кичерә алмыйлар инде, һәр сүз белән кәефемне бозырга маташалар:

– Ә нигә нәкъ сине алырлар дип уйлыйсың? – сүзгә Дим исемле малай да кушылды. – Ашыкмый тор! Монда балалар күп. Әгәр килгән апа бүтәннәрне күрсә, бәлки, сине калдырып китәр.

– Әйе шул! – Нил дә шым калмады. – Син бит, Ильяс, яман җебексең – авырыйсың да торасың. Физкультурадан да гел «өчле», ә минеке «бишле». Бәлки, апага спортсмен ул кирәктер. Алай булса, гафу ит инде.

– Наилә апаны күптән беләм. Ул үзе килеп алам, диде. Мин бит сорадым, – ничектер акланырга тотындым. Малайларның чәме тагын артты:

– Ярый, апа килсә, без дә үзебезне күрсәтербез.

– Ә мин җырлап җибәрсәм...

Ай, Аллам! Каян гына сөйләдем икән! Әнием апаларыма белми әйтмәгән икән. «Сереңне беркемгә дә сөйләмә. Әгәр бик түзмисең икән, яулыгыңа сөйлә. Яулыгыңа төен төйнә дә сереңне шуңа пышылда. Бу серле төенне синнән башка берәү дә чишә алмас. Дустыңа да сөйләмә. Дусның да дусты була», – дип сөйли торган иде.

Малайларның һәрберсе шушы бәхеттә үзен сынап карарга тели. Әйе, алар моны миннән яшерми дә. Җанымны көйдереп, нинди хәйлә уйлаганнарын әйтәләр бит әле.

Чикылдык Рөстәм җыр җырларга булган. «Мамонтёнок» җырын. Аның белән ялкытты инде. Кем өйрәткән икән? Районда смотр булса, директорыбыз гел Рөстәмне җырлата. Сүзләре дә бигрәк җәлләткеч бит:

Пусть мама услышит,
Пусть мама придёт,
Пусть мама меня непременно найдёт!

Ведь так не бывает на свете,
Чтоб были потеряны дети…

Шул урынына җитсә, Рөстәм күз яшьләрен кызганмый еларга керешә. Беркөнне мәдәният йортында да шулай итте. Моны күреп, жюрида утырган апалар да еларга тотынды, ә халык гү килеп кул чаба. Һәм беренче урын – Рөстәмнеке! Детдомга зур-зур түрәләр килсә дә, Мәүлидә Нургалиевна Рөстәмгә шул «Мамонтёнок»ны җырларга куша. Тыңлаганда тегеләрнең күңеле тулышып китсә, директор йомышын әйтеп сала.

− Әгәр сәхнәдә елыйсым килмәсә, юри телемне тешлим, – дип мактанган иде ул. Шуның өчен директор аңа яңа кием дә биргән. Вәт, йомры баш! Әгәр Наилә апа алдында шулай кыланса – харап бит! – дим дә, тик кенә торырга уйламый:

− Ә мин төркемгә апа килеп керсә, идән юарга тотынам. Нинди эш яраткан малай дип уйлаячак. Ә егәрле кеше кемгә кирәкмәсен? Шул чакта миңа үпкәләмәгез...

Менә Наилә апа килде. Белсәгезче, бүтәннәрнең ничек караганнарын. Балга сарган сагызаклар шикелле уратып алганнар. Апага юньләп атларга да ирек бирмиләр. Кунакка детдом буйлап экскурсия ясадылар. Шунда да балалар калышмады. Күзләреннән күреп торам: апа аларга игътибар итсен дип тырышалар. Ә Наилә апа, килүгә, мине генә җитәкләп алды да кулымны ычкындырмады. Мондагы шартлар белән танышып чыккач, директор Наилә апаны һәм мине үзенең кабинетына алып керде.

− Ходай бар икән. Күптән бер бала алырга хыяллана идем. Менә бит... − апа аркамнан сөеп алды. − Әле каникулга алып кайтам. Шул арада тиешле документларны да юллармын.

Шуннан мине бүлмәмә җибәрделәр. Ә әйберләрем күптән әзерләнеп куелган иде. Тиз генә курткамны кидем, сумкамны асып алдым. Залга чыксам, Алия апам белән Зөлфирә утыра. Үпкәләүләре йөзләренә чыккан. Елаганнарын да яшермиләр.

− Ильяс абый, син безне ташлап китәсеңме? Шул дөресме? – ди сыктап Зөлфирә. Ни эшләргә белми, сүзсез калдым. Ничек туганнарым турында оныттым соң? Шултиклем кыен булып китте.

− Әти үләр алдыннан нәрсә дип әйткәнне оныткан! – Алия күземә дә карамый үзалдына сөйләнде. – Бергә булыгыз, бер-берегезне ташламагыз, дигән иде әти. Ә син... – Апам учы белән битен каплады да сыгылып елый башлады.

− Мин хәзер бөтенләй абыйсыз каламмы? Сине сагынсак нишләрбез? – Сеңлемнең сүзләре пычактай кадалды. Җавап та биреп булмый. Нәрсә дип әйтәсең инде?

− Сатлыкҗан! Әни белән әти моны күрсә, нәрсә диярләр иде икән?

Үземне кая куярга белмим. Ирексездән, күздән яшьләр тәгәрәде. Моңа кадәр авыз ерып йөрдем дә ул, ә хәзер... Иң якын кешеләрем турында онытканмын бит.

− Ильяс, тизрәк бул. Директор көтә. – Тәрбияче кабаландырса да, инде директор кабинетына аягым тартмады.

Әйе, дөрес эшләмәдем шул. Сатлыкҗан, дип, Алия апам дөрес әйтә. Тамакка балчык кисәге тыгылдымыни! Иркенләп тын алып та, сүз әйтеп тә булмый. Аяклар да тыңламый. Ә күздән яшь ага да ага. Мең төрле уйларга чумып, кабинетка чак килеп җиттем. Наилә апага уллыкка барасы килә, туганнарны да ташларга ярамый.

– Нәрсә булды сиңа? – дип сорашты ул.

– Бернәрсә дә булмады, – дидем, үземне тынычландырып. – Наилә апа, сез мине гафу итегез. – Үзем калтыранам, сүзләрне дә тотлыга-тотлыга әйтәм. – Тик мин сезгә бара алмыйм. Монда яшәргә калам.

Директор да, медсестра да шаккатты. Алардан уңайсызланып, күземне яшердем, шуннан җәһәт кенә кабинеттан чыгып йөгердем. Урамга чыккач, күз күргән якка йөгердем дә йөгердем. Көне буена урманда йөрдем. Кич җиткәч кенә детдомга килдем. Наилә апа киткән иде.

## Үкенеч

Җәйге лагерьдан ял итеп кайтып киләбез. Балалар йорты алдына килеп төшкәч тә, безне тәрбиячебез Рәйфә апа каршы алды.

– Саумысез, апа! – дип, ихлас елмаеп, аңа сәлам бирдем.

Тик тәрбияче мине күрүгә әллә ни шат түгел иде. Саулык та сорашмады. Кайнап торган ачуы йөзенә чыккан. Моны мин аның нурсыз битенә карап шунда ук тоемладым.

– Юньле кеше булып кыланма, кәкре аяк! – диде тәрбиячем, сөзәрдәй итеп карап.

Мин берни дә аңламадым. Тиктомалдан Рәйфә апа нигә алай каты бәрелде икән?

– Нәрсә булды соң, апа? – дип, кыяр-кыймас кына сорадым.

Бу сүзләрем аның ачуын арттырды гына:

– Белмәмешкә салышып торма, ачыгавыз! Телеңә хуҗа була алмый, адым саен сайрап йөрисең, иманыңны укытырмын әле!..

– Мин нәрсә дип сөйләп йөргәнмен соң? – Үземне яклап сүз әйтүемә, Рәйфә апа котырганнан-котырды. Моны күреп, башка балалар да йортка керергә ашыкмады, читтән генә шушы тамашаны күзәтте. Кемдер авызын ерды, кемдер исә минем өчен борчылып торды. Детдомда шундый бер-бер хәл була калса, бүтәннәр, ишетми калмыйм, дип, әллә каян килеп җитә. Азак, күрми калганнарга ләззәтләнеп сөйлиләр.

Тәрбиячем беләгемнән тотып алды.

– Үксез бозау асрасаң – авызың тулы май булыр, үги бала асрасаң – авызың тулы кан булыр, дип юкка әйтмәгәннәр икән. Менә шушы мәхлук та мине, бер гаепсез, авыл халкы алдында исемемне чыгарды. – Аның ярсуыннан маңгаена тир бәреп чыкты. – Хәзер кеше күзенә күренер әмәл юк. Кая барма, минем бәгыремне чәйниләр.

Нәрсә әйтергә белми аптырадым да калдым. Рәйфә апа нигә шулай ябырылды икән? Хәтеремә төшереп карасам да, аның алдында бер гөнаһымны да тапмадым. Ахырда:

– Берәр кем белән бутыйсыздыр, – дигән булдым.

– Шым гына тор, карга! – Тәрбияче беләгемнән ныграк кысып тотты. – Йә борыныңа сугармын.

Ярсыган тәрбиячегә берәр сүз кушу да куркыныч булып китте. Беркөнне кичен тыштан соңлап кергәне өчен дустымны ничек тукмады. Дәү йодрыгы белән селтәнеп, аның күзен күгәртте. Соңыннан дустым, кеше күзенә дә күренергә оялып, башын түбән иеп йөреде. Ул Рәйфә апаның юан кулларына бер эләктеңме, җиңел генә котылырмын димә!

Тәрбиячем төкерекләрен чәчә-чәчә акыруын дәвам итте:

– Йә әйт әле, кайчан мин детдомнан әйберне өемә урлап ташыдым? Кайда күрдең? Сезнең тәлинкә-калакларыгыз, чынаякларыгыз миңа ни хаҗәтемә кирәк? Синең ястыгыңны, юрганыңны, тастымалыңны урлап алып кайттыммы? Нәрсә сарык сымак өнсез торасың, җавап бир!

Рәйфә апаның талпан сыман миңа ябышып, колагымны ертырдай итеп кычкыруыннан калтырана башладым. Кинәт җебедем дә төштем. Күзләремнән тәгәрәгән эре яшь тамчылары битемне өтеп алгандай булды.

− Сезнең турыда алай дип сөйләгәнем булмады! − Бар көчемне җыеп әйтә салдым.

− Кара син аны, гаебен танырга да уйламый. Бөтен авыл халкы хәзер мине тикшерә. «Ильяс»ның авызын тый» дигәннәре дә булды... Синең генә этлегең бу, синең генә! Теге тапкыр безгә бәрәңге алышырга килгәндә, саескан сыман йөри идең. Ревизор шикелле, күзең чыгардай булып, чокчынып йөргәнсең, димәк. Хәзер дөньямны тикшерергә булдыңмы? Не позволю! Минем белән булышканчы, әнә бугыңда чокын. – Рәйфә апаның җан көченә төртүеннән җиргә мәтәлеп барып төштем. Аяк-кулларым сыдырылды.

− Мин синең бу этлегеңне беркайчан да онытмам. Үкенер көннәрең алда әле... – Рәйфә апа тамак төбе белән кычкырды да детдомга кереп китте.

Шатланып йөргән җиремнән кәефем тиз генә бозылды да куйды. Кайсы җирдә ялгыш сүз ычкындырдым икән, дип исемә төшерергә маташтым. Тик барыбер берни дә хәтергә килмәде.

Шушы хакта борчылып, төне буена йоклый алмый чыктым. Яраларым гына түгел, күңелем дә сызлый иде. Минем бит Рәйфә апа турында беркайчан да начар сүз сөйләп йөргәнем булмады. Киресенчә, аңа һәрчак ярдәм итәргә әзер тордым. Яз җитсә, төркемебез малайлары белән бәрәңге чәчәбез, көз җыеп бирәбез. Билләр арып, хәлсезләнеп кайтып тәгәрәсәк тә, мыжгып йөрмәдек. Кышын тәрбиячебезнең ихатасында кар көрәү, малларына печән салуны, елгадан өенә су ташуны да бүтәннәр белми әле. Әгәр Рәйфә апаның эшен эшләргә бармыйм, дисәң, тәрбиячебезнең җавабы әзер:

− Болай булгач, яңа кием дип авызыңны да ачма!

Детдомга китерелгән барлык әйберләрне дә тәрбиячебез генә келәттән алып бирә ала. Аның әйткән сүзен үтәмәсәң – йөр әйдә иске киемең белән. Бүтәннәр, синең күзеңне кыздырып, яңа ыштан, ап-ак күлмәк кия, ә сиңа бирелергә тиеш булса да, искесе белән хушланасың. Үзенә дошман булганнар гына Рәйфә апаның сүзен колакка элмәячәк. Әмма андыйлар безнең төркемдә юк диярлек.

Шул көннән алып Рәйфә апаның миңа мөнәсәбәте үзгәрде дә куйды. Саулык сорашсаң, җавап бирми. Авызы ерылып китеп барган җиреннән, мине күреп калса, йөзе кинәт үзгәрә дә куя. Аяз көнне яшен суккандай.

Безнең төркемдә тәрбияче булгач, ничек инде сөйләшми йөрисең? Йә тегене, йә моны белешергә кирәк. Тик Рәйфә апа мине күрмәмеш тә белмәмеш.

Беркөн әйбер китергәннәр дигән хәбәр ишеттем. Башкалар алганда, буш торып калмас өчен бардым тәрбиячемә.

− Малайларга яңа аяк киеме бирәләр, дип әйтәләр. Апа, миңа да аласызмы? Кырыгынчы размерны киям, − дигән булдым.

Рәйфә апа көлемсерәп карады:

− Аяк киемнәрен келәттән күптән алдым. Тик сиңа җитмәде...

Бу сүзләрдән соң аптыраšта калдым:

− Ничек инде алай? Барысына да бар, ә миңа − юк.

Тәрбиячебезнең исе дә китмәде. Киресенчә, бу турыда сөйләгәндә, йөзендә канәгатьлек күренгәндәй булды.

– Әлләче. Синең барлыгыңны бөтенләй оныткканмын. – Моны ул нииндидер ләззәт белән әйтте. – Ярый, тайгак аягың иске ботинка белән дә өзелеп калмас әле! – Башкача мине ишетергә теләмәвен белдереп, арты белән борылды да кабинеттан чыгып китте.

Моннан соң да Рәйфә апа төчеләнеп тормады. Сәламемне алмады. Киләттән барлык балалар кием сайлаганда, миңа иң соңгы булып чират җитә. Тәрбияченең теләге шундый. Ә калдык-постыкны үзегез аңлыйсыздыр. Аяк киеме бирелсә – йә ике-өч размерга зуррак булып чыга, костюм йә күлмәк булса, киресенчә, кыскасы эләгә. Соңыннан йөрисең бүтәннәр алдында оятыңнан кызарып.

– Апа, бу бит кыска, – дип әйтүем була, тәрбиячем шунда ук әрләп ташлый:

– Хөкүмәт бушлай киендергәнгә рәхмәт әйт әле. Үзеңә килешлесен эшли башлагач алырсың!

– Ичмасам, чак кына озынрак җиңлесе юкмы? Монысы бигрәк бит...

– Хан баласыдай сайланып торма! Алсаң – аласың, алмасаң – вәссәлам! – Ризалашмый кая барасың инде? Ялангач йөреп булмый бит.

Эх, шул вакытта нитиклем гарьләнгәнемне белсәгезче! Оятыңнан җир тишегенә кереп китәрдәй буласың. Нигә тәрбиячем шулай итә икән? Бер зыяным да тимәде шикелле. Тик теге көнне, лагерьдан кайтканда, ничек әрләде. Шуннан башланды бит бу газаплар.

Мәктәпне тәмамлаган елны Рәйфә апа янә «хәстәрлеген» күрсәтте. Университетка керер өчен характеристика кирәк. Ә аны тәрбияче генә язарга тиеш. Менә шунда ул теләгәнен кинәнеп язды. Мондый характеристика белән университетка түгел, ГПУга да якын китермиләр.

Шулай да, ничектер башым җитеп, мәктәпнең бер укытучысыннан характеристика яздырттым. Шуны тапшырып кына, югары уку йортына керә алдым. Ә инде Рәйфә апаның зур кинәнү белән язган характеристикасын әле дә кадерләп саклыйм.

Менә анда нәрсә дип язылган:

«Ильяс Мөхәммәтов – бик сәер кеше. Балалар йортына килгәннән үк, башкалардан ничек тә булса аерылырга омтылып тора. Һаваланырга ярата. Мәкерле. Кинәчел. Үч тотучан. Үзе турында югары фикердә. Олыны да, кечене дә санлый белми.

Ильяска артык ышанырга ярамый. Алдашырга оста. Бик мөһим мәлдә яшьтәшләрен уңайсыз хәлдә калдыра. Балалар арасында тиктомалдан низаг куптару сәләтенә ия. Кешегә, әгәр дә берәр ярдәм күрсәтсә, шуны күргән берсенә арттырып сөйли. Балалар йорты җитәкчелеге һәм тәрбиячеләр арасындагы кайсыбер аңлашылмаучылыклар да шул сәбәпле килеп чыга.

Аны дөрес юлга бастыру өчен, нинди генә алымнар кулланмадык. Тик гаиләсендә үк алынган кире тәрбияне үзгәртү җиңелдән түгел.

Гомумән, Ильясны иң тәртипсез, авыр холыклы балаларның берсе дип атарга мөмкин. Киләчәктә мондый кешенең җәмгыятькә файда китерә алуы бик тә шикле.

Тәрбияче – Рәйфә Түлебаева».

...Моннан соң хәтсез генә еллар үтте. Балалар йортында минем белән бер чорда тәрбияләнгәннәр күптән инде үзаллы тормыш белән яши. Мин дә, университетны тәмамлап, башкалада эшләп йөрим.

Күпме генә күңелне кырган вакыйгалар истә калса да, детдомда узган еллар сагындыра. Бигрәк тә бер төркемдә булган һәр яшьтәшемнең якты йөзе, сөендергән-көендергән дә шуклыклары һаман хәтердә.

Балалар йортында элек бергә тәрбияләнгәннәр без үскән авылда очрашуга җыелдык. Тормышта үз урынын тапкан егермегә якын кеше килде. Элекке тәрбиячеләребез, укытучыларыбыз да чакырылган иде. Күрешү хөрмәтенә мул гына итеп табын әзерләнде.

Мондый очрашуга сусаган һәркем детдомдагы хәл-вакыйгаларны исенә төшерде. Уңышларыбыз турында сөйләдек. Бер-беребезнең мәрәкәләрен исләп, көлешеп тә алдык. Табын артында вакыт тиз үтә икән.

Көн кичкә авышкач, кызмача булып алган Рамил яныма килде.

– Ильяс абый, сине бер минутка гына мөмкинме? – дип чакырып алды. Без аның белән бер бүлмәдә яшәдек. Укуга бик тырыш булды. Төрле ярышларда, олимпиадаларда аңа җитүче юк иде. Балалар йортыннан соң ниндидер һөнәрчелек училищесына укырга җибәрделәр. Аннан инде туган ягына эшләргә кайтты.

Мин чыктым.

– Абый, сиңа бер нәрсә әйтергә иде. Теге ни...– Рамил, сүзне нәрсәдән башларга белми, ык-мык итеп торды.

– Ничек бар, шулай әйт соң...

– Синең алдыңда үземне шултиклем гаепле итеп тоям...

– Китчәле, юкны сөйләмә! Бер зыяның да тигәне булмады.

– Тиде шул. Син үзең генә белмисең. – Рамилнең бите кызарып китте. – Шул гамәлем кайчаннан бирле тынгылык бирми. Әле булса да үкенеп бетә алмыйм. Инде бу күргәндә дә синең алда гафу үтенмәсәм, тыныч йоклый алмам.

– Нәрсә әйтергә теләгәнеңне аңламыйм, Рамил.

– Авылда бердәнбер умартачы Госман абыйны хәтерлисеңдер?

– Әйе.

– Менә шул абыйга без төркемдәш Мурат белән барган идек. Шулхәтле бал ашыйсы килә иде. Үзең беләсең бит инде – умартачыда бал мул була. Ә балалар йортында андый сыйны күргәнебез дә юк.

– Шуннан, бал ашадыгызмы?

– Их, ашамасам, күпкә хәерлерәк булыр иде. – Ул бераз тынып торды да, авыр көрсенеп, сүзен дәвам итте. – Госман абый безнең нәрсәгә килгәнебезне белсә дә, тиз генә сыен чыгарырга ашыкмады. Тәүдә ихатасына кертте, хәл-әхвәл сорашты, ничек укуыбыз, балалар йортындагы тормыш белән кызыксынды. «Рәйфә апагыз балаларга кул күтәрергә ярата, диләр. Шул дөресме?» дип төпченде ул. Әгәр ничек бар, шулай сөйләсәк, бал белән сыйлыйм, диде». Рамил авыр сулап куйды.

– Ә сез нәрсә дидегез?

– Күрәләтә балдан колак кагасы килми бит! Ничек бар, шулай сөйләдек. Аның нәрсәсен яшерәсең – чыннан да шулай бит инде. Берәр нәрсәне дөрес эшләмәсәң, башка ачкыч белән сукканын сөйләдек. Үзенең өенә безне эш эшләтергә йөрткәнен дә әйтеп салдык. Шуннан абый өенә алып керде. Хатыны чәй ясады. Өстәлдә яңа гына аертылган балны күргәч, күзләр ялтырап китте. Ә Госман абый төпченүен дәвам итте. «Рәйфәнең өе эчтән матурмы?» дигән була. «Уй, абый! Сез тәрбиячебезнең өен күрсәгез, башыгыз әйләнер иде. Анда нәрсә генә юк! Тик әйберләрнең күбесе – детдомныкы. Чынаяклар да, башка савыт-саба, челтәрләр дә, вазалар да, мендәр тышлыклары да безнеке. Аны

тәрбиячебез ничек үзенә ташып өлгергәндер», – дип әйтеп салдым. «Ә моны син каян беләсең? Бәлки, тәрбиячең шундый ук әйберләрне кибеттән сатып алгандыр?» – диде умартачы, тәрбиячемне яклап. Үземнең әйткәнемне ничек дәлилләргә дә белми калдым. Әгәр Госман абый шушы хакта Рәйфә апага әйтсә? Алайса, бетте баш. Ничектер котылырга кирәк иде. «Бу турыда безнең Ильяс яхшы белә. Ул үз күзләре белән күргән», дип алдап әйткәнемне сизми дә калдым. Тик сез бу турыда мин әйтте дип әйтмәгез инде, дип үтендем. Рәйфә ападан тукмалырмын дип курыктым. Ә сиңа, бездән зуррак булганга, барыбер бернәрсә дә эшли алмас дип уйладым...

Менә сиңа мә! Көтмәгәндә мондый хәбәрне ишеткәч, үзем дә аптырап калдым. Һәрьяклап өлге булган Рамилнең авызыннан бу сүзләрне ишетермен дип кем уйлаган?

– Гафу ит инде, абый! – Рамил гаепле карашын читкә юнәлтте. – Бер калак татлы бал шулкадәр ачы газапка әйләнер дип уйламаган идем...

Шулчак якында гына кемнеңдер авыр итеп уфтанганын ишетеп, борылып карадык. Ә анда лаеклы ялдагы тәрбияче Рәйфә Түлебаева тора иде. Ул берике адым артка чигенде дә агачка сөялде.

## Әти каешы

– Ильяс, сиңа нәрсә булды? – дип төпченергә тотынды Алия апам.

– Бернәрсә дә булмады.

– Ә нигә һәрвакыт миннән яшеренәсең? Берәр нәрсә әйтсәм – ишетмәмешкә салышасың. – Апамның болай дип әйтүенә нәрсә дип җавап кайтарырга белмәдем. Үземне соңгы вакытта шулай тотуымның сәбәбе дә бар. Тик дөресен генә сөйлисем килми. Алия апа безнең өчен әти дә, әни дә сымак. Әле дә ул бар. Детдомда ул безне гел яклап йөртә. Әмма мондагы балалар арасында апамның үзеннән дә көчлерәкләре күп. Әгәр минем белән шушы көннәрдә нәрсә булганын сөйләсәм – ул нык борчылачак. Эчемдәге сызлануымны белдермәскә тырышам. Шуңа да уң колагымны учым белән каплап, яшерергә маташам.

Бер тотынса, Алиянең төпченергә яратканын беләм. Аның яныннан тизрәк китәргә кирәк икәнен яхшы аңлыйм.

– Ярар, апа, мин ашыгам. Шигырь ятларга кирәк, – дигән булдым да тизрәк бүлмәмә йөгердем.

Ул көнне хәтерләсәм, әле дә кыен булып китә. Шул турыда уйлап ятсам, төннәр буена йоклый алмый чыгам. Апамнан яшерсәм дә, бу турыда сезгә түкми-чәчми сөйлим әле...

Безнең детдомда Даян исемле ялбыр чәчле малай бар. Аңардан барысы да курка, чөнки ул безнең «башлык». Даян абый да Даян абый, дип, ялагай малайлар аның авызына гына карап тора. Балалар йортында Даян үзе баш, үзе түш.

Куркаграк малайлар аның бөтен йомышын да үти. Кемдер киемен юа, кемдер үз ризыгын аңа бүлеп бирә, ә берәүләре, Даян кушуы буенча, авылга урлашырга йөри. Миңа да аның зыяны аз тимәде.

Балалар йортына килеп эләгүне авыр кичердем. Еш кына авырый башладым. Хәтта битемнең дә, кулларымның да тиресе кибә башлады. Төрле крем сөртеп карыйм – файдасы юк.

Ә Даян детдомда һәркемгә исеме белән түгел, ә кушамат белән эндәшә. Ул вакытта мин ару гына кушаматсыз йөреп алдым.

− Сине кем дип йөртәләр? – дип сорап куйды ул, мине коридорда очраткач.

− Ильяс.

− Ул мәгънәсез исемне онытсаң да була. Сиңа хәзер икенче исем табабыз. – Ул миңа баштанаяк күз йөртеп алды. Тиресе кипкән кулларыма чирканып карап куйды. − Син әллә үләргә йөрисең инде? Битеңә дә, кулларыңа да нәрсә булган ул?

− Әлләче, − бу кимсетүле сүзләрдән уңайсыз булып китте. Шулай да акланырга тырыштым. – Үзем дә белмим. Элек алай түгел иде. Детдомга килгәннән бирле шулай.

Даянның авызы ерылды. Әллә нинди зур ачыш ясагандай, учын-учка шапылдатып сукты да сөрән салды:

− Таптым, таптым! Бүгеннән синең исемең – Кипкән Балык! Ишеттеңме – Кипкән Балык!

Гарьлегемнән җир тишегенә кереп китәрдәй булдым. Ә Даян, шашынып, «ачышы» белән уртаклаша бирде:

− Кипкән Балык, Кипкән Балык!..

Шул арада кайдандыр малайлар җыелып китте. Ул ялагайларга җитә калды. Даянга ярарга тырышып, тешләрен ыржайтып, узыштан хихылдарга тотындылар:

− Ну, Даян абый, хәтәр башлысың да инде! Шәп исем тапкансың бит!

Бәләкәче дә, яныма килеп, терсәге белән төрткән булды:

− Карале, чынлап та, Кипкән Балык. Исеме үзенә килешеп кенә тора шул...

Менә шулай, Даян миңа кушамат та тагып куйды. Кушамат белән эндәшсәләр – игътибар итмәскә тырыштым йә бөтенләй ишетмәмешкә салыштым. Нык ачуым килде Даянга. Болай итеп котыруы үз башына булса ярар иде, дип пышылдадым эчтән генә.

Беркөнне безнең төркемдә яшәгән Дим үзенең бүлмәсенә чакырып алды. Монда аңардан башка берәү дә юк иде. Мөгаен, бәрәр кызыклы нәрсә сөйләргә уйлыйдыр.

− Монда иркенләп сөйләшер бер кеше дә юк, – дип, сүзен башлады ул. – Уйлаганымны детдомда башкаларга әйтеп бармыйм. Сатлыкҗаннар күп. Койрык болгаучылар адым саен. Шунда ук әләкләшергә генә торалар. Ышанычлы кешеләр юк диярлек. Менә карап йөрдем дә, Ильяс, синең белән үзара гына сөйләшеп алырга булдым. Ышанычлы малай икәнлегең маңгаеңа язылган. – Дим, минем белән аралашуга шат икәнен белдереп, ихлас елмайгандай итте.

Бу сүзләрдән эчемә җылы йөгерде. Һо, шулай булмый ни! Ышанычлы малай, диде бит! Үзем, чынлап та, шәп икәнмен дип, эчтән генә куандым. Тик моны Дим нәрсәдән чыгып әйтә? Күрәсең, кешеләрне яхшы аера беләдер.

− Рәхмәт. Син дә тәрбиялегә охшагансың, – дидем.

− Алай булгач, синең белән бернәрсә дә яшерми сөйләшә алабызмы? – Йөзенә җитдилек чыккан Дим урыныннан калкынып куйды.

− Була!

− Тик бу турыда сөйләшкәнебезне берәү дә белмәсен. Ярыймы? – Ул бармагы белән янап куйды.

− Икмәк тотып ант итәм...

− Ярый, алай булгач, − Дим, кемнәндер шүрләгәндәй, тирә-ягына каранып алды. − Ильяс, син ничек уйлыйсың: детдомда кем иң көчлесе?

− Бер дә белмим.

– Ничек инде белмисең? – Ул, чиксез аптыравын белдереп, күзләре чыга язып миңа текәлде. – Ә Даян абый нәрсә? Аның иң көчле икәнен белмисеңмени?

Шул Даянның исемен ишеткәч, әллә ничек булып китте. Җитмәсә, абый дип әйткән була бит әле!

– Кем-кем, тик Даян берничек тә көчле түгел! – дидем кинәттән. – Үзеннән кечерәкләрне тукмый, бөтенесен дә мыскыл итә, безнең ашыбызны тартып ала... Шундый кеше ничек көчле булсын? Үзеннән зурраклар алдында куян сыман дер калтырап торадыр әле! – Ачуымнан нәрсә уйлаганымны сөйләдем дә бирдем. Дим, авызын ачып, сүзсез калды.

– Әлләче, Ильяс, ничек кенә димә. – Даян абый иң көчлесе инде! Син алай дип башка берәүгә әйтә күрмә, югыйсә аңа җиткерерләр. Шунда сиңа да, миңа да эләгер. – Аның хәстәрлекле сүзләреннән бу турыда берәүнең дә белмәячәгенә ышанычым артты.

– Шул кешенең этлеге йөзенә чыккан. Көн дә берәүне елатмаса – исеме Даян булмый. Ярый әле, син шул явыз белән бер бүлмәдә яшәмисең. Көн күрсәтмәс иде. – Бер әйтә башлагач, туктый алмадым. Чынында шулай бит. Тик бу турыда беркемгә сөйләп булмый. Ярый әле, Дим бар. Бик ышанычлы күренә. Хәзер уйлаганнарымны тик аңа гына сөйләячәкмен. Мин сөйләгәндә, Дим башын селкеп тик утырды. «Әйе», дип, сүз белән генә әйтмәде. Ләкин аның минем белән килешүе аңлашыла иде.

– Ә шулай да Даян ничектер авыл кызларын үзенә карата. – Дим детдомның «башлыгы» белән горурланып куйды.

– Әгәр аларга хатларны Даян үзе язмаганын белсәләр, әйләнеп тә карамаслар иде. Туңбаш бит ул Даян. Бер сүздә өч хата җибәрә. Шуңа «бишле»гә укыган малайларны бүлмәсенә чакыртып, әйтер сүзен диктовать итеп, кызларга хат яздырта.

– Китчә-ле-е! Даян хаталы язмыйдыр?

– Югыйсә, белмисең! Яза шул. Беркөнне үзе язып караган, ди. Хатны «дарагая дивушка» дип башлаган. – Ирексездән шаркылдап көлеп җибәрдем.

Шулчак нәрсәдер дөбер-шатыр итеп алды. Бүлмәдәге шифоньерның ишекләре шар ачылып китте дә, аннан кызарып беткән Даян атылып килеп чыкты. Йөрәгем туктап калгандай булды. Бетте баш. Йөзе качкан «башлык», йодрыкларын төеп, миңа ташланды:

– Үтерәм, Кипкән Балык, үтерәм! Минем турында шулай дисеңме әле-е-е? – Даянның көчле йодрыгыннан күз алдымда очкыннар чәчрәп китте. Күземне күгәртерлек сукмасын дип, учларым белән битемне капладым. – Карале, маңка! Нәрсә дип авызын ачкан була. Мин неграмотныймы? Алай дип әле берәүдән дә ишеткәнем юк. Телеңә хуҗа булмасаң – мә! – Көчле итеп тибүдән бөерем чәнчеп куйды. Шуннан тагын селтәде. – Даян шулай дисеңме әле? Даян болаймы? – Башлык хәле беткәнче төйде. Авыртуга түзә алмыйча утыра төштем. Шуннан тәмәке исе сеңгән каты бармаклары яңагымны тотып алды.

– Нәрсә, яшисең килми әллә? – Чыгырыннан чыккан Даян әллә нинди нәфрәт белән тишәрдәй итеп карады. Шулчак берәү аркама нык итеп типте. Монысы Дим иде.

– Даян абый турында тагын берәр нәрсә әйтеп кара! – диде ул, чәрелдәп.

Нинди камауда калганымны аңлап, башыма эссе йөгерде. Бу капкыннан җиңел котыла алмассың хәзер. Нык итеп тукмамыйча, үчен кайтармыйча, «башлык»ның күңеле булмас. Әмма, ничек кенә авыртса да, еламадым.

– Торгыз әле шул кәлтерәкне! – Даян янында биеп торган «көчегенә» боерык бирде. Теге мине аягыма бастырырга маташып эткәләде.

– Беләсеңме, син – бүгеннән мәет! Котыла алмаячаксың! – Даян бүлмә буенча сөйләнә-сөйләнә йөри бирде. Шуннан миндә нәрсәдер күреп, шып туктап калды. Тиз генә яныма килде:

– Моны кемнән алдың? – Детдом башлыгы билемдәге каешка күрсәтте.

– Әти-ем-не-ке. Үләр алдыннан бүләк иткән иде. – Калтыраулы тавышым шүрләвемне сиздерде.

– Чиш! Бүгеннән алып ул минеке! – Әтиемнән калган бердәнбер мирасны ничек башкага бирәсең? Минем өчен моннан да кадерлерәк әйбер юк. Шуны таккан саен, әтием искә төшә, ул янымда йөргән сыман хис итәм. Каешка карасам – әтиемнең ягымлы йөзе күз алдыма килеп баса. «Мә, улым, билең нык булсын!» – дигән иде бит ул аны биргәндә. Шуннан күп тә үтми үлеп тә китте. Ә матур гына соры каешны һәрчак тагып йөрим.

– Юк, бирмим! – Иң кыйммәтле әйберемне югалтудан куркып, ике кулым белән каешка тотындым. Болай итүемә Даян тагын да ярсыды.

– Мин синнән сорап та тормыйм! Дим, чиш тиз генә! – Башлык кулларымны каерып борды.

– Бирмим каешны! Ул бит әтиемнеке! – Бәлки, тыңларлар, дип, тартып алмауларын үтендем. Даян кулларымны тагын ныграк каерды. Сөякләрем менә-менә сынар сыман.

Ә Дим шул вакытта чишәргә тотынды.

– Менә, Даян абый, булды! – Кадерле әйберемне кулына эләктергәч, авызы ерылып, аңа сузды. Даян зур ләззәт белән каешны кулында әйләндереп-әйләндереп карап алды:

– Шә-ә-әп!

– Барыбер бирмим, дидем! – Бар көчемне җыеп, каешка барып ябыштым. Тик Даян аны нык тоткан, ычкындырмады. Карышуыма җаны көеп, үземне очыра төртте.

– Черки башың белән маташасыңмы, ә? Каешың кирәкме?

– Әйе.

– «Мә», бик теләсәң! – Даян каеш белән миңа селтәнде. Кинәт колагым зыңк итеп калды. Каешның тимер ягы колагыма эләккән иде. Башым чатный. Тәнем калтырый. Түзеп булмаслык авыртудан иреннәремне тешләдем. Күзләремнән эре тамчылар бәреп чыкты. Ә Даян белән Дим, бернәрсә булмагандай, бүлмәдән чыгып киттеләр. Әтиемнең каешы китте...

Чарасыздан түгелеп еладым. Юк, авыртудан түгел. Күңелгә авыр. Бу каеш белән әтиемнең, ичмасам, бер сукканы да булмады. Ә Даян мыскыл итеп сукты...

– Нигә генә шундый көчсезмен икән? Мәктәптә яхшы укыйсың, дип мактаган булалар. Аннан ни файда? «Бишле»гә укыганчы, шушы икеле капчыгы Даян шикелле гәүдәле булсам иде, – дип, күз яшемне тыя алмыйча, гомердә тәүге тапкыр яхшы укуыма үкендем.

Шул көндә үк колагым күгәреп чыкты. Алай гына да түгел, начар ишетә башладым. Апамның әйткәнен шуңа өзек-өзек кенә ишеттем. Аңа күренмәскә тырышып, яшеренеп йөрдем. Байтак еллар үтте...

Туган якларыма кунакка кайттым. Юл уңае балалар йорты урнашкан авылдагы классташыма кереп чыгарга булдым.

– Теге Даянны хәтерлисеңме әле? – Классташым күпмедер сөйләшеп утыра биргәч, кинәт шулай дип сорап куйды.

– Хәтерлисе дә килми! – Теләр-теләмәс кенә җавап кайтардым. Мин шулай

дип кырт кистем. Ә чынында исә аның язмышы турында яхшы беләм. Моннан берничә ел элек автовокзалда чүплектә чокынып йөргәнен күргән идем. Аннан соң хәле тагын хөртәйгән дип ишеттем. Урлашканы өчен төрмәдә дә утырып чыккан.

– Ишеттеңме, яңарак кына аның белән нәрсә булганын? – Дустымның бу сүзләреннән кызыксынуым арткандай тоелды:

– Нәрсә булган соң?

– Даян үткән айда гына үлде бит!

– Нич-чек? – Көтелмәгән хәбәрдән аптырап калдым.

– Менә шулай. Авыл читендәге каенлыкта тапканнар. Үзенең соры каешына асылынган...

## Тасма

– Тагын шул тасма дип килдеңме, ә? Тәкатемне генә корыттың бит! – Мәүлидә Нургалиевна мине күрү белән ярсып китте. Саулык сорашкан идем, ишетмәде дә.

– Апа, тиздән мәктәптә чыгарылыш кичәсе була. – Үземне гаепле тойгандай, ишетелер-ишетелмәс кенә эндәштем. – Класс җитәкчесе барысына да тасма алыр өчен акча җыя. Бүтәннәрнең әти-әнисе күптән тапшырган. Мин генә калдым...

– Шуннан ничек итим? – Директор мыскыллы елмайды да аннан чәнчеп карады. – Тугызынчыдан соң ГПУга бар, дип әйттемме? Әйттем! Ә син карышкан булдың. Имеш, университетка бара берәү. Ике ел элек чыгып киткән булсаң, күптән берәр төзелештә эшләп акча табар идең. Йөрмәс идең монда мыжгып, соранып. Хәзер «тасма» дип миемне черетәсең. Никаких, башкача берәр нәрсә сорап авызыңны да ачма!

– Мәүлидә апа, бөтен мәктәп алдында ялгызым тасмасыз торыйммы? Уңайсыз бит...

– Тор, нишләп уңайсыз булсын. Син бит бүтәннәрдән аерылырга яратасың. Детдомдагы башка балалар тугыз классны бетереп, шатланып, ПТУга укырга бара. Ә син, әллә кем баласыдай кыланып, университетка барам, дип ныкыштың. Минем өстемнән әләкләп, министрга да яздың. Синең аркада чокымаган җирне калдырмадылар. Үзеңә, ичмасам, читтән карар идең. Чак җил иссә, очып китәргә торсаң да, һаман Уфа дип авыз ачасың. Берәү артист йә галим була, имеш. Йөрисең шунда кеше көлдереп. – Директорның бу сүзләреннән гаепле башым иелә төште. – Мин сиңа тасмага акча бирмим. Сорама да. Әнә, бик аерылып торасың килгәч, бөтен мәктәп алдында тасмасыз тор. Йөр шунда ала карга булып!

– Апа, биреп торыгыз инде...

Директор мине тыңлап та тормады. Ачуы кабарып, кулларын селти-селти, нәфрәтле күзләре белән тишәрдәй булып, кабинетыннан куарга тотынды:

– Куй, хәчтерүш, башымны каңгыртма. Күземнән югал!

Мин, башымны иеп, гарьлегемнән кызарып чыгып киттем. Нигә генә директорга кердем, дип, үземне битәрләдем. Ишекне япкач та, директорның тынычлана алмый кычкыруы колакка ачык ишетелде:

– Кайчан гына котылам инде шушы бәндәләрдән. Тәмам арыттылар бит. Сәрхуш әти-әнисенә кирәкмәгәннәрне мин карарга тиешмендер шул... Бар белгәннәре – теләнү. «Апа, шул кирәк, апа бу кирәк», дип ашап баралар. Кайчан гына өннәре тыгылыр икән...

Болай булгач, директордан тасмага акча өмет итеп булмый. Халык алдында гарьлеге ни тора! Ничек тә берәр әмәлен табарга кирәк. Шушы уйлар төнен дә тынгылык бирмәде. Их, каян гына табарга икән шул йөз сумны?

Башыма бик шәп уй килде әле! Әһә! Таптым! Аскы урамда бер абый тимер-томыр җыя. Ә авылда алар урам тулы. Бүтән малайларның аңа тимер ташыганын күргәнем бар. Минем кулдан килмимени? Әгәр шуларны җыеп алып барсам, тасма өчен акча кесәмә үзе кереп ятачак.

Иртәгесен мәктәптән соң авыл буйлап чыгып киттем. Безнең малайлар тимер кабул иткән теге абыйга нәрсәдер алып барган. Соңыннан акчасына тәм-том алып, мактанып йөриләр иде. Менә хәзер үзем дә шул эшне башкармакчымын. Ә тимерне каян алырсың дип уйлыйсызмы? Авыл урамыннан үтсәм, елга буен караштырсам, табылыр әле. Кемгә кирәк соң ул эшкә ярамаган калай? Ә минем өчен зур табыш. Малайлардан шул шөгыль турында бераз сораштырып та алган идем. Баксаң, ул тимернең ике төре бар икән. Тәүгесе «кара металл» дип атала. Күпчелек тракторлар, йорт кирәк-яраклары шуннан эшләнә. Тагын «төсле металл» дигәнен җыялар. Анысы исә сирәгрәк очрый: алюминий, бакыр, латунь. Әле шул «кара металл» табарга йөрүем.

Шул уйлар белән елга буена киттем. Ару гына араны үттем. Караеп яткан нәрсәләрне күрсәм, су эченә үк кереп карадым. Тик юньле әйбер табылмады. И, нигә гел шулай икән? Кирәкмәгән чакта тимер-томыр юлда аунап ята, ә эзли башласаң – тапмыйсың.

Әле вакыт бар: мөгаен, буш кул белән кайтмамын. Кешеләрнең бакчалары буйлап киттем. Йә берәр консерва очрый йә сынган көрәк. Алардан гына нәрсә чыга инде? Берәр авыррак әйбер табарга иде. Көтмәгәндә, калайлар өеменә юлыктым. Күрәсең, кемдер өй түбәсен алыштырган да искеләрен чыгарып ыргыткан. Ничек җайлы булды әле! Аларны матур итеп кенә бер-берсенә салдым, шуннан төреп куйдым. Таралмасын өчен, бау белән бәйләдем. Менә бит, тырышсаң була! Мондагы бөтен калайларны да берьюлы алып китүе мөмкин түгел, шуңа көчем җиткәнче алдым. Монысын илтеп тапшырырмын да, тагын килермен әле! Тик берәү дә күреп калмасын.

Төрелгән калайларны күтәрдем дә теге кабул итүче абый ягына юнәлдем. Кешеләр күрмәсен өчен, урам буйлап бармыйм, арткы очтан атлыйм. Әгәр берәр таныш кеше күреп калса, оятыңнан ят та үл! Унбиш кило чамасы иде бу йөгем. Килосы бер сум торса, унбиш сум кесәгә кереп ятачак. Шуннан тагын барырмын.

Көч-хәл белән теге йортка барып җиттем. Капканы шакыдым. Эте өргәнгә хуҗасы килеп чыкты:

– Нәрсә кирәк? – диде ул, җитди генә.

– Абый, менә металл алып килдем. Сезне кабул итә, диделәр, – зур эш башкаргандай, ышаныч белән әйттем.

Теге абый калайларны күрде дә елмаеп җибәрде:

– Юк, энем. Мондый нәрсәне ала алмыйм. Миңа калын металл кирәк. Ә калайның файдасы юк.

Көтелмәгән җаваптан аптырап калдым:

– Ә нигә, бу да тимер түгелме соң? – дидем.

– Тимер дә ул. Тик аның сыйфаты түбән. Кабул итү пунктында шундый шарт куялар. Так что, ала алмыйм...

Шатланып, зур планнар корып килгән идем, кинәт барысы да юкка чыкты. Җитмәсә, ерактан күтәреп йөрдем шуны! Ә хәзер аны нишләтим?

− Сезгә калдырып китим. Бәлки, кирәге тияр, – дип, «сыйфатсыз» йөктән котылу ягын карадым. Бу сүзләр абыйны куандырмады.

− Юк, юк! Кирәкми, − дип кырт кисте ул. – Чүп-чарыңны монда калдырма. Алып барып ташла.

Хәзер инде тагын да авыррак булып тоелган йөкне алдым да килгән якка юнәлдем. Башка чара калмады. Көнем бушка үтте.

Детдомга кайтып кергәндә, караңгы төшкән иде. Яман нык арылган. Җитмәсә, шултиклем ачыктым! Шуңа да иң тәүдә аш бүлмәсенә йөгердем. Мөгаен, миңа дигән аш, суынган булса да, өстәлдә торадыр. Булсын, суык дип сайланып тормам. Ичмасам, эчемә берәр төен төшсә дә, күңел күтәрелеп китәр.

Ул көнне дежур Гәүһәр савыт-саба юып йөри иде. Карыйм: өстәлдә бернәрсә дә юк. Ахырда:

− Минем өлешне әллә алып куйдыңмы? – дип эндәштем.

− Тагын да соңрак килергә кирәк иде! – дип кырт кисте дә Гәүһәр, берни булмагандай, эшен дәвам итте.

Ач кешенең ачуы яман, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән. Кызның сөйләнүенә җаным көйде дә соң! Ничек килештереп тора! Әллә кем дип әйтерсең. Тәрбиячеләр сыман гына чирттерә. Кызып киткәнемне сизми дә калдым:

− Соңлап килүемдә синең ни эшең бар? Минем ризыгым торсын иде... Сиңа тиямени?

− Әллә, белмим! Әнә, тәрбиячедән сора! Син булмаганга ачуы килеп, ашыңны чиләккә түкте...

Берәр сынык икмәк калмаганмы икән? Ымсынып өстәл тирәсен караштырдым. Юк шул. Ач килеш йокларга ятудан башка чара калмады. Бер булмаса – булмый икән. Ни акча таба алмадым...

Иртәгә дә акча табу нияте баштан чыкмады. Тизрәк нәрсәдер эшләргә кирәк. Югыйсә, соңгы кыңгырау көнендә торырсың тасмасыз. Гарьлеге ни тора! Күрәсең, кичә минем нәрсә белән булышуым турында малайлар яхшы белә. Күргәннәрдер инде урамда. Бишенче төркемдәге Нил шулардан ишеткәндер.

– Ильяс, сиңа бик шәп нәрсә әйтәм, – дип башлады сүзен, күзләрен уйнатып. − Акча кирәкме?

− Кирәк тә ул...

Шул җавапны гына көткән Нил елмаеп җибәрде. Учын-учка сугып, сүзен дәвам итте:

− Алайса, бик җилле тәкъдимем бар. Колхозның гаражы кайда икәнен беләсеңме?

− Беләм... Идел буенда. Аскы урамда.

− Дөрес. Сиңа әйтер сер бар – тик бүтәннәр белмәсен! – Башкалар ишетмәсен диптер, егет пышылдауга күчте. – Гаражның эченә безнең төркем малайлары кереп караган. Уй-й-й, анда тимернең күплеге! Ул алюмин, ул бакыр… Тик торганнан баерга була!

− Тимер күп булса ни, аның хуҗалары бар бит, − дигән булдым.

− И бигрәк беркатлы икәнсең! Кемгә кирәк шул тимер-томыр? Әнә, бөтен авыл халкы шуннан ташый. Әйдә безнең белән бар.

Нилнең бу сүзләре сагайтып куйды. Ничек кенә булмасын, барыбер иясез түгел бит ул гараж. Каравылчысы да бар икәнен беләм. Икенче яктан, бу гамәлем турында белеп калсалар... Мәктәптә күзне дә ачтырмаслар. Җитмәсә, угры балаларны исәпкә кую турында ишеткәнем бар. Шуны белә торып, ничек урлашып йөрмәк кирәк?

– Куй, кулымнан килмәс. Үзегез генә барыгыз, – дип, котылу ягын карадым.

– Ки-и-т! – Нил ачуыннан җиргә лычкылдатып төкерде. – Шулкадәр куркак кеше булырсың икән! Берәрсе тотар дип шүрлисеңме? Бернәрсә булмый: кирәбез дә, алабыз да чыгабыз. Акча аяк астында ята. Мәктәп тасмасы гына түгел, әллә нәрсәләр алырсың әле. Авылдан бер малай тимер-томыр җыеп, велосипед алган, ди. Без кайсы җиребез белән ким?

Шуннан, зур хәстәрлек күрсәткәндәй, Нил кулын җилкәмә салды.

– Сине якын күреп кенә әйтүем инде. Детдомда башкаларга эндәшсәм, артымнан ябырылып барырлар иде. Ә син, исәр, инәлтеп маташасың...

– Әлләче, моңа тиклем алай итеп йөрмәгәч, рәтен-чиратын да белмим бит.

– Ну, тапкансың, баш ватар бәла! Ярый, беренче тапкырга син ишек төбендә торырсың. Өйрәнерсең. Ә акчасын сиңа да бүләрбез. Әллә тасма аласың килмиме?

И, шул мәктәп тасмасы дип хыялый булдым бит. Әле дә Нилнең шул сүзне әйтүе булды, йөрәк леп-леп итеп куйды. Соңгы кыңгырау көне җитеп килә шул. Ә акча таба алмасам? Ул чакта нәрсә буласын күз алдына да китерәсе килми. Нил дә яманлыктан шушындый тәкъдимне әйтмидер. Әллә барырга микән? Ишек төбендә генә торырсың, диде бит.

– Безнең белән барасыңмы-юкмы? Башка инәлеп тормыйм! – Нил кабаландырып куйды.

Бераз шым гына уйланып тордым. Урлашасы да килми, тасмасыз да калырга теләмим. И, ни булса да булыр, дидем дә ризалаштым.

Эңгер төшкәч, шул гараж ягына юлландык. Мин, Нил һәм тагын өч малай идек. Ару гына араны тын гына бардык. Детдом артта калгач та, Нил тәмәкесен борхылдатып җибәрде.

Без аның белән әллә ни аралашкан кешеләр түгел. Ул минем елгы, тик ике класска түбәнрәк укый. Мәктәптә әллә ни яхшыдан укымый. Аның төрле мутлыклары, качып йөрүе хакында барысы да белә. Шуңа дуслашасы килмәде дә. Ә менә хәзер мин аның белән урлашырга китеп барам. Урлашырга! Шуны аңлап, үземә оят булып китте. Бәлки, берәр башка урында тимер-томыр бардыр? Нәкъ гаражга төшәргә димәгән бит.

– Ә башка җирдә төсле тимер юкмы соң? – дип сорап куйдым юлдашымнан.

Нил авызын кыйшайтып елмайды. Аннан, миңа текәлеп:

– Ба-а-ар! – дип сузып әйтте ул. – Агач башында!

– И, шаяртырга дисәң, сиңа куш инде.

– Бер дә шаярмыйм. Детдом артындагы каенлыкка барсаң – алюмин туптулы. Һәр агач башында диярлек...

– Юкны сөйләмә! Аны агач башына кем ташыган соң?

Нил, әллә акыллы күренергә тырышыпмы, әллә белгәнен җиткерергә теләгәннәнме, тавышын көчәйтте дә, сүзен дәвам итте:

– Үзең син, Ильяс, бернәрсә дә белмисең. Һәр агач башына кеше тимер ташып йөрмәс инде. Ә менә саесканнар ташый. Алар оя кора. Ояларында алюмин күп була. Үзем күрдем.

Нилнең сөйләгәнен ишеткәч, кызык булып китте. Артабан сөйләвен сорадык. Хәзер бар игътибар аңарда иде.

– Шуннан, шуннан? – дип төпчендe малайларның берсе. Әйтерсең, безнең алдыбызда икеле капчыгы түгел, ә заман батыры басып тора!

– Саесканнарның тимер-томырдан оя коруы турында өлкәннәрдән ишеткәнем бар иде. – Нил кабаланмый гына сөйли. – Ул кошның ялтыр-йолтыр җыйганы турында күп сөйлиләр. Хәтта берәү аның оясыннан алтын

балдак та табып алган! Миңа да кызык булып китте. Үземнең төркемнән ике малайны ияртем дә, киттек урманга. Көз көне иде. Чынлап та, каен башында оялар күренә. Тик анда менәргә кирәк. Ни аста ботаклары юк. Агачны кисеп тә төшерергә мөмкин, тик пычкыбыз юк. Авылга килеп, электрик абыйдан пычкы сорап алдык. И, кисәбез моны, и, кисәбез. Тиргә батып, хәлсезләнеп беттек. Ял итәбез дә, тагын эшкә тотынабыз. Ару гына вакыт этләнгәч, теге каен дөбер-шатыр авып китте.

− Ояда тимер бар идеме? − Малайлар түзми, тизрәк беләселәре килә.

− Бар, кәнишне! – Нил күкрәген киереп җибәрде. − Анысы гел алюмин чыбыклардан тора иде. Тиз генә җыеп алдык. Ару гына чыкты. Тик бер килога җитми.

− Шуннан аны нишләттегез?

− Бүлдермәгез! – Нил, кинәнеп, күргәннәрен сөйләде. − Бер агачны еккач, кыздык та киттек. Икенче каенга бардык. Аны да кисә башладык. Күпмедер вакыт этләнә торгач, ул да гөрселдәп җиргә ауды. Тагын тимерен җыеп алдык. Тагын бер каенны кисеп ташладык! Ну, тимерне җыйдык кына! Башкалар ничек шуны белми йөргәннәр икән? Акча бит – баш очында!

− Алай булгач, акчаны күп эшләгәнсездер? – дип сорашам «тимер патшасыннан». Нил тынып калды:

− Эшләде сиңа! − Ул авыр көрсенде дә кул селтәп куйды. − Лесник килеп чыкты да бөтен планны бозды. Каян белеп калгандыр ул? Әллә сагалап йөргән. Хәзер милициягә алып барам, ди. Ну, кот очты. Пычкыны шунда ук тартып алды. Пакетка салынган тимер-томырны да алды. Ярый, җиңел котылдык әле. Башкача алай итеп йөрү юк.

Нил сөйләп бетергәннән соң, бераз шым гына бардык. Гараж да якында гына иде. Барысы да яхшы килеп чыкса ярый да ул. Анда якынлашкан саен, йөрәк дөп-дөп тибә. Хәерлегә булсын.

Тәүдә тимер киртә аша сикереп, колхоз биләмәсенә кердек. Шуннан гаражның зур ишеге астыннан шуышып эчкә үттек. Нил бөтенебездән алда йөри, берәр нәрсә әйтәсе килсә, йә ымлай, йә кулы белән ишарәли. Эчтә иске трактор тора, төрле запчастьләр тулып ята. Кергәч тә, нәрсә эшләргә белми, ишек төбендә торып калдым. Малайлар уздырыштан эшкә тотынды. Кемдер тракторны актара, ә Нил бөтенләй өскә менеп китте. Маймыл кебек үрмәләде дә озын кабельне суыра башлады. Мин генә аптырап тик торам.

− Ата-а-с! – Кемдер яман кычкырып җибәрде. Йөрәк жу итеп калды. Куркыныч килә, качыгыз дигәнне аңлата ул сүз. Нил шулай дип алдан ук әйтеп куйган иде. Күз ачып та өлгермәдем − әле генә тимер җыйган малайлар юк булды. Алар яшен тизлеге белән, фырт-фырт итеп, тәрәзәдән чыгып качты. Шул тәрәзәгә үрелеп карадым да тик менә алмадым. Тегеләй дә маташам, болай да – килеп чыкмый. Күтәрелергә көчем җитми. Ә ишекнең йозагын шыгырдатып кемдер ача башлады! Бетте болай булгач. Ялгызым гына камауда торып калдым. Күрәсең, каравылчы бурларны шәйләп алган. Нәрсә эшләргә? Шунда ук башка бер уй килде: гаражның теге як очында ике бүлмә бар. Шунда яшеренергә! Юкса, тотып алса, каравылчы баштан сыйпамас.

Бер абый, гаражның зур ишеген ачып, эчкә керде. Мин кече генә бүлмәнең ишек артында качып торам. Ул нәрсә эшләгәнне күрмим, әмма нык итеп сүгенгәнен, такылдап йөргәнен яхшы ишетәм. Йөрәк яман нык дулый. Калтыранам. Ходай ярдәм итеп, җиңел котылсам ярар иде.

Тук, тук... Тавыш бу якка килә. Әһә, менә ул якында гына. Һәр адымын, тын алышын шултиклем сизәм. Куркуымнан кычкырып җибәрмим, дип, үземне тынычландырырга тырышам. Каравылчы гараждан чыгарга уйламый да. Нәрсәдер эзли. Тук, тук, тук... Менә ул минем янымнан гына үтә. Бүлмәгә кермәсә ярар иде! Ул тагын якынлашты. Әһә, бүлмә яныннан үтеп китте! Тик иртә куанганмын икән. Кинәт ул туктады. Кире килде. Бүлмәгә керде дә ишек артына үрелде! Безнең күзләр очрашты!

− Ах, чукынчык, менә син кайда! – Сакчы көрәк кебек куллары белән якамнан тотып алды. Буыннарым җебеп төште.

− Ми-мин-мин ти-мә... – калтыравымнан әйтер сүземне әйтә алмадым. Тәнгә эссе булып китте. Баш әйләнә. Харап булдым бит!

− Шым, дидем, тварь! – Абый зур йодрыгы белән башыма тондырды. Күз алларым караңгыланып китте. − Монда нәрсәңне карап йөрисең, ә? Хәзер күрсәтермен инәңне...

Каравылчы мине, җилтерәтеп, үзенең постына алып китте. Юлда качарга теләгәнемне сизеп, кулымнан каерып тотып алды. Бәләкәй генә бүлмәсенә керткәч тә, аркама тибеп җибәрде.

− Утыр, дидем! – Ачуыннан шашкан ир утыргычка күрсәтте. Утырдым. Башым иелде. Аның күзенә карарга да куркам. Хәзер нәрсә эшләр икән?

− Син детдомныкымы? – диде кычкырып. Әйе, дигәндәй, баш селектем. – Беләсеңме, сездән күпме этлек күрдем! Гаражны вич урлап бетереп баралар, этләр!

Ир нәрсәдер хакында озак җикеренде, өстәлгә шапылдатып, суга-суга, мине әрләде. Нәрсә дигәнен куркуымнан онытып та бетердем. Тәүдә ничә яшь икәнен сорашты. Аннан минем алдыма кәгазь кисәге, ручка салды:

− Үзеңнең әшнәләреңнең исем-фамилияләрен шушында тезеп яз! Иртәгә сезнең белән милиция сөйләшер!

Тагын котым очты. Ничек язарга соң аларны? Әгәр исемнәрен тезеп язсам, кайткач, теге малайлар кирәгемне бирәчәк. Язмасам, бу абый иманымны укытыр. Күрәләтә үзебезнекеләрне сатасы килми, әләкләүче дигән даным чыгуы бар. Ручканы кулымда әйләндереп утырганымны күзәтеп, абый түзмәде, янә берне тондырды. Иренемә эләкте. Өстәлгә кан чәчрәде.

− Язасыңмы, юкмы? Хәзер үзеңне милициягә алып барам! – дип янады ул.

Хәзер үземне Ильяс Мөхәммәтов дип язсам, бөтен мәктәп беләчәк. Ояты ни тора! Нилгә дә, аның ярдәмчеләренә дә эләгер. Шулчак башка бик шәп уй килде! Сакчыны алдарга! Детдомда бөтенләй булмаган исемнәрне күрсәтергә!

Калтырана-калтырана язарга тотындым. Үземне «Илдар Мәхмүтов» дип күрсәттем. Нилнең исемен Варис дип яздым. Фамилияләрен дә алдап яздым. Ничек җиңел килеп чыкты! Хәзер кайтарса, котылам бит бәладән. Ә азак Илдар исемле малайны эзләп карасыннар!

Каравылчы исемлекне алды да игътибар белән укып чыкты. Берчә миңа ачулы караш ташлады, берчә кәгазьгә текәлде. Шуннан телефонга үрелде!

− Сез жуликларга ышанып булмый! Детдомга шалтыратыйм әле. Алдашмыйсыңмы икән?!.

Ай, Аллам! Нигә генә ризалаштым икән? Хәзер абый шалтыратса, алдаганым өчен, кирәгемне бирер инде! Йөрәк күкрәкне ертып чыгардай тибә. Елап җибәрмим дип, үземне чак тыеп утырам. Ул детдомның саннарын җыйды да җавап көтә башлады. Шуннан трубканы ачулы итеп салды:

− Занято икән. Ничего, яңадан шалтыратып карармын.

Бер-ике минут шым гына сөйләшми утырдык. Бу минутлар минем өчен

елдай тоелды. Йөрәк тынгы бирми. Абый янә телефонга үрелде. Тагы теге саннарны җыйды. Эчтән генә, телефонны алмасалар ярар иде, дип теләдем. Каравылчы кабат трубканы ташлады:

– Корып киткереләр! Нигә шулай телефоннан озак сөйләшәләр икән?

Шуннан миңа текәлде:

– Ә син чынлап та Илдар буласыңмы?

– Әйе, чынлап.

– Теге егетләр дә дөрес күрсәтелдеме?

– Әйе.

– Ярар, алайса – югал күземнән! Иртәгә сезнең белән милиционер сөйләшер.

– Яшен тизлеге белән чыгып сыздым. Гараж территориясеннән чыккач, тын алуы җиңелләште. Юл уңае елгага төшеп, канаган битемне юып алдым. Ярый да җиңел котылдым. Ә телефонга җавап бирсәләр, андый малайлар бездә юк, дисәләр?! Мондый начар эшкә ияреп барганым өчен үземне әрләп бетерә алмадым. Менә шулай табыла икән җиңел акча!

Мәктәп тасмасы алуга өмет югалды. Кәеф юк, башкалар белән сөйләшәсе дә килми. Нигә, миңа дигәндә, гел киресенчә килеп чыга икән?

Беркөн мәктәптән кайтып килгәндә, безнең детдом завучы Насыйха апа белән сөйләшеп киттем. Ул шундый ачык, ихлас кеше. Белемле, итагатьле булганы өчен, аны авылда барысы да хөрмәт итә. Малае да тәртипле. Мәүлидә Нургалиевнаныкы кебек урамда эчеп-тузынып йөрми.

– Ильяс, нигә кәефсезләндең? – дип кызыксынды завуч.

– Мәктәп тасмасын ала алмыйм, – дидем. Бүтән кеше булса, бәлки, дөресен әйтеп тә тормас идем. Ә Насыйха ападан яшерәсе килмәде. Барыбер беләчәк.

– Бу турыда беләм, – диде ул. – Тик шуның өчен бетеренергә ярамый. Әйдә, сиңа акча биреп торам, – завучның бу сүзләреннән авызны ачып, аптырап калдым! Мин сорамадым бит, ә апа бирәм, ди. Күпме йокысыз төннәрем, тынгысыз көннәрем үтте шуны хәстәрләп. Ә хәзер шулай җиңел генә килеп чыксын әле.

– Сез шаяртмыйсызмы? – Аның әйткәннәренә һаман ышанып бетә алмадым.

– Юк, шаяртмыйм. – Насыйха апа башымнан сыйпап алды. – Акча килә дә китә ул, ә күңел ярасы мәңгегә кала. Тик, Ильяс, сиңа акча бирүем хакында берәүгә дә әйтмә. – Завуч кесәсеннән йөз сум чыгарды да миңа сузды.

Шатлыгымнан күккә күтәрелердәй хәлдә идем. Мәңге яшәсен инде Насыйха апа!

– Апа, зу-ур рәхмәт! Алла бирсә, сезгә бурычымны кайтарырмын, – дидем куанычымнан.

– Ярар, борчылма. Ә соңгы кыңгырауга сине карарга өчен киләм! Тасма килешер үзеңә!..

Соңгы кыңгырау бәйрәмендә миннән дә бәхетле кеше булмагандыр. Алып баручы микрофоннан безнең исемнәрне әйтә, ә без мәйданга чыгып басабыз. Халык алдына нindидер горурлык белән чыктым, чөнки мәктәпне яхшы тәмамладым. Икенчедән, чыгарылыш укучылары өчен тасма күкрәгемне бизи. Нигәдер барысы да шул тасмага караган төсле тоела иде. Еллар үткәч тә, иң кадерле мирастай шул тасманы саклап йөрттем.

...Берчак детдомга юлым төште. Сәбәбе дә бар: күп еллар завуч булып эшләгән Насыйха апаның юбилее иде! Кыен чакта изгелек күрсәтеп, канат куйган кешене ничек онытасың? Күптән аңа нindидер бүләк табу хыялы

белән янам. Менә вакыты да җитте. Чит илгә сәфәргә барганда, бер остадан үзе эшләгән ваза сатып алдым.

Шуңа матур имза салдым да тышыннан бәйләп куйдым. Мәктәптәге теге тасмам белән...

## Эпилог урынына

Сез бәләкәй чакта әкият яраттыгызмы? Әлбәттә, мондый сихри дөньяны үз итмәгән кеше юктыр җирдә! Мин дә әкиятне үлеп яраттым. Әгәр чак кына шуклансам, апам «бүген сине әкият тыңлатмыйбыз», дип куркыта иде. Беләм, һәр кич әнием матур итеп төрле әкиятләр сөйли. Кем үзен начар яктан күрсәтә, әнә шул кеше бу тамашадан мәхрүм була. Шуңа әллә ни котырырга, «җәза» алырга тырышмыйсың.

Эх, шул матур чорны искә төшерсәм, күңел җилкенеп китә! Булган бит тормышымда бәхетле көннәр... Әнигә бәйле ул хәсрәтсез мәлләр. Дөньяда күпме әкият бардыр – анысын белмим. Ә менә әнинең «сандыгында» алар иксез-чиксез. Шуңа кич җиттеме, аңардан әкият теләнә башлыйбыз. Караватны ян-яктан уратып алабыз да, нәрсә сөйләр икән, дип йотлыгып тыңлыйбыз.

– Булганнарын сөйләп бетердем инде, – дип аклана әни. – Йокларга кирәк.

Белеп торабыз, ул бүген арыган. Шуңа да «әкиятләр бетте» дип котылмакчы була. Ә без, ай-ваена карамыйча, үзебезнекен талкыйбыз. Болардан җиңел генә котылып булмастыр, дип инде, әни әкият йомгагын сүтәргә тотына. Шултиклем тәмләп торып сөйли. Әйтерсең лә үзең шул патшалыкта йөрисең, үзең явыз диюләр белән алышасың, үзең бахыр төлкене коткарышасың...

Тик әни бер әкиятен сөйләп бетерсә, шунда ук ятарга ашыкмыйбыз.

– Тагы берәр әкият сөйлә инде, – дип аптыратабыз.

– Юк, балаларым, хәзер әкият тә йоклый, – дип юата ул.

– Ничек инде йокласын, әле күпләрнең уты сүнмәгән. Әнә күрше Юнирнең әнисе әле сөйлидер...

Ахырда әни тагын берәр кыскарак әкиятне сөйли. Без тагы авыз ачып, һәр сүзен йотып тыңлыйбыз. Тик анысы бетү белән, әни яраткан сүзен әйтеп сала:

– Бүгенгә җитеп торыр. Әкияткә дә ял кирәк. Әгәр аны күп сөйләсәң, кыш озын булачак...

Шул әкиятле көннәрдән генә торса иде тормыш... Әниебез безнең арадан киткәннән соң, әкият тыңлаганым булмады. Нык сагындыра шул мәлләр.

***

...Детдомда минем белән бергә үскән дусларымның язмышы сезне кызыксындырадыр. Тормыш нык үзгәртте шул аларны. Кемнәрдер бәхет тавына күтәрелде, икенчеләре тормыш упкынына тәгәрәде.

Мәүлидә Нургалиевна... Балалар йортында ул хәзер эшләми. Моның сәбәбе дә бар. Җәйге ял мәлендә директор, гадәттәгечә, элек тәрбияләнеп чыккан бер «башлыкны» лагерьга вожатый итеп җибәргән. Анысы Уфада ташчыга укып йөргән икән. Вожатый балаларны көн дә интектергән, бүтәннәр алдында мыскыл иткән. Көннәрнең берсендә, йоклар алдыннан, бер малайга үзе өчен җырларга кушкан. Тик малай җырны матур итеп башкара алмаган. Моның өчен «тәрбияче» бахырны тукмап ташлаган. Кемдер вожатыйның бу гамәлен видеога төшереп, интернетка куйган. Китте шау-шу... Телевизордан да, радиодан да көне буе шул турыда сөйләделәр. Детдомда тикшерүләр башланып, директорга

һәм кул күтәргән егеткә карата җинаять эше ачыла. Бик күп җитешсезлекләр ачыклангач, Мәүлидә Нургалиевнаны эшеннән җибәрделәр.

Әмилә... Классташым белән һәрчак горурландым. Аның һәрвакыт үз сүзе, үз максаты булды. Кемгәдер ошарга тырышып, ялагайланып йөрмәде. Әгәр ниндидер гаебебез табылса, җаваплылыкны бергә күтәрдек. Тугызынчы класстан соң училищега – тегүчегә урнаштырган иделәр. Аны яхшы укып бетерде, әмма тукталып калмады. Үз теләге белән университетка укырга керде. Хәзер Әмилә Уфада яши, аралашып торабыз. Матур гаилә корды. «Мин күргән михнәтләрне балам күрмәсен. Шуңа тырышам», – дигән иде ул бер очрашканда.

Нил... Кайчандыр аның белән гаражга тимер-томыр урларга йөргән идек. Шунда тотылгач, бүтән беркайчан да урлашмыйм, дип үземә сүз бирдем. Ә Нилгә бу шөгыль ошап калган, күрәсең. Калада укып йөргән чакта, бигрәк әвәсләнеп киткән, диләр. Көннәрнең берсендә кибеткә төшкән, кассадан ару гына акча чәлдергән. Моның өчен, әлбәттә, башыннан сыйпамадылар, төрмәгә яптылар...

Дим... Хәтерлисездер, Даян белән икәүләп әтиемнән калган каешны тартып алган иделәр. Кем генә ялгышмый инде. Ул да шул Даянның коткысына бирелеп, аның уңаена йөрде. Димне дә детдомнан соң училищега укырга керттеләр. Болай тәртипле генә укып йөрде. Ятимнәргә дип бирелгән пенсия аларның махсус исәбенә җыела. Балалар йортыннан чыгып, унсигез яшь тулгач кына, аны кулланырга була. Димнең дә исәбенә ару гына җыелган булган. Барып тикшертсә, ике йөз меңнән артык акчасы ята! «Тиздән бай булам! Киләсе айда унсигез яшем тула, шунда кулыма ике йөз мең сум алачакмын!» – дип, тулай торакта барысына да сөйләп йөргән. Соңгы тапкыр аны банкка китеп барганда күргәннәр. Җиде ел үтсә дә, Димне бүтән очратучы юк. Хәбәрсез югалгач, эзләп йөрүче туганы да таба алмады.

Динар... Җәйге лагерьда «бурны» эзләп табучы шул иде. Тормыш аның да башыннан сөеп тормады. Калада укып йөргәндә, бер иргә кереп бәйрәм иткәннәр. Нык исереп алгач, фатир хуҗасы белән талашып киткәннәр. Ике егет хуҗаны үтергәнче тукмаганнар. Шуннан мәет яткан фатирны бикләп чыгып качканнар...

Динар һәм аның әшнәсен унбишәр елга ирекләреннән мәхрүм иттеләр. Алия, Алсу, Зөлфирә... Бөтен туганнарым белән аралашып торабыз. Аларның өчесе дә шәһәрдә яши, һәркемнең үз дөньясы бар. Алия апам – өч бала әнисе, Зөлфирә сеңлем ул үстерә. Һәрхәлдә аларның бүгенгесе өчен шатланам. Гаиләбездә һәркем үз урынын тапты.

Бер түбә астында яшәп, бертөрле кием киеп, бер үк ризык ашап үстек. Тик безне язмыш нигә төрле якка борды соң?

Безнең төркемне генә алыйк. Егермегә якын бала идек. Кыска гына вакыт үтте. Шул арада дүртесе якты дөньядан китеп барды. Ә сигезе – тимер рәшәткә артына эләкте...

Аларны уйласам, күңел сыктый, тамакка төер тыгыла. Нигә тормыш шундый мәрхәмәтсез булды? Болай да авырлыкта үскән дус-ишләремнең язмышлары нигә шулай кыйралды икән? Нигә?! Бәлки, бәләкәй чакта әкият тыңлап үсмәгәнгәдер?..



Лилия
Фәттахова

# МӘСӘЛЛӘРДӘН ГӨЛӘНДӘМ

## Көтү хәлләре

Сарык көтүенә ияләшкән Бүре,
Әйткән тинтәк малның өркәклеген күреп:

«Берсен ботарлыйсың – башкалары кача.
Һичбер каршылык юк – көн дә берне аша!»

...Сарык сарык инде! Көтүчесез – харап...
Тәк ияреп йөри, камчы-кулга карап.

И сөенә булыр, Яклаучым (!) дип тоеп,
Бергәлектәме эш, миең булса сыек?!.

## Тигезлек

Ике чүмеч эленеп торган гел янәшә.
Берсе – гади аш чүмече, берсе – затлы:
Сырлап-бизәп, матур итеп эшләнгән ди,
Карап туймаслык зиннәтле, сөяк саплы!

Әйткән берчак затлы чүмеч, һаваланып:
– Синең белән рәттән тору оят миңа.
Хезмәтчедәй чабулыйсың кабаланып,
Минем даирәм – мәртәбәле кунак кына!

Гади чүмеч тыйнак кына көлемсерәп
Тыңлаган да күршесенә җавап биргән:
– Аерыммы, минем белән янәшәме,
Син дә бары аш бүләсең, кабәм, – дигән.
...................................................................
Үз-үзеңә читтән карау муафыйк эш:
Биегерәк үрмәләсәң, егылмый төш...

---

Лилия ФӘТТАХОВА (1972) – *шагыйрә; «Танырсыңмы?..» дигән китап авторы. Чаллыда яши.*

## Кайсы яхшырак?

Күзе ачылган песи баласына
Мәгърур Арысланны күрсәткәннәр:
– Арысланнар – синең ырудаш ул,
Тик саграк бул, – диеп кисәткәннәр.

– Күрәсеңме, күз карашы нинди?!
Җәнлекләрнең падишаһы мин, ди.
Утыруын кара, торышларын,
Җиңүчедәй муен борышларын!..

Нәни песи, хәвеф-мазар сизми,
Алпан-тилпән киткән аңа табан.
Арыслан тик берне ыр-р-лап куйган –
Һушын җуйган безнең песи-олан.

Исен җыеп, куркулары узгач,
Зурлар кебек уйлап куйган ди ул:
– Мин беркайчан болай усал булмам,
Читлекләрдә тормам, – дигән ди ул.

## Алдавыч сөенеч

Әйләнмәле читлек-тәгәрмәчкә
Керткәннәр ди җитез тиенне.
Уен-тормыш кызык тоелганмы, –
Тиен сөенечкә тиенгән!

Тәгәрмәчне әйләндергән өчен
Җылы кулдан азык аласың!
Ләкин менә... белмәгән шул тиен
Бик озакка шунда каласын.

...Йөгерү түгел, аяк атларга да
Хәле беткәч, арып егылгач,
Чыгарырлар аны бу читлектән:
Ярымтере булыр, ярымач.
............................................
Ә тәгәрмәч барыбер туктамас ул...

## Соңарган үкенеч

– Сезгә кадәр өй түрендә иде урыным,
Хуҗам өчен бер сөйкемле сөяк идем, –
Дигән Мәче үзен баскан борчаларга. –
Каян гына сездәй әрсезләрне күрдем?!

– Без түгел лә, үзең безне эзләп таптың,
Ахры, пакьлек-чисталыктан туйган идең! –

Шулай диеп сөенешкән яңа дуслар.
...Азган чирү азгынлыкны тойган инде.
.............................................................
Кадер-хөрмәт күрим, дисәң, бу тормышта,
Нәфес-шайтан коткысына бирешмә син.
Кулың чиста, күңелең чиста, исемең чиста! –
Бет-борчалар теләгенә ирешмәсен.

## Һәр теләкнең ахыры хәерле түгел

Колач җитмәслек кәүсәле бер Агачның
Зураюдан, ахры, бераз «башы киткән»:
– Бу ботаклар, бу яфраклар нигә миңа?
Үзагачым исән булса, шул да җиткән...

Туктаткан ул тамырлардан килгән дымны.
Ботак-яфрак корыр, дигән, туенмагач.
Күп тә үтми, зәгыйфьләнгән ябалдашы –
Һәм... кискәннәр, хәлсез инде, дип, бу Агач.
..................................................................
Бер үк Кояш асларында, бер туфракта
Яшим дисәң, комсызланма! Урын җитә!
Күбрәк алсам – баермын, дип уйлый күрмә,
Күбрәк бирсәң – зуррак әҗер сине көтә.

## Хакыйкатьне эзләү

Әкәм-төкәм, Ташбака һәм Жираф
Бер заманны бәхәсләшеп киткән.
«Бу Җир – бишек очсыз-кырыйсызмы,
Әллә бармы аның берәр чите?»

– Минем уйлавымча, – дигән Жираф, –
Җирнең чите аның күккә тигән.
Тагын бераз тәпиләсәм әгәр,
Мин, мөгаен, барып җитәр идем.

– Син җүләрме? Ничек күккә тисен?
Җирнең чите аның – безнең урман.
Күпме яшим, күпме иңлим менә,
Җитәлгәнем юк бит әле һаман.

Шулай диеп олпат Ташбака да
Үз фикерен белдерәсе иткән.
– Ә минемчә, җирнең чите юктыр,
Чиксездер ул, – дигән Әкәм-төкәм.
.........................................................
Бер кырыйдан гына ишетеп алса
Бу бәхәсне әгәр Кеше заты:
– Җир – түгәрәк, – дияр иде кебек,
«Яссы» диеп ялгышканын онытып...

## Уйлап сайла

– Мин алтынга бихуш, – дигән бер яшь сылу, –
Малы булса, шайтанга да яр булырмын.
«Амин» дигән чакка туры килеп, моңа:
Күзе төшкән карт кына бер җанкыярның.

Алтын-көмеш  сылукайның ушын алган.
Вилла, яхта, хезмәтчеләр, шәп машина...
Бизмәненең тәлинкәсе төшкән аска:
Яшьлеге һәм чибәрлеген байлык баскан.

Җанкыярның үз дәүләте – үз кануны:
Һәр кешегә дәрәҗәгә тиң урыны.
Яшь сылуга да урынын күрсәткән ул,
Һәм кирегә юл юклыгын кисәткән ул...
............................................................
Бу дөньяның эте дә бар, бете дә бар.
Ходай биргәч, агы да бар, карасы да...
Тормыш юлын сайлаганда, бизмәнеңә
Уйлап сал син ни саласы-аласыңны.

## Тынычлыкка ни җитә

Бу – Сарыкның утлап йөргән җире иде,
Ул тынычлап шунда гомер сөрә иде.
Тик бер көнне җирдән чишмә тибеп чыкты,
Шул көннән соң монда тәмам мәхшәр купты.

Әллә каян килеп тапты Дөясе дә,
Килеп җитте Айгыры да, Биясе дә.
Дуңгызына чаклы монда ияләште,
Килгән бере, үҗәтләшеп, җир бүлеште.

...Хәзер монда бай утлауның эзе дә юк.
Актарылган, туздырылган чишмә-арык.
Ни «ә», диеп, ни «бә», диеп әйтә алмый
Коты очкан, гаҗизләнгән мескен Сарык.
............................................................
Көчленеке бу замана, дисәләр дә,
Хәрам малдан әле кем соң рәхәт күргән?!
Күрше малына ымсынмый яшәп кара:
Үз азыгың үзеңә, дип, Күктән бүлгән.

# ЛИЛИЯ ФӘТТАХОВА. МӘСӘЛЛӘР

Бүген татар әдәбиятында бик күп традицион әдәби жанрларның икенче сулыш алуы, яңа тормыш белән яши башлавы күзәтелә. Жанрның яки жанр формасының, күпмедер вакыт әдәбият мәйданында югалып торганнан соң, яңа югарылыкта яшәп китүе дә (әйтик, нәсер, кыйсса, бәян, мәдхия, кыйтга, театраль роман, антиутопия һ.б.), яки чыганак-жанр белән бәйләнештә яңа модификациясе тудырылу (икенчел текстлар: дога, сыктау, робагый, газәл, зөһед һ.б.) да – ике гасыр чиге милли сүз сәнгатебездә әдәби иҗатны үзгәртү-баету юлы кебек кабул ителә.

Бер үк вакытта кайбер жанрлар өлкәсендә торгынлык та сизелә. Әйтик, рус әдәбият белемендә хәзерге заманда мәсәл жанры кирәкме-юкмы дигән бәхәс тә булып узды. Әлеге сөйләшүдә катнашучылар әдәбиятта бик борынгыдан мәгълүм бу жанрның, совет чорында социаль заказга бәйле шактый актив күтәрелеш баскычын үткәннән соң, постсовет әдәбиятында үз вазифаларын башка жанрларга (кечкенә юмористик-сатирик хикәяләргә, анекдотларга, шигырьләргә, тапкыр фразаларга, мәзәкләргә һ.б.) тапшыруы сәбәпле, тарихи жанр булып кала баруы турындагы нәтиҗәгә киләләр. Мәсәл жанры үсешендәге өзеклек татар әдәби барышында да сиземләнә. Әмма интернеттагы шәхси сайтларда башлап язучыларның массачыл әдәбият күренеше буларак бәяләнерлек мәсәлләрен шактый очратырга мөмкин.

Менә шундый бер вакытта журналның 9 мәсәл текстын берләштергән гөлләмә тәкъдим итүе – көтелмәгән матур күренеш, әлбәттә. Алдан ук әйтеп куярга кирәк – Лилия Фәттахованың мәсәлләре өлгергән каләм белән иҗат ителгәннәр.

«Көтү хәлләре» дип исемләнгән беренче текст классик мәсәлләргә куела торган барлык таләпләргә җавап бирә: аллегорик образлылыкка корылган (сарык көтүе, көтүче, бүре); мөһим бер күренешне күз алдына китереп бастыра – сарык көтүенең хокуксыз да канәгать кенә гомер сөрүен сөйли; мораль чыгарыла: аны акыл һәм инициатива булмаса, берләшеп тә максатка ирешеп булмый кебегрәк шәрехләргә мөмкин.

Асылда, дөнья әдәбиятында җәмгыятьне сарык көтүе белән чагыштырып, кешеләрнең әйдаманга карап торуыннан көлеп, уннарча сатирик мәсәл язылган. Әмма бу очракта авторның уңышы – соңгы тезмәдә *«Бергәлектәме эш»* фразасын куллануда булып чыга. Әлеге фраза заманыбызның иң билгеле өндәмә-шигарьләреннән саналган «Бергә булыйк – бердәм булыйк» белән ассоциация уята, аны кире кага. Нәтиҗәдә, эчтәлек актуальләшә, әсәр бүгенге татар җәмгыятенә сатирик бәя булып яңгырый.

Икенче текст – «Тигезлек», Г.Тукай тәрҗемә иткән «Баскыч»ны да хәтерләтә. Гади чүмечнең борынын күтәргән бизәклесенә җавабында һәр язмышның, һәр кешенең, асылда, бертөсле булуы әйтелә. Автор исә мораль өлешендә сатирик мәсәл юлын сайлый: аерым бер кешедәге «биегрәк үрмәләү» сыйфатын тәнкыйтьли. Гәрчә моральне фәлсәфи якка борганда, текст күпкә кызыклырак төс алырга мөмкин иде. Бу очракта ул XX йөз башында яки 1920-1930 елларда иҗат ителгән татар мәсәлләреннән аерылмый.

Гомумән алганда, мәсәлләрнең өч: сатирик, дидактик, фәлсәфи жанр формасы аерып билгеләнә. Галимнәр совет чоры әдәбиятында фәлсәфи төрнең махсус юкка чыгарылуын искәртә. Татар әдәбияты мисалында без сатирик мәсәлләрнең – эзоп теле (мәсәл теле) ярдәмендә асмәгънәле, яшерен эчтәлекле шигырьләр рәвешендә яши башлавын Г.Афзал иҗаты мисалында күрәбез.

Татар әдәбиятында фәлсәфи мәсәлләрнең аерым үрнәкләре язылса да (Ә.Исхак, Г.Афзал, М.Әгъләмов һ.б.), аларда фәлсәфи фикерне иҗтимагый-сәяси тәнкыйть белән үрү алга чыга. Бу очракта да шушы күренеш күзгә ташлана. Әйтик, «Кайсы яхшырак?» мәсәлендә (гөлләмәдәге иң кызыклы текстларның берсе!) песи баласының *«Мин беркайчан болай усал булмам, / Читлекләрдә тормам»*, диюе фәлсәфи яссылыкта да, иҗтимагый-сәяси яссылыкта да шәрехләнә ала. Беренче очракта ул көчсез кешенең һәрвакыт үз көчсезлегенә аңлатма, аклану таба алуына ишарә ясый. Соңгы строфадагы

*«Зурлар кебек уйлап куйган»* фразасы бүгенге җәмгыятьтәге куркаклык, эгоизм кебек сыйфатларга тәнкыйть рәвешендә яңгырый. Текстның ике төрле укылыш варианты булу – татар әдәбиятында мәсәл жанры өчен яңа һәм перспективалы күренеш.

«Алдавыч сөенеч» мәсәлендә дә шулай. Тормышның кешене туктаусыз куалавы – яшәеш законы кебек тә, җәмгыятьтәге тәртипләргә нисбәтле дә укыла ала. Шул ук вакытта әлеге текстта мораль өлешен *(«Ә тәгәрмәч барыбер туктамас ул...»)* «язып бетерәсе» килеп кала. Тагын бер җөмлә табылган булса, ул, әлеге ике укылыш вариантыннан тыш, тагын башка мәгънәләргә дә юл күрсәтә алыр йә булмаса без тапкан вариантларны ныгытып куяр иде. Димәк, бу жанрдагы мораль өлешен текстларны катлауландыру максатында файдаланырга мөмкин.

«Соңарган үкенеч» мәсәлләрнең өченче, дидактик төренә карый. Эчтәлек «булганны – кадерләмибез, югалткач – үкенәбез» дигән фразага мисал була ала. Текстта укучыга юнәлтелгән дидактик нәтиҗә-мораль өлеше күренешне гомумиләштереп бәяли: *«Кадер-хөрмәт күрим, дисәң, бу тормышта, / Нәфес-шайтан коткысына бирешмә син. / Кулың чиста, күңелең чиста, исемең чиста! / Бет-борчалар теләгенә ирешмәсен».* Матур риторик эндәш, шушы мораль өлеше текстның стильләштерүгә якынаюы турында сөйли.

Дидактик мәсәл булган «Һәр теләкнең ахыры хәерле түгел» – һәм сәяси, һәм фәлсәфи яссылыкларда да укыла. Моңа аллегорик образларның (агач һәм кәүсәсе) аңланылыш варианты күп булу аша ирешелә. Нәкъ менә күптавышлылык (полифонизм) текстның өстенлекле ягы булып чыга. Әйтик, бүгенге телләр вазгыяте белән аваздашлыкта, ул сәяси көчле текстка әверелә. Фәлсәфи яктан – кеше яшәештә үзе биргәнне, үзе биргән кадәр генә башкалардан, тормыштан ала, дигән закончалык төсендә формалаша.

Әлеге күренешнең киресе – дидактик «Уйлап сайла», «Тынычлыкка ни җитә», «Сабак» мәсәлләре, аллегорик образлары да, эчтәлек һәм мораль дә бер юнәлештә укыла торган текстлар, яңалыгы булмау тәэсире калдыралар.

Фәлсәфи мәсәл – «Хакыйкатьне эзләү» – һәркемнең үз хакыйкате, асыл хакыйкать юк, дигән фикерне (дөнья мәдәниятендә моны Ницшега нисбәт итү яши) Әкәм-төкәм, Ташбака һәм Жираф мисалында иллюстрацияли. Мораль өлеше моннан нәтиҗә чыгарып кына калмый, бәлки кеше затына карата үзирония ярдәмендә фикерне тагын да үстерә: бер хакыйкатьнең икенчесе тарафыннан кире кагылуын, хакыйкать дип уйлаганның ялгыш булу ихтималын ассызыклый: *«Бер кырыйдан гына ишетеп алса, / Бу бәхәсне әгәр Кеше заты: / – Җир – түгәрәк, – дияр иде кебек, / Яссы, диеп, ялгышканын онытып...*. Шул рәвешле, бу очракта да эчтәлекне киңәйтүнең үзгә нәтиҗәле юлы табылган: сурәтләнгән күренештән чыга торган нәтиҗәне мораль өлешендәге фикер тулыландырып һәм төгәлләштереп кенә калмый, бәлки үзгә мәгънә өсти. Шундый ук күренеш «Алдану» мәсәлендә дә күзәтелә.

Шулай итеп, Лилия Фәттахова мәсәлләре мисалында билгеле бер гомумиләштерүләр соралып тора. Беренчедән, текстлар классик мәсәл жанрына куела торган таләпләргә җавап бирә, бу күренешне татар әдәби барышында мәсәл жанрының үсеше дәвам итү дип карарга кирәк. Икенчедән, әсәрләр укыла, һәм моңа аларның форма камиллеге: рифма-ритм төгәллеге, мәгънә ачыклыгы ярдәм итә.


Шул ук вакытта Лилия Фәттахова яки башка шагыйрьләр иҗатында мәсәл жанрының киләчәге турында да кайбер фикерләр белән уртаклашасы килә. Шиксез, бүген мәсәл жанры (яки теләсә нинди башка традицион жанр) кабат яңарып, актив үсеп китсен өчен, берничә шарт үтәлү кирәк: бу жанрга ихтыяҗ булу; жанр эчтәлегенең тематик һәм проблематик актуальлеге; авторның әдәби яңалык тәкъдим итә алуы.

Кеше холкында, тормышта, җәмгыятьтә тәнкыйтьләрлек, гыйбрәт алырлык, уйландырырлык сыйфатлар беркайчан да бетмәячәк. Жанрга ихтыяҗ, эчтәлегенең тематик һәм проблематик актуальлеге шуның белән билгеләнә.

Авторның яңалык тәкъдим итә алуы аның осталыгы һәм әдәби барышның гомуми торышын күзаллавы белән дә бәйле. Әгәр яңалык булмыйча, текст XIX гасыр яки XX йөз башы әдәбиятыннан күчереп куелган кебек тәэсир калдыра икән, ул массачыл әдәбият чикләреннән уза алмый. Лилия Фәттахова мәсәлләрендә яңалык эчтәлекне катлауландыру, берничә укылыш вариантына ия текстлар тудыру юлында табылган.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

Альберт
Хәсәнов



# КӘҖӘКӘЙ – МАТУР БӘЛӘКӘЙ

ХИКӘЯ

Берни эшләр хәлең юк, апаем, «Татнефть» геологлары чираттагы скважинаны менә бу җирдә бораулыйбыз, дип, энәле циркульләрен кая төртсә, бораулаучылар аны шул ноктада бораuларга керешә. Карабаш тавының, тәҗрибәле альпинистлар түгел, кыр кәҗәләре дә көчкә-көчкә үрмәли торган, иң текә төшенә туры килгән «БУ-75» бораулау вышкасын, хет нишлә, булмаса, телеңне тешлә, урынга утырта алмыйсың. Утыртсаң да дөмбердәп өстеңә авачак. Ә Чияле Тау вышкарьларына андый җирләр планетабызда гомумән юк төсле. Алар бит өлгерләр, һәр җирдә беренчеләр. Җир шарының кайсы гына почмагына – Иранга, Гыйракка, Әфганстанга, Бангладешка, Сүриягә, Мисырга, хәтта Һиндстан тарафларына да барып чыгып, һәркайсы үзенә һәйкәлгә тиң бораулау вышкасы куйган кешеләр.

ВМКның вышкарьлары, Карабаш тавының кәҗә тәкәсе дә штурм белән ала алмастай текә җирләрен, куәтле «С-80», «С-100» тракторлары, бульдозерлар, экскаваторлар белән уеп кереп, футбол кыры кебек тигез мәйдан ясадылар. Теләсәң, вертолёт кына түгел, пар аэроплан утырт.

«2014 нче»не бораuларга, заманында Татарстанда дан казанып, күп скважиналар бораулаган әрмән агае Ашот Егояннныкы төсле үк куе кара мыеклы мастер Сәүбән Корбанов егетләре алынды. Әлеге бригада егетләре угленоска скважиналарын, «шалт!» – бораулап та чыгалар. Бу юлы да шулай булыр дип торалар иде. Бораuларга керешкәннәренә инде ай була, әмма эшнең очы-кырые күренми әле. Забойга кондуктор да төшерелмәгән. «2014 нче» – убыр скважина булып чыкты бугай. Забойга нәрсә салсаң, шуны йотып тора. Бораулаучылар будкадагы бар одеялларын, матрас-юрганнарын, хәтта баш астына салып йоклый торган йомшак мендәрләрен забойга салып бетерделәр. Сәүбән Корбанов – бик тәҗрибәле мастер. Ике еллап Иранда да эшләп кайтты. «Йоту» хәлләренең моңа кадәр дә очраганы булгалады. Аптырагач, күршедәге басудан, бертуктаусыз яуган яңгыр астында калып, череп-каралып беткән карабодай саламын да бер трактор китертте. Аны мүкләткәч тә, убырның аппетиты басылмады. Геологлар әйтүенчә, аста, бораулап үтәсе катламда, коточкыч зур бушлык. Мәскәү метросы кебек, аннан да зуррак буш коридор. Скважина бораулау практикасында шундый бушлыклар да очраштыргалый...

Шулай да, карабодай саламы өстенә, бер-бер чиләген берничә бораулаучы көчкә күтәрердәй суперизмә дә тутыргач, убырның аппетиты бераз кимегәндәй булды. Бораудолото бушлыкка очмый башлады. Забойга әкрен генә бораu төшерә башладылар.

Тормышта могҗизалы хәлләр гел янәшә дигәндәй, әллә тәмам туйдырган хуҗасыннан качып, әллә үзе яраткан тәмле үләнгә бай Карабаш тавында җәй буена иректә йөреп кыргыйланган бер карт кәҗә, «2014 нче»гә ияләште. Килеп чыга да үз эшләре белән мәш килгән бораулаучыларга «Мә-ә-ә!» дип сузып сәлам бирә. Бораулаучылар да теләп ала аның сәламен. Эшләре кым-кырыс булса да... Чөнки кәҗә аларның һәркайсы өчен якын, таныш йорт хайваны. Барысының да, хәзер булмаса, бала чагында кәҗәнең шифалы сөтеннән авыз иткәне бар. Озын кәкре мөгезләрен аларга төбәп, ак сакалын селкеп торган бу акыллы кәҗәкәйне смена саен алмашкан бораулаучылар нинди дә булса тәмле әйбер белән сыйлыйлар. Янында ул булганда, эшләве үк рәхәт, диләр. Бораулаучыларга сүзсез төбәлеп карап торган кәҗәкәйнең кыяфәте нәкъ борынгы фәйләсүфләрнеке төсле. Ак сакалын җай гына селкеткән чакта данлыклы Сократ, Демосфеннарга охшап киткән кебек... Эшең тыгыз булса да, ничек инде аңа сүз катмыйсың да ничек итеп башыннан сыйпамый гына яныннан узып китәсең?!

Ә кәҗәкәй буровойга көн дә килә. Сыйлап торгач, ник килмәсен ди!

Буровой янындагы мәйданга вышкарьлар, забойга төшереләчәк торбаларны сузарга дип, пилорамнан гына чыккан хуш исле каен-усак, нарат-чыршы такталары түшәгәннәр. Шушы искиткеч, хәтта башны әйләндерерлек хуш исне бөтен үпкәләреңне тутырып иснәү өчен генә дә эстакада яныннан китмәссең. Хуш исле булмыйча, ярдыргычка эләккәнче, ул бүрәнәләр өч-дүрт ай суда ята, җебеп әчи. Вышкарьлар аларны пилорамга тыкканчы, Чулманның Бәтке затоныннан салларны сүтеп ташыйлар. Саллар Чулманга Урал түрендәге Соликамск, Березники, Ивдель калаларыннан, Чусовая елгаларыннан төшә. Ә бу шәһәрләрдә урман кисүчеләр, сал агызучылар – барысы да төрмәдә утыручылар. Кайчак Бәткедә, саллар сүткәндә, бүрәнә арасыннан шундый нәрсәләр килеп чыга, сискәнүдән кулыңнан балтаң төшеп китә, чак елап җибәрмисең. Сал агызучылар үзләре өстерәгән озын кунычлы резин итек балтырына искиткеч осталык, нечкә зәвык белән кырган агач курчаклар, балалар уенчыклары тыгалар. Итек балтыры эченнән еламый гына укып та булмый торган поэмалар, «Послание»ләр килеп чыга. Урман кисүчеләр, сал агызучылар арасында туганнары белән язышудан мәхрүм ителүчеләр дә бардыр. Алар да бит кеше баласы. Бу бичаракайларның, әлеге бүләкләрне, язмаларны кем дә булса аласына ышанып, якты дөнья белән башкача аралашу чарасызлыгыннан, җан ачысыннан салуларыдыр.

Бәткедә, яңа килгән салларны сүткәндә, Дамир Добердиевнең үзенә дә шундый «Послание»ләр туры килгәне бар. Андый «бүләкләрне» контора музеена тапшыру тәртибен керттеләр.

...Йөзенә грек фәйләсүфләре кыяфәте иңдергән кәҗәкәй алай гына да калмады. Көннәрнең берендә ул хуш исле такталар түшәлгән эстакада өстендә бәтиләде. Бәрәкаллаһ! Кәҗәкәй бу очракта бик акыллы, шул ул вакытта алдан күрүче, хәйләкәр хайван булуын раслады, чөнки эстакада өсте коры, чиста. Эт-бүре кебек мәлгуньнәр килеп чыкмагае дип тә борчыласы юк. Бәтиләрен имезүчене эстакада өстеннән бораулаучылар, вышкарьлар да кумас... Аналарга хөрмәт һәр җәмгыятьтә, мохиттә булырга тиеш! Бораулаучылар аны чиратлашып ашатып торалар. Үзләренә чәй кайната торган әлүмин фләгәдән аңа чишмә суы алып килеп эчертәләр.

Кәҗәкәй, ыңгырашмый-сукранмый гына, берсеннән-берсе матуррак, бөдрә йонлы, ап-ак ике бәрән китерде. Матурлар инде! Курчаклар прәме! Туган сәгатьләрендә үк аяклана да башладылар. Әйләнә-тирә гел кешеләр бит! Кулларыңа ал да сөй рәхәтләнеп!

Кәҗәкәй бәтиләрен тапкан урыннан китәргә җыенмый төсле. Куучылар

буламы соң?! Бораулаучы һәм вышкарьлар «убыр» скважинаның барысын да комсызланып йотып баруы белән күрәшә. Эстакада өсте буш. «Ликвидация» бетмәгәнлектән, әлегә бораулау торбалары да кирәкми.

Бәтиләр эстакаданың теге башында, буйга-буйга сузган рәтләрдә ята бирәләр. Кәҗәкәй кыска гына арада кайдадыр йөреп килә дә тагын җылыткан урынына барып ята.

Киңәш алыргамы, «2014 нче»гә Гилертны да дәштеләр. Ничек дәшмәсеннәр, ул бит танылган тау инженеры! Җир шарында булмаган урыны, аяк басмаган нефть мәйданы юктыр. Көнчыгыш илләрендәге шактый атаклы университетлар профессоры. Карап торышка чүт кенә чәче коелып пеләшләнә башлаган бер дигән Гамбург егете. Күп телләрдә сөйләшә. Килүенә әле ничә ай гынадыр. Кирәк әйберен сораганда, сүзен табып, татарча гына сорый. «Иранда разведка бораулаганда, Татарстан агае Мөхәммәд Кадыйрда тордым, кара-каршы утырып, бик тәмле чәйләр эчә идек», – дип тә сөйләгәне бар. Гилерт хәзер буровойларга электроника, кибернетика кертү белән шөгыльләнә, ахры. «Татбур»га, ВМКга шул максатларда килеп чыккандыр. Буровойларга ничек шундый үтә дә катлаулы технологияләр кертергә җыеналар – Дамир Диндарович һич аңламый. Дөньяда иң алдынгы ысуллар белән вышка төзүчеләрнең партоешма җитәкчесе, инженер булса да, күп еллар инде «без экиятне чын итәр өчен туган» дигәнгә ышанып яшәсә дә. Бу инануны ул яшәгән мохит, аны шундый рухта тәрбияләгән вышкарьлар таләп итә. Шулай да буровойга ничек итеп электроника, кибернетика кертеп тутырасың, анда бит күтәргечләрне, силовой блок, роторны, квадратны хәрәкәткә китерүче электромоторлар... Хәер, Архимед аганың «Эврика!»сы һаман кулланылышта лабаса. Дөньяның әле теге, әле бу почмагында яңгырап тора. Бәлки, Гилерт та шуңа омтыладыр. Искитмәле тыйнак, эчкерсез, намуслы немец!

Моннан берничә ел элек Гилерт Татарстан бораулаучыларына чит телдә язулы зур-зур тимер мичкәләрдә майлар-мазьлар китергән булган. Ул майларны буровой егетләре бүген дә бик мактап телгә алалар.

– Ул май белән майлап җибәрсәң, торбалар җир куенына сызгырып кереп бара. Тагын китерт, – диләр. – Чын бизнесмен син, Гилерт!

Бар нәрсәне йотарга әзер «2014 нче»гә алар икәү бардылар. Гилерт юлда да уңай юлдаш. Күп сөйләп туйдырмый, әмма белмәгәне юк. Гилертның киңәше бу очракта да бик файдалы булырга мөмкин.

Гамбург егете килә-килешкә эстакада өстендә бәтиләрен кочып ятучы кәҗәкәйне күреп алды.

– Вас ист лост! – булды аның беренче сүзләре. – Нәрсә бу?

Аннан: «Шприхензигин дойч? – дип сорап куйды. – Гафу ит, үзем дә сизми немецчага күчәм».

Дамир да, берни булмагандай: «Я, я! Шпрехен зи битте! Вейтер! Дәвам ит! Дауерен!» – диде.

Гилерт кәҗәкәйне күреп бик гаҗәпләнде: «О-о, ди Циеге! Циеге! Васт ист шонн! Кәҗәләр, теп-тере кәҗәләр! Бу искиткеч матурлык! Буровой уртасында! Майне кляйен либер Циеген! Кәҗәкәйләрем!» – диде.

Шунда ук дипломатын ачып, тегеләргә Гамбург печеньесын тәкъдим итте. Кәҗәкәй үзе дә, бәтиләре дә, каян чыккан бу печенье, дип төпченеп тормадылар, кетердәттеләр генә!

– Майне либер Циеген! Минем кадерле кәҗәкәйләрем! – дип кабатлады алман кунагы.

Гилерт – бик зур галим. Шул ук вакытта хайваннарны, дүртаяклыларны бик сөя

икән. Малкайлар яныннан көн буена китмәде. Геологлар, механиклар, мастерлар белән аяк өсте генә сөйләшеп ала да тагын кәҗәләр янына чыга. Кәҗәләр дә Гамбург егетенә ияләнделәр. Ашаткач, башларыннан сыйпагач, иркәләп торгач, бик тиз үз иттеләр.

Ә бәтиләрнең чаярагы Гилертның алдына ук сикереп менә башлады. Муеныннан гына кочмый! Үбеп алырга әзер! Гилертның килүен, җиләнен җыеп тезләнүен генә көтә. Немец инженеры үзе дә: «Майн клайне либер Циеген»*, – дип, еш-еш кабатлап, кәҗә бәтиен кочаклап, бөдрә йонын язгандай итеп, сыпырып-сыпырып куя. Бәтинең юеш танавыннан үбеп тә ала.

Шушы күренешләрне исе китеп карап торган Дамирга: «Үземне сәеррәк тотмыйммы? Бер дә гаҗәпләнмәгез, мин Багдадта читлек эченә кереп, өч айлык юлбарыс баласын туйганчы әвәләдем, – диде. – Каһирәдә, зоопаркта, яңа туган фил баласына шешә белән җылы сөт эчердем. Бер эчкәндә мөлдерәмә чиләкне төпләп тә куйды. Әнисенең сөте беткәнме, нәрсәме... Янымда торган ана фил, хоботы белән төртеп, рәхмәтен белдерде. Африкада Чад күлендә бер баланы крокодил авызыннан йолкып алып калдым, бәхеткә, винчестерым үзем белән иде. Комсызга атарга туры килде».

Гилертка «шустрый» сүзе ошады. Немецчадагы «Шерстхафт»ка якын, диде. Алдына менеп иркәләнгән кәҗә бәтиенә дә «Шустрый» дигән кушамат такты. Буровойдан китәргә бер көн кала, «Мин «Шустрый»ны үзем белән алам», – диде.

– Алып кая куясың? – булды Дамирның соравы.

– Үзебезнең ВМКга алып кайтам. Бу турыда башка сүз кузгатмыйк та!

– Тыйнаклыгы җитеп бетмәгән әлеге кәҗә егетенең бер дә кирәкмәгән төштә шыбыр-шыбыр кара борчак коя торган гадәте бар бит. Уйлап та тормый инде менә.

– Ул турыда, майн геноссе Дамир Диндарович, мин белми, дисезме? Ә бу ике кул нәрсәгә? Җыештырырбыз! Әкренләп, урынга утырырга өйрәтербез. Биш ай эчендә аю баласын урам аша сузылган металл аркан өстендә биергә өйрәтәләр. Синнән күрәм – без бит әкиятне чынбарлык ясаучылар. Беренче мәлдә минем офиста яшәр. Ашханәбез янда, күршебездә генә бит. Бик авырга китсә, «Шустрый»ны Гамбургка, утарыбызга кайтарырмын. Анда аңа күңелсез булмас. Ишегалдында Кытай казлары каң-каң килә, читлектә – махсус чыгарылган француз кроликлары. Әнием фрау Роза Мария Гилертның тагын әллә нинди өй хайваннары җитәрлек...

...ВМКга алар өчәү кайттылар. «Шустрый» бик канәгать. Гилертның артыннан да калмый, маэмай кебек чаба. Диспетчерларның ишек төбенә бер эт баласы ташлап киткәннәр. «Кәтлит кисәге бирсәң, мин сине яратам», – дип ятучы эт малаеның сыртына ук менеп кунаклаган бәти, кергән-чykканны йонлач тәпиләре белән кочарга ук әзер. Беренче мәлдә шушы паспортсыз җан да «Шустрый»га өреп маташтьы. Янәсе, йөрмә бу тирәдә! «Шустрый»ның гына исе китмәде. Яңа гына чыгып килгән, әмма очлы булырга охшап торган, чәнчә бармак хәтле генә мөгезләрен йонлач маэмайның йөзенә терәде. Тегесе дә, кем белән мөгезләшергә туры киләчәген аңлагандай, ләң-ләң килеп, аягына ук торып басты, койрыгын бот арасына кыстырып, таю ягын карады. «Шустрый»ны шеф-повар Элеонора Әсхәтовна да, аның балалары да бик яраттылар. Еш кына алар ашханә янында бишәүләп утыра торган булдылар. Кичләрен һава суларга чыккач та, башкалар сокланырлык бер компания булып йөрделәр.

Командировка срогы бик тиз үтеп китте. Тиздән Гилерт Гамбургына бөтенләйгә кайтып китте. Үзе белән «Шустрый»ны да, ике баласы белән Элеонора ханымны да алды ул. Дамир аларны Бөгелмә тимер юл вокзалына кадәр озата барды. Бу кадерле затларның бишесенә дә хәерле юл, ак бәхетләр теләп калды.

* Майн клайне либер Циеген – бәләкәй кәҗәкәем.



Айзирәк
Гәрәева-Акчура

# ТӨРКИЯНЕҢ БЕРЕНЧЕ НЕФТЬЧЕСЕ – ТАТАР

ДОКУМЕНТАЛЬ БӘЯН

Сулар һавамны, басып йөрер җиремне, эчәр суымны алыштырган гына көннәр иде. Күңел әле туып-үскән якларында, Татарстанның көнчыгыш районнарына хас дистә чакрымнарга сузылган тигез һәм төрледән-төрле чәчәкләргә күмелгән болыннарда тәгәри. Киңлек һәм иреклек тойгысын өләшүче кырлар буйлап йөгерә...

Таң җиләслегенә сихри бер нурлы шифа өстәп, җир куеныннан аерылырга теләмәгәндәй, иркәләнеп-назланып һәм яктырып кояш чыга. Көн буе күз угыннан китми диярлек. Аннары җиргә өләшкән җылысын, офыкларга тараткан нурларын җыеп бетермичә, соңарып кына кабат җир куенына чума. Күңел, көн кичкә таба авышканда, шул манзараны күз алдына китерә, иртәгә яңгыр яварсы-юкмы, дип, алсу төстәге офык сызыгына тезелгән ак болытларны саный. Әгәр дә кояш баеганда караңгы болытлар күренсә, иртәгә яңгыр явасын көт тә тор!

Монда алай фаразлап булмый икән. Кояш та җирдән күтәрелми төсле. Ничектер шулай, тауларнымы, әллә җирдәгеләрне үртәп, качышлы уйный. Таулар артыннан «былт» итеп кинәт килеп чыгар, бер караганда, күләгә ясап качар һәм, шулай уйный торгач, кинәт юк та булыр. Йә тау артына качкан җиреннән чыкмас, йә диңгезгә төшеп батар.

Ник бәйләндем шуңар, кая барсаң да шул бер кояш бит! Тау артына качамы, диңгезгә батамы... Яки җир куенына кереп чумамы – шул бер кояш! Әмма барыбер, Туган Җирдән еракка киткәнгәме, кояш башкачарак кебек. Гәрчә, рәхәтләнеп, монда җылысы күбрәк тә әле, тик барыбер офыкка багып фаразлыйсы килә.

Менә шулай, кояшка бәйләнеп йөргән көннәрдә, Төркия татарларыннан ишеткән ике мәгълүмат башыма кереп калды.

– Төркиядә петролне татар тапкан!

– Ни ул петрол?

– Кара алтын.

– Нефть?

– Әйе! Төркиядә беренче нефтьне тапкан кеше татар бит!

«Петрол» төшенчәсе төрекләргә французлардан кереп калган сүз икән. Таш һәм май сүзләренең латинчасы кушылып ясалган, ягъни «таш мае». Татарча

«җир мае» дигән кебек инде. Төрекләр нефтьне «петрол» диюдән тыш, бездәге кебек үк «кара алтын» дип йөртәләр.

Шуны ачыклап торганда, тагын бер сүз ишеттем:

– Төркиядә таулар ел саен берничә сантиметрга урыннарыннан күчә!

Йөзләгән чакрымнарга сузылган таулар тезелгән. Шулар арасына салынган юлдан, кояшка бәйләнә-бәйләнә, үргә таба менеп барыш иде. Чынлап әйткәндә, кояшның кайда ничек баеганын оныттырган мәгълүматлар булды бу.

Төркиядә беренче нефтьне тапкан кеше татар бит!

Төркиядә таулар ел саен берничә сантиметрга урыннарыннан күчә!

Бер уйлаганда, әлеге ике җөмлә бер-берсенә һич бәйле түгел кебек. Әмма шактый вакыт һәр ике җөмләнең сүзләре, иләк өстендә биегән вак ташлар төсле, күңелдә бергә иләнеп йөри бирде.

Төркия, татар, беренче, петрол, еллар, таулар, тапкан, күчә...

Күчә, тапкан, таулар, еллар, кара алтын, беренче, татар, Төркия...

Шушы халәт, дистә гасырлар дәвамында күзгә күренмичә урыннарыннан күчкән биек тауларның элеккеге нигезләрен эзләткәндәй, еллар буйлап чигенә-чигенә барып, Төркиядә «таш мае» тапкан татар юлына төшерде. Кем соң ул?

«Әгәр дә киләсе елларда, Төркиянең нефть өлкәсен алга җибәргән кешеләргә һәйкәл куелса, иң беренчесе Кәмал Локманга булырга тиеш!»

1963 елның 26 июнендә Төркиянең Бөек Милләт мәҗлесе мөнбәреннән, ягъни Парламент җыелышында яңгыраган сүзләр бу. Энергия һәм табигый байлыклар министры халык депутатлары алдында ясаган чыгышында, Кәмал Локманның җөмһүрият өчен эшчәнлеген югары бәяләп, әнә шундый сүзләр әйтә.

Кәмал Локман вафатыннан соң таралган рәсми некрологтан: «Икътисад министрлыгы Җир асты байлыклары мөдирлегендә фәнни хезмәткәр (1929-1932), Нефть эзләү һәм эшкәртү идарәсендә (1932-1935), М.Т.А. Нефть төркемендә (1936-1956) эшли. 1957 елда Төркия Җөмһүрияте Нефть үзәге рәисе була. Аннары, ялга чыкканчы, рәиснең техник киңәшчесе вазифасын теләп башкара. 1968 елда Төркия география оешмасы тарафыннан зур хезмәтләре өчен медаль белән бүләкләнә».

Утыз алты еллык хезмәт юлы нефть өлкәсенең һәр тармагын колачлый: тәүге геологик эзләнүләрдән, коеларны казудан башлап, директорлык вазифасына кадәр күтәрелә. Төркия Петрол инженерлар палатасын оештыра һәм җитәкчелек итә.

1976 елда, үлеменнән соң таралган рәсми некрологларга, хатыны тарафыннан язылган кыскача биографик шәрехләмәгә һәм Бөек Милләт мәҗлесе елъязмасына таянып, «Төркиядә беренче нефтьне тапкан татар кем ул?» дигән сорауга җавап итеп: «Дәүләт күләмендә зурланган, югары мәртәбәләргә ирешкән геолог, инженер, галим Кәмал Локман», – дип әйтергә мөмкин. Ләкин җитми шул. Хәтта гомере буе авылдан беркая чыгып китми яшәгән татар кешесе язмышын рәсми некролог кына тасвирлап бирә алмас. Әлбәттә, тулырак җавап бер гасырдан артык элекке чорлардан башлана. Җиде кат җир астына күмелмәгән ул, әмма ерак илләрдә, чит телләрдә. Шуңа күрә аны табып бетерәм, дисәң, ярты гына түгел, берничә ел кирәк булуы мөмкин. Бу әлегә дөньякүләм нефть индустриясендә эз калдырган зур татар шәхесе хакында таныша башлау гына.

Төркия сахафлары – иске китап сатучыларның интернет сайтларыннан табылган, алынган китапларны, журналларны өйгә китерүләрен түземсезләнеп көтеп алдым. Китерүгә, саргайган, юка битләре коелырга торган басмаларны сак кына берәм-берәм карый башладым, төрекчә укырга тырыштым. Кайберләренең битләрендә ручка белән сызылган, билгеләп куелган тамгалы урыннарны күргәч, кемнәрнең китап киштәләрендә, өстәлләрендә торды икән болар, дим. Кулдан-кулга күчә-күчә, миңа да килеп җиттегез бит, дим.

Берсен ачып җибәрсәм, чын култамгалы икән! Төркия консулы исеменә язылган. Бүләк иясе инде күптәннән мәрхүм, ә кемнәрдер менә аның мирасы башкаларга кирәк булыр дип уйлаган, күрәсең, китабын сатуга куйган. 1967 елда дөнья күргән басмага «...бер хатирә буларак бүләк ителде. 6.5.67», диелгән, «К.Локман», дип, имза салынган. Имза ачык укыла, эре хәрефләр белән язылган.

Ә аклы-каралы фотолардан баккан Кәмал Локман үзе мондыйрак: буе уртачадан бераз калку, бик кыска итеп киселмәгән чәчен артка таба тарап куйгангамы – йөзе ачык, карашы туры күренә. Иң беренче күзгә ташланган йөз үзенчәлеге – киң маңгае акыллы, башлы кешедер дигән уй-фикер уята. Анкара татары, сигезенче дистәсен ваклап килгән Наилә ханым Бенарк әлеге фото сыйфатламасын тагы да тулыландырды: «Бик озын түгел иде, 170 см тирәседер. Кара да, ак та түгел, «бодай» тәнле. Бик ачык, ямьле кеше иде. Элемтәләр корырга, аралашырга, сөйләшергә бик яратты. Туганнары турында ишеткән булмады. Гаиләсе белән Истанбулда бакчалы өйдә торды. Кызы яшькә миннән дә зуррак иде. Аларны инде белмим. Кәмал бәй 268 кешене эшкә урнаштырдым, дия иде...»

Менә шулай, татар нефть инженеры тормышын азмы-күпме тулырак күзалларга ара-тирә сакланган хатирәләр, саргаеп тузган журнал, китап битләреннән табылган язмалар акрынлап булышты.

Үзенең һәм чордашларының язмаларын укыган саен, шулай ук күренекле нефтьчене яшь чакларында күреп калганнар белән сөйләшә торгач, күңелдә иләнеп йөргән сүзләр берәм-берәм кәгазь битенә коела барды. Һәм Кәмал Локман чорына кайттым. Аның нигезе бездә икән ләбаса!

Төркия, татар, беренче, нефть, еллар, таулар, тапкан, күчә...

## Мөгаллим баласы

*«Ул май рәвешендә һәм, эчендә газ булу сәбәпле, урынын үзгәртергә сәләтле. Җирнең бер катламында ярылган, чатнаган урын тапса, шунда һиҗрәт итәр, күчәр. Табылганчы күп эшләтер, арытыр. Һич өмет ителмәгән бер җирдә үзен күрсәтер. Икенче төрле әйткәндә, нефтьне эзләү-табу – табигать белән бәйле көрәш...»*

Гомере буена сузылган мәсьәләге хакында аңлатырга, язарга, сөйләргә беркайчан авырыксынмады Кәмал бәй. Кара алтын табуга кагылышлы истәлекләренә, фәнни эзләнүләргә, ачышларга кагылышлы чираттагы мәкаләсендәге фикерләрен геологик сызымнар, аңлатмалар белән раслап тәмамлап куйды. Шәкертләре, бу язуларга карап, нефть табу юлына тиз төшенер кебек.

Ул кара алтынга кагылышлы үз фикерендә нык торды: «Төркиядә нефть милләт ихтыяҗына җитәрлек дәрәҗәдә бар», – диде. Ә хезмәт итүгә, эшләүгә

килгәндә, инанганы шул булды: «Гомумән, бер эшнең негатив, кире ягын күрү һәм бар җаваплылыкны үз өстеңә алмыйча котылырга тырышу, качып китү өчен «юк» сүзен куллану мәгълүмдер. «Бар» дигәндә, ул «бар»лыкны булдыру өчен күп эшләргә, күп тырышырга кирәктер». Һәрхәлдә, бу юлларны укыганнар, тәҗрибәле остаз сүзләренчә, тормышта «бар»лык өчен шактый тырышырга кирәклеген истән чыгармаслар.

Шул чакта Кәмал бәй, каләмен читкә куеп, туган якларыннан сәламнәр китереп җиткергән, бәгырен иркәләгән хатны куеныннан алды. Бик кадерләп кенә ачты. Җир астыннан дәүләт туендырырлык байлык тапкан җыерчыклы куллары дерелдәп куйды. Әйтерсең, моңарчы бу кадәр кыйммәтле һичбер нәрсә тотмаган.

Гомер йомгагы сүтелеп беткәнче, күп еллар дәвамында хәбәрләшә алмаган туганнары язганнарны укырга насыйп булды аңар, аннары кардәше йөзен күрде. Туган җиренә дә аяк басар әле, күрерсез!

Бераздан, туган-үскән якларына сәфәр кылу уе белән, әзерлек чараларына керәште. Әмма һич кенә дә бу ниятенә үзенең юлын тәмамларга җыенып тотынмаган иде...

Таулар җирнең эчке үзгәрешләре нәтиҗәсендә миллион еллар элек барлыкка килгәннәр һәм даими хәрәкәт итәләр. Кешелек дөньясы ул хәрәкәтне, җир бик каты тетрәп куйса, яисә диңгез сулары күтәрелеп ярларына ташыса, әлбәттә, нык сизә.

Әмма күп гасырлар дәвамында бер-берсенә терәк булып тезелгән, болытларга кадәр үрелгән горур таулар каршында басып торганда, аларны күчерерлек кодрәт барлыгына бик ышанасы килми. Югыйсә, күзгә күренмәгән күчеш менә шул, табигать хозурлыгына сыенган, тауларга сокланган, яшел итәгенә ятып ял иткән мизгелдә дә дәвам итәр. Шул ук вакытта икенче бер күчеш – биек-биек тауларны күчергән кодрәткә иярепме, меңәр чакрым тирәнлектә нефть йөрер.

Бәлки, бу табигый күчешләр иң әүвәл адәм башына төшкән яки ул үзе сайлап алган күчештән башланадыр?! Бәлки, адәм баласы үзе дә, шул күчүләр сәбәпле, таулар биеклегенә күтәреләдер?!

Кәмал бәйнең бу дөнья юлы XIX йөзьеллыкның тәмамланган елында башлана. Ә туып-үскән җиреннән аерылган, күчеп киткән чагы XX гасырның унынчы елларына туры килә.

1899 елның 8 маенда Казакъстанның Казакълы шәһәрендә дөньяга килә ул. Әтисе Шәрәфетдин имам-мөгаллим, әнисе Латыйфа мөгаллимә – Оренбург татарлары, бу якларга Каргалы авылыннан күченгәннәр.

...Гыйлемле һәм дини гаилә тәрбиясендә үскәнгәме, кечкенәдән зирәклеге белән үзенә җәлеп итүчән бала булды. Башлангыч белем бирүче Ибадуррахман остазы да аның сәләтенә, тырышлыгына хәйран калып соклануын яшереп тормый иде. Бәлки, шәкертенең акыллылыгын күрә, тоемлый белүе аны, тора-бара, Кәмал тормышына иң җитди йогынты ясаган тәүге кеше булырга этәргәндер дә.

XX гасыр башында милли һәм фәнни алгарышлар, аң-фикер күтәрелеше, мәгърифәтчелек идеяләре таралу чор яшьләре күңелендә төрле өлкәләр белән кызыксыну, яңа тормыш коруга талпыну хисен арттырды. Россиядә һәм көнчыгыш илләрендә яшәгән төрки халыкларның белемле, зыялы, эрудицияле егетләре, кызлары, чит илләр белән дини һәм сәүдә багланышларын тоткан затлы, җитешле нәсел дәвамчылары, шулай ук дөнья күрергә, гыйлем

тупларга омтылган шәкертләрнең күбесе Төркиягә барып укырга хыялланды. Әлбәттә, заманның ирекле, шифалы сулышы аз гына иссә дә, ислам аша «Бишектән ләхеткәчә гыйлем ал!», «Кытайга барып булса да гыйлем ал!» гыйбарәләре каннарына сеңгән төрки халык балаларын тергезеп җибәрде төсле. Тик... Һәркем өчен рус патшасының хәер-фатыйхасы җиңел генә табылмый.

1910 елда туган җирендә башлангыч сыйныфларда укуын тәмамлаган һәм Истанбулда белем алуын дәвам итәргә теләгән унбер яшьлек Кәмалга чит илгә чыгу рөхсәтен бирмәделәр.

Шушы вакытта остазы Ибадуррахманның да, Төркиягә барып, илаһият белемен алырга карар кылуы мәгълүм иде. Алай гына түгел, шәкертенә чит ил капкаларын ачу җаен тапты ул. Патша хөкүмәтеннән чит илгә чыгу өчен паспорт алганда, Кәмалне кардәшенең улы итеп яздырды. Бу исә Кәмалга Төркиягә китү мөмкинлеген бирде.

Кәмал, Истанбулга килгәч, «Хадыкыят-ы Мәшверете» башлангыч мәктәбендә 5 нче сыйныфта, теленең төрекчәдән аерылып торуы сәбәпле, үзеннән кечерәкләр белән укый башлады. Гыйлеме күпкә югары малай бу хәл белән килешеп калырмы соң?! Тырышкан – ташка кадак каккан, дигәндәй, әле шуның өстенә зирәклек тә өстәлсә – алгарыш тиз килер. Ике айдан соң инде имтихан тапшырып, бер елны «сикереп» кенә үтте дә урта мәктәпнең икенче сыйныфына күчте. Шул ук вакытта өченче сыйныф имтиханнарына әзерләнә башлады.

Бу вакытта Истанбулда укучы мөселман студентлары үзләренең җәмгыятьләрен корган иде. Әлеге «Русия ислам студентлары җәмгыяте» эшчәнлеген алып барган Йосыф Акчура, Әхмәт Агауглы, Хәлим Сабитлар төрки милләтеннән булган 60 студентның хөкүмәт тарафыннан укытылуын таләп иттеләр. Һәм аларның таләпләре кабул ителде. Исемлеккә исә урта белем бирү мәктәбен вакытыннан алда имтихан тапшырып тәмамлап йөргән Кәмал Локманны да керттеләр. Ә кайсы студент кайда белем алачагы жирәбә нигезендә ачыкланды. Аңар, бәхетенә тигән көмеше дигәндәй, Шам (Дамаск) шәһәре чыкты. Шулай итеп, ул, укуын «Солтания» лицеенда дәвам итәр өчен, Истанбулдан Шам шәһәренә юл тотты.

1910 елда Йосыф Акчура, чит илләрдә яшәүче төрки халыкларны таныту, аларның мәдәниятен, әдәбиятын, иҗтимагый фикерләрен тарату максаты белән, «Төрек йорты» журналын чыгара башлаган иде. Шушы басма Кәмалнең гыйлем алу омтылышларын тагын да ныгытты төсле. Исмәгыйль Гаспралының бер мәкаләсе күңеленә Франциягә китеп уку теләген салды.

Сугыш һәм акчасызлык, мохтаҗлык ниятен тиз генә тормышка ашырырга җай бирмәсен аңлады аңлавын... Ләкин бер уена кердеме, тиз генә фикереннән кире кайта торганнардан түгел ул. Башта, 1916 елда белем алуын тәмамлады, аннары тимер юл хезмәткәре булып эшли башлады. Ике ел эшләгәннән соң, гаскәргә алынды һәм, Госманлы империясе алып барган сугышларда катнашып, Фәләстингә кадәр барып җитте. Аннары, барыбер мең төрле михнәтләрне җиңеп, Франциягә юл тотты. Әлбәттә, анда рәхәт тормыш вәгъдә итәрлек кеше дә, көтеп торучы да юк иде. Беренче чиратта, Гренобль шәһәре фабрикасына эшкә керде. Шуннан соң гына Гренобль Политехнология институтына инженерлыкка укырга барды. Көндезләрен гыйлем тупласа, төннәрен фабрикада эшләргә карар кылды. Ул бит, Шамда укыганда ук, үз-

үзенә сүз бирде: «Кайда эшләп булса да, барыбер Исмәгыйль Гаспралы кебек, Франциядә укыячакмын!»

Әмма никадәр тырышып һәм чиләнеп эшләсә дә, хезмәт хакы институтта укыганы өчен түләргә җитми интектерде. Кайчак хәтта кәһвә алып эчәргә акчасы калмый иде. Уналты мәртәбә хөкүмәткә ярдәм сорап хат язды язуын, ләкин бер җавап килмәде.

Хәле таш диварга барып терәлгәннән ким түгел. Болай өметсезлеккә бирелеп йөргәнче, әллә уку йорты мөдире белән сөйләшеп карасынмы?! Аңа үзенең матди яктан бик авыр хәлдә калуын, шуңа карамастан укырга бик теләвен аңлатып бирсә?!

Мөдир укуга хирыс, тырышлыгы белән аерылып торган шәкертен тыныч кына тыңлады. Франция Милли мәгариф министрлыгына түләүсез укытуны сорап хат юллаячагы хакында әйтеп калды. Ләкин Кәмал үзе дә хатларны күп язды инде...

Көннәрдән бер көнне мөдир Кәмалны бүлмәсенә чакыртып алды:

– Сезне тәбрик итәм. Франция хөкүмәте эшлекле һәм белемле, акыллы бер төрки шәкертнең Франциядә укуы белән горурлана. Һәм түләүсез уку мөмкинлеген бирә.

Әлеге хәбәрне ишетүдән, укуын дәвам итәчәгенә шатланудан үзен кая куярга белмәгән егет берара телсез калып торды. Аннары рәхмәт әйтте дә:

– Тормыш беренче мәртәбә елмайды! – дип, тәкрарлый-тәкрарлый, эшенә ашыкты.

Уку белән бергә ул дөнья хәлләреннән, Төркиягә, татарларга бәйле вакыйгалардан хәбәрдар булырга тырышты. Төркиянең чит илләр белән Мусул нефте хакында алып барган дәүләтара сөйләшүләре турындагы мәгълүматлар игътибарын җәлеп итте. Шул яңалыклар хакында сөйләшеп утырганда, Румыниядән килгән студент иптәше үзенең нефтьчеләр мәктәбенә керергә теләве хакында сөйләде. Аның сүзләренә караганда, нефтьчеләрне әзерләгән махсус югары уку йортына бары 40 студентны кабул итәләр икән. Шулай да Кәмал үзен сынап карарга булды. Инженерлыкка укыганнан соң, Страсбургның югары милли нефть мәктәбенә имтихан тапшырды.

Керүен керде, һаман да шул, адашып калмас «нужа бабай» артыннан йөгереп килеп җитте, яңадан укуга түләү мәсьәләсе калыкты. Шуннан, озакка сузып йөрми, Төркиянең Икътисад министрлыгына мөрәҗәгать итте. Хөкүмәт бу юлы, нефть өлкәсе белгечләре кирәклеген искә алып, Кәмалнең уку һәм яшәү чыгымнарын дәүләт хисабына алырга карар бирде. Тик бер шарт белән: аның өчен җаваплылыкны үз өстенә йөкләгән кеше табарга!

Бу юлы, тәвәккәллеген җыеп, Сорбонна университетында укыткан Садри Максуди Арсал белән очрашты, аңа үзенең гозерен җиткерде. Мәшһүр татар мөгаллиме милләттәшенә ярдәм кулы сузмый калырмы?! Әйтерсең, тормыш менә шул рәвешле яшь шәкерткә икенче мәртәбә елмаясы итте!

Матди кыенлыклар күрсә дә, үз көче, акылы һәм юлында очраган мәрхәмәтле җаннар ярдәме белән алга атлады егет. Зур шәхесләргә үтеп керә-керә һәм аларның ышанычын аклап, югары белем алуга ирешә. 1927 елда укуын яхшы балларга вакытыннан алда тәмамлады. Андыйларны исә эш әзерләп, чакырып торалар...

1927 елда нефть өлкәсендәге эшчәнлеген Румыниядә башлап җибәрсә, аннары Польшага китте. Ике елдан соң Төркиягә кайтып, бу өлкәнең иң беренче белгечләреннән исәпләнеп, нефть индустриясен торгызу башында

торды. Моңа кадәр җир өстендәге һич тузмас һәм искермәс байлык – гыйлемне нинди тырышлык белән эзләсә, җир астыннан кыйммәте төшмәс кара алтынны юллауга, чыгаруга шундый ук үҗәтлек белән тотынды...

## Мөһаҗир татарлар ярдәмчесе

Госманлы империясе заманнарында ук сәүдәгәрләр һәм юлчылар өчен корылган кәрвансарайлар, ягъни мәчете-мәдрәсәсе, кунып чыгарга бүлмәләре, кәрваннарны куярга, төяргә, мал-туарны сатарга базары булган комплекслар төзелгән. Урта Азия халыклары аларны кәрвансарайлар дип төзесә, Төркиядә исә «ташхан», диләр. Татарчалап әйтсәк, «ташханә», «таш бина» була.

Борынгыларның, кәрван кучсә дә, кәрвансарай урынында кала бирә, диюләре хак. Истанбул үзәгендә, Госманлы империясе солтаны Мостафа Өченче идарә иткән заманда, XVIII гасырның икенче яртысында корылган Лаләле мәчете янындагы Ташхан яныннан кәрваннар өзелмәгән, дип сөйлиләр. Үзе исә чорлар җилендә әле яртылаш ишелеп, әле кабат төзелеп, әле тузып, әле яңарып тора бирә.

1970 елларда бу бина шәхси эшмәкәрлеген оештырган эшкуарларны үзенә туплады. Истанбулның гөрләп торган бер сәнәгать үзәгенә әйләнде ул. Төрекләр күбрәк тукыма җитештерү, ягъни текстиль белән мәшгуль булдылар. Шушы урын эшкә һәвәс, тырыш, алтын куллы мөһаҗир татарларны да үзенә тартты. Биредә урнашкан йөзләп ательеның уннан артыгын татар кешеләре оештырып җибәрде. Кайберләре бер генә түгел, берничә эш урынына хуҗалык итә башлады. Нәкъ менә шушы ательелардан Төркиядә беренче мәртәбә ясалган әйберләр тарала башлады. Диңгездә су керер өчен «үрдәк аягы», йөзүчеләр, тимерчеләр, солдатлар өчен махсус күзлекләр, ханым-туташларга төрле чәч кыстыргычлары, музыка уен коралы – тимер кубызлар ясауны татарлар кертеп җибәрде. Кәбир Канбир, Сабри Шәнәр, Мәхмәт Хулуси Акчура, Шабан Байкал, Гакиф Аблай, Мөхәммәтҗани Ваккас, Аднан Аблай, Мәхмәт Өлкәр кебек татарларның ательеларында эш төнлә дә туктамады.

Шәхси оешма хуҗалары үзләре янына күбрәк татар авылларында яшәгән милләттәшләрен чакырып, аларны эшле итәргә тырышалар иде. Шуңадыр да, эшчеләрнең туксан проценты татарлар булды.

Шул данлыклы Ташханга илтә торган Фәтхи бәй урамында Османия Корыһөйүк татар авылында туып-үскән Мәхмәт Хулуси Акчура ательесы урнашкан.

Ташхандагы берничә ательега хуҗа Кәбир Канбир, гадәттә, дустының эш белән мәшгуль олы малае Якупка: «Әй, энем, эшлисез дә эшлисез, акча җыеп нишлисез?» – дип, тәрәзәдән карап кына шаяртып китә иде. Монысында эчкә узды. Мәхмәт Хулуси үзенә шәһәргә килеп урнашырга ярдәм иткән танышын ачык йөз белән каршы алды.

Алар хәл-әхвәл белешеп торган арада бүтәннәр өстәлде. Тумышы белән Башкортстан якларыннан булган, Истанбулның башка бер тарафында кибет тоткан Мәхмүт Ураллы килеп җитте. Төркия Республикасында латин графикасын өйрәтүче тәүге укытучылардан саналган, Оренбург татары Садыйк Таргул да озак көттермәде. Аның артыннан тагын берничә кеше күренде... Менә шушы эшкуар һәм мөгаллим татарларга бөтенләй үзгә өлкәдә дан казанган нефтьче инженер Кәмал Локман кушылды.

...Кәмал бәй читтә яшәүче татарлар белән инде иң мәшһүр лидерлары, язучы Гаяз Исхакый исән вакыттан бирле әвәрә килә. Исхакый татарлар җәмгыятен җитәкләүне Кәмал бәй дәвам итәр дип уйлаган иде. Әмма ул вакытта хөкүмәт кануннары дәүләт хезмәткәрләренә җәмгыять җитәкчесе булуны тыя иде. Әлбәттә, ул, нефтьче инженер, кара алтын чыгару эшләрен башлап йөрүче дәүләт хезмәткәре буларак, иҗтимагый-сәяси эшләр башында тора алмаячагын, ә оешмага ярдәмче буларак күбрәк файда китерәчәген аңлады.

1954 елда ук чордашлары ясаган тәкъдимне кырт кисүе, кабул итмәве шул сәбәпле. Җавабын ачыктан-ачык әйтте:

– Мин ярдәм итәчәкмен... Ләкин рәсми хезмәткәрләргә сәяси эшләр белән мәшгуль булу катгый тыелган өчен, мондый бер вазифаны өстемә ала алмаем.

Бу мәсьәләне Исхакый, үлеменә бер атна кала, 1954 елның 15 июлендә кабат кузгатты. Ул чакта дуслары Гали Акыш белән икесенә сүз катты:

– Кәмал бәй, син минем урынга килерсең, Гали, син аның сәркатибе булырсың.

Гали үзенә ышанып тапшырылган вазифага алынды. Кәмал исә бу вакытта эндәшми калуны хубрак күрде. Чирленең хәле авырайганны күрә торып, бәхәс кузгату урынсыз иде. Алга таба исә, җитәкче ярдәмчесе буларак, даими рәвештә татарлар белән аралашып, аларга ярдәм кулы сузып яшәде. Үзе эшләгән нефть өлкәсенә татарларны җәлеп итүе аларны эш белән тәэмин итәргә тырышудан иде.

Яшүсмер чагына аяк басарга өлгергәнче үк, якыннарыннан аерылу, ялгыз башы чит җирләрдә күргән авырлыклар, мохтаҗлык кыенлыклары – болар берсе дә эзсез узмады. Газапларны үзе татыган кеше генә башкаларның хәлен аңлар, диюләре хак. Шуңадыр, чит җиргә аяк баскан төрки милләт балаларына мәрхәмәтен кызганмады ул. 1953-1970 елларда Кытай һәм Япониядән килгән мөһаҗир татарларга кылган изге гамәлләре бихисап булды.

Бәлки, Кәмал бәй, эшем күп, иңнәремә дәүләткүләм зур җаваплылык салынган, фәнни белгечләр белән башкарасы тикшеренүләрем бихисап, дисә... Аның сәбәпләрен бүтәннәр аңламаслар идеме әллә?! Барыбер ул житешә алганча очрашуларга йөрергә тырышты, милләттәшләреннән читтә тормады, аннары бергәләп татар авылларына сәяхәткә дә барды әле...

Үзенә ярдәм иткәннәрне дә һич онытмады, «Садри Максуди Арсалның Сорбон университетындагы соңгы дәресе» дигән мәкаләсен ул остазының вафатына алты ел тулу уңаеннан язды. Үзе тыңлаган дәрес сабагын һәм хакыйкатен киләсе буыннарга җиткерәсе килде, ахры. Бу үзенә күрә, Йосыф Акчура, Исмәгыйль Гаспралы, Гаяз Исхакый, Садри Максуди кебек бөек шәхесләрнең изге гамәлләрен, гыйлемнәрен, рухи көчләрен дәвамлы итүнең бер алымы иде.

Дөрес, төрки халыкларның тормышына, мәдәниятенә, иҗтимагый һәм сәяси фикерләргә багышланган мәкаләләре санаулы гына, язганнары күбрәк геология-география, инженерлык кебек төгәл фәннәрне колачлады. Ләкин, шунысы хак: милли хисләрен аңлатканда да, төгәл мантыйкны сакларга, фикерләргә омтылды.

«Милләт тойгысы югары дәрәҗәдәге бер хиссият буларак беленер. Бу хиссият нормаль заманнарда тынычтыр. Сулаган һава кебек, аның барлыгын да абайламыйбыз. Бер куркыныч булса, милли тойгылар инсаннарга каршы торырга бер көч бирә. Органик фербөтенлек синтетик уңышка ирешү теләгеп ярата... Милләтчелекне аңламаган яки аңламаучылар кебек күренгәннәр

миллиятчелекнең кирәклеге булмаганын әйтәләр һәм гуманизмга сарылалар. Аларга күрә, милләт арадагы кирәксез бер элементтыр. Асыл булган – инсанлыктыр. Моңардан милләт аңын вә миллиятчелек фикерен читкә куеп, бар инсаннарны бертигез ясарга кирәк, дип әйтәләр. Бер караганда, бу бик уңайлы, үзенә җәлеп итә торган фикер кебек күренә. Ләкин бу фикер дөрес һәм реаль түгел. Чөнки милләтләрне юк итү мөмкин түгел. Бер җәмгыять эчендә гаилә ничек кирәкле һәм реаль аң яки фикер исә, кешелек дөньясы эчендә милләт шулай ук. Бүген дөньяның иң алга киткән өлкәләренә караганда, боларның милләт булганын күрәбез. Франция, Англия, Япония...»

Шул ук вакытта Кәмал Локман үз юлын ярды, җир асты байлыкларын өйрәнүдә, файдалануда яңадан-яңа уңышларга ирешеп, бөтен тырышлыгын шушы өлкәне үстерүгә багышлады. Энә белән кое казыгандай гыйлем туплады, тикшерде, җир асты байлыкларын эзләде, тапты. Гомере буена берьюлы күп төрле тармакларны тартып барды.

...Истанбулның тарихи үзәгендә якынча утыз квадрат метр мәйданлы ательега төрле чор мөһаҗир татарлар нигә җыелды соң? Әлбәттә, Ташхан тирәсендәгеләрне эшкуарлык берләштерә. Үзара ярдәм итешеп, киңәш корып эшләү чит җирләрдә югалып калмаска, гаилә тормышын тартырга, балаларын туендырырга ярдәм итә. Сәүдә һәм көнкүреш элемтәләрен бабаларыннан калган бер гореф-гадәт итеп нык тотарга тырышалар. Ә менә Хулуси ательесына җыелуларының тагын бер мөһим сәбәбе бар. Бу вакытта татарларның Идел-Урал җәмгыятен нәкъ менә ул җитәкли. Һәм шул сәбәпле, актив җәмәгать әгъзалары өчен аның эш урынына килеп фикерләшүләр гадәти хәл. Төркия кануннары таләп иткәнчә, җәмгыять исемен үзгәртергәме? Истанбулда калган һәм авыллар корып яшәгән татарлар белән ничек күрешергә? Корбан ашын ничек уздырырга? Татар авылларына сәяхәтләрне кайчан башларга? Бу очрашуда да сөйләшүләре шактыйга сузылды...

## Нефтьче инженер, геолог, җитәкче, язучы, галим

Кәмал бәй 1931 елдан башлап нефть өлкәсенә бәйле төрле географик, геофизик тикшеренүләрнең ничек узуы, җир асты казылма байлыкларының күләме, аларны ачыклау юллары турында мәкаләләрен язып бастыра башлады. Җөмһүрият корылгач, Төркиядә тәүге кара алтын эзләү-табу эшләрендә кайнаган вакытка бәйле, «Тикшерүләр. Рамандаг (Раман тавы) нефте» мәкаләсен 40 нчы елны кара алтын табылгач тәмамлады.

*«Биш-алты елдан бирле, Мардин һәм Сиирт арасында Ятмаларны тикшерү һәм эзләү институты тарафыннан гайрәт һәм ныклык белән башкарылган тикшерүләр нәтиҗәсендә, бу елның (1940. – авт.) 23 апрелендә – Балалар бәйрәме гарәфәсендә (алдагы көнендә. – авт.) нефть табылуы бөтен мәмләкәтне һәм милләтне сөенеч эчендә калдырды. Бу көн хәзерге заманда нефть эзләү һәм табу тарихында бөек бер башлангыч, бер үзгәреш көне булып тора.*

*Беренче Төркия нефтенең табылу көне Бөек Милләт Мәҗлесе (Төркия парламенты. – авт.) ачылган һәм Төркия Республикасы төзелгән көн алдына туры килүе бер хәерле галәмәттер.*

*Бу сәбәпле (Рамандаг Петроле) хакында гомуми бер парча язу файдалы булыр.*

*1934 елның язында Раман тавы географик яктан өйрәнелә башлый, 1937-1938 елларда геологик тикшеренүләр үткәрелә, җире тикшерелә. Фәнни тикшерүләрдән соң, 1939 елның язында, бу җирләрдә кое казу, бораулау турында карар чыгарыла. 19 майда кое казырга 5-6 тонналык скважина машинасы китерелде. Скважина ике ай дәвамында китерелде. Ниһаять, 1939 елның 24 июлендә җирне тишә башладык. 9 ай соңрак 1048 метр тирәнлектәге коеда нефть табылды.*

*Безнең нефть эзләү һәм бу юлда сарыф ителгән вакыт һәм акчаны, махсус кулланган машинабызны, техник җайланмаларны, башка милләтләрнеке белән чагыштырганда, иң кыска вакыт эчендә һәм аз чыгым белән эшләгәнебезне ассызыклап үтим. Чөнки башка милләтләр бер урынга 10-15 скважина белән кое казыганда, без бер белән тикшердек. Бу исә, әлбәттә, эзләнүләрне озакка сузды.*

*Дөресен әйткәндә, нефть эзләү эше бик кыен, күп көч һәм чыгым сорый торган бер эштер. Мәгълүм булганча, җир асты байлыкларын тәшкил иткән матдәләр, төрекөмештән тыш, җәүһәр таштыр. Нефтьнең болардан аерым үзенчәлеге бар. Ул май рәвешендә һәм, эчендә газ булу сәбәпле, урынын үзгәртергә сәләтле. Җирнең бер катламында ярылган, чатнаган урын тапса, шунда һиҗрәт итәр, күчәр.*

*Җәүһәр таш кайсы геологик дәвердә һәм кайда барлыкка килсә, шунда даими саклана. Хәлбуки, нефть, һиҗрәт итү үзенчәлекләре булганнан тыш, барлыкка килгән җирендә калмас, тупланмасына җиңел урынга китеп җирләшер. Шуның өчен кайчак нефть җыелырга мөмкин шартлар күренеп, кое казылса да, нефть чыкмас. Ул ноктаның, йә биш километр уң ягында, йә ун километр сул ягында, яисә көньягында һәм төньягында табылырга мөмкин. Нефть эзләү бик кыен, табылыр өчен бөтен билгеләре булса да, вакыт-вакыт шанс кирәк.*

*Сүзнең кыскасы, нефть назлы, ялындыра торган бер матдә, үзен кулай-кулай тәслим итмәс. Табылганчы күп эшләтер, арытыр һәм бәгъзам һич өмет ителмәгән бер җирдә һәм һич өмет ителмәгән заманда үзен күрсәтер. Икенче төрле әйткәндә, нефть эзләү, табу табигать белән бәйле көрәш, димәктер.*

*Җирнең өстендә һәм астындагы бөтен эшләр һәм тырышлыклар нәтиҗәсез, көтелмәгән вакыйгаларга тарыр. Дулкынланып көтелгән нәтиҗә вә уңышка ирешү өчен, күп ныклык һәм сабырлык таләп ителер. Кыенлыкларга түзем булганда, уңышка ирешү шансы артыр.*

*Югарыда күрсәтелгән сәбәпләрне күз уңында тотканда, нефть эзләү эшләребез һәм чыгым, һәм вакыт, һәм шанс ягыннан уңышлы булды, дип уйлыйм».*

Икенче бер мәкаләсендә Төркия нефть тарихын өч өлешкә бүлеп күрсәтте: Җөмһүрият төзелгәнчегә кадәрге вакыт (1890-1923), республика төзелгәч (1923-1938) һәм бүгенге көннәре (1938-1954). Һәм кара алтын эзләнгән, табылган дүрт-биш төбәккә күзәтү ясап чыкты:

*«Беренчесе – Искәндәр шәһәре тарафы.*

*Госманлы империясе чорына караган, 1887 елгы фәрман сакланган. Анда Камил паша дигән кешегә нефть эзләү рөхсәт ителә. 1899 елда алманнар һәм инглизләр 10 мәртәбә тикшерү уздыралар, коелар казыйлар. Әмма уңышка ирешә алмыйлар. Бөтен техник җайланмаларын Чәтәл авылы янына ташлап китәләр. Алман-инглиз фирмасы тарафыннан унга кадәр кечкенә скважина*

*бораулангани һәм нәтиҗәсе булмавы хакында 1913 елда «Яшь төрек» газетасында чыккан бер игъланнан өйрәндем.*

*Икенчесе – Тракия – Истанбулның Европа ягы.*

*Биредә 1892 елларда инглизләрнең 2 тонна табулары һәм ташлап китүләре мәгълүм. Аннары Австралия компаниясе тикшерүләр үткәрә, табалмый.*

*Өченчесе – Мусул шәһәре яны. Бу шәһәр хәзер Иракныкы.*

*Элеккеге еллардан бирле бу урыннарда кара алтын җиргә май кебек чыгып торган. 1903 елда бу җирләрне тимер юллар ясату бәрабәренә Алман банкы вакытлыча үзенә ала. Шуннан соң геологик тикшерүләр үткәрелә. Англия, Иран, Германия илләре «Төрек нефть компаниясе»н коралар. Берникадәр вакыттан соң аларга Америка, Франция, Армения кушыла. Һәм компания «Ирак нефть компаниясе» дип атала башлый. Төркия бу җирләрне Иракка калдырганда, 1926 елда Яңа Республика һәм Англия, Ирак хөкүмәтләре арасында килешү төзелә. 25 ел дәвамында кара алтын табудан кергән керемнең йөздән ун өлеше Төркиягә бирелергә тиеш була. Бу килешүгә 25 ел узып китсә дә, тормышка ашырылмый.*

*Дүртенче төбәк – Ван тарафы.*

*1916-1917 елларда Эрзурум һәм Ван шәһәрләре Россия кулында була. Ул вакытта геологик тикшерүләр үткәрәләр, нәтиҗәгә ирешмиләр. Россиядә революция башлангач, калдырып китәләр.*

*Күренә ки, бу дәвердә нефть эзләү һәм чыгару өчен рөхсәт биргәннәр, кире алганнар... Ширкәтләрне ачуландырудан башка яхшы бер эш күренми, нефть тә яткан бер җиреннән чыкмаган. Шуңа күрә бу дәверне нефть рөхсәтнамәсе спекуляциясе вакыты дип атарга мөмкин.*

*Төркия Җөмһүрияте төзелгәч тә, кара алтын эзләү туктатылмый.*

*Яңа төзелгән хөкүмәт нефть эзләү эшләрен мөһим саный. Моннан тыш 1926 елда «Төркия җирлегендә булган бөтен нефть эзләү, чыгарту, сату эшләре хөкүмәт карамагында» дигән закон кабул ителә. 1933 елда «Нефть эзләү һәм эшкәртү идарәсе корыла. Хөкүмәт хисабына Америка геологлары ярдәмендә Мардин шәһәре янында 1934 елда 1351 метр тирәнлектәге коелар тишелә. Нәтиҗә булмау сәбәпле, мондагы эшләр 36 да туктатыла. 1935 елда Җир асты байлыкларын эзләү һәм тикшерү институты төзелә. 1937 елда Хермиста 941 метр тирәнлектә газ белән аз гына кара алтын чыга. Башка урыннарда да нәтиҗәләр күренми.*

*1934 елда геологик тикшерүләр Раман тавы тирәсендә башлана, 1940 елны 1048 метр тирәнлектә 10 тоннага кадәр нефть табыла. Беренче коедан чыга, аннары бишенче коедан. Аңардан көнгә 1 тонна чыга, ул кое хәзергә кадәр гамәлдә. 1942 елда чыгарылган нефтьне эшкәртү өчен, кечкенә завод төзелә. Көнгә ун тоннага кадәр кара алтын эшкәртелә. 1945 елда сигезенче – 1316-1350 метр тирәнлектән көнгә 5-6 тонна кара алтын бирә торган кое казыла. Бу коега нефть сыеклаткыч салына, шулай итеп, ул 40-50 тонна нефть бирә башлый. Аннары инде тугызынчы кое казыла һәм Гарзан җирләрендә тикшерүләр башлана. Тикшерүләр вакытында ике төрек һәм бер америкалы хезмәткәрнең гомерен өзгән каза килеп чыкса да, эшләр туктатылмый. 1947 елда көнгә 1000 тонна эшкәртә алган нефть-битум заводы аякка бастырыла.*

*1933-1947 елларда (беренче нефть разведкаларыннан башлап, 8 нче, 9 нчы коелар ачылганга кадәрге вакыт), – 14 ел эчендә, икътисади һәм финанс яктан кыйммәткә ия нәтиҗәләргә Төркия – үз көче, технологияләре, белгечләре белән ирешкән ил».*

Кәмал Локман, бер яктан, нефть эзләүче инженер, җир асты байлыкларын өйрәнгән техник белгеч, кара алтын табуга бәйле эшләргә җитәкчелек итүче, икенче яктан, Төркия нефть индустриясе барлыкка килү һәм үсеш тарихына багышланган дистәләгән китаплар, йөзләгән мәкаләләр язган тарихчы, мөгаллим. Шул ук вакытта үзен чордашлары арасында җәмәгать эшлеклесе буларак белдерде, инженерлер, геологлар, нефтьчеләр җәмгыятьләрен коруга үз өлешен кертергә тырышты.

Хәер, язып кына калмады. Тәҗрибәсе һәм гыйлеме белән уртаклашу теләге көчле идеме, җир асты байлыкларына багышланган чаралар үзәгендә кайнады. Төпле җир белгече буларак ышаныч яулаганга, Төркиядә үткәрелгән фәнни чараларда, шулай ук чит илләрдә оештырылган дөньякүләм нефтьчеләр конференцияләрендә катнашуын, чыгыш ясавын көтеп алалар иде. 1951 елда Голландиядә, 1963 тә Франкфуртта дөнья нефтьчеләре җыелган конгрессларда булды. Француз, инглиз, гарәп һәм күп сандагы төрки телләрне яхшы белгән Кәмал Локман исеме нефть индустриясе белгечләре арасында танылган бер исемгә әверелде.

Мәсләге буенча йөргән-гизгән илләрне санарга кул бармаклары җитмәс: Бельгия, Германия, Чехославакия, Италия, Швецария, Австрия, Венгрия, Греция, Мисыр һәм башкалар. Дөньякүләм нефть табу, чыгару өлкәсендә кайнап, нинди генә җирләрне күрмәде, ә туган нигезенә аяк басалмады. Бары тик 1976 елны, гомере буе озата килгән җирсү, сагыш, сагыну хисләрен төяп, Төркистанга юл алды...

***

Кәмал Локман Ташкентта туганнары янында 1976 елда 77 яшендә бакыйлыкка күчә.

«Төркиянең әүвәлге җир белгечләреннән тагын берсен югалттык. Кәмал Локман Ташкентта кичергән йөрәк кризисыннан соң арабыздан аерылды», – диелгән төрекчә язылган рәсми хәбәрдә.

Мәшһүр нефтьченең кичерешләре һәм үлеме хакында Гаяз Исхакыйның кызы, Төркиядә танылган галимә Сәгадәт Чагатай ачык язып калдырган. Кәмал бәй вафатыннан соң, «Азәрбайҗан» журналында аның истәлек язмасы чыккан. Әлеге 1976 елгы журналны да сахафлар китерде. Шул язмадан бер өзек:

«Бу елның җәй айларында, туганнарын күрергә теләп, Ташкентка киткән югары дәрәҗәле инженер Кәмал Локман бәйнең алтынчы августта үлеме турындагы хәбәр алынды.

...Мәрхүм Кәмал бәй үзенең туган һәм бала чагы узган, бабалары туып-үскән Идел-Урал һәм Төркистан өлкәсен һич онытмас. Бөтен илдәшләрен дус тотар, аларга төрле ярдәм күрсәтер. Төрки өлкәләренең төрле җирләреннән килгән мөһаҗир дусларыбызның этиләре кебек иде. Һәрберсен самими каршылар, кулыннан килгән кадәр ярдәм итәр, эш җире табар, урнаштырыр. Шактый кече яшьтән эти кочагыннан, якыннары мохитеннән аерылып, күп нәрсәдән мәхрүм калып, үзен җитештергән. Бу ялгызлык һәм горбәт ачысы аның бөтен гомере буена сузылды, бер бала гаҗизлеге илә үз иле турында хатирәләре һәм сагыш-хәсрәтләре бар иде. Озак вакыт якыннарыннан хәбәр алмады, ниһаять, соңгы елларда языша башлады. Килгән хатларны куенында бер муска (дога) кебек яратып саклар, дус-ишләре белән аралашканда, алар турында кат-кат сөйләр, чыгарып укыр, шатлануын белгертер. Берара туганының баласын Төркиягә китертте, аның белән күрешеп, хәсрәтен басты.

Ниһаять, гомере буе сагынган вә бара алмаган якыннары мохитенә тормышының соңгы көннәрендә китте, күрергә теләде. Әмма үзенә яшәргә насыйп булмаган туфракларда күзләрен йомды. Аның насыйбы шул туфракларда күмелергә булгандыр, иншаллаһ, хәбәр ителгән кебек, якыннары тирәсендә, аны яратканнар арасында соң сулышын алгандыр. Ул теләгәнчә һәм үзенә лаек шәкелдә, кичергән авырлыкларына бүләк буларак, мөкатдәс Төркистан туфрагында күмелгәндер».

Шушы урында, бу язма аша, исеме үзенә лаек шәкелдә туган иленә кайтсын дигән теләк белән, тагын бер мисал өстисе иттем.

50 нче елларда нефть өлкәсенә килгән төрек тикшерүчесе һәм язучысы Халит Әдип Өзҗан үзенең кыскача нефть тарихына багышланган бер мәкаләсендә Кәмал Локман сүзләрен искә ала. «Кәмал Локман әйткән кебек, нефть «назлы» бер матдәдер. Ни язык ки, хәзергә кадәр өлкәбез өчен бик нык назланмыштыр һәм назлануын дәвам итәдер», – дип яза ул. Язмасын, милләттәшебез сүзләре белән башлавы бер җәлеп итсә, башка фикере горурлык хисен уята. Ул Төркиядә зур тырышлык куйган атаклы нефтьчеләрне өч буынга бүлеп исемлек төзегән. Әлеге исемлектә иң беренче булып Кәмал Локман исеме аталган.

Шуны да әйтү кирәктер: тәүге югары белемле нефтьче татар алып барган күпьеллык геологик тикшеренүләрдән соң, 39 нчы елны казый башланган һәм 40 нчы елны тәүге кара алтын табылган коелардан әлегә кадәр нефть чыга.

***

Төркиядә беренче нефтьне тапкан кеше татар бит!

Төркиядә таулар ел саен берничә сантиметрга урыннарыннан күчә!

Төркия, татар, беренче, нефть, еллар, таулар, тапкан, күчә...

Әлеге бер-берсенә һич бәйле тоелмаган ике җөмлә, күңелдә иләнеп йөри торгач, шушы рәвешле кәгазьгә ятты. Шул чакта гына бу сүзләр уртак бер мәгънә алды төсле.

Һәр заман, һәр мизгел күчештә. Җирнең һәр катламы, һәр байлыгы. Һәр милләт, һәр кеше ихтыяри яки мәҗбүри күчештә.

Йөзләгән чакрымнардан күренеп торган биек таулар урыннарыннан күчәр. Авырлыклардан сынмаган, гыйлем һәм хезмәт яраткан инсаннарны күченүләр шул таулар биеклегенә күтәрергә сәләтле.

Меңләгән чакрым аска – җир үзәгенә яшеренгән нефть «үзенең тупланмасы өчен җиңел урынга китеп җирләшер». Гыйлем, эш эзләгән һәм динен-нәселен саклаган мөһаҗир татарлар, бер-берсенә ярдәм итешеп, булышып, җиде ят җирләрдә тамыр җибәргән төсле.

...Әмма һичкем ул күчеш – табигый яисә иҗтимагыймы, яки шәхси булсынмы, кайда башланып, кайда тәмамланачагын әйтә алмас.



Вәсимә Хәйруллина

# ЙОЛДЫЗ БЕЛӘН КҮК МАТУР...

## Ватаным

Иксез-чиксез басулы,
Чишмәләре ярсулы,
Елгалары мул сулы,
Җирендә байлык тулы.
Бу җир минем Ватаным,
Минем Татарстаным!

Эшчән халкым, милләтем
Күтәрә татар данын.
Көрәшкәндә билле без,
Яуга керсәк, җилле без,
Нык тамырлы нәсел без,
Динле, илле, телле без.
Бу ил минем Ватаным! –
Кайнап тора дәрманың.

Кодрәтле батыр халкым
Саклаган татар данын.
Фидакарьлек каннарда,
Иман-әхлак җаннарда,
Булдырабыз, без – татар,
Татар барда бар хәтәр.
Бу минем горур халкым,
Бу ил минем Ватаным.
Тыныч атсын һәр таңың,
Яшә, Татарстаным!

Вәсимә ХӘЙРУЛЛИНА (1943) – *шагыйрә; «Тәгәрмәчле яңгыр», «Көмеш балдак», «Дуслык тагany» һ.б. китаплар авторы. Сарман районының Чураш авылында яши.*

## Чәкчәк

Гәрәбәдәй уелган,
Сап-сары бал коелган,
Чиккән сөлге өстенә
Түбәтәйләр куелган.

Чәкчәк табын түрендә
Яктылык сирпеп тора,
Затлылык кертеп тора,
Телеңдә эреп тора.

Манпасилы өсләре,
Кояш кебек төсләре.
Пешерүчесе кемдер, –
Ничек уңган төшләре!

Көлеп тора, кара син!
Белеп тора бәһасен!
Татар сыен кунаклар
Авыз итеп карасын.

Милләт йоласы, йөзе,
Бик тәмле телле үзе,
Кунакка милләтемнең:
«Рәхим ит!» – дигән сүзе.

Мирас – безгә борыннан,
Болгар иле чорыннан,
Игенченең сәламе
Алтын иген кырыннан.

## Яз

Яз сикерде түбәдән,
Көмеш тамчылар булып.
Кышның толыбын кисте,
Үткен кайчылар булып.

Гөрләвек булып акты,
Боз диварларны ватты,
Кошларны алып кайтты,
Җырлатты да сайратты.

Матур җырлар чалынды
Урманның колагына.
Алка-яфрак эленде
Агачка, куагына.

Итәк-җиңен сызганып,
Җиһанда яз йөгерә:
Җир ашлый, сөрә, чәчә,
Бар нәрсәгә өлгерә.

Җир, су, һава, җәнлекләр,
Кешеләр хәрәкәттә.
Эшчәннәргә шушы яз
Китерер бәрәкәт тә.

## Кош теле

Карлыгач теле түгел,
Сандугач теле түгел,
Чыркылдамый, сайрамый,
Чебен-черки ауламый.

Кош авызында түгел,
Ләкин кош теле үзе.
Әби пешерә торган
Камыр хакында сүзем.

## Кем чиртә, нәрсә чиртә?

Әти маңгайга чиртә:
– Тор, – ди, – бүген шәп иртә. –
Мондый көнне елгада
Балыклар әйбәт чиртә.

Рөстәмгә дәшим дисәм:
Тәрәз чиртәм – эндәшми.
Гитара чиртә таңнан,
Миңа гел исе китми.

Ярар, борынына чиртим:
Берүзем генә барам!
Чиртергә дип, кесәмә
Бераз көнбагыш салам.

Песи дә килә арттан,
Хәйләсен бик шәп беләм:
Күрми калсам, «чиртәчәк»,
Сыйланыр балык белән.

## Алабай

Алка койрык – Алабай
Бигрәкләр дә ялагай.
Күзе йомры чиядәй,
Теле –  алсу бияләй.

Минем кулымны ялый,
Үзе күземә карый:
– Ияртче мине, абый,
Кая барсам да яры-ы-й...

## Яратыйк

Йолдыз белән күк матур,
Чәчәк белән җир матур.
Безнең елмаюлардан
Туган-үскән ил матур.

Йорт яме – әти-әни,
Дус белән рәхәт уен.
Яшәү матур, күңелле,
Изгедә булса уең.

Дөньяга үзебездән
Шатлык таратыйк әле.
Илебезне, җирне без
Ныклап яратыйк әле!

## Бөреләр битен юа

Кыш сөяген сындырып,
Эретеп йә туңдырып,
Март килде кызып-кызып,
Юеш эзләрен сузып.

Пәкедәй үткен җиле
Карны чәрдәкли, тишә.
Тал кызларын уятып,
Билбау төенен чишә.

Түбәдән карлар шуа,
Бөреләр битен юа.
Кояш менә югары, –
Нурлары кышны куа.

## Гөберле

Яшел гөберле бака
Безнең бакчада ята.
– Гөбер-гөбер, чур-чур-чур!
Кара, күзе нинди зур!

Гөбер-гөбер, гөберле,
Булсын озын гомерле.
Ул бакчаны тазарта:
Лайлачларны ярата...

## Кыш һәм яз көрәше

Кыш тартыша. Яңгырларга
Карны бутый үч итеп.
Борын төрткән бөреләрне
Салкын йөри чеметеп.

Ләкин язның дуслары күп:
Кояш, тамчы, гөрләвек.
Яз җылысы, карны тишеп,
Кереп китә җиргә үк.

Ә анда ямь-яшел күзле
Үләннәр карап тора.
Иреккә чыгар көннәрен
Түземсез санап тора.

Кышның яралы йөрәге
Эреп бетә, тарала.
Җиһанда чәчәкле, җырлы
Яңа тормыш ярала.

## Яңа китап

Яңа китап – яңа дус,
Ал да кулыңа, таныш.
Рәссам ничек тырышкан:
Ясаган бик матур тыш.

Тышлыгы да шәп чыккан,
Ялтырап тора, каты.
Автор исеме – өстә,
Аннан – китапның аты.

Тышлыгын ачу белән,
Каршылар сине форзац.
Анда әле тагын да
Рәсемнәр булмый калмас.

Бик күп нәрсә белерсең,
Кереп китсәң эчкәрәк.
Кем рәссамы, нашире,
Ниләр сөйли эчтәлек...

Бәлки, булыр сүз башы,
Танышу автор белән.
Инде укый башларга
Ашыгасыңдыр, беләм.

Ярар, әйдә, рәхәтлән,
Укы китапның үзен.
Кинән, һәрбер юлыннан
Сеңдер акыллы сүзен.

Яңа китап – яңа дус,
Укуга һәвәс булсаң.
Әниең дә сөенер,
Яңа китаптан уңсаң.

## Кыш кичеккән

Кояш инде баеп бара,
Чыккан иде бит яңа.
Көнчыгыш белән көнбатыш
Көннән-көн якыная.

Көннәр кыска – бер тотамлык,
Көзге төн кара, шыксыз.
Җил йөри үтәдән-үтә,
Урманнары ышыксыз.

Юлда яфраклар кыштырдый,
Эзлиләр ышык урын.
Җилләр аларны бөтереп
Чыгара сары буран.

Ялангач калган басулар,
Шәп-шәрә бөтен җир-су.
Табигатьтә сагыш һәм моң,
Язларны көтеп җирсү.

Өшегән яшел уҗым да,
Хәтта болыт күшеккән.
Ак капкаларын ачарга
Кыш бүген дә кичеккән.

## Бәс

Ак чәчәктәй куаклар,
Агачлар ак, ак авыл.
Көмеш төсле бәс төшкән,
Үткән мәллә ак давыл?

Бәс – бабам сакалында,
Һәр мыек бөртегендә.
Кечкенә Сөмбелнең дә
Көмеш бәс керфегендә.



*Иҗтимагый үзәк, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты үткәргән фәнни конференциядә «фест дисбесе»н ничек укуы турында сөйли. 1993 ел*



*Эшләпәле Нурихан Фәттах белән хатыны Руфина. 25 апрель, 1965 ел.*



*Райондашлар. Сулдан уңга: академик Нил Юзиев, драматург Риза Ишморат һәм халык язучысы Нурихан Фәттах. 1993 ел.*



*Мәскәүдә СССР язучыларының VIII съездында катнашучылар. Сулдан уңга: Рәдиф Гаташ, Нурихан Фәттах, Нонна Орешина, Гәрәй Рәхим, обком вәкиле Дания Зарипова, Әмирхан Еники, Тәлгат Галиуллин, Ренат Харис, Илдар Юзеев. 1986 ел.*

# ТАТАР ИЛЛЕ НУРИХАН

Безнең буынга Нурихан Фәттах исемен мәктәп елларында ук хәтергә сеңдерү бәхете эләкте. Әдипнең «Бала күңеле далада» романы (1966), «Мөдир Саҗидә» (1968) повесте, хәтта нигездә балалар өчен язылган «Ирек, Алмаз һәм Җәлил» (1966), «Яшь чакларда» (1967) исемле хикәя җыентыклары белән бер сыйныфтан икенчесенә күчә-күчә таныштык. Сюжетлары әллә ни бормалы булмаса да, әсәрләр йөгерек, шаян теле, анысыннан да бигрәк – «таныш» геройлары белән җәлеп итә иде. Әйтик, ул заманда һәрбер зуррак авыл саен фельдшер-акушерлык пункты (аннан тыш әле почта бүлеге, җирле радио челтәре, электр станциясе, сельпо, пекарня, мәктәп, клуб, китапханә, әллә ничә төрле терлек фермасы, ындыр табагы, парник, тимерчелеге, ремонт цехы булган машина-трактор паркы, кирпеч заводы, пилорам, ветеринария участогы, май заводы бүлекчәсе, тегү мастерское, ашханә, икешәр-өчәр кибет) бар, ә Нурихан ага үзенең Саҗидәсен безнең авылдагы шәфкать туташы Әнисә ханымнан күчереп язган сыман. Башка геройлары, тиктормас комсомоллары да – авылыбызда чебеннән фил ясап, чикерткәдәй сикереп йөрүче замандашларга охшаган. Кайчан килгән дә, ничек танышкан бу Нурихан ага безнең яшьләр белән, дип аптырап укыган вакытлар әле кичә генә булып узган кебек. Чынында да, концерт-спектакльләрдә, сайлауларда катнашудан, «Комсомол прожекторы» гәзитен чыгарудан качып йөргән киребеткәннәр, кунакка кайткан кызның кулын бүлешә алмыйча тәпәләшеп алуны «һөнәр иткән» калай әтәчләр авыл саен бар иде бит инде...

Ул елларда ук авторының тормыш юлына, шәхесенә игътибар итү дигән мәнне белмәгәнбез. Ә югыйсә, Нурихан ага мин фәкыйрегезгә, Мөхәммәт ага Мәһдиев теле белән әйткәндә, «пачти» якташ туры килә. Мин – Сөн елгасының сулъяк ярындагы Актаныш төбәгеннән, ә ул – Башкортстанның терәлеп яткан Яңавыл районыннан. Студент елларында туган төбәгенә кайтып йөргән чакта Уфа – Казан трассасындагы безнең Байсар авылы аша да үтми калмагандыр. Кемнәр белә, табигатьнең гүзәл почмакларын сурәтләгән чакта, бәлки, Нурихан ага Сөн елгасын, аның аша язгы ташу узган саен, һәр елда да өр-яңадан салына торган агач күперләрен, Сөнне кичкәннән соң, машина-тракторлар менә алмый азапланган Каравыл, Чәүкә, Алкаби тауларын да күз алдына китергәндер әле. Алай дисәң, безнең як белән Нурихан ага үзе туып-үскән төбәкнең бизәкләре бер үк. Казан – Уфа юлы буйлап барганда, игътибар итәсезме? Ике арада 15-20 чакрым ара узган саен Аллаһы Тәгалә корган тау сыртлары ята. Әүвәл бер ягы – һәрчак текәләнеп менгән тау гөмбәзе, аннары икенче ягына сөзәкләнеп төшкән тау итәге, ике арада – инеш-күлләр чәчелгән зур иңкүлек. Бик биектән яки хыял күзлегеннән карадыңмы, кодрәтле көч коры җирдән океан дулкыннары ясап куйган сыман. Әле шунда каен, имән, нарат, усак, зирек, юкә агачларыннан хасил урманнарга, гөлҗимеш, чия, шомырт, карагат, камырлыкка бай куаклыкларга да урын табылган бит. Нурихан аганың студентлыктан соң, илленче елларның икенче яртысында, чирәм җирләрне күтәрергә дип, Павлодар өлкәсенә барып йөргәнен инде аның биографиясен өйрәнә башлагач кына белдем. Шыр далада, брезент чатырларда айлар буе газап чиккәннән туган төбәгенә, ашкына-ашкына, очкандай кайтуына бер шигем юк...

Ә биографиясен өйрәнүне Нурихан ага «Әтил суы ака торур» романы (1970) белән кискен мәҗбүр итте. Арттыру юк, татар дөньясын ядрә сыман шартлатты бу әсәр. Без инде, студент булып, Казан университетында гыйлем кыясын яулыйбыз. Ә тулай торакта, кулдан-кулга күчеп, инде яртылаш теткәләнеп беткән яңа китап йөри. Җитмешенче еллар, «сөекле» партия идарә иткән заман. Елдан-елга күчерелеп

барган исемлек буенча, безгә, булачак филолог-журналистларга, Алексей Толстой, Евгений Евтушенко, Борис Пастернак әсәрләрен дә советча укыталар. Лев Толстой, Михаил Шолохов, Василий Ян, Алексей Чапыгиннар да бөек, мәгәр аларның һәммәсе дә рус халкының гына язмышын вә тарихын тасвирлый шул. Тулай торакларда инде Василий Шукшинның Степан Разин фетнәсе турындагы «Я пришёл вам дать волю», Солженицынның «Один день Ивана Денисовича» кебек китаплары да кулдан-кулга күчеп йөри. Ләкин аларның һәммәсе дә һаман өлкән агай язмышы турында бит. Укырга тиешле әсәрләр йөзәрләгән, әмма сыңары да татар милләтенең язмышына багышланган түгел. Элеккерәк елларда безнең язмышыбызга кагылган хезмәтләр дә туыштырган, мәгәр алар җиде йозак астында, Үзәк Комитетның безгә үз тарихыбызны актармаска дигән 1944 елгы җәлладчыл фәрманы көчен югалтмаган. «Вак» халыклардан башкортларга Степан Злобин язып биргән «Салават Юлаев» романын укырга рөхсәт бар да, таба алсаң, казакъларның Ильяс Есенберлин язган трилогиясен укы. Ә татарга үз тарихына кагылырга, аеруча Алтын Урда дәүләте нигезләрендә казынырга кискен тыю! Бүгенге биеклеккә менеп алгач кына тәкәббер без, ә ул елларда үзебезнең болгар каһарманнары да, Билге каганнан алып Батыршаларга, Максуди-Исхакыйларга чаклы сузылган татар тарихы да дөм караңгы иде. Нинди 7-8 дәүләт тоткан, инде 552 елда ук Алтай даласындагы ташларга язылып, тарихларга кергән бөек милләт ди син? Кыйбладинең – коммунизм, ә үзең – өлкән агай канаты астына баскан совет милләтедер! Ятла шуны, ятла!..

Менә шушы кара пәрдәне безнең күздән Нурихан Фәттах алып атты. Шул бер «Әтил суы...» аша болгарларның VI-VII гасырларда ук Идел белән Чулман буйларына килеп урнашуын да, биш кабиләне үзенә буйсындырган Алмыш ханның 922 елда, «урыслар»дан да алда, дәүләт динен һәм ерак Баһдад хәлифәте кунакларын кабул итүе хакында да белеп алдык. Безнең аяк астында инде тураеп басардай һәм башны югары тотып атлардай тарихи туфрак пәйда булды. Бүген бөек Кол Гали һәйкәле, ханнар аллеясы, кабаттан аякка бастырылган Олы Манарасы, төзекләндерелгән төрбәләре, җир йөзендәге иң зур Коръәне, Ак мәчете, ахыр чиктә, дарелфөнүне – Ислам академиясе белән дан казанган Болгар каласы бөтендөньяның йөзек кашыдай кадерле ядкәрләре исемлегендә урын алган икән, аның халык хыялында формалашкан тәүге нигез ташын газиз Нурихан ага, бөек Фәттах салды! Һәм «Әтил суы ака торур» романында сурәтләнгән Болгар дәүләте хәрабәләреннән һаман арынмаган янәшәдәге Бөек Биләр белән Сувар да, Җүкәтау белән Кашан калалары да кабат аякка бастыруны өмет итә әле...

Ни кызганыч, шушы «Әтил суы ака торур» романы өчен «азык, чимал» эзләп, Нурихан аганың әле 1960 елларда ук Болгар каласы хәрабәләре урынында археологик казуларда катнашуын, әдәби романнан тыш дистәләгән тарихи мәкаләләр язып, тарихыбызның бүгенге яңарышына җирлек әзерләве турында искә алучы юк. «Әтил суы...» романын һәркем сөя, әле бүген дә эзли-эзли укый, әмма яңартылган Болгар туфрагына аяк бастыгызмы, анда Нурихан аганың исемен ялгыш та ишетмәссез...

Без җитмешенче елларда «Әтил суы...» белән саташып һәм очынып йөргән арада Нурихан ага тарихның тагын да ераграк төпкеленә, татар милләте формалашкан Ерак Көнчыгыш елъязмаларына чумарга өлгергән икән. Аның моннан 2600 ел элек үк бүгенге Кытай белән Монголия җирләрендә формалашкан татар кабиләләре турындагы «Сызгыра торган уклар» исемле роман-дилогиясе янә үткән тарихыбыз белән горурланырга мәҗбүр итте. 1980 еллар башында безнең өчен әле дөм-караңгы булган һәм Кытай дәүләтен дер селкетеп торган чаган татарлары, урман татарлары, берьюлы утыз күрем (курень – мең чатырны берләштергән ыстан) куярга да куәтләре булган кара татарлар турында да мәгълүмат алдык. Безнең колак өчен бөтенләй чит-ят булган алухай, ангыт, гәрәй, тугыз татар атлы ырулардан хасил шушы ерак бабаларыбызның киләчәктә бөек Алтын Урда каһанлыгын, үз башбаштаклыклары аркасында анысы таркалгач, Казан, Себер, Кырым, Касыйм, Әстерхан, Ногай ханлыкларын төзиячәкләре һәм ярты җиһанны биш гасыр буена дер селкетеп тотачаклары турында уйлап карарга да куркабыз, тәүге кат укыгач, хәтта үзебезнең Ерак Көнчыгыштан таралган милләт булуыбыз да кыргый фикер шикеллерәк тоела иде әле. Нурихан ага үзенә бозваткыч

ролен алган, аның «Сызгыра торган уклар»ы дөнья күргәннән соң, бер дистә ел үткәч кенә, безнең тарих фәнендә дә ерактагы татар милләтенең узган юлы турында йөзәрләгән хезмәт пәйда булды. Яшерәсе түгел, «болгарлыктан татарлыкка күчкән өчен» Нурихан аганы сөймәүчеләр дә, аңа аяк чалучылар саны да артты. Югыйсә, «болгарчы» яки «татар яклы», дип, читәннең ике ягында мөнбәр корып ызгышырга җирлек тә юк. Бөтенләй гадиләштереп бетерсәң, хакыйкать бәрәңге бакчасыдай аермачык төсмерләнә: болгар кабиләсе дә, татарлар да бер тамырдан чыккан. Ерак бабаларыбызның бер өлеше, Атилла җиһангирга ияреп, әле II-III гасырларда ук Европа кыйтгасына күчеп килгән һәм IV гасырда – әүвәл Кара диңгез, ә VII гасырда инде Идел буенда үз дәүләтен корса, шәрыкта калганнары, XI-XII гасырларда гына Кытай басымыннан качып бу якларга «кыяклый» башлаган, ә XIII гасырда инде Бату хан кул астында ташкын булып күчкән. Бөтенләй галәм югарылыгына менеп күз салсаң, Ерак Көнчыгыштагы төркиләрнең әүвәл җитлеккән өлкән улы «болгар»ны, аның артыннан «Сабантуй»лардагы көрәш өчен әзер «татар»ны да «башка чыгару», аерым йортлы итүе түгелмени? Ә асылда, ничек кенә бүлмә-боргалама – бер үк кан һәм гомумтөркиләр без!..

Кайсыдыр даһиның: «Адәм баласының уңышы яулаган үрләре белән генә түгел, ә ул кичәргә мәҗбүр киртә-каршылыклар белән дә үлчәнә», – дигән гыйбрәтле сүзләре бар. Туры сүзлелеге, бернинди дә чигенү-ялагайлыкларны белмәве өчен язмыш Нурихан агага да шактый тал чыбыгы ашатты. Гәрчә тәүге тарихи романы «Әтил суы...» ук Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булса да, партия карарларын колагына да элми торган Нурихан аганы коммунист түрәләр күз чалымына да китерми тилмерттеләр. Инде ике романнан хасил «Сызгыра торган уклар» да бер дистә ел буе бәяләнми ятты. Тукай бүләгенә дә Нурихан ага хаким фирка юкка чыкканнан соң, 1994 елда гына лаек булды. Нурихан аганың менә шулай типкәләнеп йөрүен күз алдыннан кичергәч, әдипнең соңыннан Рабит Батулла шаяртып язган студентлык еллары күз алдына баса.

Нурихан ага студентлыкка аяк баскан 1946 ел. Бөек Ватан сугышы китергән тоташ җимереклек, ялангачлык, мохтаҗлык өстенә коточкыч ачлык килеп өстәлә. Ярымҗимерек тулай торакның бер бүлмәсендә 40-50ләп егет бергә гомер кичерәләр. Кулда акча, әле берәр төрле ялланып эшләүдән соң анысы табылса да, базарында да ризык-ашамлык юк. Кайсыдыр бүлмә егетләре Казан янындагы колхоз кырларыннан җир астында калып туңган кишер-чөгендер җыеп кайта, Нурихан абыйның ишләре «байлар» әрчегәннән соң ихатага чыгарган бәрәңге кабыкларыннан кичке «сый» әзерли. Һәрбер егет холкында авыл агайларына гына хас кысмырлык, алга карап исәп тоту да яши. Ашханәдә кәбестә шулпасын «сосып» куйганнан соң, кичкелеккә йә иртәнгә дип, коры-сары, ипи катысын җыеп кайту бар. Ризыкны тумбочканың иң түренә яшереп ләззәт кичерәләр, кайберәүләр ясалма гына йозаклар да элә. Мәгәр файдасы юк, кайбер төндә хәтта шул йозаклы тумбочкалардан да «мал» югала ди. Соңрак ачыкланган: студент елларында комсомол активисты булып исәпләнгән, тора-бара өлкә комитетның олуг түрәсенә әвереләчәк берәү чит-ят хисабына сыртта утыруны егет чагында ук кәсеп иткән икән...

Нурихан ага партия, аның түрәләре белән, асылда, санлашмый гомер сөрде. Икенче бер хатирә искә төшә. Нурихан аганың инде, гаилә корып, Киров районындагы иске агач йорт фатирында гомер итеп яткан вакыты. Ул урамдагы сәләмә йортларны сүтеп, анда «яшәүчеләрне» яңа районга күчерү турында сүз таралгач, бөтен тирә-күрше хакимият янына, кабинетлар ишеге төбенә чыгып чаба. Нурихан ага үзенә нинди кара мөһер сугылган булуын да, очсызланып чабулауның файдасызлыгын да тиз чамалый. Ул тота да, җитмеш-сиксәненче елларда әле ятим, ташландыграк исәпләнгән Нагорный бистәсендә участок ала. Шәһәрнең сүтелергә хөкем ителгән кайсыдыр урамында 1900 еллар башында ук корылган бер иске бай йортын да карап куйган икән. Анысын да сатып алгач, көз айларында сүтеп кайтара да, икенче җәйдә «бай сараен» яңартып һәм сипләп, кабат җыеп куя. Таш нигезен хатыны Руфинә ханым белән бергәләп үзе сала, ишек-тәрәзәләрен, түбә-кәрнизләрне дә, күңеленә ятардай итеп кыргачлый. Иң мөһиме – Нурихан ага таш җанлы түрәләр каршында йөз суы түгеп йөрүдән котыла,

гомерен туктаусыз иҗат белән үткәрү өчен, үзенә оя әзерли... Нурихан аганың ни дәрәҗәдә хуҗалыкчан булуын нык чамалыйм. XIX йөз азагында, XX гасыр чигендә татар байлары тергезеп калдырган нарат биналарны байтак күрдем. Әгерҗе районының Иж-Бубый авылында сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Әхмәтҗанов шәкертләр өчен дип 1884 елда төзеткән мәдрәсә бинасы 2010 елга чаклы район үзәгендә туган як музее булып та хезмәт итте әле. Шул ук райондагы Татар Шаршадысы авылында генерал Шәехгали йорты кичәге көнгә чаклы әүвәл урта, аннары тугызъеллык мәктәп иде. Мамадыш районының Дүсмәт авылында духовная семинария өчен төзелгән уку йорты бинасын 1980 еллар үрендә дә «әрәм» итмәделәр – Минзәлә төбәгендәге яңа бер «бай», сүтеп-җыеп, үзенә куыш корды. Иж-Бубыйда Мөхәммәтҗан бай 1880 елларда ук төзегән нарат мәчет каршында бүген дә баш ия аласыз. Бүрәнәләре арасына киез түшәп салган әлеге ике катлы йорт әле бүгенге «бөек» төзүчеләрнең дә борынына чиертерлек дәрәҗәдә кукраеп утыра... Ә Нурихан ага каршында мин шушы «авылчанлыгы», хуҗалыкчанлыгы өчен дә баш иям. Үз кадерен үзе белгән, башкалардан таптатырга ирек куймыйча яшәгән ир-егет ул...

Татар әдәбиятында Нурихан агага кадәр булган мирасны күзаллыйм. Бөтенләй үк бушлык, дип кырт кисеп тә булмый. Афзал Таһировның тарихи әсәрләр исемлегендәге «Ямалкә тавы», мәсәлән – заводларда крепостной булып газап чигүче һәм, азат дәүләт төзүгә өметләнеп, Емельян Пугачёв явына кушылган татар крестьяннары турында 27 битлек повесть. Газиз Гобәйдуллинның «Татар-башкортлар Пугачёв явында» атлы 9 битлек тарихи очеркы бар. Шул ук Газиз Гобәйдуллин «Тарихи сәхифәләр ачылганда», бөек Мәрҗани «Мөстәфадел-әхбар...», Ризаэддин хәзрәт атаклы «Асар» хезмәтләрен язып калдырган. Ләкин исегезгә алыгыз: аларның барысы да диярлек фәкать 1990 еллардан соң, безгә хәбәрдарлык һәм мөстәкыйльлек килгәннән соң гына нәшер ителде, аңа чаклы әлеге әсәрләр турында ишетеп белүче дә санаулы иде. Ә Нурихан ага «Әтил суы ака торур» һәм «Сызгыра торган уклар» романнарын, алардан тыш тагын йөзәрләгән тарихи язма һәм мәкаләләрен 1970-1980 еллар башында ук бүләк итте. Ул – татар әдәбиятында тарихи романнарга нигез салучы да. Ул – татар өчен ябылган, бикләнгән, тыелган тарихи торгынлык буасын ерып җибәрүче дә. Әмма, ни үкенеч, Нурихан аганың романнары да, «Фест дисбесе» шикелле дистәләгән хезмәте дә һич югы төрки телләргә булса да тәрҗемә ителмәгән. Тәрҗемәгә дисәң, бездә елгыр җаннар, үзләренең бер яңалык та өстәмәс һәм теләсә кайсы милләттә кабатланырга, яңгырарга мөмкин гыйшык яки табигать күренешләре турындагы куплетларын урыс, казакъ, азәри, үзбәк, хәтта инглиз теленә дә калыплау өчен, акча дигәннәрен таба белә, ә менә татарның ачы язмышын, ул үткән газаплы да, шанлы да көрәш юлын, бөек Алмышлары, бөек Кол Галие, дөя шикелле тез чүкмәгән өчен, башы кыеп төшерелгән Бачман тарханы, Бикчура ханы, Мәскәүләрне дер селкеткән Туктамышы, 50-60 еллар буена милләтнең азатлык яуларын җитәкләгән Теләкәй-Күчем-Акайлары, коллыкта да кулына балта тотып һәм дошманнарының башын ярып, теле йолкынган, әмма аягүрә һәлак булган Батыршасы, 68 яшендә төрмә диварына терәп юк ителгән Мөхлисәсе турындагы әсәрләрне чит халыклар алдында яңгыраттыру өчен акча бирүче юк... Зыялылык җитмәгәнгә, Исхакый, Сәйдәш, Нәкый Исәнбәт, Нурихан Фәттах исемнәре өч-дүрт йортлы урамнарга «чәпәп» куелган. Йә, оят-хурлык түгелме бу?

Башкортстан турында аерым әйтү зарур. Безнең әдәбият белән сәнгатьне яртылаш рәвештә диярлек бүгенге Башкортстан җирлегендә туып-үскән талант ияләре тулыландырып торды. Җитмешенче елларда анда җанисәп вакытында татар халкын көчләп башкортлаштыру башлангач, Нурихан ага кебек фидакярләребез дәшми кала алмады. Туры сүзле әдип «Казан утлары» журналында «Башкорт» атлы мәкалә бастыруга, ике милләт арасына чөй кагуда гаепләп, көтү-көтү дошманнары аның өстенә ташланды. Шуннан соң хәтта туган ягына юл бикләнде, аны күзләрен акайтып текәлгән көе дә күрми башладылар. Гәрчә дәшми калганнары да шундый ук аяныч язмышка дучар булды. Башкортстан туфрагыннан чыгып, иҗат күгенә менгән рәссамыбыз Эрот Зарипов, Нәкый Исәнбәт, Әмирхан Еники, Риза Ишморат, бертуган Нил һәм Илдар Юзеевлар, Нурихан Фәттах, Әхсән Баян, Саҗидә Сөләйманова, Әдип Маликов, Ризван Хәмид, исәннәрдән Рәдиф Гаташ белән Роберт Миңнуллин һәм тагын

әле дистәләгән талант ияләренең туган җирләрендә музей-һәйкәлләре, алар исемендәге урам һәм мәктәпләр юк. Гаҗәеп хәл: «читтә» туып-үскән булгач, моны безнең хөкүмәт ияләре дә Татарстан туфрагында күтәреп чыкмый, алар Башкортстан җире өчен дә чит-ят икән. Президентыбыз һәм хөкүмәт әһелләренә әлеге сансызлыкка чик куярга, тугандаш республика белән уртак тел табарга да күптән вакыт лабаса!..

Хатирәсе белән бәгырьләрне менә шулай итеп теткәләгән, әмма гаярьлеге өчен сокландырган Нурихан ага белән шәхсән үземә фәкать 1984 елда гына танышу бәхете эләкте. Гәрчә әле сыңар китабым чыкмаса да, «өметле каләм», дип, мин фәкыйрегезне дә Татарстан Язучылар берлегенең чираттагы корылтаенда катнашырга чакырдылар. «Волга» кунакханәсенә урнаштырдылар, корылтай өч көн буе барды (коры хисап белән сайлаулардан гына хасил соңгы корылтайлар белән чагыштырышлы да түгел). «Казан утлары» журналында Нурихан аганың «Сызгыра торган уклар» романы басылып чыккан, ә без аңа мөкиббән киткән көннәр. Үземнең «пачти» якташ икәнлегемне әйтеп танышкач, Нурихан ага тик бер генә сорау бирде бугай: «Ни язасың?» «Хикәяләр тырмаштырам», дигән җавап әсир итмәгәндер, шуннан соң безнең аралашу кул кысышудан ары узалмады.

Ун ел үтеп китте. 1994 елда «Сәет батыр» китабым дөнья күргәч, «Төрек араштырмалары вакыфы» аша Төркиягә кунакка чакырдылар. Шушы җәмгыятьтә торучы галимнәр белән әңгәмә вакытында Нурихан аганың яклаучысына әверелдем дә куйдым. Төрек галимнәре берничә юл аша татар оешмаларыннан Нурихан аганың тарихи романнарын, алардан тыш әле «Шәҗәрә» исемле китабындагы «Фест дисбесе»н тәрҗемә итү һәм бастырып чыгару өчен рөхсәт сорый, әмма ул елларда Төркиянең Министрлар кабинетына кадәр сукмак салып өлгергән үтә елгыр татар түрәсе боларның ниятен сугым пычагыдай кисеп бара икән. Төрек әдәбиятчылары Әмирхан Еникинең хикәяләр җыентыгын, Батулланың «Сөембикә» романын, фәкыйрегезнең «Сәет батыр»ы белән «Татарларның Ватан сугышы» әсәрләрен дә төрекчәгә калыплау турында теләк белдереп караган, әмма түрә һәммәсенә кара мөһер суга, «башканлык» аша боларга юл бикли…

Исән чакта Нурихан аганың да ул киртәне ерып чыгарга, буа шикелле киртәләнеп куелган тыюлыкны җимерергә куәте җитмәде. Ходайга шөкер, еллар үткәннән соң, Нурихан аганың «Аллаһ һәм фиргавеннәр теле» исемле хезмәтен үзләренчә укып, меңәрләгән төрек татар әдибенә гашыйк булды.

Мин исә Нурихан аганың буйсынмас, горур, тәвәккәл булуына гомер буе сокланып яшәдем. Аның белән кунакларга йөрешү, табын уртаклашу бәхете елмаймады. Ләкин беләм, ул минем «Татарларның Ватан сугышы», «Сәет батыр», «Татарлар Пугачёв явында» исемле әсәрләремне сөенеп кабул иткән иде, үз якларында – Яңавыл, Борай, Балтач районнары җирлегендә булып узган яулар турындагы хәбәрләр өчен һәрчак рәхмәт әйтте. Соңгы бер-ике елда гел шалтыраткалап яшәде, кунакка да дәште. Тормышның өч тиенгә дә кирәксез мәшәкате аркасында вакыт таба алмадым. Аның 75 яшьлек юбилей кичәсенә дә чакырулы идем. Остазларымның берсе булган Мөхәммәт Мәһдиевнең яман чир белән интеккән вакытында, мескен хәлгә калуын чит-ят күзгә күрсәтмәү өчен, ишеген бикләп тотуы канга тикле сеңгән. Мин шул ук яман чир эзәрлекләгән Нурихан аганың юбилеена да бармадым. Бәлки, нәкъ шуңадыр, Нурихан ага хәтеремдә һәрчак үтә чибәр һәм бөркеттәй гаярь, ярымшаярган дустымдай, гел елмаеп тора. Исән чакта аны бары тик шундый итеп сагынырмын.

**Вахит ИМАМОВ**

# «ТЕГЕРМӘНДӘ» НИЛӘР БАР?

Дөнья шулай яратылган: җир йөзендә һәрнәрсәнең башлангычы була. Берни дә юктан гына хасил түгел. «Әүвәл йомырка барлыкка килгәнме, тавыкмы?» соравына җавап таба алмасалар да, әдәбиятта иң элек язучы формалашкан, шуннан соң гына әсәр язылган, дип шикләнми әйтә алабыз.

Шулай да язучы нидән башлана соң? Туган төбәк, ата-ана тәрбиясе, белем алган мәгариф учагы, җәмгыять, мохит, сәясәт... һәм, гомумән, яшәешнең бер генә өлкәсенә дә битараф булмаудандыр. Саналганнарның һәммәсенә бәйле рәвештә, тәүге иҗат җимешләре үзебез күреп кичергәннәрне бәян итүдән оеша. Кайсы гына прозаик әдипне алма, аның беренче җыентыгындагы хикәя-хикәячекләр – балачак, үсмерлек елларында «яшәлгән» вакыйга үрнәкләре, маҗаралы һәм мавыктыргыч ситуацияләр. Алар әле өйрәнчек кенә, бик самими, әдәби яктан эшләнешләре дә «беренче коймак төерле була» гыйбарәсенә туры килә. Әмма да ләкин әдиплеккә имза салынган Тукай премиясе лауреаты, халык язучысы дәрәҗәләренә ирешкән олпатларыбызның үсеш эволюциясен, иҗатына башлангычны кайдан алуын, гомумән, чишмә башын тәгаенләргә ярдәм итә. Чагыштырма юнәлештә караганда, кызыклы гына фактлар да ачыла: кайбер язучыларыбыз өлкәнәйгән көннәрендә дә тәүге китабындагы сыйфат-дәрәҗәдән ерак китә алмый.

Филфак студентлары арасында көрпәле юмор белән исемнәре аталган «Безнеңчә берничек тә түгел» (дөресе – «Сезнеңчә ничек?»), «Әтил суы акмый торсын» («Әтил суы ака торур»), «Сызгырта торган уклар» («Сызгыра торган уклар») һ.б. әсәрләре аша күңелләргә уелган Нурихан ага Фәттах иҗаты әлеге фактtan шактый ерак тора.

«Иң беренче шигыремне мин өченче класста укыганда яздым. Кыш көне иде. Дәрестән соң елга аръягында, чыршылыкта чаңгы шуып, туңып-ачыгып кайттым да күңелне биләгән шатлыклы тәэсирләрне кәгазьгә төшермәкче булдым. Шигырьне мин «Кыш» дип атадым һәм Яңавыл районында чыга торган «Октябрь юлы» газетасына җибәрдем. «Шигырь»не, билгеле, басмадылар. Авторга хат-фәлән дә килмәде бугай...» – дип искә ала ул үзенең әдәби каләмгә үрелә башлау мизгелләрен. Әдип фикеренчә: «Язучы булу өчен күп нәрсә таләп ителә. Иң әүвәл табигый талант һәм тырышлык кирәк. Ләкин сине аңлаучы, кирәк чакта сиңа ярдәм кулы сузучы халкың – әйе, халкың! – булмаса, ялгыз талант белән генә әллә ни ерак китеп булмый».


Татарның тарихын каплап торган таш кыяларны җимереп кереп, бикле йозакларны азау теше белән өзгән Нурихан ага гомере буе шул халкына тугры кала. Үзгә бер самимилек белән өртелгән тәүге, без бүген тәкъдим итәчәк «Тегермәндә» җыентыгына тупланган хикәяләрен укыгач, милләт күгендә якты йолдыз булып балкыган олпат әдип язмагандыр аларны, дип, бераз елмаеп та куясың.

«Тегермәндә» мәҗмугасы 1957 елда Татарстан китап нәшриятында сигез мең тираж белән дөнья күрә. Редакторы – Резеда Вәлиева. Бәясе – 65 тиен.

Үз эченә дүрт хикәяне туплаган ул: «Безнең бабай», «Балыкчылар», «Велосипедлы Мөнир», «Тегермәндә». Аларның барысының да геройлары – үсмер малайлар. Җәй көне авылга әбиләренә ялга кайткан Рөстәмнең нәни ачышлары да, балык каптырырга юнәлгән Әдһәм, Сабирҗан, Вәлинең кармак салу серләре дә, велосипедка ия булып, масаеп, дусларын оныткан Мөнирнең кыланмышлары да, җигүле ат дилбегәсен үз кулына алып, әтисен утыртып, тегермәнгә юл алган Җәмилнең анда күргәннәре – барысы да шул чор үсмерләренең психологиясен ачып бирә, бүгенге көндә дә актуальлеген югалтмый.

«Безнең бабай» – җыентыкны ачып җибәргән хикәя. Әйдәгез, укып, бергәләп искә төшерик аны – «Әдипнең тәүге китабыннан...»

**Рамил ХАННАНОВ**



Нурихан
Фәттах

# БЕЗНЕҢ БАБАЙ

ХИКӘЯ

Бәләкәй Рөстәм җәй көне әнисе белән авылга – әбиләренә кунакка килде. Алар үзләре бик еракта, бер зур шәһәрдә торалар иде. Рөстәмнең әле беркайчан да авылда булганы юк иде. Әбисе аны бик ягымлы йөз белән каршылады, тәмле әйберләр белән сыйлады.

Әби үзенең олы улында тора иде. Ә аның улының хәзер үзенең дә бәләкәй балалары бар иде. Рөстәм алар белән бик тиз дуслашып китте.

Ул аларга үзләренең матур шәһәрләре турында, ишекләре үзеннән-үзе ачылып ябыла торган трамвайлар, троллейбуслар турында, зоопарктагы маймыллар, юлбарыслар турында сөйләде. Балалар аны исләре китеп тыңлап тордылар.

– Бездә андый кызык нәрсәләр юк шул, – диде Хәлим. – Безнең авылда сиңа күңелсез булыр инде.

– Бар, бар! – дип кычкырып җибәрде шулвакыт бәләкәй Фәһимә. – Бездә саескан оясы бар! Менә!.. Абый, әйдә, Рөстәмгә саескан оясын күрсәтәбез!

– Әйдә!

Балалар, җитәкләшеп, ындыр артына таба йөгерделәр. Саескан оясы авыл янындагы урман эчендә иде.

Хәлим, бөтенесеннән дә зуррак булганга, алдан китте. Алар болынга килеп җиттеләр.

Еракта, урман буенда, сыер көтүе утлап йөри иде. Хәлим мактанып куйды:

– Әнә безнең көтү!

– О-о, нинди күп икән сезнең сыерларыгыз! – диде Рөстәм, гаҗәпләнеп.

Шундук Фәһимә сүзгә кушылды:

– Әйе, безнең сыерлар бик күп. Менә!.. Сарыклар да күп безнең. Бөтенесенекеннән дә күбрәк, Саттар бабай үзе әйтте.

Якындагы юлдан тузан туздырып автомашина узып китте.

– Безнең машинамы бу? – диде Фәһимә, кулын маңгаена куеп. – Ә, безнеке икән!

Урманга килеп җиткәч, балалар саескан оясын бөтенләй исләреннән чыгардылар. Күп сөйләнергә яратучы Фәһимә:

– Абый, әйдә умарталыкка барабыз?! – диде.

Аннан соң Рөстәмгә:

– Бабай безгә бал ашатыр... Безнең бабай бик юмарт ул. Менә... күрерсең әле! – диде.

Умарталык урман эчендә иде.

– Әйдәгез, – диде Хәлим. – Рөстәм безнең умарталыкны күрер, бал кортларын күрер.

Балалар тиздән умарталыкка килеп җиттеләр. Аларның каршысына умартачы бабай килеп чыкты.

– Минем кортларның хәлен белергә килдегезме? – диде бабай, елмаеп.

Ул аларны тәбәнәк кенә бер өй эченә алып керде дә өстәл янына утыртты, һәрберсенең алдына берәр тәлинкә бал куеп чыкты, берәр балкалак белән берәр телем күмәч бирде.

Рөстәм хуш исле сыек балны бик яратып ашады.

– Ашагыз, ашагыз, улларым, кызларым, – диде бабай. – Кортлар бу балны бүген иртән генә җыеп алып кайттылар. Бал ашарга балалар килсә, безнең балны кызганмый ашат, диделәр. Тәмлеме, туйдыгызмы? Туйгач бал да ачы... Ачы була башладымы әле?..

Балалар, бал ашап туйгач, бабайга, бал кортларына бик зур рәхмәт әйттеләр дә килгән юллары белән кире кайтып киттеләр. Бабай аларны урман авызына кадәр озатып куйды.

– Сездә бик күңелле, мин гомергә авылда яшәр идем! – диде Рөстәм.

Алар өйгә кайтып җиткәндә, кич булды. Тиздән зурлар да кайтты. Бөтен гаилә ашарга утырды. Барысы да ашарга тотындылар.

Шул чакны әби Рөстәмнең, нәрсәдер көтеп, ашамыйча утыруын күрде.

– Нигә ашамыйсың, улым? Әллә яратмыйсың? – диде әби.

– Мин бабай кайтканны көтәм, – диде Рөстәм. – Нигә сез дә көтмисез, кайтып җитәр инде ул.

Барысы да, гаҗәпләнеп, ашаган җирләреннән туктап калдылар.

– Нинди бабай? – диде Рөстәмнең әнисе, улының ни сөйләгәнен аңламыйча.

– Бабаңның үлгәненә ун ел була инде, улым. Исемә төшердең мәрхүмне, – диде әби, яулык очы белән күз яшьләрен сөртеп.

Рөстәмгә бик уңайсыз булып китте.

– Безгә бал ашаткан бабай соң... – диде ул, ни әйтергә дә белмичә.

Хәлим белән Фәһимә кычкырып көләргә тотындылар. Рөстәм кып-кызыл булды.

– Кортчы Галләм бабайны әйтә ул, – диде Фәһимә. – Бүген ул безгә бал ашатты.

– Нишләп ул синең бабаң булсын? – диде Рөстәмнең әнисе, тагын да ныграк гаҗәпләнеп.

– Үзләре «безнең бабай», «безнең умарталык», диделәр, үзләре көләләр... – диде Рөстәм, үпкәләп.

– Кемнәр?

Рөстәм Хәлим белән Фәһимәгә төртеп күрсәтте.

– Алайса, көтү дә, машина да сезнеке түгелмени?

Хәлимнәрнең әтисе балаларына ачулы гына карап алды.

– Нәрсә алдашып йөрисез сез? – диде ул аларга.

– Юк, без алдашмадык, әти. Нигә безнеке булмасын – безнеке! Сыер көтүе дә безнеке, автомашина да, умарталык та безнеке – безнең колхозныкы. Без алдашмадык, – диде Хәлим.

Аның сүзеннән беркем дә көлмәде.

# КАЛӘМ АЛСА – УЙ САЛЫР!

## ДАНИЛ САЛИХОВКА 60 ЯШЬ

Театр дөньясында актёрлыктан драматурглыкка күчкән шәхесләр бик ишле һәм бу табигый дә. Габдулла Кариев, Таҗи Гыйззәт, Галиәсгар Камал, Туфан Миңнуллин, Рабит Батулла, Әмир Камалиев, Фәнәвил Галиев, Гафур Каюмов һәм, әлбәттә, хәзерге татар драматургиясен әйдәп баручы әһле каләмебез Данил Салихов – профессиональ актёрлар өммәтеннән. Бүгенге көндә аның төрле театрларда кырыкка якын пьесасы куелган. Ә күпмесе әле үз вакыты җиткәнен көтеп ята...

Драматурглар арасында төрле жанрларда эшләүче әдипләр дә җитәрлек. Шәриф Камал, Илдар Юзеев, Аяз Гыйләҗев, Ркаил Зәйдулла, Ләбиб Лерон, Мансур Гыйләҗев, Хәбир Ибраһимовлар... Бу хөрмәткә лаеклы язучыларыбызның нинди киртәләр, каршылыклар, язылачагының асылына төшенә алмаулар аша драма жанрына интегеп килүләрен аңлар өчен, олуг язучыбыз Илдар ага Юзеевның: «Мин көнләшәм сездән (бу очракта – Данил Салихов белән Рәдиф Сәгъди. – *Р.С.*), сез, актёр буларак, сәхнә законнарын яхшы белү сәбәпле, турыдан-туры драматургиягә кереп киттегез, ә минем исә, театр сәнгатен яратучы буларак, егерме елдан соң гына әсәрләрем сәхнәдә куела башлады...» – дигәнен хәтергә төшерик. Әйе, драма ул – математика кебек четерекле фән, фәлсәфи фән, аның сөйләме дә үзгә, тормыштагы кебек, вакыйгаңны конфликтка корып, идеяңне үстерә алырга өйрәнәсең икән, бәлкем синнән пьеса язучы да чыгар! Һәммәсе дә үҗәтлегеңнән, талантыңнан тора...

Данил Салихов – минем күз алдымда актёр да, драматург та булып үскән шәхес. Бер чорда театр училищесында уку, соңрак бер сәхнәдә уйнау безнең араларны якынайтты, бер театрда актёр булып эшләгәндә, шактый аралашып киттек, дисәм, дөрес булыр.

Данил Салиховның иҗат юлына кереп китүе Актаныш районының Киров совхозы, күрше-тирә авылларда сәхнә тотуы, җырга һәвәслегеннән башлана. Ул 1976 елны Казан музыка училищесына вокалистлар группасына укырга керә. 1979 елны даһи сәнгатькәрләребез җыйган милли театрларга кадрлар әзерләү курсына күчә. СССРның халык артистлары М.Сәлимҗанов, Татарстанның халык артистлары А.Хәйруллина, Н.Гәрәева, И.Хәйруллиннар аларны сәхнә серләренә өйрәтә. Бу төркемнән Академия театрының күренекле режиссёры, Г.Тукай премиясе лауреаты Фәрит Бикчәнтәев, драматург Гафур Каюмов, театр директоры дәрәҗәсенә кадәр күтәрелгән Роберт Мортазин, Татарстанның халык артисты Венера Шакировалар чыкты. Сәнгать мәктәбен тәмамлагач, Татар дәүләт Академия театры сәхнәсендә дистәгә якын спектакльләрдә төрле холыктагы рольләрне башкарды ул. Зур талант иясе Д.Сираҗиев 1983 елда куйган «Алмазбулат» пьесасында (авторы – Ю.Сафиуллин) – төп роль Алмазбулат; чит ил классикасы «Причуды Белисы»да (Лопе де Вега) – Пруденьсью (1983). Бу әсәрне Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштергән иде. Шулай ук М.Горькийның «Минем университетларым» (1984) спектаклендә Студент роле. Режиссёры – даһи Празат Исәнбәт. Озакламый язмыш безне кабат күчмә театрда, ягъни К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театры сәхнәсендә очраштырды. Биредә дә ул кыска гына вакыт эчендә дистәдән артык образ тудырып, язучылыкка кискен адым ясарга нигез салды, 1987 елны Празат Исәнбәт режиссёрлыгында аның беренче пьесасы – «Туй күлмәгем – соңгы бүләгем» дөнья күрде. Төп роль Дамирны мин фәкыйрегезгә бик озак еллар төрле төбәкләрдә, Урта Азиядәге республикаларда да уйнарга туры килде. Фаҗигале мәхәббәткә багышланган бу әсәрне халкыбыз җылы кабул итте. Пьеса мәкерләрдән сак булырга, кешелегеңне югалтмаска өнди. Әкренләп, булачак драматург шул тарафка юнәлеш алды. Актёрлык хезмәтен дә ташламыйча, бер-бер

артлы яңадан-яңа әсәрләр иҗат итә башлады. Баш-аягы белән олы сәнгатькә кереп китте. 1987 елда Т.Гыйззәтнең М.Сәлимҗанов куйган «Ташкыннар» драмасында – Басарый; 1991 елны Ш.Хөсәеновның Марсель ага сәхнәләштергән «Әни килде»сендә – Инсаф, Т.Миңнуллинның 1988 елда куелган «Гармун уйный беләсезме?»сендә Наил ролен башкарды, режиссёры да Туфан ага үзе иде. Яңадан-яңа пьесалары да бер-бер артлы сәхнәдә калка башлады. 1989 елны Исламия Мәхмүтова тарафыннан куелган «Яшьлек хатам, йөрәк ярам» дигән драмасы сәхнәгә менде. «Капчыктагы Мәгъфия» комедиясе Башкортстанның Сибай дәүләт театрында дөнья күрсә, «Пуля» дигән әсәре тамашачыны психологик тирән кичерешләр аша тетрәндерде. Данил Салиховның күп кенә әсәрләре Минзәлә, Уфаның «Нур», Туймазы, Стәрлетамак, Оренбург театрларында, Дагыстанның «Ногай» театрында озын гомерле булдылар. Аның пьесаларына бәя биргән әдәбият галиме Әлфәт Закирҗанов: «Тормыш-чынбарлыкның төрле якларын иңләп алган, жанр формалары байлыгына йөз тотып, сурәт-чараларның бай палитрасын файдаланып иҗат иткән пьесаларда кеше шәхесенә тирән ихтирам, халкыбызның язмышы өчен борчылу, аның бүгенгесен һәм киләчәген матур, якты итеп күрү теләге чагылыш таба... Сугыш вакыйгаларының кеше язмышларында тирән эз калдыруын чагылдырган «Узып барышлый», «Өзелгән йөзем» драмалары күпсанлы тамашачыларны сөендергән, драматургның иҗат йөзен билгеләгән әсәрләреннән санала. «Узып барышлый» моңсу драмасы бүгенгебезнең ачы хакыйкатен ачып бирүе белән игътибарны җәлеп итә. Асылына «Адәмнәр ни өчен кешелек сыйфатларын югалта?!» дигән сорауга җавап эзләү салынган», – дип билгеләп үтә үзенең «Рухи таяныч» китабында.

...Әлбәттә, язучының тормышында, драматургия юлына кереп киткәндә, каршылыклар да очрады. Башлангыч чорында ук, әйтик, беренче әсәре – «Туй күлмәгем – соңгы бүләгем»не театр сәхнәсенә әзерләгәндә, зур көрәш барды. Күчмә театрда кайберәүләр, көнләшеп тә, явызланып та, аяк терәп каршы тордылар. Алар басым ясаган саен, татар яшьләре, шулай ук сәхнәгә яңалык кертергә тырышып йөргән өлкән буын вәкилләренең дә яклавы көчәйгәннән-көчәйде. Әсәрне куярга ризалык биргән Празат Исәнбәтнең: «Драматургиягә яшьләрне чыгарырга кирәк, югыйсә, тагын бер ун-унбиш елдан, яза алырлык кеше калмаска мөмкин», – дигән сүз-фикерләре дә үз ролен уйнады. Инде бер-бер артлы иҗаты чәчәк ата барган әдип, тагын шаккатырып, театр эчендәге ыгы-зыгы, интригалардан туеп, икенче юлдан китте. Язучылар берлегенең әдәби фонд директоры да, ТАИС җитәкчесе дә булып эшләде Данил. Бүген 360тан артык әгъзаны берләштергән Татарстан Язучылар берлеге рәисе булуы да аның «универсаль солдат» икәнлеген күрсәтә.

Гаилә корып яши башлавының беренче елларында ук, ул, Орловка ягыннан җир алып, үз кулы белән дача-бакча төзеде, мунча, сарай салып куйды. Күпләр икеләнеп торганда, ишәеп барган гаиләсен интектермәс өчен, кооператив фатир алып, үзе хуҗа булып, үз почмагында яши башлады. Бусы да – кискен адымнар ясарга яратучы Данил иде!

Ул да түгел, велосипед алырга гына хәлләреннән килгән артистларны шаккатырып, «Запорожец» автомобиле дә юнәтте. Дөрес, бер килеп туктаса, без этеп җибәрмичә кабынмый торган иде ул, әле үрләсә дә, «пах» та «пых» кара төтен атып, безнең йөзләрне корымга батырып китеп бара торган иде.

...Бүген исә Данил әфәнде безнең илнекен генә түгел, чит төбәкләрдән кайткан техникаларны да, кирәк булса, үзе сүтеп җыя. Аның язган пьесаларында да ошбу хәлләр вакыт-вакыт тиешле урынын таба, көлкеле ситуацияләр тудыра. Төрле жанрда иҗат ителгән «Ак күгәрчен», «Гыйлаҗ тәрәзәләре», «Өзелгән йөзем», «Язмыш», «Узып барышлый», «Көттереп килгән яңгыр», «Мөгез», «Бәхетеңне кәҗә сөзсә» һ.б. пьесалары тематик төрлелек, күтәрелгән җитди проблематика, психологизм, кулланылган сәнгать алымнары белән башкалардан аерылып тора.

Драматургка зур уңыш алып килгән, Әлмәт дәүләт театрында Камил Вәлиев сәхнәләштергән әсәрләренең берсе – «Чукрак» драмасы. Ул татар авылы мисалында 1917 елгы инкыйлаб, дингә каршы көрәш, мәчет манараларын кисү, гражданнар сугышы, Сталин репрессияләре һәм 1990 елларда, кабат кире кайтып, авылларда,

шәһәрләрдә яңа мәчет манаралары калкуын – шулар аша халкыбызның фаҗигале язмышын чагылдыра.

Бүгенге көндә пьеса язып караучылар күп. Ләкин, төпле режиссёр кулына эләкмичә, профессиональ театрда әсәре куелмыйча, хет әллә нинди әсәрләр яз, әмма да сине драматургка санаучы табылмаячак! Бу жанрны сәхнәдән карасаң гына, тулаем бәя биреп була. Режиссёр аңа җан өрә, актёрлар уены аны яшәтә, декорация, ут-музыка ярдәмчел тәэсир чарасын үти. Шулай итеп, буш урында күпмедер вакытка тормыш кайный башлый. Тамашачы үзе дә, онытылып китеп, шунда кайнаган вакыйгалар арасына кереп чума, күпмедер вакыт яшәп ала. Кызыклы урыннарда көлә-сөенә ул, фаҗигале-кайгылы җирләрендә күз яшьләрен түгә. Ун меңләгән, йөз меңләгән кеше карый уңышлы язылган әсәрләрне, шуңа күрә дә дәүләт театрларында куелган һәр пьеса бер китап чыгаруга тиң. Күренекле театр белгече Дания Гыймранова, гомумән, безнең буын драматургларын аермый, тиң күрергә тырыша иде. Ул шулай ук Данил Хәбибрахман улын да ихтирамлап, болай дип язды: «Без аның пьесаларында бүген тирә-ягыбызда йөргән каһарманнарны күрәбез. Алар авыл-бистәләрдә безнең арада яшиләр. Ләкин, автор көнкүреш язучысы дип кенә тамга салып булмый. Аның әсәрләрендә оригиналь сюжетлар һәм көтелмәгән ситуацияләр, хәтта фантастик элементлар да калкып чыга... Тормыш мәзәкләре аша ул безнең яшәешебездәге иң мөһим булган дәресләрне тамашачыга җиткерә. Караучыга нык басым ясамыйча гына, җиткерәсе фикер-сүзен үзенчә тасвирлый».

Әлбәттә, киләчәк буынга мирас итеп калдыру өчен, ташка чоку да кирәк. Ягъни пьесалар җыентыгын чыгару мөһим. Данил Салихов та – куелган-куелачак әсәрләрен туплап, 8 китап чыгарган автор. Дөрес, берсе аның Башкортстан язучысы Наил Гаетбаевның кәмитләрен туплап, Данил Салихов тарафыннан татар теленә тәрҗемә итеп чыгарылган.

Миңа төрле конкурсларда жюрида утырырга туры килә. Меңләгән үзешчән сәнгать театрларыбыз бар. Ул конкурс-чараларда катнашучылар һәр ел саен Данилның ике-өч әсәренә туктала. Уйнарга да, куярга да җиңел, diләр үзешчән сәнгать режиссёрлары. Шулай булуына иманым камил, чөнки автор, актёр буларак, һәрбер ролен күңеленнән үзе уйнап карап, күзаллап яза. Сәхнә кануннарын яхшы белү, әсәрне кирәкмәгән диалоглардан арындыруга ярдәм итә.

Чит ил, рус, татар драма әсәрләренең җәүһәрләре белән мәктәп елларында ук кызыксынган, театр училищесында укыганда өйрәнгән, соңыннан зур сәхнәләрдә шул әсәрләрдә рольләр башкарган Данил Хәбибрахман улының тәҗрибәсе җитәрлек бүген. Тырышлыгы хәттин ашкан. «Балта тотса – йорт салыр, каләм алса – уй салыр шәхес ул!» Хезмәтеннән буш чагында да тик тормас җан. Ашыт елгасы буендагы йортына кайтса, хуҗалыкта эш бетәме? Өстәвенә, биләмәсендә бал кортлары үрчетә! Шулар белән кайнашып ял итә, егәр туплый. Ә умартачылык белән шөгыльләнү – татлы мәшәкать кенә түгел, үзе зур сәнгать! Данилны кайчагында шул тырыш бал кортлары белән чагыштырырга була! Тынгысыз, тырыш! Теләсә, колхоз рәисе, район җитәкчесе булып та уңышлы эшли алыр иде. Кулыннан хуҗалык өчен мөһим бөтен эш килә. Ләкин ул зур сәнгатьне һөнәр итеп сайлаган! Бу өлкәдә дә җиң сызганып эшләвең зарур! Затлы әсәр тудыру төрле объектив детальләр эзләү, янәшәңдә кешеләрне-һөнәрмәннәрне күзәтү, сөйләм-холыкларын кәгазьгә төшерә алу, аны бер тулаем идеягә кору киң итеп фикер йөртә белүне сорый. Драматург та, бал кортлары кебек, тамчылап төзи үзенең әсәрен. Ошбу изге җан ияләре кәрәзле оя корган кебек үк, әсәргә дә олуг хезмәт салына, кәгазьдә тормыш вакыйгасы оеша башлый. Бал кортларына төрле чәчәк кирәк булса, драматургка исә бертуктаусыз баш миен эшләтү мөһим. Ятсаң да, торсаң да, трамвай-троллейбус, метро-автобуста барсаң да, бертуктаусыз уйлану зарур әдипкә! Күренекле драматург Данил Хәбибрахман улының күңеле тулы, башы тулы яңадан-яңа уй-фикерләр, идеяләр! Шуның аһәңе буларак, премьералардан соң, бал татыган кеше кебек, иҗат ләззәте кичерә ул! Ошбу иҗат ләззәтенә өстәп, дустым-каләмдәшемә бәрәкәтле тынгысызлык та телим, бергә-бергә газиз халкыбызга ихлас рәвештә хезмәт итәргә насыйп әйләсен!

**Рәдиф СӘГЪДИ,**
*Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе*

# ЙӨРӘГЕ АША «ДӨНЬЯ УЗА ШАУЛАП...»

## РӘМИС АЙМӘТКӘ 50 ЯШЬ

*Рәмис Аймәтнең «Шомырт салкыннары» (2000) җыентыгы затлы шигъриятькә иямләшкән татар укучысын хис-кичерешләрнең көче, тирәнлеге, үзгәрүчәнлеге, газаплы-әрнүле иң югары ноктага кадәр күтәрелә алуы белән гаҗәпләндереп, әдәбият мәйданына үзенчәлекле шигъри сүз остасы килүе хакында хәбәр биргән иде. Егерме елга якын һәр кичерешне сызланулы күңел кыллары аша уздырып, укучы йөрәгендә дә үз моңының кайтавазын тудырып иҗат итә ул...*

Р.Аймәт җанында мең-миллион хисси тирбәлешләр тулы кешене сурәтләү объекты ясый, лирик героен үзенчәлекле, башкаларга охшамаган, беркемне дә кабатламаган, кешелекнең бар кайгы-шатлыгын кичерергә сәләтле шәхескә әйләндерә. Шул ук вакытта хис-кичерешләрнең сәбәбе, күнегелгәнчә, тышкы дөньяда түгел, геройның үз җанында, фикер-күзаллауларында булып чыга. Нәтиҗәдә, Р.Аймәт иҗатында кешенең эчке матурлыгы, рухи көче, акылы-фәлсәфәсе – яшәешне хисси кабул итүдә, яшәү мәгънәсе исә – һәрдаим көчле хисләр кичереп тә, яхшылыкны һәм матурлыкны алга куеп яшәүдә дигән фикер ассызыклана. Татар шигърияте өчен яңа сүз, үзгә аһәң, ят фәлсәфә бу.

Еш кына шагыйрь мондый кичерешләрнең сәбәбен кешенең кешелек асылында таба. Мәсәлән, «Кошмы? Колмы?» (1997) шигырендә Ирекккә чыгаруны сорап ялварган лирик геройның авыру халәте – кешелекнең уртак сызлануы: күңелендә хөр яшәргә омтылыш белән кол булып тууында дип күрсәтелә. Монда сүз аерым лирик «мин»нең ирек сөюе яки аның ирегенчикләүче тышкы сәбәпләр турында түгел, бәлки, гомумән, һәр кешедә тән һәм җанның тәңгәл килмәве: җан биеклеккә омтылып, очарга, күкләр иңләргә теләп тә, канатларсыз тәннең җиргә бәйләнгән булуы хакында бара. Лирик субъектның «Кошлар кавеменнән мин» дип риторик эндәшүе болай яңгырый: *«Чыгарыгыз мине Ирекккә! / Киңлекләрне иңләп очар идем, / Канат җәеп җирне кочар идем, – / Тартыла ла җаным биеккә, / Тартыла ла җаным биеккә»*.

Риторик эндәшнең күплек сандагы билгесезлеккә адреслануы, кабатлаулар, омтылышлар хакында кинәт кенә шәхси дулкынга күчеп сөйли башлау хис-кичерешләрне киеренкеләндерә һәм хәрәкәткә китерә: таләптән – теләккә, аннан – ялваруга, өметсезлеккә кадәр ара узып, хисләр, ахыр чиктә, өмет һәм өметсезлек арасында тирбәлә. Икенче строфада, лирик герой «коллар нәселеннән» булуын әйткәндә, хәтта ирекккә омтылышның, ирек хакында уйлау-хыяллануның да йөрәктә «богау чыңы» зеңләтүе бу омтылышның беркайчан да тормышка ашмаячагын ахыргача ныгыта: *«Әйләнде лә җаным өрәккә! / Ялварыплар күкләремә баксам, / Кыйгак-кыйгак кына канат каксам, – / Богау чыңы зеңли йөрәктә, / Богау чыңы зеңли йөрәктә»*.

Шуның белән бергә кешенең, оча алмаячагын аңлап-белеп тә, күкләргә омтылуы – иң олы хыял, иң якты, кеше җанын түбәнлеккә төшүдән саклап торган сыйфат итеп күтәрелә. Югары омтылышларның җирдә матди яшәү мәҗбүрияте белән тәңгәл килмәве лирик герой күңелендә тирән борчылу һәм сагыш, моң китереп чыгара, әмма ул – җиңү сагышы, якты сагыш; кешенең матди башлангычны рухи башлангычка буйсындырып яшәве бу хискә горурлык өсти.

Лирик герой күз алдына менә шундый – тирән кичерешләргә, фәлсәфи карашка ия шәхес булып калка.

«Тантана» (1998) шигырендә бу мотив тагын да үстерелә. Кешеләр – шул ук кошлар, тик аларның канатлары киселгән. Лирик герой да шуларның берсе – канатлары сынган, «Куырылган канаттан кан тама» торган җир кешесе: *«Мин яшим... Бер Тәңрем кайларга язгандыр: / Күпме соң дөньяда хак яшем? / Һәр үлән сабагы, һәр яфрак, һәр җисем – / Ул минем иң якын кардәшем... / Канаттан кан тама. / Кемгәдер – тантана...»*

*«Канаттан кан тама, / Кемгәдер – тантана…»* юлларының кабатлануы лирик геройның – җир тормышыннан канәгать һәм шашып яшәргә ашыгучы кешеләр арасында ялгыз булуын ассызыклый. Аның күңеленә кардәш-җандашлар – бары тик «һәр үлән сабагы, һәр яфрак, һәр җисем». Әмма бу герой, классик әдәбият геройларыннан аермалы буларак, шушы кешеләр төркемен әйдәп, башка юлга чыгарырга яки үзгәрергә чакырырга омтылмый. Ул бары тик үзенең халәте – сагыш һәм чарасызлык, җан сызлавы турында сөйли. Бу халәтне тудырган сәбәпләрнең булмавы берничә укылыш вариантына ишарә ясый һәм «семантик бушлык», лакуна ролен үти. Бу бушлык укучы тарафыннан төрлечә тутырыла ала.

Кайчакта шагыйрь лирик субъект кичерешләрен укырга ачкыч сүз яки фраза, ягъни символ калдыра. Әйтик, «Ярты юлда» шигырендә шундый фраза шигырьнең исеменә чыгарылган: ул башлап ташланган эшләргә дә (татар мәкале белән интертекстуаль бәйләнештә), кеше гомеренең тиз узуына да ишарә итә.

Шигырьдә тирән сагыш, моң, кайгы халәтендәге лирик герой тудырыла. Аның кайсыдыр бер мизгел эчендәге кичерешләре шундый көчкә ия ки, әйтерсең лә алар тормыш агышын, вакыт хәрәкәтен, җиһанны туктаткан: *«Хәрәкәтсез җиһан – нидер көтә бар да, / Онытылып дөнья аһ-зарыннан»*.

Үз чиратында, дөнья «аһ-зары» лирик герой күңелендә кайтаваз таба, аның җанындагы аһ-зарга әйләнә, күңел халәте поездлар китә алмый торган вокзал кебек күзаллана башлый: *«Китәлмичә тора поездлар да / Актарылган күңел вокзалымнан»*.

Бу халәтнең сәбәпләрен ачмый-ачыкламый гына, тормыш хәрәкәтен туктатырлык көчкә ия гаять тирән, галәми авыртулы кичерешләр берәм-берәм санала.

Күп кенә шигырьләрдә хис-кичерешләрнең һәм моң-сагышның сәбәбе яшәешнең чикле булуы белән аңлатыла. Автор һәр очракта да тормыш сурәтен детальләп тергезү аша моңа төшендерә бара. Мәсәлән, «Җәйнең соңгы җыры» (1998) шигырендә җәйне озату, тормышка ашмаган өмет-хыяллар белән саубуллашу гаҗәеп төсмер ала: *«Инде... үтте! Ерак офык аръягында / Җанкаемның яшел кошы – оча гына. / Мин үлмимен, юк, үлмимен / – китәм бары / Дөрләп янган чуар төсләр кочагына. / Мин үлмимен, юк, үлмимен / – күчәм бары / Лепердәшкән яфракларның җыр-моңына. / Иярәмен җан җылымны саклап барган / Ап-ак сагыш – киек казлар чылбырына»*.

Яшел җәй – очып киткән яшел кош, көзге чәчәкләрнең кызыллыгы, яфракларның сагышлы җыры, киек казлар чылбыры, «салкын көзнең шәрә җиле» бию, яңгыр – ел фасыллары алмашыну картинасын тудыра. Кешеләштерү-сынландыру һәм җәй белән лирик герой янәшәлеге, көтелмәгән шәхсиләшкән метаморфоза-үзгәрешләр әсәрнең төп эчтәлеген – җәй җырын – яшәешнең чиклелеген аңлаган, үтеп барган һәрнәрсәне җаны аша уздырып саубуллаша алган кеше монологына әйләндерә. Җилле көз һәм лирик геройның күңел халәте аерым-аерым торган чынбарлыклар түгел, бәлки бер үк вакытта пейзаж да, «мин»нең эчке кичерешләре дә. Үзен яшәештә «күз яшедәй тәгәрәпләр төшеп» барган соңгы тамчы итеп күзаллаган бу кеше һәр үзгәреш-тирбәлешне җаны аша уздыра һәм кичерә белә. Әйләнә-тирә дөньядагы һәр хәрәкәт аның йөрәгендә сагыш тудыра (яралый яки үзен галәм күз яшенә әйләндерә).

Хисләрнең киеренкелеге, бер чиктән икенчесенә ташланып торуы, лирик геройның дөньяны җаны аша уздырып, кичереп яшәү сәләте иҗат эше белән бәйләп куела. Күп кенә шигырьләрдә лирик герой – шагыйрь, иң олы газап яки иң якты шатлык, иң олы өмет – иҗат тудырган хис булып аңлашыла. Мәсәлән, «Очыш көтәм» (1994) шигырендә илһам чаткысының, янып, шигырьгә әйләнү мизгеле тергезелә, аның

бәгырьне яндырып, күзләрне каплап, иҗатчыны бар дөньядан аерып иҗат ителүе шагыйрьнең дә гадәти кеше түгел, бәлки үзенчәлекле хис-күзаллаулар дөньясында яшәүче булуын тагын бер кат раслый. «Шагыйрь» (1998) шигырендә шагыйрь образы тагын да төгәлләшә төшә: һәрбер мизгел «аның җанына» туктала, кабер казып китә; уч кадәрле йөрәге аша «дөнья уза шаулап», «йөрәгендә күпме ямаулык», учында йолдыз кабыза, җан аклыгын саклап кала ала, шигырьдә эреп югала... Әлеге сыйфатлар Р.Аймәт шигырьләрендәге лирик геройда кабатлана, аның чын мәгънәсендә хис кешесе булуын тәэмин итә.

«Хис белән яшәүче» лирик герой – кайчакта үзен «мәңгелек иренендә (...) Дога» («Мин әле тумаган...», 1998) итеп тоя. Катлаулы фәлсәфә кешене «тумаган», тумаган килеш «яшәп арылган», күкләрдә үзенә җеназа укыла торган адәм баласы итеп күз алдына бастыра: *«Бу дөнья – гарасат мәйданы, / Әллә соң яшәү дә – бер җәза?! / ...Мин әле тумаган, ә инде / Күкләрдә укыйлар җеназа»*.

Сызлану фәлсәфәсе төрлечә тәэсирле, ассоциатив образ тирәсенә туплана. Тумаган килеш, кешегә күкләрдә җеназа укылу – гомернең чиклелеген, аның мизгелдән дә кыскарак булуын ассызыклый, *«Ничә кат туамдыр? Язмышым / Күгендә гел тимер рәшәткә»* дигән юллар кешенең яшәештә ирекле булмавын күрсәтә, тормышның кешегә авырлыклар гына китерүе чиктән тыш арттыру юлы белән ясалган «дөнья – гарасат мәйданы» һәм «яшәү – җәза» раслаулары ярдәмендә җиткерелә, *«...ишетәмсез / Җанымда галәмнең гүләвен?»* фикере исламдагы көзге тәгълиматын хәтерләтә; «Ак биләвем»не җую – кешеләрнең күңеле каралу хакындагы мифка ишарә ясый... Шул рәвешле, күпсанлы ассоциацияләр кешенең галәм, яшәеш нигезләренә кагылышлы сызланулы кичерешләрен өскә калкыта.

Тышкы дөньяны, табигать яки әйбер образларын лирик геройның хис-кичереш халәте белән янәшә кую әлеге образларны символлаштыру юлына әйләнә. Мәсәлән, «Төш» (1994) шигырендә алма-өмет – коелган алмаларга, тормышка ашмаган хыялларга әйләнә. Еш кына Р.Аймәт хисләрне гаять катлаулы, шигырь юлларына әйләнеп кайтырга мәҗбүр итә торган үзенчәлекле образлар ярдәмендә көчәйтә. Мәсәлән, «Ялвару» (1999) шигырендә мәхәббәт сорап ялваручы, чарасызлык чигенә җиткән лирик герой үзен «язмыш сынавында» гөрселдәп ауган имән кебек күзаллый: *«Язмыш суккан имән кебек мин дә / Аунап ятам җирдә – ни чара?! / ...Канатларым тамырлана инде, / Тамырларым канат чыгара...*

Канатлары тамырланган, тамырлары канат чыгарган имән – кеше җанын телгәләгән омтылышларның көче турында сөйли.

Лирик герой хис-кичерешләрен иң киеренке чиккә җиткерү, гаять тәэсирле тышкы тирәлек образлары белән янәшә кую «Без генәме?» (1997), «Китү» (1995), «Син киткәч» (1996), «Ул төнне дә» (1997), «Элегия» (1992) кебек күпсанлы мәхәббәт лирикасы үрнәкләрендә аеруча ачык. Бәхеткә ирешүнең мөмкин түгеллегенә төшенү мәхәббәткә багышланган шигырьләрдә хисләрнең сызланулы, тормышның тәртипсез-хаотик булуына китерә.

XXI гасыр башында Р.Аймәт иҗатында милләт язмышы мотивы ачык билгеләнә торган шигырьләр пәйда була. Аларда үзгәртеп кору чорының иҗтимагый-сәяси шигарь-лозунглары татар халкы тарихына күчә, «без» образы хасил була. Әмма, мондый шигырьләрдә дә кичерешләр шәхсиләшә: аларның эчтәлеге лирик геройның татар халкы язмышындагы аерым сәхифәләргә рухи-эмоциональ мөнәсәбәте төсен ала. Мәсәлән, «Тәрәзә» (2001) шигырендә рәшәткәле тәрәзә символы үз иле белән чит илләр арасына тимер пәрдә корган, үз халкын рәшәткәле тәрәзәләр артына яшергән совет идеологиясенә ишарә ясый: *«Өсләремә рәшәткәләр ава, / Якты хыялларны кыя-кыя. / Ябыла бара күңел тәрәзләре, / Европага тәрәз уя-уя...»*

Шигырь шул чорда иҗат ителгән һәм совет чорында формалашкан күзаллауларны, мифларны җимерүгә хезмәт итә торган күпсанлы текстлар белән бер дулкында язылса да, анда вакыйгаларга шәхси мөнәсәбәт һәм бәя күзәтелә. Бу бәя көтелмәгәнчә яңгырый: рәшәткәләрне вату лирик геройның якты хыялларын тормышка ашырырга ярдәм итмәү генә түгел, бәлки аларның үзләрен җимерә. Шигырь башында үтешли генә С.Хәким иҗатыннан татар укучысына халыкның инкыйлабка кадәрге

тормышының символы буларак таныш «карындыклы тәрәзә» образы кулланыла. Лирик герой тарафыннан үзгәртеп кору чираттагы «Европага тәрәзә ачу, тәрәзә ую» буларак бәяләнә, анысы исә күңел тәрәзәләрен ябу дип атала. Чөнки ул татар милләте вәкилләрен тамырлардан, традицияләрдән, «карындыклы тәрәзә»ләрдән аера, ераклаштыра, өзә. Тирән иҗтимагый-сәяси фикер инкыйлабка кадәрге тормышны, советчыл идеологияне генә түгел, үзгәртеп корулар вазгыятен дә күтелмәгән яссылыкта тәнкыйтьләп уза.

«Безнең язмыш» (2002) шигырендә, «без» алмашлыгы кулланылса да, сүз шәхес язмышы турында бара: *«Безнең язмыш Ходай кулында, / Үрелгән ул җитмеш толымга»*.

Актив рәвештә мифологик материалга мөрәҗәгать монда да лирик геройны – милли җәмәгатьчелекнең бер вәкиле итеп карарга юл калдыра. Шулай булса да, лирик геройның хис-кичерешләре махсус шәхсиләштерелә: милләт язмышы кеше язмышына күчерелә: *«Шүрәленең бармагыдай, / Бүрәнәнең / Ярыгына әллә кысылдымы? / ...Безнең язмыш. / Ялгыз күке, / Сансыз күке баласыдай, / Туамы ул чит-ят ояларда? / ...Безнең язмыш»*.

«Гөлләр чагым эзлим» (2002) шигырендә лирик герой кичерешләренең сәбәбе шулай ук милләт язмышында булып чыга. Көчле позициядә мондый риторик эндәш яңгырый: *«Дәшим кемгә? / Кемгә дәшим? Булмый! / Бар дөньясы сукыр һәм чукрак»*.

Шулай итеп, XX гасыр ахырындагы иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр Р.Аймәт иҗатына хас әдәби гомумиләштерү ысулын үзгәртә алмый. Хәтта гражданлык лирикасында ул – дөньяда үзен аңларлык, ничек бар, шулай кабул итәрлек башка берәү булмаган индивидуалист («Кемнәр генә?», 2003). Аның лирик герое үзен кешеләр арасында чит итеп тоя («Мин җирләргә төштем», 2001), хыялларында – җирдән китеп югала, үзен эзләмәүләрен сорый («Эзләмәгез мине», 2000): *«...Эзләмәгез мине беркайдан да, / Кайтмаска (!) дип киттем Дөньядан!»*

Бу авыртулы, чиктән тыш сызланулы ялгызлык хисе теләсә нинди ситуациягә бәйле рәвештә хасил була. Ләкин, барыннан да элек, мәхәббәтне югалту лирик геройны үзен ялгыз итеп сизүгә этәрә («Без генәме?», 1997): *«Аерды ла толымыңдай сукмак, / Араларга ятты елан сымак. / Беркем дә юк. Шомлы шәүләмени – / Язмыш атлый, язмыш бара сынап»*.

Мәхәббәт аның иҗатында шулай ук шәхсиләшкән, шуның белән бергә, әлеге хис шигырьләрдә һәрвакыт иң югары ноктасына, чигенә җиткерелә: мәсәлән, бу шигырьдә яраткан кешесен югалтуны лирик герой галәмдә мәхәббәтнең югалуына тиңли.

Лирик геройның чиктән тыш хисчәнлеге, ялгызлыгы һәм шушы халәтне җиңүнең, атлап үтүнең мөмкин булмавы һәр шигырьдә диярлек аларны детальләп сурәтли бару төсен ала. Бу герой җирдә үзенә тиң башка кеше булмаган ят планета кешесе булып та тоелып китә. Шуңа ул кешелек җәмгыятендә үзенә урын таба алмый. Мәсәлән, «Автопортрет» шигырендә лирик герой үзе хакында болай ди: *«Айдан сынып төшкән ялгыз нур мин, / Ялгыз җыр мин тумый онтылган»*.

Бер үк вакытта әлеге герой үзенә нәсел-ыруының, халкының, милләтенең тарихи хәтерен сыйдыра: *«Дала уртасында ничә гасыр, / Утлы хәтер кебек талпынып, / Үрли-үрли янган учакның мин / Күзгә күренмәгән ялкыны»*.

Р.Аймәт лирик субъектының үзбилгеләнүендә интертекстуаль бәйләнешләр зур роль уйный: ул XX гасыр башы татар шигъриятендәге романтик геройга, Г.Тукай, С.Рәмиевләрнең пәйгамбәр-лирик геройларына якын тора: *«Үзәк өзгеч кышкы салкында мин / Җирне гөлгә төреп кайткан яз. / Мин гасырлар буе кайта-кайта / Кайтып җиталмаган кайтаваз»*.

Р.Аймәт иҗатының бу үзенчәлегенә үз вакытында Лена Шагыйрьҗан игътибар иткән иде[1]. Аймәт поэзиясендәге экзистенциальлеккә, сызлану фәлсәфәсенә Р.Фәйзуллин күрсәтте[2]. Ләкин, гомумән алганда, шагыйрь иҗатында һәм романтик, һәм экзистенциаль мотивлар постмодернистик өземтәләр, цитаталар

[1] Шагыйрьҗан Л. Үз йөрәге аша // Мәдәни җомга. – 2002, 19 июль.
[2] Фәйзуллин Р. «Чикле чиксезлек» // Казан утлары. – 2005. – №2. – 140-142 б.

базасын формалаштыруда катнаша, нәтиҗәдә, элгәрге шагыйрьләр иҗатына хас традицияләр белән бәхәс, дискуссия туа: *«Үксез кыл мин төпсез, тар бушлыктан / Аваз салган өзелә-өзелә... / Давыл эчендәге бер Тынлык мин, / Тынлык эчендәге Зилзилә»*.

Текстлардагы музыкальлек, сүзләр сайлаудагы гармония, хәтта эстетлык, фәлсәфилек, яңгыраш матурлыгы, аһәң татар укучысында иҗатның «традиционлыгы» тойгысы уята. Бу тәэсирне хасил иткән сәбәпләрнең берсе – чиктән тыш эмоциональлектә, ихласлыкта, лирик зат кичерешләрен шәхсиләштерүдә.

XX гасыр ахыры рус поэзиясен тикшерүчеләр охшаш тенденциягә игътибар итә: «XX гасырның 90 нчы еллары лирикасының сурәтләү предметы булып «шигырь яза торган кеше»[3] килүне билгелиләр. Ләкин эчтәлектәге эмоциональ башлангычның сүзләр мәгънәсеннән, семантикасыннан өстенлеге, аһәң гармониясе, үзенчәлекле фәлсәфә Р.Аймәт шигъриятенең уникальлеге хакында сөйли. Даими рәвештә «мин» һәм дөнья, дөнья һәм иҗат арасындагы чикләрне үтеп чыгу үзенчәлекле лирик субъект тудыра, ул, үз тормышының гына герое булып калмыйча, аның авторына әйләнә, ягъни тормышка карата аннан югарырак актив позициягә баса (М.М.Бахтин терминологиясе буенча).

Р.Аймәт иҗатында символлар ярдәмендә эчтәлек хасил итү тенденциясе дә көчле булып, ул, бигрәк тә, гражданлык лирикасында калку билгеләнә. Бу яктан, аның «Бозлы җилкәннәр» җыентыгына тупланган гражданлык лирикасы үрнәкләре аерып күрсәтелә ала. Кайсыбер шигырьләрдә авторлык символлары шәхси яссылыкта да, милли-иҗтимагый эчтәлектә дә укыла ала. Җыентыкны ачып җибәргән «Күзгә күренмәгән нокта» шигырендә нокта – милли үзбилгеләнү булып та, лирик геройның ирешергә омтылган максаты рәвешендә дә, өмет кебек тә укыла ала. Аерым бер юлларда аның идеаль мәгънәсе дә күренеп китә: *«Әллә минем карашларым гына / Барып җитәме соң ул Ноктага? / Юкса бәхет күлмәген дә киеп / Тумадым бит фани бу дөньяга»*.

«Ирек» шигырендә – ирек образы шәхси, милли һәм иҗтимагый-сәяси мәгънәләрне бергә туплаган символга әйләнә. Әйтик, «Минем илем»дә лирик герой тудырган ил – иҗат булып та, хыял-идеал мәгънәсендә дә, шәхси тормыш кебек тә укыла ала.

Аерым бер шигырьләрдә символлар, интертекстуаль бәйләнешләр, ассоциативлык күптөрле укылышка юл күрсәтә. Иң көчле үрнәкләрнең берсе – «Соңгы өмет» шигырендә үзгәреп тора торган хис-кичерешләр чолганышындагы, тирән сызлану һәм борчылу кичерүче лирик геройның халәте – тарихи ситуация, милләт язмышы булып аңлашыла. Ирек җиле – кырау символик образлары илдәге атмосфераны күрсәтеп килә. «Агачлар да очар күкләрдә» дигән юллар Р.Зәйдулланың Балтыйк буе республикалары ирек алуга багышланган «Литва» шигыренә ишарә ясый. Нәтиҗәдә, азатлык юлына чыккан Татарстан, аның очышы өзелү сурәте тергезелә: *«Ирек – канат! / Без канатсыз калдык, / Очып барган килеш никләргә?! / Бәрелдек тә килеп кыя-тауга, / Мәтәлдек без чоңгыл күзенә? / Ирек җилен тойган гына идек – / Инде... / Соңгы Өмет өзелә»*.

Шундый гомуми картина фонында, нәкъ үзенчә итеп, шагыйрь бу очышның шәхси ягын калкуландыра: «ташланырга әзер җаныма», дип, азатлыкка очышның һәр кешегә бәйле булуын искәртә, аннары моны тагын бер сурәт – «Дөньяларга / пар канатлы булып тусак та» дигән фраза белән ассызыклый. Нәтиҗәдә, илнең, халыкның, милләтнең азатлыгы һәр кешенең күңелендәге омтылышка, эш-гамәлләренә бәйле дигән фикер хасил була.

Р.Аймәтнең хисчән лирик герое – табигать матурлыгын үзенчәлекле күрә-тоя алучы, аны дөнья матурлыгы белән тигезләүче. Әйтик, Зөлфәт шигыре белән интертекстуаль бәйләнештә иҗат ителгән «Бәллүр кебек садә иртәләрдә» шигырендә табигатьнең югалырга әзер матурлыгы – иҗат кешесе, шагыйрь күзенә күренә, аңа илһам китерә һәм уй ирееге бирә торган кыйммәт кебек тә күренә: *«Бәллүр кебек*

[3] Современная русская литература (1990-е гг. – начало XXI в.). / С.И.Тимина, В.Е.Васильев, О.Ю.Воронина и др. – СПб.: «Академия», 2005. – С.109.

*садә иртәләрдә, / Ак биләүдә чакта бар җиһан, / Иңнәремә килеп кунар кебек, / Канатларын җәеп ак илһам. / Уйларыма һич юк киртәләр дә / Бәллүр кебек садә иртәләрдә».*

«Илһамлы минутлар», «Моңлы яңгыр» һ.б. шигырьдә дә табигать сурәте иҗатчының халәте белән бәйләп куела. Хәтта пейзаж лирикасы үрнәге кебек язылган шигырьләрдә дә икенче эчтәлек, кеше тормышы белән янәшәлек тоемлана («Китә җәем... (Элегия)», «Төн (Манзара)» һ.б.). Мәхәббәт лирикасы, шулай ук, лирик геройның үз халәтен, үз җанын телгәләгән хис-кичерешләрне җырлау рәвешен ала. Иң катлаулы кичерешләр өермәсендә калганда, чарасызлык чигенә җиткәндә, тормыш белән хушлашканда да, Р.Аймәтнең лирик герое көчне үз уенда, үз җанында, үз күңел дөньясында, акылында таба, шуның белән үзе фәлсәфи яктан авырлыклар һәм кайгылар итеп бәяләгән тормышта яктылык һәм өмет барлыкка инана. Бу яктан, иң мөһим шигырьләрнең берсе – «...Күкләремдә ай, йолдызлар сүнгән чакта...» Иң соңгы өметләре өзелеп, тормыш авырлыклары белән бергә-бер калган вакытта да кешене уй, акыл чарасызлыктан алып чыга, диюче озын шигырь Р.Аймәт лирик героеның тормыш кредосы, шигаре булып яңгырый: *«Бу дөньялар ничек кенә җилләмәсен, / Биләп ала уйчан уйлар биләмәсе, / Күкләремдә ай, йолдызлар сүнгән чакта, / Күзләремә төн карасы сеңгән чакта...»*


Шулай итеп, Рәмис Аймәтне кеше халәтен, аның һәм шәхси, һәм иҗтимагый кичерешләрен, шәхеснең каршылыклы дөньяда гармония табарга омтылып яшәвен җырлаучы шагыйрь дип атап булыр иде. Ул – лирик шагыйрь. Иҗатының үзенчәлеге, безнең фикеребезчә, гадәти булмаган, чиктән тыш эмоциональ һәм кешелек дөньясының сызлануын үзе аша уздырырга сәләтле лирик герой тәкъдим ителү белән бәйле. Аның ярдәмендә кешенең эчке матурлыгы, көче – яшәешне хисси кабул итә алуда; яшәү мәгънәсе – көчле хисләр кичерә алуда.

Хәтта иҗтимагый-сәяси мотивлар ачык күренеп торган шигырьләрдә дә хис-кичерешләр шәхсиләшә: аларның эчтәлеге булып лирик герой күңелендә татар халкы язмышы белән бәйле тарихи вакыйгаларның яңгырашы килә. Гражданлык лирикасында да ул – дөньяда үзен һичкем аңлый һәм кабул итә алмый торган индивидуалист. Дөнья сурәтендәге дисгармония, хаос-тәртипсезлек лирик геройның статусына тәэсир итә. Ахыр чиктә, аның лирик герое бу тышкы тәртипсезлекне, хаксызлыкны гармониягә китерү юлын да үз күңеленнән эзли башлый.

Р.Аймәт иҗаты мисалында XX-XXI гасырлар чиге татар поэзиясендәге үзгәрешләр аермачык күренә. Татар шигъриятендә рух һәм илһам чыганагы булган туган авыл, туган җир, халык һәм милләт – аның әсәрләрендә сызлану, борчылу объекты, «соңгы кан тамыры» өзелергә торган авыл («Соңгы кан тамыры»), аварга җыенган татар каены («Татар каены»), «Гөлләр чагы»н югалткан Ватан («Йөрәккә эндәшү») булып калка. Шушы сызлануга бәйле символлар, башка шагыйрьләрнең әсәрләре белән интертекстуаль бәйләнешләр, янәшәлекләр аша Р.Аймәт ассоциатив сурәтлелеккә ирешә, укучыны төрле мәгънәләр эзләүгә тарта. Катлаулы, хисси образларны бер-берсенә янәшә куеп, тезеп барып, гаять зур тәэсир итү көчен хасил итә. XXI гасырда татар шигъриятенең үзгәреш юлы бу.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*

## ШӘҮКӘТ БИКТИМЕРОВ
(1928-2012)



СССРның халык артисты (1977), Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1967), РСФСРның Дәүләт премиясе лауреаты (1979) Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров 1928 елның 28 октябрендә Казан шәһәрендә туа, Саба районы Миңгәр авылында үсә.

1949 елда Татар театр училищесын тәмамлый һәм Татар академия театрында эшли башлый, ләкин шул ук елны армиягә алына. Театрга яңадан 1953-1954 елгы сезон башында гына кайта.

1975-1980 елларда Шәүкәт Биктимеров – ТАССР Югары Советы депутаты.

Шәүкәт Биктимеров – татар сәхнәсенең реалистик традицияләрен дәвам иттерүче. Төрле хасияттәге төп образларны иҗат итә. Ул романтик пландагы актёр түгел. Сәхнәдәге беренче адымнарыннан башлап, психологик тирән, тормышчан дөреслек, ышандыру, чынбарлык, табигыйлек нигезендә иҗат итә. Искиткеч мөлаем артист булып танылa. Ш.Биктимеров уйнаган рольләрендә тышкы яктан үзгәрмәсә дә, рухи бертөрлелек аңа хас түгел. Актёрның үзенә бирелгән образларның холык-фигыльләрен оста гәүдәләндерүе аркасында алар барысы да эчке яктан төрле-төрле, акыллы фикер йөртүче киң масштаблы шәхесләр. Артист каһарманның эчке тойгыларын бар тирәнлеге белән күрсәтә.

Аның рольләре: Нургали – «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт), Мелузов – «Талантлар һәм аларга баш иючеләр», Дульчин – «Соңгы корбан», Кнуров – «Бирнәсез кыз» (А.Островский), Хәмит – «Беренче чәчәкләр», Ишан – «Зәңгәр шәл» (К.Тинчурин), Галин – «Габбас Галин» (Ш.Камал), Таһир – «Хөррият» (М.Әмир), Тәлгать – «Беренче мәхәббәт» (Х.Вахит), Сәетгәрәй – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт), Заһит – «Бертуган Таһировлар» (Ф.Хөсни), Байтимер – «Гүзәлем Әсәл» (Ч.Айтматов), Ленин – «Баһадирлар» (Н.Погодин), Ислам – «Әни килде» (Ш.Хөсәенов), Кривохатский – «Бер төн» (Б.Горбатов), Фаюнин – «Ябырылу» (Л.Леонов), Бәхтияр – «Канкай углы Бәхтияр», Нурислам – «Дуслар җыелган җирдә», Рәфис – «Хушыгыз!», Әлмәндәр – «Әлдермештән Әлмәндәр», Җәллад – «Моңлы бер җыр», Зариф – «Монда тудык, монда үстек», Сибгат – «Ат карагы», Хәсән Акчурин – «Без китәбез, сез каласыз», Нурхәмәт – «Илгизәр + Вера» (Т.Миңнуллин), Туктамыш хан – «Идегәй» (Ю.Сафиуллин), Дорозуар – «Тол ханымда тукталыш» (Э.Лабиш), Чмутин – «Сагыш» (А.Галин), Пастор Мандерс – «Өрәкләр» (Г.Ибсен) һ.б.

Шәүкәт Биктимеров төрле характердагы өч йөздән артык рольне зур осталык белән башкара, ләкин тамашачылар актёрны, Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәрендәге Әлмәндәр образында күргәч, шул образ белән тәңгәлләштерә башлыйлар. Бу инде артистның геройны югары дәрәҗәдә талантлы итеп һәм тулаем ача белүенә бәйледер. Әлеге образ озак еллар дәвамында сәхнәдә татар милләте йөзен, аның намусын, иманын һәм кыйбласын чагылдырган легендар каһарман булып тора. Шул легендар роль өчен Шәүкәт Биктимеров Станиславский исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.

2012 елның 28 маенда Казанда вафат була.



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## «Адин чурт!»

Бер башкорт артистының малае рус мәктәбенең беренче классына укырга керә. Беренче көнне үк малай өенә җылап кайта.

– Нәмә булды? – дип сорый әтисе.

– Мине татарин дип үртиләр, – ди малай, мышкылдап.

– Ә һин иртәгә әйт уларга. Мин татарин түгел, башкир, диген! – дип өйрәтеп җибәрә әтисе.

Икенче көнне тагын да ныграк җылап кайта малай.

– Нәмә булды инде тагын? – ди әтисе.

– Үртиләр, – ди малай.

– Мин өйрәткәнне әйттеңме һун?

– Әйттем... – ди малай. – Татарин, башкирин – адин чурт, дип көләләр!

## Дөрес әйтә бит!

Сабан туеның кызган чагы – көрәш бара. Берәве ега, берәве егыла. Мәйдан уртасына әтәчләнеп чыгучылар да бар. Алары инде бераз салып алганнар. Алар йә гаделлек таләп итәләр, йә булмаса, көрәшергә дәгъва кылалар. Аларны милиционер иптәшләр, кулларыннан җитәкләп, читкә чыгарып утырталар.

Менә мәйдан уртасына күлмәген салып ташлап, бер кызмача урыс агайне чыкты. Көче ниндидер, тавышы каты, бөтен мәйданны яңгыратып кычкыра:

– Дайте мне полотенце, буду бороться! – ди. – Татары меня уважают, сами лягут! – ди.

Дөрес әйтә бит – шундый шул без, бүтән халыкларны хөрмәт итү йөзеннән, үзебез егылабыз. Тик бүтән халыклар безнең шул «яхшы гадәтебезне» аңлап кына бетермиләр...

**БАТУЛЛА**

## Ике дурак

Төзүчеләр сараенда Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсе булды. Соңыннан мәҗлес җыелды. Бу мәҗлестә обкомның идеология секретаре Мирзаһид Вәлиев тә бар иде. Бераз төшереп алгач, Фәрваз Миңнуллин Батуллага әйтә:

– Карале, мәҗлес бик рәсми бара, бөтенесе дә Мирзаһид Фәтхиевичтан куркып бөрешкән, Сибгат абый булып күрсәт әле, – ди.

– Сибгат абыйдан рөхсәт кирәк! – ди Батулла. Фәрваз бу турыда мәҗлес хуҗасына җиткерә. Хуҗа, әлеге эшне хуплап, Батуллага ым кага. Батулла, нәкъ Сибгат Хәкимгә охшатып, бер-ике мәзәк сөйли. Халык рәхәт көлә, ашау-эчү, күңел ачу башлана, мәҗлес күтәрелеп китә.

Икенче көнне Матбугат йортында Батулла Сибгат ага белән очраша.

– Кичә әйбәт сөйләдең, мәҗлесне күтәрдең, – ди Сибгат. – Ләкин тегеңә... – шагыйрь

имән бармагын өскә, түшәмгә төртеп, – тегеңә ошамаган. Миңа әйтә, нигә син шул сакаллы дуракны мәҗлесеңә чакырдың, нигә син шул дуракны куып чыгармыйсың, ул бит, Сибгат абый, сине мыскыл итә, ди. – Бераз тын торгач, остаз тагын өстәп куя: – Юмор аңламый, дуррак!

## Чын ялкау кирәк!

– Татар Язучыларының корылтае якынлаша, нишлибез? – ди Ләбиб Лерон.

– Һичшиксез, рәис итеп Ләис Зөлкарнәйне сайларга кирәк, – ди Батулла. – Ул бөтен яклап та моңа лаек.

– Дөрес, Батулла ага! – ди Ләис Зөлкарнәй.

– Ялкау бит ул! – ди Ләбиб.

– Шуңа күрә мин аны тәкъдим итәм дә! – ди Батулла. Тегеләре – Гариф та, Мөхәммәди дә – ялкау булсалар да, хет үзләре өчен эшләп калды. Бу үзе өчен дә берни эшләмәячәк!

– Дөрес, Батулла ага! – ди Ләис.

**Морад ДУСАЙ**

## Хикмәтле исем

Мәгъсум Гәрәй белән Камил Кәрим очрашса, һәрдаим бәхәс чыга. Вәләкин ике каләмдәшнең бәхәсе һич тә каләмгә бәйле түгел. Биредә хикмәт – аларның авылдаш булуында, чөнки икесе дә – Татарстаныбызның иң зур авылы саналган Шәледән. Сүз, әлбәттә, авылларында калган мал-мөлкәтне бүлешү хакында да бармый. Хикмәти асыл монда һич тә җисемдә түгел, ә бәлки исемдә, атамада ята!

– Безнең авылның чын исеме – Шале! – ди Мәгъсум Гәрәй, – кайчандыр аңа французлар нигез салган булган. Соңрак Каф тавы артындагы горур ырулар да килеп кушылган. Аларда әле хәзер дә Шале авылы калган – шул бер тамырдан инде без! – ди ул.

– Син монда юкны сөйләп торма, Мәгъсум абый! Үзеңне дә, авылны да оятка калдырып... Шаледән икәнсең – бар Шалеңә кит! – дип, Камил Кәрим аны шундук Каф тавы артына «олактыра»...

«Казан утлары» журналының проза бүлеге урнашкан тарихи 147 бүлмәдә бу бәхәсне Марат Закир тыңлап утыра. Бахыр, бер ача күзен, бер йома. Авылдашларының бәхәсендә әле «Чуен», әле «Корыч» тавышлары чыңлый, мин сиңа әйтим! Хәтта, аратирә ике металл бәрелешеп, тирә-юньгә чаткылары да чәчри сыман. Хәер, монда да бер хикмәт ята, җәмәгать. Ник дигәндә, берсе – Чуен Гәрәй малае, икенчесе – Корыч Әдһәмнеке. Авылда кушаматсыз кеше булмый.

...Әйе, бәхәс отыры кыза гына бара. Шәл бәйләүчеләргә баглы кыйсса да сөйләнә, Алып тауларындагы Дудергоф калкулыгының көтүче йорты да искә алына, кыскасы, гәп кызганнан-кыза бара.

– Абзыйлар, авылыгыз Мишә елгасы буенда урнашкан, шулай бит?! – дип, ниһаять, Марат Закир да сүз кыстырырга җөрьәт итә.

– Әлбәттә! – ди Чуен.

– Нәкъ үзе! – ди Корыч.

– Инде килеп, Мишә буенда да урнашкач, борын-борын заманнарда авылыгызның исеме Мишәле булмадымы икән? – ди Марат Закир.

– Бик мөмкин! – диләр болар берьюлы.

– Этимолог-галимнәр фикеренчә, Явыз Иван тарафыннан Казан ханлыгы яулап алынгач, су буенда татарларга яшәргә ярамаган – аларны куганнар. Шул вакытта авылыгыз Мишәленең «Ми»е төшеп калган да «Шәле»гә әверелгән, – дип нәтиҗә ясаган Марат.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫ

Казандагы С.Сәйдәшев исемендәге Зур Концертлар залында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов ТР Дәүләт Советына еллык юллама белән мөрәҗәгать итте. Ул республиканың тотрыклы социаль-икътисади үсешен саклауны төп максат итеп куйды. Социаль әһәмияткә ия программаларны гамәлгә ашыру мәсьәләсен күтәрде. Президентның юлламасында 2019 елда ике зур вакыйга – ТАССР оешуның 100 еллыгы һәм һөнәри осталык буенча WorldSkills чемпионатын үткәрү дә күздә тотыла. Р.Миңнеханов журналистларны мәгълүматның сыйфаты һәм дөреслек өчен җаваплы булырга чакырды.

Тууына 200 ел тулу уңаеннан мәгърифәтче, тарихчы Шиһабетдин Мәрҗанигә Казанда һәйкәл ачылачак. Бу хакта да ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Дәүләт Советына еллык юлламасында әйтте. Һәйкәлне «Мәрҗани» мәчете янында кую күздә тотыла.

### КҮҢЕЛДӘН – КҮҢЕЛГӘ

Бу көннәрдә Казанда уза торган мәдәниара диалог буенча ЮНЕСКО форумына «От души – для души» китабы чыгарылды. Анда Татарстанның Беренче Президенты, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев чыгышлары һәм мәкаләләре кертелгән.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, «Яңарыш» республика фонды башкаручы директоры Татьяна Ларионова китапның рус, татар һәм инглиз телләрендә чыгуын билгеләп узды.

Аның сүзләренчә, Минтимер Шәймиевнең мәдәниара багланышлар буенча чыгышларын җыентык итеп чыгаруны халыкара белгечләр тәкъдим иткән.

### 2019 –ЭШЧЕ ҺӨНӘРЛӘРЕ ЕЛЫ

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән, 2019 ел – Эшче һөнәрләре елы дип игълан ителде

### Г.ТУКАЙНЫҢ ӨР-ЯҢА ӘДӘБИ МУЗЕЕ

Ел буена барган реставрация эшләреннән соң, Казандагы Г.Тукай әдәби музееның яңа залларын, бөек шагыйрь иҗатына һәм тормыш юлына багышланган яңа экспозицияне ачу тантанасы булды. Аны ТР Милли музее генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова, Г.Тукай әдәби музее мөдире Гүзәл Төхбәтовалар ачып җибәрде. Кунаклар арасында галимнәр Нурмөхәммәт Хисамов, Фоат Галимуллин, Хатыйп Миңнегулов, язучылар Вахит Имамов, Камил Кәримов, Газинур Морат һ.б. бар иде.

### ХАЛЫКАРА КОНФЕРЕНЦИЯ

ТР Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты «Гаяз Исхакый һәм XX гасыр башында татар милли яңарышы» дигән темага халыкара фәнни-гамәли конференция үткәрде. Аны ачу тантанасында институт директоры Ким Миңнуллин, галимнәр Индус Таһиров, Хатыйп Миңнегулов, Юлай Шамил углы (Висконсин, АКШ), Әхмәт Канлыдыр, Ильяс Камал углы, Түләй Дуран (Төркия), Х.Гумматова (Азәрбайҗан), Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов чыгыш ясады. Пленар утырышны ТР Фәннәр академиясенең вице-президенты Дания Заһидуллина алып барды.

### КЫРГЫЗСТАН ТАТАРЛАРЫ ЯНЫНДА

Кыргызстанга эшлекле сәфәре вакытында Татарстан Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессының Милли шура рәисе Васыйл Шәйхразиев «Туган тел» татар-башкорт үзәге активы белән очрашты. Кыргызстан Республикасының Мәдәният, мәгълүмат һәм туризм министрлыгы бинасында узган очрашуга алтмыштан артык милләттәшебез җыелган.

Кыргызстан татарлары мондагы тормыш-көнкүрешләре, уңышлары һәм проблемалары, телләренең киләчәгенә бәйле борчу-кайгылары хакында сөйләде.

«Туган тел» оешмасы Кыргызстанда инде 28 ел эшли. 1998 елдан аны Гөлсинә Үлмәскулова җитәкли. Республиканың 7 төбәгендә оешманың филиаллары бар. Үзәк каршында якшәмбе мәктәбе булдырылган. «Туган тел» үзәгендә барлык милли һәм дини бәйрәмнәр билгеләп үтелә.

## «СӨЕМБИКӘ» ОПЕРАСЫ

Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында «Сөембикә» операсы премьерасы (либретто авторы – Ренат Харис, композитор – Резеда Ахиярова, режиссёр – Юрий Александров, рәссам – Виктор Герасименко) күрсәтелде. Операда Сөембикә тарихи һәм сәнгати образ буларак гәүдәләндерелә.

## ТАРИХНЫ ӨЙРӘН

«Вконтакте» челтәренең «Татар авыллары – Татарские деревни» төркеме бәйге игълан итте.

Үз авылын, үз төбәген танытырга, башкаларга да күрсәтергә теләгән һәр кеше «Авылым тарихы» бәйгесендә катнаша ала! Язмалар агымдагы елның 31 октябренә кадәр кабул ителә.

Бәйгедә катнашу өчен: 1) Авылыгыз тарихына багышланган материаллар эшләргә; 2) Авылның килеп чыгу тарихы турындагы риваять-легендаларга тукталырга; 3) Авылыгызда булган атамаларга (урам, чокыр, урман, болын атамалары һ.б.) игътибар итәргә һәм ни өчен шулай аталуына тукталырга (легендалар буенча, картлар сөйләве буенча...); 4) Язмаларны sabrad@mail.ru адресына юлларга кирәк.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең соңгы утырышында әдәби ел йомгакларына әзерләнү мәсьәләсе тикшерелде. Земфира Исламова, Зиннур Тимергалиев, Светлана Грунис Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде. Язучы Факил Сафин Абдулла Алиш исемендәге әдәби премиягә тәкъдим ителде. Утырышны берлек рәисе Данил Салихов алып барды.

## ОСТАХАНӘ УТЫРЫШЫ

Татарстан Язучылар берлегендә тәнкыйть һәм публицистика остаханәсенең киңәйтелгән утырышы булды. Анда филология фәннәре кандидаты, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов иҗаты тикшерелде. Утырышта Фоат Галимуллин, Тәлгат Галиуллин, Рифат Сверигин, Әлфәт Закирҗанов, Равил Рахмани, Галимҗан Гыйльманов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Рәфкать Кәрами, Фирдәвес Зариф, Хәнәфи Бәдигый, Нәҗибә Сафина һ.б. чыгыш ясады. Рамил Ханнанов Татарстан Язучылар берлегенә тәкъдим ителде.

## ЮБИЛЕЙ

Татарстан Язучылар берлегенең Г.Тукай клубында шагыйрә, публицист Фәүзия Солтанның иҗат кичәсе булды. Аны Г.Камал театры артистлары – шагыйрәнең якташлары Равил Шәрәфиев, Хәлим Җәләй башлап җибәрде. Язучының иҗат һәм тормыш юлы турында КФУ доценты, әдәбият галимәсе Нурфия Юсупова сөйләде. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов, каләмдәшләре Зиннур Мансуров, Ркаил Зәйдулла, Шәмсия Җиһангирова, җәмәгате, галим, язучы-прозаик Тәлгат Галиуллин котлады. Җырчылар Зөһрә Сәхәбиева, Азат Тимершәех, Чулпан Зиннәтуллина чыгыш ясады. Кичәне Резеда Сәлахова белән Илфак Хафизов алып барды.

## ЯҢА ТАТАР КИТАБЫ КИБЕТЕ

Казанның Бауман урамында урнашкан ГУМ сәүдә үзәгенең өченче катында Татарстан китап кибете ачылды.

## КОТЛЫЙБЫЗ!

ТР Президенты Указы белән, массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш керткәне һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте филиалы – «Казан утлары» журналы редакциясе» җаваплы сәркатибе Нуриев Вакыйф Вәкил улы Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнде

2018 елның 13 сентябрендә 79 нчы яшендә шагыйрь һәм журналист Башкортстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты **Рим Зиннәтулла улы Идиятуллин** вафат булды.

2018 елның 17 сентябрендә 82 нче яшендә татар галимәсе, филология фәннәре докторы, профессор **Фәһимә Миргали кызы Хисамова** вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман М.ЮНУСА «Кипчакская дочь Аксана» (с предисловием Р.РАХМАНИ); стихи Г.МУРАТА, Р.АЙМЕТА, Э.ШАРИФУЛЛИНОЙ; басни Л.ФАТТАХОВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*«Драматургия»: драма Д.САЛИХОВА «Мухамет».*
*«Новые имена»: повесть А.БАЙМУХАМЕТОВА «Детство без сказок».*
*Литературный конкурс «Достояние»: рассказ А.ХАСАНОВА «Козочка – маленькая красавица»; документальная повесть А.ГАРАЕВОЙ-АКЧУРА «Первый нефтяник Турции – татарин».*
*«Детская библиотека»: стихи В.ХАЙРУЛЛИНОЙ.*
*«90 лет со дня рождения Н.Фаттаха»: статья В.ИМАМОВА, посвящённая творчеству писателя. Фотографии Н.ФАТТАХА.*
*«Из первой книги писателя»: рассказ Н.ФАТТАХА «Дедуля» (с предисловием Р.ХАННАНОВА).*
*«Юбилеи»: статьи Р.САГДИ, посвящённая 60-летию Д.САЛИХОВА и Д.ЗАГИДУЛЛИНОЙ, посвящённая 50-летию Р.АЙМЕТА.*
*«Наш календарь»: 90 лет со дня рождения Ш.БИКТИМЕРОВА.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: «Казанское ханство. Утямыш хан и Сююмбике у мавзолея Сафа Гирея». Художник Рушан Шамсутдинов; поэтесса Альфия Ситдикова.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel by M.YUNUS «Kipchak daughter Aksana» (with preface by R.RAHMANI); poems by H.MURAT, R.AYMET, E.SHARIFULLINA; fables L.FATTAKHOVA.*
*«Actual criticism»: section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*«Dramaturgy»: D.SALIKHOV «Muhammad».*
*«New names»: novel by A.BAYMUHAMETOV «Childhood without fairy tales».*
*Literary contest «Heritage»: story by A.KHASANOV «Goat – little beauty»; documentary novel by A.GARAEVA-AKCHURA «The first oil man of Turkey is Tatar».*
*«Children's library»: poems by V.KHAIRULLINA.*
*«90th anniversary of N.Fattah»: article by V.IMAMOV dedicated to creativity work of the writer.*
*Photos by N.FATTAH.*
*«From the first book of the writer»: story by N.FATAH «Grandpa» (with preface by R.KHANNANOV).*
*«Jubilees»: R.SAGDI «It will make sense!» (60 years old to D.SALIKHOV); D.ZAGIDULLINA «The whole world passes through his heart with noise...» (50 years old to R.AYMET).*
*«Our calendar»: 90th anniversary of SH.BIKTIMIROV.*
*«Pages of humor»: section is conducted by M.GALIEV.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: «The khanate of Kazan. Utyamysh Khan and Syuyumbike at the mausoleum of Safa Giray». Artist Rushan Shamsutdinov; poetess Alfiya Sitdikova.*

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* «Казан ханлыгы. Үтәмеш хан һәм Сөембикә Сафа Гәрәй төрбәсе янында». *Рушан Шәмсетдинов картинасы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* шагыйрә Әлфия Ситдыйкова.